# казан утлары

12

ДЕКАБРЬ • 1977

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

12
ДЕКАБРЬ
1977

## Бу санда

Р. МИНГАЛИМОВ. Мин күрмәгән ике якташ. Шигырь . . . . . . . . . . . . . . . . 3
Д. СИРАЙ. Шул җырны көйлим. Шигырьләр . . 5
Ә. БАЯНОВ. Тавыш — табигать бүләге. Повесть . 8
Э. МОСТАФИН. Атлар китә... Шигырьләр . . . 70
Ш. МАННАПОВ. Сөембикәң белән. Шигырь . . 73
Ә. ГАДЕЛ. Казан. Шигырь . . . . . . . . . . 73
М. СКОРОХОДОВ. Тундра хикәяләре . . . . . 74

КЛАССИК ӘДӘБИЯТ ҮРНӘКЛӘРЕ

Г. УЭЛЛС. Тәвә кошлары белән сәүдә. Хикәя . . 81

ОЧЕРКЛАР

М. ЗАРИПОВ. Моңлы Казан, нурлы Казан . . . 86

КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫ СХОДКАСЫНА 90 ЕЛ

Р. НӘФИКОВ. Беренчеләр беренче сафларда . . 121

МОХТАР ӘҮЭЗОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

М. ӘҮЭЗОВ. Өйләнү. Хикәя . . . . . . . . . 126

ИСТӘЛЕКЛӘР

Н. АРСЛАНОВ. Ахирәтем Әл-Искәндәр . . . . 132
М. САДРИ. Һәрчак хәтердә . . . . . . . . . 135

ГАБДЕЛҖАББАР КАНДАЛЫЙНЫҢ 180 ЕЛЛЫГЫНА

Р. ӘХМӘТОВ. Матурлык, мәхәббәт һәм мәгърифәт җырчысы . . . . . . . . . . . . . . 139
Х. ТАЗЮКОВ. Габделҗаббар Кандалый мирасын барлау юлында . . . . . . . . . . . 143

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Н. ГАМБӘРОВ. Бәхеткә юл — гел алда . . . . 148

КИТАП КҮЗӘТҮ

Ф. ӘГЪЗӘМОВ. Прозабыз турында хезмәт . . 153
Р. МӨХӘММӘДИЕВ. Укучы ничек кабул итәр . 157

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ТӨРЛЕСЕННӘН

**Н. ФӘТТАХ.** Түгәрәк өстәл янында сөйләшү . . 162

Безнең календарь . . . . . . . . . . . . . 166

НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

**Ш. ГАЛИЕВ.** Булат хикмәтләре. Шигырьләр . . 172
**Р. МИҢНУЛЛИН.** Йолдыз буласым килә. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . 174

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

**З. НУРИ.** Чәнечкеләрдән муенса. Шигырьләр . 176

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 181

1977 елда журнал битләрендә басылган әсәрләр 185

Редакциянең адресы. Казан, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов** (баш редактор урынбасары), **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 2/IX-1977 ел. Басарга кул куелды 24/XI-1977 ел. ПФ 07025. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 84544. Заказ Б-336. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1977 ел.

## Рөстәм Мингалимов

### Мин күрмәгән ике якташ

Төн учында поезд йөгерә,
Мин вагонда уйлап ятам.
Хәтеремдә бер хикәят —
Ике егет безнең яктан.
Йөри алар учак ягып,
Безнең урман уртасында.
Киемнәрен киптерәләр,
Сөйләшәләр нидер шунда.
Юеш күктә бер йолдыз юк,
Алып качкан ай-көмешбаш.
Бик охшашлар — ике егет,
Мин аларга бераз охшаш.
Төнлә учак якканым бар,
Киемнәрне киптергән бар.
Аннан тагы, ни әйтсәң дә,
Якташлар бит әле алар!
Бер чишмәдән су эчкәнбез,
Тик үзләрен күргәнем юк.
Алар яшәп караганнар
Патша-канун заманда ук.
Ә канунга сыймаганнар,
Сыймаганнар Камышлыга [1].
Ике егет ияргәннәр
Язмышлары тавышына:
Усал язмыш урманнарда
Бүре булып улап йөргән.
Кайчак язмыш кәлтә булып,
Мәгарәгә шуып кергән.
Эзләгәннәр егетләрне,
Ләкин тота алмаганнар:
Ничә тапкыр куа чыгып,
Ничә тапкыр алданганнар.
Ни өчендер бу егетләр
Җырлаганнар кайчак төнлә —
Камышлыга якын булган
Иң биек тау түбәсендә.
Тыңлаганнар туганнары,
Дус-ишләре тыңлагандыр.

[1] Камышлы — Куйбышев өлкәсендә бер авыл.

Дошманда да йөрәк бар ич —
Тыңламыйча булмагандыр.
Заманнарны кисәр көйгә
Ни җырламас ул моңлы баш?! —
Ике егет бик охшашлар...
Мин аларга бераз охшаш.
Тауларда да йөргәнем бар,
Шулай төнлә җырлаган бар.
Аннан тагы, ни әйтсәң дә,
Якташлар бит әле алар!
Йокы алмый шуңа бүген,
Мин вагонда уйлап ятам:
Хәтеремдә — учак уты,
Ике егет безнең яктан.
Киемнәре кипте кебек,
Якташларым ит кыздырды.
Язмышлары кара төндә
Кара юлга ятып торды.
Аннан китте ике егет...
Язмышлары алдан бара —
Үзе бара һәлакәткә,
Яшәүгә дип, алдап бара.
Бик охшашлар ике егет,
Мин аларга бераз охшаш.
Ни әйтсәң дә, якташлар бит,
Ниндидер кыл безнең тоташ.
Бер чишмәдән су эчкәнбез!
... Тик заманнар хәзер башка.
Хәле башка Камышлының,
Һәм минем дә хәлем башка.
Мин җырлаган җырлар башка,
Ияр үзгә, атлар бүтән...

Мин күрмәгән ике якташ,
Һаман сезне истә йөртәм.

# Дифгат Сирай

## Шул җырны көйлим

Инеш сипкәнме әллә хуш исне
Мул итеп шулай ябь-яшь талларга?
Яшь тал исеннән исереп җил дә
Дәртле җыр көйләп йөри ярларда.

Шул тал исеннән исердем мин дә,
Җыр тора ташып күңел түрендә.
Яшь таллар белән бергә иелеп
Шул җырны көйлим туган җиремә.

## Биш тәрәзә

Биш тәрәзә — бишесендә
Биш кояш балкып яна.
Биш егет киткән бу өйдән
Бишәүләшеп бер таңда.

Һәр таң саен биш кыз үтә
Биш тәрәзә яныннан.
Бишесендә биш егетнең
Йөзе гүя чагылган...

Биш тәрәзә — бишесендә
Биш кояш тора көлеп:
Балкыта шулай аларны
Сүрелми калган өмет.

## Адашкан яз

Кыш уртасы. Ә урамда
Сулар ялтырап ята.
Яз адашып йөри тышта,
Котырынган бураннарның
Җиңеннән тарта-тарта.

Изүне чишәр идем,
Адашасы иде шулай....

Гөрләвекләргә әйләнеп,
Яшьлегем үзәннәренә
Йөгереп төшәр идем.

## 12 апрель

Гаҗәеп күңелле көн [1] иде,
Тамчылар биеште тып та тып.
«Галәмдә — Кеше! — дип күкләргә
Кычкырды Җир үзе. — Юл ачык!»

Гаҗәеп көн иде — сөенеч
Алырга ашыгып җил чапты...
... Ничә ел үтсә дә, шул җилгә
Торам күк ачып мин кочакны.

## Егерме миллион яра

Әй, дөнья, булма битараф,
Тәнемне капшап кара:
Егерме миллион җөй анда,
Егерме миллион яра.
Хәтерне капшап кара син,
Мәңгелек утлар капкан;
Егерме миллион баласын
Югалтты яуда Ватан...
Әй, дөнья, булма битараф,
Күзеңне ачып кара:
Егерме миллион җөй җанда,
Егерме миллион яра.

---

[1] Ю. Гагарин Галәмгә очкан көн.

# ӘХСӘН БАЯНГА 50 ЯШЬ



*Әхсән Баян шигырь сөючеләргә дә, роман һәм повесть яратучыларга да һәм шулай ук республикабыз театрлары тамашачыларына да таныш исем. Иҗатының башлангыч чорыннан башлап, алтмышынчы еллар уртасына кадәр Әхсән Баян «Диңгез шавы», «Еллар тавышын тыңлыйм», «Мират», «Әйт сүзеңне, яшьлек», «Ике аккош», «Елларга ышаныгыз», «Сез аңларсыз мине» һәм башка шигырь китаплары белән укучыга үзенчәлекле һәм җитди поэзия әсәрләре иҗат итүче шагыйрь булып танылды. Ә инде алтмышынчы еллар уртасында язучы иҗатының яңа бер мөмкинлеге, проза әсәрләре язуга сәләте ачылды. «Ут һәм Су» романы, «Яшьлегемне эзлим», «Дүрт монолог», «Тау ягы» һәм «Төлке тоту кыен түгел» дигән повестьлары белән автор әдәбият сөючеләрнең игътибарын бүгенге көннең зур проблемаларына юнәлтте.*

*Шул ук вакытта ул үзенең Мәскәүдә, үзәк нәшриятларда рус телендә басылып чыккан китаплары белән бөтенсоюз укучысына да билгеле булды. «Огонек» журналында дөнья күргән «Дүрт монолог» повесте, «Советский писатель» нәшриятында 1968 елда чыккан шигырьләр һәм поэмалар җыентыгы һәм 1971 елда басылган «Яшьлегемне эзлим» повесте, «Современник» нәшрияты тарафыннан 1975 елда бастырып чыгарылган «Кышкы чәчәкләр» исемле поэма һәм шигырьләр җыентыгы әнә шундыйлардан. Киләсе елда «Современник» нәшрияты авторның дүрт повестен туплап, бастырып чыгарырга әзерләнә.*

*Бер үк вакытта Әхсән Баян драматургия өлкәсендә дә эшли. Аның «Һәйкәл» дигән драматик поэмасы Минзәлә театры, ә «Күзләре нинди иде» дигән пьесасы Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры сәхнәләрендә уңыш белән бардылар.*

*Язучы һаман эзләнүдә, язучы һаман юлда. Быел декабрь аенда Әхсән Баянга 50 яшь тулды. Бу түгәрәк датага язучы яңа әсәр, «Тавыш — табигать бүләге» дигән повесть белән килде. Без «Казан утлары» журналын укучылар исеменнән Әхсән Баянны иҗат бәйрәме белән котлыйбыз һәм бу санда аның шул яңа повестен тәкъдим итәбез.*

Әхсән Баянов

# ТАВЫШ — ТАБИГАТЬ БҮЛӘГЕ

ПОВЕСТЬ

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

Очрашканда тел шартлаткан җанвар бабаң:
«Син кал карап, үтмәс тешле мескен надан,
Син кал карап, минем тешләр — хәнҗәр, кылыч,
Татымаска тырыш аны, яшә тыныч!»

Кара урман — аның мәңгелек биләмәсе.

Ничәмә еллар ул шушы дөньясыннан чыгу омтылышын белми яшәде — йоклады, ашады, тагын ашады, тагын йоклады. Кара урман тарлык була димени — беркайчан да шушы җирдән каядыр кузгалып китәргә нияте юк иде аның. Сөйгән ярына һәм ике баласына арка терәп, тирән һәм тыныч чокырда рәхәтләнеп кыш уздыргач, көн яктысын кабат күрү шатлыгыннан үкерә-үкерә пошкыргач, тагын бер рәхәт чигеп аунагач, җир тырнады, ышкынып агач мүкләрен койды да ары табан яши китте.

Мәңгелекне хәтерләткән тын биләмәсендә тора-бара ашау хакында да кайгыртмавын, шактый ук симергәнен дә башына кертмичә, икенче төрле әйткәндә, гамьсез гомер кичерүен чамаламыйча йөри торгач, бермәл уянып киткәндәй булды да янында сөекле яры һәм балалары юклыгын күрде. «Урманнан ерак китә алмаганнардыр әле, шушы тирәдә тагын очрашмый калынмас» дигәндәйрәк ышаныч саклану сәбәпле, безнекечә әйткәндә, гаилә югалттым дип кайгыра белмичә — тагын ары китте. Әмма аймылышны кызгануга охшаш тойгы яралгач, ул инде мәңгелек гамьсезлегенә кире кайта алмады һәм шул вакытта үзендә өр-яңа бер теләк туганын чамаларга һәм шуңа буйсынырга мәҗбүр булды. «Туган биләмәдән башка әйләнә-тирәдә тагын нинди җирләр һәм манзаралар була икән?» Адәм теле белән әйткәндә, кара урманның нәкъ үзедәй тыныч һәм шомлы җанында сәяхәт омтылышы кузгалды — «чит илләр» күреп кайту тынгысызлыгы колак төпләрен чыңлатырга тотынды. «Китәргә, китәргә!»

Кая? Австриягә? Австралиягә? Париж? Скандинавия?

Юк, дәгъвасы болай ук баш әйләндергеч түгел, яз көне сөекле ярын эзләп табу шикелле ачы һәм ләззәтле омтылышыннан гына калышуы ихтимал булган яңа тойгы гаҗәп тә тыйнак: гомер уздырган биләмәсеннән арырак нiләр бар икәнен генә күрәсе килү иде. Һәм ул, гадәттәгедән җәһәтрәк атлап, нигәдер кояш яктырткан якка табарак юл тотты. Ягъни дип әйтик, сәяхәткә чыгып китте аю. Бер көн барды —

урманның чите күренмәде. Тәүлек, ике тәүлек — искитмәле үзгәреш сизелмәде. Бердәнбер үзгәлек шул — акланнар күбәя төште, агачлар сирәгәйде. Кәүсәләрдәге йомшак мүк югарганнан-югара барды. Ә тагын бер тәүлек узгач, ямьсезрәк үзгәреш белән — ашау кытлыгы дигән нәрсә белән очрашты. Тәмле ит һәм бал хакында әйтмәстән, җиләк-җимеш, кырмыска оялары кебегрәк ризыклар да азайган икән. Тамак кайгысы борчырлык ук булмаса да (ни дисәң дә, ул бит инде кышка җитмәле мая җыйган!), хәтергә килгәнгә күрә, кәсебенә дә керешеп, кырмыска оясы исенә нярә килсә, тагын сәер хәлгә юлыкты: кырмыска оясы нигәдер агач чардуган белән уратып алынган иде. Җимереп ташларга, шуннан соң гына айкый башларга туры килде. Ап-ак һәм чип-чиста йомыркалар кара урмандагыдан ваграк тоелса да, тәм ягыннан һич тә калышмалы түгел иде. Әйтер җир юк, шәп нәрсә шәп инде ул.

Ашап туйгач, дөнья беткәндәй каушап кайнашкан кырмыскаларга бераз гына гаҗәпсенеп карап торды да, сәфәрне дәвам итә төшкәч, тәнендә кычытуга охшаш борчу сизеп, ашаудан да ләззәтлерәк шөгыльгә керешмәкче, җәйнең үзе сыман ягымлы үләнгә ятып аунамакчы итте. Аунавын да аунады, ләкин көтелгән ләззәт кенә әллә кайда, еракта калган булып чыкты — үләннәрнең җирдә нишләптер төпләре генә тырпаеп тора һәм алар, аунаган чакта, тәнгә рәхимсез кадала, авырттыра, ачу кузгата. Тик кемгә, нигә ачуланырга икәне генә билгесез.

Аю торды. Аклан уртасындагы йомшак өемнәргә ышкынды. Аунар өчен дип үскән үлән шушында җыйналган икән. Ачу басылганчы ышкынгач, кашынгач һәм ялангач урман эченә керим дигәндә, кинәт сискәнеп китте аю: башы чүпрәк белән капланган берәү әллә нинди ачы тавыш белән чыелдап, башына шундый ук ак әйбердән эшләнгән, алгы яклап бер өлеше күзләренә төшебрәк торган нәмәрсә кигән икенче бер кешенең күкрәгенә капланды. Сәфәр чыкканнан бирле гаҗәпкә калдырырлык беренче мәзәк менә шушы иде. Болай ук якыннан аның бер кешене дә күргәне юк иде әле. Аю гадәттә кешеләрдән үзе курка, ә чынында кешеләр аннан куркалар икән ләбаса. Кызык. Кара урманда ятсаң, моны ничек белер, кайда күрер идең! Менә бит сәяхәтнең күңелле мәгълүматлары! Беләсе, күрәсе килү бер дә начар нәрсә түгел икән ул.

Дөресен әйткәндә, аюның бу ике адәм баласын кочаклап, сыйпап, ялап карыйсы ук килеп, бер-ике адым атлаган да иде, тик... икесенең дә берьюлы ямьсез акыруларын ишеткәч һәм икесенең дә күзләрендә коточкыч курку күргәч, ник икәнен үзе дә төшенеп бетмәстән, читкә тайпылды. Ашарга түгел, бары тик яратып яларга гына иде аның бөтен теләге... Ялгыштылар...

Кешеләр аны аңламадылар.

Җирдә үлән йомшаклыгын юксына-юксына, чүмәләләр исни-исни, агачларга ешына-ешына тагын тәүлектән артык баргач, сәфәрче аю әллә нинди коймалар-киртәләр белән әйләндереп алынган, түбәләре матур итеп кыекланып торган, урта тирәсендәрәк су сыманрак ялтыраган ачыклыклары белән күңелне тарткан агач өемнәренә тап булды, адәмчә әйткәндә, авылга килеп керде ул. Су сыман ачыклыкны якыннан карыйсы килде, тик җимермичә узу мөмкинлеге сизелмәгәч, күрәсе килү дигән нәрсә барлы-юклы зиһенне томалар дәрәҗәдә җилкетү сәбәпле, сәфәрчебез кинәт кенә аягүрә басты да... ачык дигән җирдән караса... эчтә нәрсә генә юк! Әлеге дә баягы — кешеләр! Берсе яткан җиреннән нигәдер тиз генә сикереп торды һәм өстендәге ак нәрсәсен бөтәрләп тотты да, күзләрен кичә урманда очраган кешеләр кебек өметсез акайтып, әлбәттә, тагын бөтен көченә чарылдап кычкырды. Тагын ике-өч кеше сикереп торып, тагын шаккатудан телсез калды. Күзләре бу юлы аерата ямьсез һәм куркыныч иде. Аю җанында чиркану белән кызгану кушылып, туйганчы карарга ирек бирмәде.

Аю дүрт аягына басып борыла төшкәндә, адәмнәр урамга ук чыгып, алар тавышына этләр өреше өстәлде һәм шул мәлдә нәрсәдер бик каты шартлады да. Күңеле гел яхшылыкта булган аюга җәһәт кенә урманга чумудан хәерлерәк нәрсә табылмады.

Кешеләр аны аңламады.

Үз урманыңнан читтә җайсыз икән. Әмма чыкмасаң ни күрер идең? Теге куыш эченә карамасаң, аны һаман шул агачлар өеме дип йөрер идең ләбаса. Юк, күрәсе килү, беләсе килү бер дә олы гөнаһ түгелдер, гаепле ук нәрсә булмаска тиештер ул. Аның хакында кайбер җайсызлыкларны җиңә бару мәҗбүри чарадыр.

Кояш әле чыгып кына килә. Сәяхәтче аю үзенең шактый ук биек тау буенда икәнен күрде. Ә аста... аста күз карашы иңли алмаслык олы дәрья. Кояш яктысында карашны рәхәтләндерә торган рәвештә ялтырап ята. Менә, ичмасам, су! Түбәндәге биек ярларында яфраклы агачлар, куаклар һәм... кешеләр яши торган биек куышлар — өйләр күп икән. Ләззәтле су янына узу җайсызрак җайсызрагын. Ләкин мондый зур суны күрми калу үзе иң зур гаеп булыр иде. Ләкин ничек барып җитәргә? Шул тирәдә нәрсәдер бик яман дөберди, җитмәсә. Әнә әллә каян, күкне ямьсез кара төтен белән каплап, котыра-котыра, акыра-акыра, мәзәк өемнәр узып китте. Әмма бераздан дөнья тагын куркыныч кыяфәтеннән, ямьсез төтеннән арынды да, аюның күзләре янә чиксыйсыз диярлек матурлыкка юнәлде: су, искиткеч су, ә анда, эчкәрәк керсәң, әлбәттә, тамак ялгар җан ияләре тулып ята. Тотып алсаң, тиберченә-тиберченә, яңакларга сугыла-сугыла иркәлиләр алар, тик авырттырмыйлар — карынга да шулай ук рәхәт кенә төшеп яталар. Кечкенәрәк дәрьяларда булган тәҗрибәләре буенча фараз иткәндә, менә нинди шәп сый көтә бит сәяхәтчене. Сые да, мәзәге дә бергә икән бу сәфәр дигән нәрсәнең. Су... бу хәтле дә зур су! Уртасында яшел куаклар да үсеп утыра икән. Шунда тыныч кына ял итәргә булыр.

Таудан төшкәч, таш өемнәре аша узарга туры килде. Шушы таба яңа өемнәр дөбердәп килгәнен шәйләп, тизрәк ыргылды һәм менә ул — яр буенда. Тик караса, су өсте тулы әллә нинди җәлпәк нәмәрсәләр тезелеп тора. Кайберләрендә — тагын кешеләр. Каян килгән адым саен кеше? Монысы иң авыр җайсызлык. Аюны күрүгә — тагын акырыш, тагын буталыш. Тилергәннәр, нәрсә күрәләр икән бу чаклы гауга куптарырлык? Аларны күргәч тә аю булып аю тыныч тора белә ләбаса. Ә алар?

Су өстендә чайкалган әйберләрнең кешеле булганнары бердәй дөбердәргә керешкәч, аюның да ачуы кубып, сыйлану өмете җилдәй юкка чыкты да, шашканнар тирәсеннән тиз генә яңадан урманга сызудан башка җай тапмады ул.

Ярый әле, тау менә торгач, баягы судан һич ким булмаган яңа матурлык ачылды — алтынсу үлән дәрьясы чайкалыпмы-чайкала. Кыркылган да түгел, төбеннән алып чуклы башларына хәтле исән торган үләннәр. Монда баягы йөзү өметен дә, ашау ләззәтен дә берьюлы канәгатьләндерергә мөмкин иде. Үлән башларындагы алтын чукларны туйганчы ашагач, сагынылган йомшаклыкта, әй, рәхәтләнеп аунады да инде ул. Тик, тик...

Якында гына кыштырдау ишетелде. Бик тә якында. Ләззәткә чумып артык мавыгылган икән. Адымнар. Әлбәттә, кеше... Нинди кеше икән тагын? Монысы да куркак булып чыкса? Ул курыкмый торган, ягымлы кеше күрергә өметләнеп, аягүрә торса, алда — чынлап та кеше... Берәү генә. Кулында — куш елан шикелле таяк. Шул таякның ни икәнен күрү нияте белән аю, куркуын җиңә төшеп, чак кына алгарак атлады һәм карап тын калды. Ә кеше? Юк, монысы да курыкмый торган булып чыкмады, әмма шулай да, күзләрен коточкыч алартмаса да, тез буыннары калтыраудан әлеге таякка тотынгач, тынычлана

язды. Бу көч бирә торган таяк нәрсә икән? Кунак шуны белер өчен ныклабрак караса, әллә нинди шартлау... һәм күкрәктә — монарчы һичкайчан сизелмәгәнчә каты авырту... «Кара син, белергә тырышу, күрергә тырышу болай ук җәзаларлык гаеп микәнни?» дигәндәйрәк гаҗәпләнергә генә өлгергән арада... сәяхәтче аю җиргә үк ауды. Ләкин ул инде үзенең нинди хәлдә икәнлеген белергә дә тырыша алмады.

Кешеләр аны аңламадылар.

*
* *

Соңгы елларда, якын-тирә урманнарда кабан дуңгызлары күбәйсә дә, каладагы дәүләт музееның хайваннар дөньясы дигән бүлегенә ул экспонат буларак әле килеп җитмәгән иде. Аның карачкысын ясап бирүне Нажар Зәбиров дигән яшь галимнән үтенеп сорадылар. Үзенең төп эше булмаса да, аның табигать дусты икәнен белгәнлектән... мондый йомыш белән мөрәҗәгать итүләре беренче кабат кына түгел иде.

Музейга Нажар еш килә. Гадәттә Әби патша арбасын карагач та, үзен кызыксындыра алырлык бүтән экспонат тапмыйча, хайваннар дөньясына керә дә, бүре, төлке, кыр тавыгы, мәче башлы ябалакка озак-озак, онытылып, хатирәләргә бирелеп карап тора. Бу җәнлек-кошлар Нажарга туган һәм мәңгелек дуслар сыман тоела. Алар үзләре дә Нажарны танып, аңа адәмчә җылылык сирпеп карыйлар — мәңгелек яшәү бүләк иткән өчен аңа әйтерсең лә рәхмәт әйтәләр. Озакламый, алар белән янәшә кабан дуңгызы басып торачак һәм анысы да үзенең кечкенә кызыл күзләре белән үзенең хөкемдарына рәхмәтле тойгылар сирпиячәк. Әлбәттә, башта, беренче очрашу вакытында, аңгыра дуңгыз киләчәк бәхетен аңламыйча, качарга тырышачак. Ләкин... Ләкин Нажарның әле беркайчан да үзенең максаты итеп куйган җәнлекне ычкындырганы юк.

Нажар эшли торган институтның ярдәмче хуҗалыгы һәм җәнлекләр бакчасы каладан кырык-илле чакрым ераклыкта, пароход түгел, катер да керә алмаслык тын елга буенда урнашкан. Нажарның ярты гомере шунда уза дисәк, ялган катнашмас. Аның кызы Энҗе дә, тәпи басканнан бирле диик, бирегә еш ияреп килә. Соңгы елларда хәтта җәйне әтисеннән башка да шушында уздыра башлады. Каравылчы абыйлары белән, җәнлекләр, кошлар белән мәш килеп яталар. Шунысын да фаразларга мөмкиндер: мөгаен, әтисенең эшен иң әйбәт дәвам итүче шул Энҗе булыр, гәрчә бу хакта уйларга әле бик тә, бик тә иртә булса да.

Хатыны Фәнүсә, хәтта бер үк лабораториядә эшләсә дә, андый ышаныч-өметләр күзгата алмый. Бигрәк тә соңгы елларда. Нажарның дошманы дәрәҗәсенә җиткән кешегә яхшатланып, иренә хыянәт хәленә якынлашты инде. Юк, начар мәгънәдә түгел, болай: житәкче дигән булып, Мөдир белән әшнә булып эшләргә тырышып...

Ярый, монысын да калдырып торыйк, яңа җәрәхәткә кагылмау хәерлерәк...

Шулай итеп, җәнлекләр бакчасына килгәч тә, Нажар музей йомышын үтәү нияте белән якын-тирә урманнар буйлап йөрергә, сунарга чыгып китте. Монда кабаннар очратачагына ул иртәгә дигән көндә кояш чыгачагына ышангандай ышана. Ләкин иртәгә дигән көнне кояш чыкса да, кабан дуңгызы күзгә чалынмады. Инде төш җитеп килә иде. Арыгач, хәлдән тайгач, урман читенә чыгып утырды. Тәмам өлгергән солы басуына карап хатирәләргә бирелә язганда, кинәт ни күзе белән күрсен, бер урында солы башлары катырак селкенә иде һәм шунда... кабан очратудан өзелә язган өмет тагын дертләп куйды. Солы дәрьясы бер дә юктан чайкалырмы? Юктыр, бу, әлбәттә, җәнлек, әлбәттә — кабан! Бүтән ни булсын? Бүре дияр идең, ул инде җәнлекләр бакча-

сында кешенең дусты буларак яшәр өчен генә исән калды, ә төлке игенне болай ук чайкалдыра алмас — ыспай нәмәрсә. Әлбәттә, бу — дуңгыз, кабан дуңгызы.

Нажарның бүген хәле авыр.

Беренче сәбәп — өйдәге әйткәләш; икенчесе — эшләгән җирдә Мөдир дигән кабан белән бәрелеш; өченчесе — тамак чире тонзилитның кузгалып, температураны ким дигәндә утыз сигезгә күтәргән чагы. Дүртенчесе дә бар икән әле — уңышсыз сунарда төнге сәгать икедән көндезге сәгать өчкә хәтле йөри торгач, бөтен авыр хәле өстенә, телен аркылы тешләр дәрәҗәдә арган иде.

Дүрт сәбәп бер секунд эчендә дәррәү юкка чыкты. Югыйсә, ул нинди аучы?! Башта утырган килеш күзәтте: күп дисәң ике йөз метр ераклыкта солы урманын дер селкетә иде кабан. Ауный, мөгаен, калада калган туганының, Мөдирнең ялган уңышын белеп, ауный-ауный тантана итә дуңгыз, изә изге муллык диңгезен. Ләкин ул тиздән кеше белән күзгә-күз очрашачак. Аучы сикереп торды да очрашуга табан ун-унбиш адымны шыпырт атлады, тагын дүрт-биш адым, тагын. ...Житте. «Мөдир дуңгыз, син бит анда! Кабан, чык!»

Уйлап кына калмыйча, шулай эндәште дә, ахрысы, Нажар, чөнки дип фараз итәргә мөмкинлек бар, — әгәр дә кыргый җанвар аның олы хөрмәт белән эндәшүен ишетмәгән булса иде ки, ул мөшкәгә маңгай куярга һич тә ашыкмаган булыр иде. Әйе, дуңгызга шулай эндәште аучы һәм ни өчендер дуңгызның ул нәкъ үзенең мөдире кыяфәтендә калкып чыгачагын һичбер шөбһәсез көтте һәм... Ләкин... Ләкин әнә каршыда — йонлач баш... Нишләп соң әле болай? Мөдир бит сакал-мыекны болай йөртми, һәм дуңгыз да алай итми. Әйе, бу — кабан түгел. Каршыда... каршыда — аю, һәм ул үзе дә Нажарны танырга тырышкандай текәлеп калмасынмы. Куркыныч хәл белән очрашкач, һәр җан иясе шулай башта аптырап кала. Каршында кеше басып торганлыгы аңына җиткәч тә торып чабачак. Тик бу юлы озакка китте — нидер күрергә, хәтта сөйләшергә, аңлашырга тырышкандай тын торды бу җанвар, тик... Тик ул Мөдиргә түгел, Нажарның үзенә охшаган бугай һәм... бүтән нидер уйлап өлгергәнче, аңсыз бармак чакманы үзлегеннән тартты да аю чайкалып куйды. Ләкин ул күзләрен Нажардан барыбер алмады — әллә ничек гаҗәпләнеп калды. Бер секундта атарга өлгермәсәң, өскә сикерәчәк. Соңламады Нажар, икенче көпшәдәге патронны да бушатты. Аю исә үзе аунарга яраткан йомшак солы җиренә гөрселдәп ауды.

*

* *

Тәкъдир дигән сүз бу заманда сәер яңгырый. Табигатьтән өстен дигән мәгънәгә ишарә иткәнгәдер, ахрысы. Өстенме, түгелме, ләкин анда кодрәт барыбер олы, хәтта бөек. Күп чакта аңлап, хәтта тоеп та житкермибез. Йөнтәс аяклары белән бәргәләп аю соң мәртәбә тиберченгәч, «Кунакны ядрә белән каршылау тиеш идемени?» дигән сорау Нажарның аңында туды. Кунакның да нинди бит әле — әкияттән килеп чыкканы!

Бу җирләр, бу урманнарда күптән инде кырып бетерелгән аю, адәм белән бәхәсләшә-бәхәсләшә, әкиятләрдә генә матур яши. Ә тормышта — бүгенгечә...

Аю, адашкан аю, бу урманга, корылган мылтык каршысына, кабан урынына нишләп килеп чыктың соң әле син? Билгеле инде — очраклы рәвештә. Нишләп әле бары тик дуңгызга гына тәгаенләнгән ядрә сиңа

табан очты? Дөресен әйткәндә, син үзең дә күрдең: Нәҗәр бераз курыкты, өскә ташланмагаерак сыманрак тойды. Бәлки әле тыныч кына борылып та киткән булыр идең. Бәлки... Тик җәнлекнең генә түгел, адәмнең дә гомере бер генә һәм ул «бәлкигә» исәп тотарга яратмый. Һәм менә шуңа күрә Акылның үзенә дә буйсынып бетми торган бер тойгы, рөхсәт-киңәш сорамыйча гына бармакны үз ихтыярына буйсындырды да чакма чатнап кәпселгә бәрелде. Калганы — бәхәссез һәм син менә җирдә ятасың. Очраклы хәлдә...

Әгәр Мөдир белән мөнәсәбәтнең юньлерәк чагына туры килгән булсаң, аңга ачы төтен өргән ачу кабанга үчләшер дәрәҗәгә җитмәс һәм ул сине тизрәк таныр, бутамас һәм син дә бүгенге кадәр усал күренмәс идең. Шулай шул, тагын «бәлки».

Ә музей кешеләре шатланачак. Кабан качмас, ә аның урынына бәреп төшерелгән булса да кара урманның патшасын ук илтеп бир әле син! Очраклы хәлдә!...

Әгәр янында тире тунарга махсус алып килгән пычагы булмаса, чирле һәм арыган булуына карамастан, соңгы тамчы көчен дә сарыф итеп, шушы аю шикелле хатасын, авыр хатасын ул барыбер бакчага хәтле өстерәп кайтачак иде. Тәҗрибәле аучы бөтенесенә алдан әзер. Карачкыга тиеш кадәр генә калдырып, җәнлекнең тиресен — тышкы кыяфәтен генә аркасына салып кайтты. Ләкин, хәерсез авыруы аркасында, пөхтәлек җитмәгән иде. Хәл җыярга тукталгач караса, куллары гына түгел, аяклары, чалбары, бөтен киеме гел кан гына иде. Нәҗәр үзен палач итеп күрде. Палач! Нәҗәр — палач!

Тукта, чү, ник бу чаклы каты хөкем? Бәлки алай ук түгелдер? Атабаба кылмаган нәрсәме? Кеше үзенең яшәү законнарын сентименталь кичерешләр хакына үзгәртә аламы? Булдыра алса, һичшиксез, шулай эшләр иде, ләкин андый яшәү ысулы хәзергә юк. Ә ул яшәргә тиеш. Нәҗәр туган, адәм баласы икәнеңне искә алсак, дөрес эшләдең, вөҗданга хилафлык китермәдең — элеккечә матур гына яши бир...

Әмма җан дигәнең барыбер тынычланырга уйламый. Аны хәзер кызы Энҗе, Каравылчы һәм Әпә атлы телсез малай каршылаячак. Алар тынычландырса гына. Алар нәрсә әйтер, шунысы мөһим хәзер.

Юл капчыгын һәм «аюны» аркасына салган, ә мылтыгын кулга тоткан хәлдә, Нәҗәр «җәнлекләр бакчасы»на керде. Аны күргәч, кызы да, Әпә дә каравыл өеннән чыктылар да... нәкъ кателгәнчә: әтисеннән куркып иң башта Энҗе чарылдап кычкырды, аннары, алай ук курыкмаса да, Әпә дә, аю тиресен тотып карагач һәм үзенең дә куллары канга буялгач, шул кулларын бутый-бутый, үзе генә чыгара алган ымлыкларын кабатлый-кабатлый, шыңшырга кереште. Әйтерсең очынаочына бии.

Шау-шуга Каравылчы да чыкты. Әпә шикелле үк ул да тирене әйләндергәләп торгач, чирәмгә утырды һәм катгый нәтиҗә чыгарды:

— Бездәге аю гаиләсенең башлыгы бу. Тормыш иптәше, ике баласы, үзләре теләп безнең бакчада төпләнгән иде бит. Анысын беләсең. Шуны эзләп килгән. Тапкан да булыр иде. Изге хайван. Күпме ара калгач, килеп җиткәч!

Башка вакытта кочаклап кына сөйләшә торган кызы әтисен читтән генә шелтәли бирде:

— Әти, нишләдең? Ник аттың?

Шулай килеп чыкты ки, музей залында утырасы кабан дуңгызы кырлар-урманнар буйлап чаба бирә, ә беркем өмет итмәгән, максат итеп куймаган аю аның урынын алачак. Моны инде тәкъдир дими ни дисең? Нәҗәр — чын фән кешесе — ул да буйсынырга тиешмени таушалып беткән шундый кодрәткә?

*
* *

Бер дә юктан яңа кайгы өстәлгәнгә, Нәҗарның хәле начарайганнан-начарайды, кояш яктысы гына җандагы әңгерне куа-тарата алмады. Дару ярдәм итмәсен чамалап, врачка да барып тормыйча, аю тиресен тәбәләп кибәргә элгәч, үзенә авырырга рөхсәт итте, өч көн караватта аунады. Янбаш сызлавы өстәлгәнен исәпкә алмаганда, бүтән үзгәреш тоелмады — баш һаман чатный, әйләнә, күңел болгана. Һава сафлыгын сагынып урыныннан торды. Ярый әле, егылыр дәрәҗәгә җиткәч, карават тимеренә тотынып булса да аякларында басып калды һәм, чайкала-чайкала атлап, ник икәнен үзе дә төшенмәстән, читлекләр янына килде. Кошлар илтифатсыз гына очына-чыркылдаша, игътибар иткәне горур карый. Чөлди, челән, тәкәрлек кебек туган тиешле кошлар, муеннарын сузгалап, гаҗәпсенү белдерә. Ярый әле, болардан карачкы ясыйсы юк, бөерләрен, бавырларын алып тикшерер өчен дә мәҗбүрият туганы юк. Бәяләре бәләкәйрәк булган җанияләре — йорт күгәрченнәре һәм тычканнар коткара килә. Болары күңел һәм бакча күрке булып кына яши бирәләр. Бу тирәдә, көн-төн дигәндәй, мәктәп балалары, кошлар һәм җәнлекләрнең үзләре кебек, чыр-чу килә, сөенә, сикерешә. Шулар белән бергә — Энҗе һәм Әпә.

Кошлар рәтен узып, Нәҗәр аюлар янына килде дә ана аюның күзләренә гаепле кеше сыман карады. Көтелгән хикмәт: ике-өч ай буе күреп ияләшкән җәнлек бүген аңа ыргылырга әзер кебек иде. Хәтта ике баласы, Энҗе кушкан исемнәре белән әйткәндә, Аппак белән Йомшак та, синең белән сөйләшмибез дигәндәй, әчкәрәк постылар. Ана аю башта усал карап торса, бераздан читлеккә ал аяклары белән ябышып үкерергә үк тотынды.

Нәҗар атылган аю тиресе белән булышкан киемнәрен инде юып ук элгән, һәм тегенди-мондый ис бу яңа киемнәреннән түгел, искеләреннән дә килмәскә тиеш, җилгә очкан булырга тиеш. Әмма ана аю үз иренең кадерле исен барыбер сизде бугай. Сөеклесенең исе, бәлки әле төсе дә Нәҗарга барыбер йогып калган иде булса кирәк. Югыйсә, моңарчы гел дусларча карый белгән, ияләшкән аю ничек итеп кинәт кенә үзгәрсен ди. Ирекгә очрашырга туры килсә, ырлап-үкереп кенә калмас, туп-туры өскә ташланыр иде. Кайбер көннәрдә аларны ирекка чыгаралар бит...

Нәҗарның тәне эсселе-суыклы булып чымырдый да, ул читкә тайпыла һәм ата аю тиресе янына юл тота. Тире инде карачкы өчен әзер— каплыйсы гына калган... Һәм ул әйтерсең яңадан тереләчәк!

Тирене күтәреп, исе тегеләрен котыртмасын өчен, Нәҗар капка артына, шундагы тигез яланга чыкты. Эшкә тотыныйм дисә, калыплар да, инструментлар да мастерскойда калганлыгы беленде. Буталган баш, бөтенләй буталган.

Тирене калдырып, бакчадан уңда, чокыр буенда урнашкан мастерскойга китте.

*
* *

Балалар ачуы тиз уза. Бакча ягынан бүген аларның инде уйнаган, көлгән тавышлары ишетелә. Нәҗарның бердәнбер кызы, дөньядагы иң зур ачышы һәм бәхете булган Энҗесенең чын ихлас җыры яңгырый:

Та-та-та, тра-та-та,
Аю тәмәке тарта.
Тәмәкесен ташлады,
Мине куа башлады.

Энҗе үзе йөгерә, үзе җырлый. Артыннан килгән Әпәне ул, мөгаен, чынлап та аю итеп күз алдына китерә торгандыр. Йөгереп килгән уңайдан аю тиресен Әпәдән тартып алгач кына уе кинәт үзгәргәндер, чөнки ул аю булып үзе ырларга һәм Әпәне «таларга» кереште. Тик малай аннан «аюны» янадан алгач, кыз сикергәләде-сикергәләде дә, кетмәгәндә Әпәдән тирене кире тартып алып, икенче төрле такмакларга кереште:

— Син түгел аю, мин — аю, мин — аю — у-у-у! — Әпә тирене янадан үз кулына эләктерергә тырышса да, кыз бирешмәде. — Син түгел, мин —аю, мин —аю, та-та-та, аю тәмәке тарта...

Аюны бүлешә алмыйча тарткалаш киткәндә, Каравылчы абыйлары килеп җитте дә тирене җәһәт үзе алды.

— Кычкырышмагыз, югыйсә, икегезгә дә эләкми. Аю буласыгыз килсә, акырышмагыз, әдәпле булыгыз.

— Әһә, ыһ-ыһ, ым-мы.

— Ул энә Әпә булса да кеше кебек кычкыра.

— Әпә, улым, кил әле, бирерәк кил.— Карт, ишарәләр белән чакырып, сүзен шул рәвешле аңлатырга да кереште. — Беләсеңме нәрсә, егет кеше затлы булырга тиеш. Кызларга беренчелекне бир син, рәтле адәм булыйм дисән. Башта Энҗе аю булсын, соңыннан — син. Икегезгә дә җитә. Кил әле, кызым.

Энҗе килгәч, аны аю эченә кертте дә Каравылчы соңгы күрсәтмәсен бирде:

— Бар, җәнлек икәнсен, урманга чап. Бу таба килгәндә Әпә «аю» булсын. Килештекме? Менә шулай, тик тере аюлар янына бара күрмәгез. Һоп, чаптык! Барыгыз, җәнлек булып яшәп карагыз. Аннан кире әйтерсез, адәм булу шәбрәкме, әллә аюмы. Читлектә дә утырып карарсыз, бәлки шунда куәтлерәк аңлый төшәрсез дөньяны.

«Аю» шактый ук иләмсез хәрәкәтләр белән урманга кереп киткәч, Каравылчы җиргә утырып, болай эш юктан гына, ахрысы, мылтык затворын сүтеп карады, патроннарын барлады да янадан корды. Әлбәттә, фикер дигәне дә тик тормыйча, әйләнә бирде: «Каравылчы да булып була, галим дә булып була,ерткыч булу аерата җиңел, ләкин кеше булу кыен. Ай-һай, кыен чын кеше булу! Кайчак мөмкин түгелдер сыман ук тоела. Әмма бирешергә ярамый, сынатмаска; җиңелмәскә — Энҗе белән Әпә яшеннән башлап, гомер буе көрәшергә туры килә, хәтта менә шушы яшькә җиткәч, картайгач та».

Көч-хәл белән атлап, Нажар килде. Килеп җиткәч тә җиргә утырды да үзе китергән юл капчыгына баш куеп ятты. Коты качкан аның — чырае бронзадан ясалган сурәт шикелле иде. Болай да сорырак күзләре бөтенләй төссезләнгән. Маңгай өстендә балаларныкычарак таралган чәче үрә торган һәм бүтән чакта шөкәтсез тоелмаган озынчарак борыны — тәкәббер сыман. Бөтен кыяфәте борынгы адәмнәр, һәйкәл-сыннарны хәтерләтә.

— Энекәш, син әле ник болай, табутта яткандай аяк суздың?— Җайсызрак яткан мылтыгын Каравылчы Нажарның баш очынарак күчерде.

Нажар ыңгырашуын көчкә тыеп:

— Янам әле, Әмән абый, — дип куйды.

Тән кызулыгы гына түгел, йөрәк көйгәне дә сизелерлек иде. Шуңа күрә карт Нажарның башына кулын куйган чакта ук нинди чир икәнен әйтеп бирде:

— Аю каргышы тоткан. Бер гаепсез җан иясен күзләренә карап ат та, исән дә кал. Булмый ул алай.

— Дуңгыз урынына килеп чыкты... Кем уйлаган.

— Уйламыйча мылтык төзәргә ярыймы?

Нажар жавап таба алмаганга һәм нишләргә белмәгәнгә күрә генә капчыгын чишеп күтәрде. Аннан агач калыплар коелды. Бу минутларда Нажар тирене калыпларга дигән ниятен, хәтта тиренең үзен, аның хәзер хәтта кайда икәнлеген, хәтта менә шушы калыпларының ни өчен монда икәнлеген дә уйлап чыгара алмаслык дәрәжәдә хәлсезләнгән иде. Зиһен дигән киңлеккә әллә нинди эссе томан тыгызланып тулган, күзләр дөньяны әллә нинди буталчык шәүләләр рәвешендә күрә һәм шунлыктан фикер дә мөстәкыйль түгел — күкрәк эчендә сулкылдаган, сызлавык сыман бер ачы тойгы талпынышы буларак кына туа һәм анда да бары тик Каравылчы абый сүзләре артыннан гына иярә иде.

— Шулай шул, дуңгызга дигән ядрә аюга эләкте. Ә дуңгыз йөри — урманда гына түгел, шәһәрдә... мин эшләгән җирдә. Анысы бөтенесеннән дә явызрак. Ә бу чынлап та ялгышлык корбаны... Шуңа күрә мин аңа үлемсезлек бүләк итәм.

— Барлык аюлар исеменнән олы рәхмәт. — Каравылчы ике шакмакны алып шакылдатты да елмайган булды. — Бәхетле җанвар! Үзенең пычрак эчләрен чып-чиста агачлар белән алмаштырып, мәңге басып торачак бит инде, ә!

— Үлгәч тә эшләячәк, файда китерәчәк.

Нажар хәлсезләнеп башын җиргә салса да, Каравылчы аны кызганырга чамаламады. Киресенчә, җан әчесен әйтерсең аның өстенә бөркеде:

— Шулай да эчемә саф каен түмәрләре тутырып мәңге утыруга караганда, үземнең алама әгъзаларым белән бер-ике генә ел булса да артыграк яшәргә тырышыр идем мин.

Озак та үтмичә, урман ягыннан Энҗе кычкырган тавыш ишетелде һәм шул арада ул үзе дә күренде.

Кыз чын мәгънәсендә коты очкандай йөгерә иде.

— Аю, мине аю куа, аю, ашый!

Нажар сикереп торды да, ни күргәненә үзе ышанмыйча, Каравылчыдан:

— Нәрсә бу? — дип куркып сорады.

— Бу — син үтергән аю. Терелгән дә үч алмакчы. — Мыегын да селкетмичә, карт шулай дип җавап бирде.

Гаҗәпләнүдәнме, куркуданмы, әллә үз күзләренә һаман ышана алмагангамы, әллә, юкса, күз карашын эссе томан инде тәмам каплаганга күрәме, Нажар башта җиргә сыенды, үләнгә ябышты, тик Энҗенең ачы тавышы аның үзәгенә үк үтә иде. Ахырда мылтыкка ябышты. Каршыда Энҗе йөгерә, әйе, аны «аю» куа. Бер секундтан соңга калсаң... Әмма ничек кызның үзенә тидермәскә? Ничек җайлы ара эләктерергә?

Сайлады Нажар шундый араны. Бер секунд... Бер секундка дүрт хәрәкәт сыйды. Әтисенең нишләргә җыенганын сизгән Энҗе: «Әти, Әпә бит бу, атма, атма!» — дип кычкырырга, Нажарның мылтыкны шаартып кына тотмаганын шәйләп, Каравылчы мылтык өстенә аварга, ә Нажарның тиле бармагы мылтык чакмасын тартырга өлгерде, тик ядрәләр генә, секундның кай өлешендәдер, канлы тәкъдирдән тайпылып, якында гына яшел чирәмне теткәләп, кара туфрак айкап чыгарды. «Аю» исән калды. Аның һаман якынлашканын һич тә аңы белән түгел, бары тик тәне белән чамалаган Нажар мылтыкка яңадан ташлангач, Каравылчы тагын аның өстенә ятты да бермәлне әүмәкләшү китте һәм тиз арада «аю» ырлый-ырлый Нажарны таларга да керешә. Бөтенесен чын итеп кабул иткән Нажар исә бар көченә:

— А-а-а-т-т,— дип кычкырып җибәрде дә кинәт сыны каткан сабый бала шикелле, җиргә чалкан ауды.

Шул рәвешле, тәкъдир дигән мәгънәсез көч иң әүвәл кешенең зиһенен томалады да, аннары аны оятлы хәлдә калдырыр өчен, үзенең ти-

ле боерыкларын үтәргә мәҗбүр итте һәм тән дигәнең хәрәкәткә сәләтен югалткач кына каядыр җилде. Шуна күрә Каравылчы: «Җитте!»— дип кычкырганнан соң да Әпә тукталмагач, инде аны кочаклап җиргә аударды да тирене Әпә өстеннән салдырды.

— Котырганнар, уеннан уймак чыгарасыз ласа!

Каравылчы үзе дә каушаган һәм еш-еш сулый иде. Әпә «аю» эченнән чыккач кына Энҗе телгә килде:

— Әти, әтием, без бит шаярдык кына, — дип, әтисен уятырга, кузгатырга тырышса да, ул кыймылдамагач, еламсырый ук башлады.

Әпә исә кул һәм бит хәрәкәтләре белән: «Мин аны чынлап таладым», дигәнне аңлатып усаллашты. «Ник үзе аюны үтергән?» Янәсе — а-а-а, пуф, ыһ-ыһ.

Кызның шыңшуларына Әпәнең усаллашуы ялганып, мәзәк ук авазлар хасил була иде.

Каравылчы Нажарның күкрәгеН тыңлаганнан соң:

— Аз булса да сулый, барыгыз, врачка чабыгыз, — дигәч, Энҗе җәһәт кенә торып йөгерсә, Әпә исә кыймшанырга да чамаламады.

— Ә син ни карап торасың? — диде Каравылчы гаҗәпләнеп.

— А-а-а-ю, пуф, пуф, ыһ-ыһ! — янәсе ул аюны харап иткән!

Ачуланыргамы, мактаргамы — шайтан белсен.

— Кемгә охшап болай явыз син, ә? Атаң кем синең, атаң! — Ишарәләр.

— А-а-а-та, ыһ-ыһ. — Ишарәләр: «Атам юк».

— Ә анаң?

— А-а-а-на, ыһ-ыһ, ым-мы.

Атасыз-анасыз да кеше була икән...

Әпә, телсез. Бер мәгънәгә халык ике сүз тапкан. Юкка гына түгелдер бу. Телсез димәгән, Әпә дип исем кушкан менә бу малайга. Чынлап та аны ничек телең барып телсез дияргә мөмкин? Сүзләрен, кайбер теләклә̀рен ул телле кешедән шәбрәк аңлата белә. Ләкин үзенең каян һәм кем икәнлеген генә аңлата алмый әле. Ике ел инде, җәй җитте исә, җир астыннан калыккандай килә дә чыга. «Әпә, әпә», «ыһ-ымым...»— аның бу сүзләре Каравылчыга үрдәк бәбкәсе пипылдагандай тоела. Бәбкәнең дә гаиләсе, этка-әнкәсе була. Әпәнеке — юк. Күпме сорасаң да әйтмәде һәм әле дә әйтми. Бәлки әйтә дә алыр иде шикелле, тик ата-анасы хакында ишетергә үк теләми бугай. Кайбер ишарәләрдән чамалаганда, ата-анасы эчкечеләр, көн-төн тарткалаша-сугыша торган кешеләр булганга күрә, аларны бала ташлап кача булса кирәк. Менә шушы мәгънәләрне генә ачык итеп әйтми ул, ә калганнарын...

Менә бит, әйтәсе килгәненә туп-туры итеп бармак төзәде:

— Әпә, ыһ!

Баксаң, урман эченнән кеше чыгып килә. Прораб дигән кеше. Ул күренгәч, куллар буташу, авызлар кыйшайту тукталды, гәрчә ул адәмгә Каравылчының күтәрелеп карарга теләге-нияте булмаса да.

Прораб белән Каравылчы — эт белән мәче. Сәбәп — җитди. Сәбәп — Прораб исеме күтәреп йөргән бу адәмнең кеше була алмавында. Каравылчының фикере менә шушындый. Тегесенеке дә юньле түгелдер, әлбәттә.

— Исәнмесез, иптәшләр, исән тордыгызмы? — дигән булды Прораб үзе белән гаплашергә бик әзер түгелләрен сизгән хәлдә. — Кала сезгә сәламнәр әйтеп калды, — дигәнен дә өстәде.

Әйтерсең аны монда дуслары көтә.

Юньле сүз ишетмәскә күнеккән Прорабка Каравылчыдан «вәгаләйкемсәлам» дигән җавап җитә яза. Елмаеп ук сөйләшмәкче:

— Я, эшләр кай тирәдә?

— Менә, бәгъзеләребезнеке бетебрәк тора бит әле.

— Ә-ә, беләм, әйттеләр.

Нажар... институттагы эшен ташлап качкан.

— Нажар... институттагы эшен ташлап качкан.

— Син дә мондагы эшеңне ташлап качсаң, яртыны куяр идем.

— Һаман бер балык башы! — Прораб үртәлүдән көрсенеп үк куйды.

Елгада динамит шартлатып, кеше башына бирәр балык та калдырмадылар да, хәзер суын ук корытмакчылар. Шундый алама эш иясе булган Прораб Каравылчыдан җылы мөнәсәбәт өмет итә. Кызык та инде бу бәндә дигәнең, бик тә кызык.

Институтның җәнлекләр бакчасы һәм ярдәмче хуҗалыгы тугайда, елганың элмәккә охшап торган җирендә урнашкан. Ике йөз метр чамасы араны казысаң, хәзерге юлын ташлап, турыга юл сабарга тора. Ә прораб дигән юньсез бәндә (Каравылчының аңа исеме белән моңарчы эндәшкәне юк һәм болай барса эндәшә дә алмас) нәкъ менә шул төшне карьерга әйләндерде — комны да, ташны да шуннан ала. Эшен әгәр ары табан дәвам итсә, елга кирәкмәгән төштән ташып, хуҗалыкның бик күп җире су астында калуын көт тә тор. Күпме туглады — аңламагач аңламый — булыр икән андый кеше дә. Җитмәсә әле, үзе Каравылчыга бәйләнә. «Шушында, борын төбендә хәзинә була торып, җир читеннән материал ташып булмый бит», янәсе.

— Тугайны коточкыч базга әйләндереп рәхмәт ишетәсең киләдер әле тагын?

— Нинди баз? Күл, камышлы күл булачак! Ягъни яңа бер матурлык артачак синең зәгыйфь күзләреңне иркәләр өчен!

Менә сөйләш син аның белән...

Беренчедән, бер түгел — ике. Былтыр ул казыган җир, кем әйткәндәй, хикмәти хода, быел язгы су белән тулып, чынлап та күл рәвешенә керде. Үзәннең бу почмагы институтның ярдәмче хуҗалыгы карамагында булганлыктан, шушындагы хуҗалык мөдире үз белдеге белән генә икенче күл ясарга рөхсәт иткәч, Каравылчы хәтта институт директорының хуҗалык эшләре буенча урынбасарына хәтле җитсә дә, анысы да нинди пүчтәк нәрсә хакында сөйләшеп минем дәрәҗәмне төшерәсең дигәндәйрәк карап: «Бәләкәй генә күлдәвекне дә диңгез итеп күрмәсәк яхшырак булмасмы икән?» дип, рәтле сорауга мәгънәсез сорау биреп авызны япты. Монда бер генә тапкыр да булмаган, бу елганың холкын башына да китерә алмаган кеше ара һәм мәнфәгатьләр ераклыгы аша ничек итеп чын дөреслекне күрсен инде! Прорабка шул гына кирәк тә. Ярдәмче хуҗалык мөдире алдына, динамит шартлатып тотылган һәм шәп кыздырылган балыклар белән берәттән, күңел күтәргеч эчемлек тә бер генә шешә куелмагандыр һәм аларның бәясен Прораб — якында гына төзелеш материалы табуын рационализаторлык тәкъдиме итеп рәсмиләштерү исәбенә — үзенең шәһәрдәге төзү-монтаж идарәсеннән дистәләрчә мәртәбә артыграк итеп түләткәндер дә бәлки. Әмән абыегыздан яшерү кыен — юкка гына Каравылчы исемен йөртми ул. Каравылчы абыегыз сезнең артык та нык кызарган хәлдә шаяракөлә табигать рәхәте чигүләрегезне бер генә кабат күрмәгән бит. Ничек кенә булмасын, Каравылчы икенче күлгә теше-тырнагы белән каршы булды һәм хәзер дә, бөтен ачуын җыеп, кеше була белмәгән, бары тик прораб кына була алган бу бәндәнең кара йөзенә лач итеп төкерер иде. Әмма хәтта шунысын эшләргә дә ярамый — тавыш чыгачак.

— Табигать корткычы! — дип нәфрәт ату кебек көчсезлек белән чикләнергә туры килде аңа бүген дә.

Җитмәсә, Прорабка шул чаклысы да чамадан тыш олы тупаслык сыман тоелды, бәндәң кинәт кабынып, зәһәрләнәсе үк итте:

— Әһә, менә кем икән ул котыртучы! — шулай диде дә Каравылчының изүеннән эләктерде.— Өченчекөн нинди ахмак минем кабинет ишегенә «Табигать корткычы!» дигән язу ябыштырып киткән дисәм, менә кем икән! Эләктерсәмме, эләктерсәмме!

— Бөтен кешене эләктереп бетерә алмассың, бәдбәхет. — Каравылчы тегенең кулыннан ычкынды. — Якадар күп бит, ә синең куллар икәү генә.

Олылар әрепләшкән, якалашкан арада Әпә Нажар аркасына ниндидер кәгазь беркетмәкче булып азапланганны чамалагач, Каравылчы, Прораб сизмәслек итеп, малайны ул эшеннән туктатыр өчен аягы белән читкә этәрде. Малай актыгы, ярый әле, кулындагы язуны яшерә белде. Аны Прораб кебекләр аркасына ябыштырырга кирәк ләбаса. Каравылчы бу мәгънәне дә ишарәләп аңлата алды. Прораб Нажар янына килеп утыргач, Әпә дә, Нажарның калыплары белән уйнаган булып, Прорабка хәтта шаян мәгънәләр ишарәләп, аның якаларын, җиңнәрен сыпырыштырып, хәтта кочаклап мәш килде. Прораб исә, яхшылыктан тынычлангандай, Каравылчыга үзенең фәлсәфәсен аңлатырга кереште:

— Абый кеше, синең акыл бик тә бәләкәй радиуслы бит. Уйлап кара, картлач, сезнең хуҗалыкта һәм бакчагызда огромный корылмалар салабыз. Бетонга никадәр ком-таш кирәген уйлап, минем ничаклы байлыкка экономия ясаганымны әйләндереп чыгара алмый бит синең буш баш. Хәтта менә шушы галимнеке дә.

— Әпә, ым-мы.

— Молодец, балам, шәп. — Прораб аркасына ябышкан «Табигать корткычы!» дигән язуны күргәч, Каравылчы гүяки Прораб сүзләреннән кычкырып көлеп җибәрде дә Әпәнең аркасыннан чәбәкләде. Ә малай, үзенең телсез тантанасын ымлыклар белән авазга әйләндереп һәм шул куанычны Каравылчыга да йоктырып, аһылдый-аһылдый китеп тә барды.

Тик ул калдырган шатлыкны чырайсыз кыяфәте белән тиз арада Энҗе сүндерде. Врач табылмаган икән. Әмма Прораб хәлгә кермәкче:

— Врач дисезме? Калада совещаниедә калды. Ул ни эшкә?

— Күреп торасың ласа, янында кеше һушсыз ята.

— Һы, мин аңа сүз әйтергә киләм тагы. Ярый, булмады, алайса. — Шулай дип торып баскач, Прораб, аркасындагы язудан Каравылчы тагын көлгәнгә, кире борылды. — Ни бар, ник мөңгердисез?

— Аю биетәләр.

Башта аю тиресенә, аннары Нажарга карап алгач, Прораб үзе дә:

— Биеп яталар шул аюлар,— дип көлгән булды.— Мин әле генә каладан кайттым и анда ишеттем. Моның хатыны кем беләндер йөрәк ите центрифуговать итә дип шаулыйлар анда.

Бала алдында гайбәт сатудан уңайсызланмаган бәндә өчен гаилә агачын төбе-тамыры белән шашкан аюдай йолкып ату да кыен нәрсә түгел. Мәгънәсез катылыкны аңлыйсы килми, ә аңа җавап бирү тагын да авыррак. Каравылчы да, Энҗе дә шуңа күрә аптырап калдылар. Бәлки Әпә нинди дә булса сүз табар иде, ләкин ул монда түгел. Үлгән кешене уятырлык гайбәт үз эшен чынлап та башкарды: Нажар аңга килде. Димәк, ишеткән! Кабердән чыккан шикелле кыяфәт белән торып басты да, теге дөньядан кайтып өлгермәгән, кызыл ут сирпеп көйрәгән карашы белән тирә-юньне кармалагандай итте. Аннары Прорабның битенә кадалырга тырышкандай текәлеп, ниндидер сүз әйтергә азапланды. Артык ачуланганга күрәме, тавышы чыкмады. Су эзләп җәфаланган балык сыман иреннәрен кыймылдата торгач кына, анда да тик пышылдап кына, тиешле бер сүзне җыя алды:

— Хәш-шәрәт!

Дөрес сүзне ишетми калу кыен. Ул Прорабка, әлбәттә, ошамады, чөнки, нияте үзенчә яхшылыкта булганлыктан — максаты Нажарны гайбәткә юл куймау чарасын эзләргә мәҗбүр итү булганлыктан — ул ягымлырак сүз көтә иде. Үзенең дә кәефе кырылды.

— Мена дурак, мин аңа яхшы ният белән, ә ул... — дип тотлыгып калды, чөнки «теге дөньядан кайткан әрвах» куркытырлык ук кыяфәткә кергән иде.

— Қабатла сүзеңне! — дип, үз хәлен үзе белмичә сугышырга теләгән шикелле, Нажар Прорабның каршысына ук басып ысылдады.

Гаҗәп зәгыйфь пышылдауга адәм ышанмас куәтле ачу төйнәлгән иде. Прораб үзен кырмыска оясына эләккән еландай хис итте.

— Һыһ, син һыһ, кайт та үзең ачыкла. Күпмегә алсам, шуңа саттым, әйттем исә кайттым. Гафу — ялгыштым.

Тагын бераз гына карап торды да эшлекле адымнар белән китеп барды. Нажар, дөньяның әйләнүен туктата алмыйча чайкалып, тагын җиргә утырды.

— Уф, баш...

Каравылчы ул баш әллә бөтенләй беттеме дип курыккан иде. Шунлыктан бераз җиңелрәк сулап куйды.

— Болай булгач түзәрлек, тамагың гына әллә нишләде. Яле, тырышыбрак кычкыр әле.

— Соңгарак калдым бугай, соңгарак. — Кара син, күрәләтә тавыш югалт, имеш.

Тәмам аптыраган Энҗе, әнисе белән сөйләшер өчен, телефоннан шалтыратмакчы булып, капка төбендәге будкага йөгерде. Икенче яктан баягы шатлыгын югалткан, чырайдан язган Әпә килеп чыкты. Кулында — нииндидер кош...

Каравылчы кошны үз кулына алды да ишарәләр белән сорашырга кереште:

— Божыр. Каян алдың син аны?

Әпәнең кул һәм йөз хәрәкәтләреннән: «Һавага пырылдап очты да кинәт дөп итеп җиргә төште» дигән мәгънә аңларга мөмкин иде.

— Пуф, пуф! — мылтык ата, янәсе.

Әпә дисәң дә Әпә, божырга бу хуҗалыкта кем мылтык төзәсен.

— Пуф, пуф, эһ-ыһ.— Имеш, Нажар аткан.

— Юк бәла ягасың, бу абыең, киресенчә, кошларны үзе яклый торган кеше, нишләп атсын ди ул?

Ләкин шунда Әпәне җөпләр өчен Нажар баш калкытты:

— Ату белән бер инде ул, агуларга рөхсәт иткәч.

— Син дә шундый усалмы?

Тиз арада килеп җиткән Энҗе, әтисен кочаклады да хәбәр җиткерде:

— Әти, мин әнигә шалтыраттым. Әни әйтә, кайгырмасын ди, ул бернәрсә дә югалтмаган ди. Сине директор чакыра, иртәгә ук кайтып житсен дип әйтә әни.

Нажар сискәнгәндәй сикереп торды:

— Ничек? Ә? Директор чакыра? — Һәм терсәкләре белән җиргә таянып, үз соравына үзе җавап та бирде. — Әйе, мин анда булырга тиеш, тиеш! — Иске сәгать суккандай аклы-кызыллы авазлар чыгарып гыжылдагач, башы яңадан бөгелеп төште.

Нажар ял иткән арада Каравылчы белән балалар шактый вакыт вак-төяк хакында гәпләшеп утырдылар. Карт бу яктагы истәлекле урыннар, агачлар, әрәмәләр турында, аларны ничек итеп сакларга кирәклеге турында сөйләгәндә, Энҗе сәеррәк сүз әйтеп ташлады.

— Син, Әмән абый, үзең кешеләрне гел өйрәтәсең, ә үзең бернәрсә дә эшләмисең,— диде.

Акланып кара! Каравылчы абыегызның чынлап та бердәнбер һөнәре — кеше өйрәтү шул. Гомер буе укытучы булды — биология укытты. Пенсиягә чыккач та яраткан эшеннән аерылмас өчен, шушы ярдәмче хуҗалыкка һәм җәнлекләр бакчасына каравылга керде. Шуннан баш-

лап сүзе эшкә эверелми, дөресрәге, аны ишетми башладылар. Хәтта йомшак күңелле тоелган Нажар да картның ялваруларына колак салмый — үз мәшәкатьләреннән бушамый, янәсе. Әйе, Энжегә каршы бер генә дәлиле дә юк Каравылчының.

— Дөрес шул, балалар, менә елгабызны күрәләтә имгәттерәм, — дип офтанырга гына мәҗбүр ул.

Балалар эндәшми торганга, Нажар баш калкытты:

— Бу елганың хәле яхшырак. Минем туган яктагы елганың әнә башын ук кистеләр.

— Кистеләр? Ничек итеп? — Әтисенең сүзгә катнашуыннан шатланырга тиешле бала, киресенчә, куркып сорады.

— Корыттылар, сөрделәр — елга башланган төштә хәзер кукуруз үсә.

— Ник?

— План үтиләр, янәсе. План бирелгән.

— Ник?

Нажар баш иеп котылганга күрә, бу сорауга Каравылчы җавап бирергә тиеш иде. Ләкин ул да:

— Белмим, балам, — дип кенә куйды.

— Ә кем белә?

— Беркем белми.

— Әти белә.

— Ул да белми.

— Әти, әйдә, елганың башында яңадан күл ясыйбыз, ә? Әти!

Бәхәсләшер нияте булмаса да, әтисе торды. Торды да чайкала-чайкала телефон будкасына килеп, номерлар җыйды. Дөнья һаман күңел болгандыргыч җиңел һәм какшау иде. Шундый алама караңгылыкта Фәнүсә шәүләсе күренгәндәй булды.

— Алло, алло, мин сезне ишетмим! — Шәүләсе күренү генә түгел, Фәнүсәнең тавышы да ишетелә икән. Димәк, Нажар җавап бирергә тиеш.

— Алло, Фәнүсә, алло!

— Алло, мин сезне ишетмим!

— Ишетмисең шул, ишетмисең? Ник? Ник?

— Алло, сез кем?!

Ярый әле, ярдәмгә Энже килеп өлгергән икән.

— Әни, әни, бу — без, әти белән мин.

— Кызым, тагын ни бар?

— Әни, синнән әти сорый: нишләп син мине ишетмисең ди. Әни!

— Нажар, иртәгә үк кайтып җит, совет утырышына, ишетәсеңме, Нажар?!

— Колакларым исән әлегә.

— Әни, ул сине тыңлый.

— Менә нәрсә: син иртәгә барлык сорауларыңа үзең җавап бирергә тиеш, бөтенесен ачыкла. Уйла, хәтерлә...

Нажар ишетте, уйлады, тыңлады. Дөньяда әйтерсең тик Фәнүсә сүзләре генә яңгырый иде...

*

* *

Күз алдына китерү һич тә кыен түгел: Директорның кабул итү бүлмәсендә секретарь кыз машинкада көннәр буе нидер басып, шакылдатып утыра. Кешеләр керәме, чыгамы — гамендә дә юк. Гадәттә ул Нажарны да күрми. Ләкин бер көнне...

Бер көнне ул Нажар күренүгә урыныннан ук сикереп торды да ишек төбенә хәтле килеп каршылады.

— Ой, Нажар абый, әйдәгез, гомерегез озын булыр әле, сезне генә

уйлап утыруым иде. — Сабый сыман эчкерсез елмая кыз бала, аңа бары тик иркәләп, үз итеп кенә эндәшергә мөмкин.

— Сезнең кебек гүзәл кызлар минем хакта уйласа, дөнья чынлап та кызыклы булып китәр иде,— дисең син дә чын ихласлык белән.

Секретарь кыз синең каршыңда бөтерчектәй бөтерелеп ала да:

— Үз бәягезне белеп бетермисез әле сез, — дип баягыдан да ягымлырак, серлерәк итеп елмая.

— Шулай да ничә тиен торам соң? — дигән буласың, кызлар карашы яктылыгында рәхәт коенып.

Ә ул кызганмый сибә күз чагылдыргыч шатлыкларын:

— Тиеннәр түгел, сумнар — күктәге йолдызлар санынча. Күбрәк тә дияр идем әле.

— Нәрсә комачаулый?

— И көнләшәм дә инде шул Фәнүсә ападан. Шундый да әдәпле, чын мәгънәсендә интеллигентный, зур дәрәҗәле галимне тәки бер кулда гына тота бит.

. — Ә кул сузучылар юк түгелме? — Шаяртсаң да, үзеңнең кыз чынлап сөйләшәдер дип ышанасың килә.

Сурәтләрдә генә, мода журналларында гына очрый торган ыспай гәүдәсен һәм башын матурлык законнары таләп иткәнчә тотып, шулай ук төзек сызыклардан иренмичә иҗат ителгән иреннәрен очландыра төшеп, кыз синең•белән илһамлана:

— Әйтегез әле, Нажар абый: әгәр сезне Парижга җибәрсәләр, сез миңа бүләк алып кайтыр идегезме?

— Парижга? Мине?

— Бүләкне әйтәм, алыр идегезме?

Гаҗәпләнсәң, аптырасаң да, шаяртуны кабул итәсең.

— Нәрсә кирәк соң сиңа? — дип башыңны кыегайтасың.

— Нәрсә? Миңа нәрсә кирәкме? — Кыз уйланып кала. — Ой да, да нәрсә кирәк соң әле миңа? Ну, бер кызык экстравагант әйбер. Безнең илдә көндез шәм яндырып эзләсәң дә табылмаслык нәрсә. Булдымы? Килештек?

— Ярый, бик кызыклы бер әйбер. Вәгъдә — иман.

Шуннан соң кыз синең өчен директор ишеген үзе үк ача — рәхим ит.

Директор бүлмәсендә лаборатория мөдире утыра икән. Син кергәндә директор аңа соңгы сүзләрен әйтеп тора:

— Төшендек. Мин синең фикерне ишеттем. Булды. Ә Нажар үзе ни әйтер икән? Утыр, Нажар.

Директор булып директор кул биреп исәнләшсә. Мөдир сиңа чырай ачмыйча, утырган килеш кенә кул сузды — никтер кәефе киткән.

Директор бераз шаярткан сыман елмайды:

— Я, хәлләр ничек?

— Әйбәт, Мөдир дә елмайса...

— Ә ул нишләгән?

— Бер-бер хәл бар, ахрысы.

— Шатлыклы хәл.

— Мөдирнең чырае шатлыктан каралган, алайса?

Максатка ирештең — Мөдирнең ачуы тышка ук ыргылды:

— Перестань, пожалуйста, сабыйланма, — диде дә җилкәсен үк биреп утырды.

Директор:

— Шатлыкның сәбәбе — сез эшли торган тема, — дип сүз башлагач исә, Мөдир аны бүлдерергә дә җөрьәт итте:

— Без эшләгән тема, иптәш директор, сезнең җитәкчелектә!

Мөдирнең максатын ныклап аңламыйсың, шулай да аның нәрсәнедер кулдан ычкындырмаска тырышуын син сизәсең. Директор да, нечкәлеккә бирелмәсә дә, сүзне төзәтергә мәҗбүр була:

— Шулай, без, без эшләгән тема. Аның белән химикларның бөтендөнья ассоциациясе кызыксына. Күңелле хәлме бу, түгелме?

— Әлбәттә, Мөдирнең ачуын кузгатырлык булгач,— дип тагын шаяртмакчы буласың син, секретарь кыздан башланган инерцияне туктата алмыйча, — шәп яңалык инде бу, хәтта кызыклы.

— Менә шулай. Агулы матдәләргә кеше организмының адаптациясе. Шушы темага бездән доклад көтәләр. Симпозиумга чакыралар. Парижга.

Шуннан соң гына син секретарь кызның чынлап сөйләшкәнлегенә ышанасың. Күзләреңне чет-чет йомып:

— Парижга? — дип инде чын күңелдән гаҗәпләнәсең.— Кем докладны әзерләргә тиеш?

— Тема өстендә конкрет эшләгән кеше буларак, мин сезне тәкъдим итәм.

Мөдирнең бая кара коелган йөзе хәзер агарып чыга. Ул уйлаган бәхетнең сиңа таба борылганын сизгән килеш, шуны кабул итмичә:

— Докладны кем ясарга тиеш? — дип төпченәсең.

Нәкъ менә шул соравың белән Мөдиргә үз фикерен өстәргә җай тудыргансың да инде. Мөдир дустың, төкселегән җиңәргә тырышкан хәлдә:

— Син ничек уйлыйсың? — дип, синең карашың белән кызыксына һәм син уйлаган арада: — Мин докладны иптәш директор үзе ясарга тиеш табам, — дип өсти.

Каршы килеп кара!

Моңа Директорның гына көче җитә һәм ул фикерен шуңа күрә кистереп әйтә дә:

— Докладны кем яза, шул кеше генә ясый ала — бүтән беркемгә хокук бирелмәгән.

— Бөтен дөньяда мин әйткәнчә эшләнә бит, иптәш Директор,— дип юхалана Мөдир.

— Мин дөнья өчен җавап бирмим.

Директор шулай кискен куйгач кына Мөдир, бирешкән булып, әмма барыбер үз ниятен онытмыйча, һаман Директор дәрәҗәсен саклап көрәшмәкче:

— Иптәш директор, алайса, Фәнүсә Кадыйровна белән мин эшләгән тема буенча да без сезгә әйбәт кенә доклад әзерли алыр идек бит.

— Төшендек. Фәнни җитәкченең нәрсә икәнен белгән хәлдә, үз кулы белән эшләгән кеше минем өчен кадерлерәк. Я, Зәбиров, ни диярсез?

Нәрсә әйтсен Зәбиров?

Башны кисмәгә биреп бәхәсләшергә мөмкин: лаборатория эшенең шушы рәвешле кинәт бөтен дөньяга танылырга торуы һич тә Фәнүсә һәм Нәҗәр Зәбировларның гүзәл күзләре һәм күркәм уңышлары өчен түгел, хәтта Директорның да искиткеч шәп җитәкче булганлыгыннан түгел, ә бары тик Мөдирнең үз хезмәтләрен күрсәтә белүе аркасында гына икәнлеге көн кебек ачык. Булган хезмәтне пропагандалау зыянсыз тыйнаксызлык булса, юкны бар итүне куркыныч нәтиҗәләргә китерә торган авантюра дип атарга туры килә. Һәм менә бердәнбер бурыч: хәзер, шушы минутта, Мөдирнең күзенә карап, шул дөреслекне кычкырып әйтергә кирәк. Зәбиров андый кискенлеккә бара алмый. Әгәр аңа ташлансалар, ул тешләшә дә башлар иде, ләкин Мөдир Нәҗәрны белә, һөҗүм итәргә җыенмый. Миенең бөтен-бөтен участокларын берьюлы эшкә җигеп, ниндидер сорауга киеренке рәвештә җавап кына эзли. Әмма фәнни сораугадыр димә.

Ручка тоткан кулы белән чигәсенә таянган да өстәлдәге бер хәреф тә язылмаган кәгазьгә, ак билгесезлеккә текәлгән Мөдир. Калын маңгаен чәчсез лепкәсенә тоташтырган иркенлектә, бүртеп чыккан тамырлары буйлап, куәтле фикерләр ургылып ага сыман. Менә, ичмасам,

кыяфәт — чын галим үрнәге! Әгәр дә шушында чит кеше чакырсаң һәм шушы өч кешенең кайсы галим дип сорасаң, ул кеше һич шикләнмичә Мөдирне күрсәтер иде. Нажарның балаларныкычарак таралган чәче һәм озын чандыр гәүдәсенә карап, ул кеше кул гына селтәр иде дә, хәтта Директорны да бик санга сукмас иде. Олпатлыкта кая аларга Мөдир белән ярышу! Шушы яктан фикер йөрткәндә, ул кеше, чит илгә, әлбәттә, Мөдирне чыгарырга кирәк, дияр иде дә, безнең бөек илебезнең лаеклы вәкиле итеп аны җибәрү мәслихәт, дип өстәр иде.

Табигать берсен бирсә, икенчесен җәлләгән шул: Мөдиргә бер генә бөртек тә иҗади очкын эләкмәгән. Фәннилек ягыннан ул бик тә бәләкәй кеше булып чыкты, бу даирәгә әлеге дә баягы кыяфәт культурасы аркасында гына узган очраклы кеше булып чыкты. Шуңа күрә аны, микроорганизмнарга карап мавыга белмәсә, бәлки кешеләрнең хезмәтен оештырыр, административ мәшәкатьләрне үз өстенә алып, башкаларга әйбәт шартлар булдырыр дип, мөдирлеккә куйганнар иде. Нажар тәкъдиме белән. Ләкин өметне акламады ул. Һәрхәлдә, Нажарныкын. Бәлки әле Директорныкын да. Югыйсә, институт абруен күтәреп кайтырына ышанса, дөнья симпозиумына өлкән хезмәткәрне түгел, ә аның җитәкчесен, нәкъ менә шушы Мөдирне җибәрер иде ләбаса ул.

Бөтенесе ачык аңлашылып торганда, тагын нәрсә өстәп әйтсен Нажар?

Чит ил күреп кайту — сирәк бәхет, рәхмәт инде дип, тиз генә ризалашсын, янсә, Мөдир шикелле, шуңа ирешер өчен көч тә куярга кирәксенме? Юк, һәркемнең үз һөнәре — юк-бар мәгълүматлардан доклад әвәләп, институтка гына түгел, бөтен совет фәненә күләгә төшерү исәбенә, Нажар бөтен дөнья аренасына ташлана алмый, һәм бәхәс кемне җибәрү хакында барырга тиеш тә түгел.

Директор куйган мәсьәләне үзенчә хәл итеп, Нажар телгә килде:

— Ил исеменнән чыгарлык эшләребез бар микән, башта шул хакта уйланыйк без, — диде.

Мөдир бер хәреф тә төшерә алмаган ручкасын ак кәгазь өстенә, ә кимсеткеч елмаюын Нажар тарафына ыргытса, Директор, ихлас яктырып һәм креслосыннан Нажар янына ук күчеп:

— Мин синнән нәкъ менә шушы сүзне көткән идем, молодец! — дип мактап куйгач, Мөдирнең хәтта баягы мәсхәрәле елмаюы да кинәт сүнде.

Әлбәттә, ул җитәкләгән лабораториянең, бигрәк тә үзенең хезмәтләрен кимету кебек усаллык белән килешергә Мөдирнең һич нияте юк иде, һәм күңелендәгене ул ярып салды:

— Сездә патриотизм җитми, иптәш Зәбиров, институт абруен күтәрү хакында кайгыртырлык дәрәҗәдә фикерли алмыйсыз сез, — дип, җитди замечание ясарга тиеш булды.

Өстәл янында кара-каршы гына түгел, капма-каршы позициядә утыра иде ике кеше. Мөдир, кайбер күзәтүләрне тотрыклы хәлгә әйләндереп, агудан зарарланмый калган аерым күзәнәкләр табылуны гомумилек категориясенә күтәреп, эксперимент тәгәлләнгән, хәтта ачыш ясалган дип исәпли. Шундый кискен нәтиҗәсенә бәлки үзе дә ышанмаса да, хезмәтен, дөресрәге — фамилиясен, дөньяга танытмакчы. Диссертациясе шул темага булганлыктан, бу фикер Фәнүсәгә дә бик ошый. Тик шулай булуга карамастан, аның юньсез ире менә файдасыз дөреслекне яклый: тере организмның агуга яраклашуын өйрәнүне әүвәлгечә тыныч кына дәвам итәргә кирәк, ә җыйналган тәҗрибәләр әлегә бик тә чамалы булганлыктан, дөнья күләмендә шауламый тору акыллырак... янәсе.

Бәхәсне Директор гына хәл итә алачак. Нажар дөрес, гадел һәм карьеризмга бәйләнмәгән фикернең җиңеп чыгачагына шикләнмәгән-

лектән, сүзне шушы хәлендә калдырып, авантюра хакында Мөдирнен үзе белән конфиденциаль төстә сөйләшергә кирәк булыр дигән ныклы карарга килде дә, Директорга баягы тәкъдимен кабатлаганнан сон:

— Александр Иванович, әгәр сез безгә бераз уйларга вакыт бирсәгез, чынлап та начар булмас иде бит? — дип өстәде.

— Дөнья аренасына чыгасың килми — төшендек. — Директор шулай көлсә дә, күзләреннән күренгәнчә, Нажар белән риза иде.

Ул гына түгел, уйланырга дигән вакытны, нишләптер, Мөдир дә бик теләп кабул итте һәм, минә сиңа хикмәт, Нажарны мактый ук башлады:

— Үзегез беләсез, Александр Иванович, Зәбиров — тыйнак, әдәпле кеше. Бәлки чынлап та бераз вакыт бирү акыллы булыр? Әлбәттә, докладны ул яза тора. Эшкә зыян килмәячәк диюем.

— Бетте, төшендек, бүтән сүзем юк.

Ләкин, бераз алгарак китеп фикер йөрткәндә, Нажарга бирелгән вакыттан Мөдир файдаланган булып чыкты. Ә ул көнне...

Кабул итү бүлмәсеннән берәүне дә күрми узып барган чагында Нажарны Фәнүсә туктатты.

— Котлыйм үзеңне, Нажар! — Шатлыгын тыя алмый Фәнүсә.

— Котлыйсың? Нәрсә белән?

— Париж, Париж белән!

Әйтерсең Нажар бу хәбәрне беренче ишетә, әйтерсең хатынын тынычландырырга кирәк:

— Әле билгеле түгел, ашыкмыйк, — янәсе.

Секретарь кыз да ышанмыйча шаярта:

— Кара, ничек эреләнде, барып кайткач нишләмәс — сөйләшмәс тә инде.

Иренең битеннән үпмәкче булып, Фәнүсә аккоштай муенын сузды:

— Акыллым, ишетәсеңме, котлыйм!

Әмма ире аның башына суккандай итте:

— Мин чынлап әйтәм,— тыныч басып торуын кара! — Мин уйларга вакыт сорадым.

— Уйларга? Вакыт?

— Әйе. Нәрсә, гаҗәпмени?

— Нажарик, болай ук шаяртма, югыйсә, минем температурам күтәрелә башлады. — Фәнүсә инде үзен кызгандырмакчы.

Нажар исә, күз дә йоммыйча, өметне ахырынача җимереп ташлады:

— Мин чынлап әйттем.

Хатыны ике куллап колакларын каплады:

— Коточкыч! Нормаль түгеллегеңне белә идем, тик менә болай ук булырыңны башыма китерә алмаганмын. Кара син ә, аңа юлын-нисен түләп, Парижга барырга тәкъдим итәләр, ә ул барыргамы-юкмы дип уйлап утырачак!

Фәнүсә иренең мәгънәсезлеген төзәтү нияте беләндер инде, Директорга кермәкче иде, ишек төбендә Мөдиргә бәрелә язды.

— Иптәш Мөдир, әйтегез әле зинһар, Нажар чынлап та Парижга барырга ризалашмый чыктымы?

Мөдир бусаганы узгач, ишекне япкач, анда да бик тә сабыр гына әйтте:

— Әлбәттә, каршы килмәде, ләкин ризалык та бирмәде.

— Әйтегез зинһар, сәбәбе нәрсә икән? — Нажар үзе инде бернинди игътибарга лаек түгел.

— Сәбәбе? Сәбәбе... Нажар — акыллы кеше, үзе беләдер инде.— Кайчан гына теш кысып түзгән кешесе хәзер аны мактый!

Тик Нажар макталуга риза түгел, аның күзләреннән ачу сибелә, балаларныкы төсле алга таралган чәчләре шул ачудан чуалган булырга тиеш. Эчендә әйтелмәгән нинди дер сере бар кеше шикелле, бары тик Мөдиргә генә ышану мөмкин шикелле, Нажар аны читкәрәк алып кит-

те дә пышылдап нәрсәләрдер әйтте. Соңыннан ачыкланганча, ул аны ресторанга чакырган иде. Сөйләшәсе бар, янәсе. Сөйләштеләр!

Нажар белән Мөдир чыгып киткәч, секретарь кыз эшен ташлады да нәрсәдәндер курыккан күзләрен зур ачып, аркасын бөкре әби төсле ия төшеп, башын Фәнүсәгә сузды:

— Беләсеңме, нәрсә,— диде ул гаҗәп тә олы сер ачкандай,— болай булгач, ирецнең син белмәгән гөнаһы бар. Тымызык күлдә шайтан оя корган ди. Кыңгыр эше, хатасы бар аның. Политическийдыр ук әле.

— Ни сөйлисең, бала!

— Әйе, әйе, политический! Җибәрмәсләрен алдан ук белеп, ризалашмаган була. Хәйләкәр! Менә, ичмасам, акыл!

— Юкны сөйләмә, Нажар Парижга барачак һәм ул риза, берсүзсез риза.

Шул сүзне, Фәнүсә Директорга кереп әйткәч, Директор елмайды гына:

— Мин каршы түгел бит, әлбәттә, барыр, әзерләнсен юлга, — ди.

Тик атна чамасы вакыт үткәч... Әйе, Нажар үзе үтенеп сораган вакыт үткәч... Әйе, Нажар дус үтенеп сораган вакыт үткәч...

— Уйла, уйла, хәтерлә, галим...

## ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

Өркетүләр, ыржаюлар, бара торгач,
Тоташканнар татулыкка, иминлеккә.
Кыргыйлыктан яхшылыкка, изгелеккә
Чакыру ымы булып инде үсеп житә.

Нишләсен, уйлый Нажар, хәтерли Нажар, гәрчә уйларга һәм хәтерләргә һич тырышмаса да.

Хәтердә — ресторан.

Юка диварлар белән аерымланган бүлмәләр.

Эстрадага якын бер бүлемдә таныш түгел кеше утыра. Нәкъ шушы өстәлгә Нажар Мөдир белән кечке ашка заказ биргәннәр иде.

Тегенең кем икәнлеге билгесез, бәлки монда ялгыш килеп утыруыннан ул үзе оялырга тиештер, ләкин менә ни өчендер Нажар уңайсызлана — ояла-ояла гына ят кешегә сүз куша:

— Гафу итегез, бу урын...

Ят кеше дусларча елмая:

— Гафу итегез, сез Нажармы?

— Гафу... итегез, Нажар шул.

— Алайса, мин сезне көтәм. — Кеше торып басты да Нажарга урын тәкъдим итте, әйтерсең ул хужа. — Сезгә кайда җайлырак булыр икән?

— Мине башка берәү көтәргә тиеш иде бит, — дип, аның бөтенләй икенче җиргә күчүенә өметләнә Нажар.

— Без аны бергәләп көтәрбез, утырыгыз зинһар.— Нажарның борчылуын сизүдәндер, әлбәттә, чакырылмаган кунак хуҗаны тынычландырырга тырышты. — Сез бер дә хафаланмагыз, артык булсам, мин үз урынымны тиз табармын, курыкмагыз. — дигән булып пайпылдады.

Гүяки хәзер үк артык түгел, гүяки бу фикерне Нажарның әйтергә яхшысынмавын аңламый, әйтерсең әдәп саклау хисе белән курку хисе аның өчен икесе дә бер. Курыкмый Нажар, бары тик үзен тупаслыктан гына тыя:

— Әһә, сез барын да беләсез, ә мин сезне белмим.

Таныш түгел кеше, үзләшергә ашыгып, тагын да йомшаграк тавышка күчте. Бусы хәтта юхалану төслерәк иде:

— Мепә сез нинди икән — чибәр, акыллы. Ә мин — күрше каланың фотожелатин заводыннан — сезнең институтка вәкил булып килдем.

— Алайса, сез — вәкил.

— Әйе, вәкил, вәкил.

— Сез мине болай да беләм дидегез. Димәк, таныштык.

Вәкил кул кысышып танышу өмет итсә дә (хәрәкәттән сизелә бит ул), Нажар кул сузмады һәм инде үзенең ялгышмаганын, өстәлнең хуҗасы үзе икәнлеген аңлатырлык итеп иркен хәрәкәтләр белән Вәкилгә каршы яктан урын алды. Ул утыргач та Вәкил:

— Мин сезне үзегез фаразлаганга караганда яхшырак беләм, — дип, көтелгән тамашада әйтерсең серлерәк роль эләктермәкче булды.

— Каршылыгым юк. Ярый. Алайса, сез — безнең Мөдирнең кунагы.

— Мөдирнең исеме юкмыни?

— Бу арада ул, ничек әйтим... Мөдирлек җәһәтеннән көчлерәк таныла башлады.

Вәкил тәмәке кабызды, тәмләп суырды да шундый ук ихласлык белән сүз чәйнәп чыгарды:

— Сезнең мөдирегез — шәп кеше, мин аның белән бер факультетның бер үк курсын бетердем.

— Иң мөһиме — фикердәшләр.

— Әүлия үк икәнсез. — Вәкил рюмкаларга эчемлек салуны үз кулына алырга ашыкты. — Андый кеше белән фикердәш булу...

— Бик тә күңелле чагына туры килдегез: дөньякүләм важный ачыш ясады, Парижга симпозиумга җыена.

— Бераз ярдәм итсәгез. — Нажарның хәерсезрәк нәрсә аңлавын чамалап, ачыклык кертергә ашыкты. — Дусларга андый гына ярдәм — әхлак бурычы. Үзегезнең барыбер Парижга ниятегез юк икән бит.

Нажар кунакның нинди бурыч белән монда килеп чыкканын, дөресрәге — җибәрелгәнен тәмам төшенгәч, гаҗәпләнүдән шаяруга күчәрлек көч тапты һәм:

— Сез Мөдирнең дә вәкиле булып чыктыгыз, — дип, дусларча көлеп куйды.

— Сезнең институт абруе хакында бара сүз, житмәсә, Фәнүсәнең дә диссертациясе хакында. Ә Фәнүсә — минем өчен бик якын кеше.

Вәкилнең чыраеннан «Минем белән шаяру җиңел эш түгел ул» дигән җитди мәгънә укырга мөмкин иде. Шунлыктан Нажар:

— Ничек, ничек? — дип түземсез кызыксынуын сиздерми кала алмады.

Вәкил — канәгать. Беренче уңышын баягыдан тәмлерәк чәйни-чәйни, Нажарның түземсезлек дәрәҗәсен сынамак өчен, берара сүз таба алмаган кыяфәт белән утырды. Инде билгеле: нервасының бер генә очына булса да эләккән зәһәрле шикнең нәрсә икәнен ачыкларга тырышып, Нажар сорау бирәчәк һәм Вәкил шуннан соң гына, хәбәрнең бәясен югары тотып кына фикерне өстәлгә салачак һәм анда да түбән бәягә бирмәячәк. Һәм ул көтте. Ләкин Нажар? Нажар исә Вәкилнең сүзен түгел, хәтта үзен дә оныткандай утыра бирде. Хәтта җыр шыңшып куйды: «Агыйделнең аръягында зифа тирәк...»

Ниһаять, Вәкилнең түземе төкәнде. «Күпне өмет итсәң, аздан мәхрүм калуың бар». Шулай да, имештер, сүзсез утыруны килештермичә генә:

— Мин Фәнүсәнең авылдашы, бергә үстек, — дип куйды.

Тик Нажар көнләштерү кебек примитив юл белән үзенә карата кызыксыну уятырга тырышуның файдасыз нәрсә икәнен Вәкилгә тәмам аңлатырга тиеш тапты һәм тәкъдим ителгән көн тәртибенең беренче пунктын гына кабул итте:

— Сез Мөдир хакында, Мөдир хакында сөйләгез. Сез бит — аның вәкиле.

— Әгәр сез аларны иң кыен чакларында ташласагыз...

— Менә шулай, шәп. Ә сез карта бутаган булып утырасыз. Белеп торыгыз. Дон Жуан ролен уйнау өчен сезнең кыяфәтегез, материалыгыз җитешми.

Катырак килеп чыкты бугай, Вәкил үпкәләгәндәй читкәрәк тартылды да тынып калды. Димәк, уен хәзер эстрадага күчә: анда яшь кенә җырчы кыз гыжылдаган төслерәк, дөресрәге, Эдит Пиаф манерасында, ләкин заманча үзенчәлекле тавыш белән җыр башлый:

Синнән күпне өмет итмим,
Син миңа елмай гына.
Антлар бирмә, бир син миңа
Очрашырга җай гына.

Куплетның икенче яртысыннан җырга Нажар да кушылды. Теләге уенны үзе тиеш тапкан юнәлешкә бору иде, чынлап уйнарга, ләкин Вәкилгә Фәнүсә мәнфәгатен яклау кебек җайлы поза алырга мөмкинлек бирмәскә, Мөдирнең әшнәсе амплуасында гына калу шикелле яман эш кенә бирергә, ваклыкны затлылык белән алыштырырга ирек куймаска кирәк тапты. Сүзнең башка нәрсәгә күчүенә караганда, ул монә ирешә дә булса кирәк. Әйтик, менә шул: җыр тукталган һәм музыканы инструменталь ансамбль үзе генә дәвам иткән урында Вәкил Нажар кәефенә яңа ачкыч ятратырга тырышып якын килде:

— Кара, шәп җырлыйсың икән бит, тавышың — ефәк тенор. Фәнүсә белән сезне җыр түгәрәгендә танышкан дип сөйләүләре дә хак, алайса?

— Хәтердә калмаган инде.

— Сәхнә зәвыгын да беләсез дигәннәр иде.

— Онытылды инде.

— Ә мин хәтерлим — Фәнүсәнең дә тавышы бәләкәй чакта ук искиткеч шәп иде. Әйдә, аның хөрмәтенә.

Эчтеләр. Ризык капкалаганда җыр көчәя төште.

Таудай байлыклар сорамыйм,
Тик вакыт бир чак кына.
Сал учыма якты сүзләр,
Мин тотармын сак кына.
Аска карап узып китмә,
Бераз гына көт кенә.
Яратырга син мизгел бир,
Син тормыш бир чүт кенә.

Ләкин җыр да, аракы да Нажарның кәефен күтәрә алмады. Монда ни өчен килгәнен хәтергә төшереп ул:

— Ә Мөдир килмәде, тәки алдады! — дип куйды.

Әлбәттә, аның болай исерегрәк кыяфәткә керүе Вәкилне шатландырды шикелле. Анысы елмаеп ук әйтте:

— Ир кеше Мөдирне уйлап утыра. Җаным, яшәп калыйк, җыр шулай куша бит, әнә нинди тормыш җырлап йөри! Тиле! — шунда ул тагын эчемлек өстәде. — Әйдә, туктаусыз яшәү өчен!

Җырга кушып бераз тагын аракы капкач күңеллерәк булып китте.

Яшәргәме, әллә юкмы —
Хәл итәрбез үзебез.
Үбешик бер, аннан инде
Нишләргә без белербез.

Җырчының кыланышлары табигый рәвештә тәнец ритмына күчүгә, Вәкил кызны танцыга чакырырга җөрьәт итмәсенме! Менә, ичмасам,

егет! Әнә кара, көлешә-көлешә сөйләшәләр. Нажар исә мондыйны хыялына да китерә алмый. Һәм аның урыны монда түгел дә.

Нажарның өстәлдә акча калдырып китәргә җыенуын сизгәч, кыз белән бергәләп килгән Вәкил аны кочаклап ук алды:

— Ягез, танышыгыз әле зинһар, — дип, кызга Нажарны тәкъдим итте. Бу — безнең кадерле кунагыбыз, Үзбәкстаннан килгән атаклы җырчы — Таһир Закиров!

— О, Таһир Закиров! Нинди көтелмәгән бәхет, карагыз, ә! Бер генә җыр булса да җырлап китәрсез инде болай булгач! — Кыз шул чаклы сөенде ки, хәтта кулларын чәбәкләп куйды.

Димәк, спектакльнең икенче, кызыклырак өлеше башланды. «Сынатма» дигәнне Әпә төслерәк ишарә белән аңлатып Вәкил күз кыскач, Нажар баш рольнең үзенә тапшырылганын аңлады һәм аннан баш тарту өчен хәмер дигәннең микрограммы да булмаска тиеш икәнен генә уйлый алмады шикелле. Җитмәсә, аның чак кына калган икеләнүен дә җиңеп, Вәкил ашыктырды:

— Җырлый ул, җырлый. Шулай бит, Таһир дустым? — Тагын ишарәләр.

— Ничек? — Тагын да сөенечлерәк ишарәләр күреп, тәмам буйсынды Нажар. — Әһә, шулай, тик бераз соңрак.

Кызга шушы кадәресе дә җитеп тора — кояштай балкый, сөенә балакай.

— Менә рәхмәт, гомер буе мактанып сөйләрлек вакыйга булачак.

Кыз шунда инде Нажарны танцыга чакыргач (кара син — бер дә кул җитмәс хыял түгел икән ләбаса!), уңайсызланып кына булса да, нярә китте Нажар. Оркестр куәтле дөбердәү сәбәпле, әллә ни гәп кора алмасалар да, дөнья инде шактый күңеллегә әйләнгән иде. Хәлне тагын да матурлау нияте белән Вәкил, аларга карап сөенә-сөенә, рюмкаларга тагын эчемлек салып, биюче массаны ера-ера, болар янына килеп җитте. Ресторанда гүяки ул хуҗа, мәйдан — аныкы, җиңүче — ул, яшь, бөтен килеш-килбәте белән кычкыра: «Яратырга син мизгел бир, син тормыш бир чүт кенә!» Кочагына сыймаган зур тормышта йөзә, колачлый-колачлый йөзә, бу — аның стихиясе!

— Рәхим ит, җырчы бала, рәхим ит, Таһир Закиров, менә башта гына ачырак тоелган матур тормыш сезгә!

Мондый танышу, мондый уйнаулар сирәк, бик сирәк килеп чыга — кадерен бел, ни булса шул — Нажар көлә. Чәкешәләр, көләләр. Нажар да көлә. Бу кадәр тугарыла, мавыга, бәйрәм итә алуын ул үзе дә әле генә белә икән, мондый очракны бүтән хәтерли алмый, юк, мондый да кызыклы уенның булганы юк аның гел фән белән узган җитди тормышында. Кеше кайчакта менә шушылай сүтелеп алса ни гөнаһ? Менә, ичмасам — ял! Музыкалы, җырлы ял! Биюле ял!

Музыкалы, җырлы, биюле шау-шуда мәгънәле җөмләләр ишетелми, әлбәттә. Кичнең бөтен эчтәлеге — көтелмәгән шатлык биюе, бәхет азгынлыгы. Адәм баласы өчен болар оятмыни?

Кызга яңадан эстрадага менәргә кирәк икән — ул шунда ашыга. Вәкил Нажарга «Чибәрне ычкындырдык, ахры» дип өлгергәнче, кыз яңадан йөгереп үк диярлек килеп җитә һәм бу юлы, микрофон тоткан килеш, җырлый-җырлый атлый. Нажар: «Ә Мөдир тәки алдады, килмәде!» дип уфтанып өлгергәнче (тиле — нинди вакытта), Вәкил дус аны үз канатына сыендыра:

— Хөрмәтле Таһир Закиров, исермик. Киресенчә, барлык яман нәрсәләргә үч итеп кенә булса да, чүт-чүт кенә булса да, яшәп калырга кирәк безгә. — Кыз килеп җитүгә аның рюмкалары әзер, — юк, бирешми Вәкил.

— Эчәбез, тик бер шарт белән, — дип кенә булса да Нажар аңа тагын буйсына.

—Нинди шарт? Теләсәң, чәкешергә ходайның үзен алып киләм, әйт, боер! — Шул рәвешле буйсынып буйсындыра Вәкил.

— Сөекле туташ безгә җыр белән хәерле юл тели. Булдымы?

— Нишлибез? — Кызга Вәкил шикле үк мәгънә белән ялагайланып карый. — Таһир Закиров үзе сорый бит.

Тик кыз катгый.

— Юк, юк, хәзер инде үзегезне сорыйбыз. Хәзер игълан итәм, — ди ул ярым пышылдап.

Нажарны исә куркудан акыра дияргә мөмкин:

— Что сез, булмый!

Әмма җырчы кыз сүзсез генә «Зал ишетә бит» дигәнне аңлата да микрофонга белдерү әйтеп ташлый:

— Хөрмәтле иптәшләр, сезнең өчен бүген бездә күңелле сюрприз бар — көтелмәгән бүләк. Безнең янда кояшлы Үзбәкстаннан килгән атаклы җырчы Таһир Закиров утыра.— Кул чабулар шаулап алгач, кыз төгәлләп тә куя. — Сорап карыйк, дуслар, бәлки ул безгә бер генә булса да җыр башкарып күрсәтер!

Хәзер инде вакыйганы тыеп, туктатып кара! Бер генә юл: уен арбасыннан имгәнми генә сикер! Юк, шактый ук җайсыз хәл: «Тамагым авырта» дигәнне аңлатып Нажар җырдан баш тартмакчы иде, кыз исә: «Игълан ителгәч, ничек инде җырламый каласың, халык көтә бит» дигәнне белдереп, күзләре белән генә түгел, бөтен гәүдәсе белән, еларга җитешеп ялвара. Ахырда тезләнеп үк сорарга җиткәч, Нажар нишләсен — аны тотып кала да, микрофонны үз кулына ала. Һәм ярыйсы ук кыю рәвештә (кыюлыкны да уйнарга мөмкин икән ләбаса!) мәҗлескә сүз куша:

— Юлда бераз салкын тигән иде. Тамак авырый, җыр әйбәт чыкмаса, гафу итәрсез! — дип тыйнаклык белдерә. «Гафу, гафу!» дигән тавышлардан соң тагын бер кыю белдерү ташлый. — Шәһәрегезгә килгән көнне үк миңа бер кызык җыр бүләк иттеләр. Шуны җырлап күрсәтмәкче булам. Исеме — «Качып калма».

Залдан «Беләбез, беләбез!» дигән тавышлар ишетелгәч, ниһаять, төп рольне чынлап та кабул итүдән башка чара калмый.

Оркестр үзенең бөтен тимер һәм җиз тавышлары белән котырып үз эшенә күчә дә, тиеш урында, җырчыга кушылырга җай өчен кинәт пианога, экрен тавышка күчә, тик, Нажар өлгерә алмаганлыктан, керешне кабатларга мәҗбүр була. Сологa чират тагын җиткәч, инде кызның ым-кагуыннан башка да чамалап, ниһаять, Нажар җыр башлый — рәхим итегез, ышансын колакларыгыз. Һәм ышана колаклар, күзләр дә шикләнми — олы рәхмәт һәм ләззәт галәмәтләре сибеп ялкынлана мәҗлестә утырган дистәләрчә әһелләрнең мәхәббәтле күзләре.

Беренче куплетның яртысын гына бүлмә эчендә җырлагач та, кыз ишарәләрен тыңлаудан, үз йөрәгенең кушуы — юк, алай гынамы — үзенең җиңел җилкәләренә гүя куәтле канатлар үсеп чыкканын тоеп, залга чыкты солист, ә җырчы кыз үз тамагын күрсәтеп: «Тавышыгыз — во, кыюрак!» — дигәнне белгерткәннән соң эстрадага ук җилпенеп күтәрелде. Әнә ул — солист, атаклы җырчы!

Агыйделнең аръягында — зифа тирәк,
Тирәкләрнең тирәсендә оча үрдәк.
Үрдәкләргә карый-карый киттем алыс.
Бер кыз калды әллә качып, әллә ялгыш.
Баш очымнан очып узды шаян үрдәк:
Җилкән дигән ак ефәккә җилләр кирәк.
Матур кызга бүләк өчен җитми күлмәк,
Җил-ефәктән йомшак назлы телләр кирәк.

Нажар жырны тәгәлләр алдыннан шул чаклы мавыкты ки, үзен ни өчендер сурәткә төшереп алуларын да аң белән түгел, тойгы белән генә хәтеренә сала алды. Жыр беткәч, кул чабулар вакытында гына күңелендә курку кузгалды: «Иртәгә авыз киереп газета битеннән оятсыз карап торсаң?» Кызганычка каршы, ялгышмады диярлек.

Ә хәзер, хәзер...

Тупасрак булса да, чынын әйтик: Вәкил буылып-буылып көлә, сыгылып-бөгелеп куя, тик кычкырырга да хәл таба:

— Менә, ичмасам, тавыш! Ә син салкын тигән дип күпме халыкны бәйрәмнән мәхрүм итмәкче идең!

Кызганычка каршы, Нажар аны аңлый...

Жырчы кыз да халыкка ымлап:

— Жырласагыз, таңга кадәр тыңларга әзерләр, — ди дә, Нажарның кулларын ихлас дулкынланып, каты-каты итеп кыса. — Молодцы, поздравляю, рәхмәт — монысы инде алдаусыз бәйрәм.

Солист, әлбәттә, тыйнак — мактаулардан эреп акмый, төз тора. Ләкин сәхнәгә яңадан чыкмый. Сәбәп, әлеге дә баягы — салкын тию, тамак чире...

Шау-шу тынгач, мәҗлес көйле генә дәвам иткәндә, ниһаять, Мөдир күренде. Нажардан башкалар — ягъни кыз да, Вәкил дә аны аягүрә басып каршыладылар. Гадәттәге хәерле кич теләүләрдән соң — тагын көлешү, тагын шаяру, кызык, күңелле. Тик Нажарның инде исәбе уеннан чыгу иде. Һәм ул житди кыяфәткә керде, әмма моның белән генә максатына ирешмәгән булып чыкты.

— Я, ничек безнең эшләр? — дип, Мөдир бүлмәне елмаюы белән тутырды.

Вәкил бу сорауны көткән иде булса кирәк. Шунда ук:

— Эшләр безнең идеальный! — дип кычкырып әйтте дә рәхәтләнеп тагын бер көлде. — Менә ничек — во!

Мөдир дә үз чиратында:

— Молодцы! — дип, кемнедер мактап куйды һәм берара сүзсез генә ризык капкалагач, тантаналы рәвештә мактана төште.— Без әле Директор белән сөйләшеп утырдык. Мин дә сезгә әйбәт яңалык алып килдем бит.

— Ничек соң анда? — Вәкил күтәргән рюмкасын кире куйды.

— Бөтенесе — көтелгәнчә. Атна-ун көн эчендә приказ булачак: безнең лабораториядә бер кеше арта, Нажар, ишетәсеңме? Ул кеше — безнең каршыбызда.

Нажар үзенең шактый авырайган башын күтәреп:

— Шушы чибәр кызмы? — дип елмаерга тырышса да, әллә нигә елмаюы чырай сытугарак тартым иде.

— Шушы чибәр егет! — Мөдир Вәкилнең аркасыннан кагып куйды.— Әйдәгез, булачак коллегабыз хөрмәтенә!

Рюмкалар, әлбәттә, күтәрелде һәм бәллүр чыңы да ишетелмәде түгел — барысы да булды. Ләкин Нажарның кәефе күтәрелмәде, киресенчә, кайчан да булса ватыласы шушы пыялалар төсле кырылып кына төште. Исергәндәй иелеп, ул куллары белән күзләрен каплады. «Болай булгач, уенны туктату мөмкин дә булмаячак икән. Бу хәтле үк шаулы, жырлы, бнюле булмас та бәлки, ләкин көлке белән... көлке белән алагаем тәэмин ителгән булыр...»

*

* *

Атна да узмагандыр, якты бер иртәдә уянгач та, кояш төсле үк ап-ачык булып, көлкеле һәм шау-шулы тамашаның фажигане хәтерләтә башлаганы йөзгә бәрелде. Ләкин бу яңалык Мөдиргә бөтенләй кагылмый узды — аның өчен бәйрәм күңелле килеш калды.

Мөдирнең чырае ягымлы, адымнары нык. Бөтен институтны бер итеп йөри. Тавышы гадәттәгедән дә калынрак һәм көчлерәк иде:

— Хәерле көн, бала!

Секретарь кызның мондый кызык вакыйгалы чакта чиксез бәхет, ләззәт кичерә торган гадәте барлыгын Мөдирне күргәч тә сикереп торуыннан һәм машинкасына күз дә салмыйча текәлеп катуыннан (әлбәттә, иркә елмайган хәлдә!) ап-ачык итеп, тагын бер тапкыр күрергә мөмкин иде. Бу чибәргә дөньядан бер генә нәрсә таләп итәлә — кызык вакыйга. Сүз куертырга сәбәп булмаса, өстең никадәр бөтен, тамагың ничаклы гына тук булмасын, хаят — сүлпән, ипи — тозсыз. Адәм баласы ипи белән генә тук була алмый дигән фәлсәфә — тулысынча аңыкы...

Кыз үзенең гөнаһсыз күзләрен мөмкин кадәр киңрәк ачып сорау бирде дә шул хәлдә җавап та көтте:

— Табылмадымы? — Тик Мөдир аңламагандай торгач, бераз ачыклык кертергә тиеш булды. — Анонимканың авторын әйтәм, кем икән?

Мөдир абыйсы нишләптер җитди кыяфәткә керде.

— Ташта елан эзе каламы! — дип, «өметсез эш» дигәндәй кул селтәде.

«Уйный чукынган: үзенә ихлас ихтирам белән караган әшнә дәрәҗәсендәге дустына да ышанып җитми һәм бу бала кайбер нечкәлекләрне аңламый дип уйлый. Ә бала дигәнең ничек сулыш алуыңа чаклы дөрес сизә, шунлыктан ул нечкә генә итеп төрттереп тә куя белә».

— Вакытын белеп кенә бит, ә, — ди кыз, чырай балкышын һич киметмичә.— Бар бит оста кешеләр, ә?! Әй, кызык та бит, ә!

— Яла ягучы мондый чакта оттырмый, чөнки саф кеше битенә гайбәтнең күләгәсе барыбер йогып кала. Юк-бар хат аркасында Нажар абыеңның бик җайсыз ситуациягә кабуы бар. Бөтен кызыгы — шул гына, балакаем.

— Ә менә сезнең йөзегезгә бернинди күләгә йокмас иде. Сез һәр төрле шикләнүләрдән югары торасыз. — Шулай диде кыз, нигәдер ачыктан-ачык ялагайланып.

— Рәхмәт.

— Кызык та инде — тыңлап кына карагыз әле.

Өстәл астыннан язу чыгарды да укырга кереште. «Узган шимбәдә сезнең институтның өлкән хезмәткәре иптәш...»

Рәхәтләнеп көлү өчен укуыннан тукталып торды кыз.

— Апакайгынам, монда Нажар абыйның атасының исеменә хәтле хатасыз язылган. Ну грамотный да кеше кулына эләккән. Приложение — Нажар абыйның җырлап торгандагы фотосы, сәер кыяфәте. Ярый әле, айныткычка илтеп япмаганнар. Кызык та инде.

— Әгәр дә без аны Вәкил абыең белән култыклап өенә хәтле илтмәсәк, япкан да булырлар иде. Шулай.

— Әй, кызык та!

Секретарь, шушы хатны укыр өчен генә күгеннән төшкән фәрештәдәй җилпенә-җилпенә, тагын укырга кереште: «Җырлап торган солистканы тавышың ямьсез дип, көең кәкре-бөкре дип, эстрададан өстерәп төшерде дә үзе гаять тә борынгы бер көйгә сыер шикелле мөңгерәргә тотынды».

— Әй, җаным, эшли алды микән шул эшне — бигрәк то оялчан кеше бит. Нажар абыйны әйтәм.

— Син нәрсә, әллә чынлап та ышанасыңмы шушы чепухага?

— Ник? Әллә җырламадымы?— Кызның чырай балкышы бермә-бер кимеде, тоныкланды.

— Җырламады.

— Исереп тә буталмадымы?

— Исереп тә буталмады.

— Һи-и-и!

Шушы урында якты чырайдан җилләр исте дию генә ифрат та аз, ә үпкәләүдән иреннәре үк бүлтәйде дисәк, аны балага охшату булыр. Ә бит ул бөтенесен аңлый, хәтта җайсызрак, кәефләре кырылганрак чакларда кызыкны үзе дә уйлап чыгара алуы белән җитәкче абыйларына зур гына булышлык та күрсәтә. Шуңа күрә бу юлы без: яшәүне күркәмләндерә торган кызыкка өмете өзелү арасында кәефе җимерелде дию белән чикләник. Дөресе шул.

— Ә-ә, Директор үзендә, кирәгез,— диде дә ул, Мөдир керәп киткәнче үк машинкасын шакылдатырга тотынды.

Фәнүсә керәп: «Ник чакырды икән?» — дип сорагач та, «Керергә мөмкин» дигәнне ым белән генә аңлатты һәм аннан соң, озак та үтми, Нажар күренгәч тә бик үк ачылмады. Тик күңелле булып чыгу ихтималы булган хәлне тагын бер тикшереп карау өмете кузгалгач, дикъкатеннән мәхрүм дә итмәде. Ник чакырылганын үз максатына ярашлы рәвештә аңлатты:

— Директор урынбасары Мәскәүгә күчә — шуның урынына әйбәт кеше эзлиләр, калын, көчле тавышлы кеше булсын диләр. Сезне дә җырлатып караячак.

— Җырлатып? — Хикмәт, Нажар каушый калды!

Һәм шунда ук эшнең өметсез түгеллеген сизеп алган секретарь кыз шатлыгыннан көлеп тә җибәрде:

— Әһе, солист, солист — син! Сез!

— Ниче-ек?

— Барыгыз, бар, Директор сезне көтә. Әй, кызык та инде.

Җилпенә-җилпенә кыз үз урынына очкан мәлдә, Нажар Директор ишегеннән ачыйм гына дигәндә, авырлык көче җуела торган пространствodaгы шикелле чайкалып, бүлмәдән Фәнүсә чыкты. Күзләрендә — яшь.

— Ни булды?

Монарчы беркайчан да күрелмәгәнчә шашынып, хәтәр бер караш белән тагын чак кына чайкалып торгач, Фәнүсә үксеп тә җибәрде:

— Булды. Бар кит инде Парижыңа! Бар, ризамын диген! Идиот! Адәм көлкесе!

* * *

Директорның чырае-кыяфәтеннән нәрсәгә дә булса өметләндерерлек галәмәтләр сирпелми иде. Киресенчә... Нажарның сәлам бирүенә каршы «утырыгыз» дип кенә куйды да ким дигәндә өч минут эндәшми утыруы белән үзен дә, Нажарны да дәһшәтле бәрелешкә әзерләде. Нажарны түземсезлек газаплый башлады: тик кушылган икән, утыра бир, сабыр гына көт. Ләкин юк, Нажарның сабырлыгы озакка җитмәде.

— Гафу итегез,— диде ул калтыранган тавыш белән,— минем беләсем килә: нишләп Фәнүсә бу бүлмәдән үксеп чыкты?

— Рәнҗетүче без булмадык.— Директорның карашы һәм сүзләреннән күңелгә генә түгел, хәтта тәнгә дә каты салкынлык бәрелгәндәй тоелды.

— Ул моннан чыкты һәм яшь түгә. Минем шуның сәбәбен беләсем килә, гафу итегез.— Салкынлыкка каршы шундый ук җавап. Әйтерсең тигез дәрәҗәдәге кешеләр.

— Дөреслек кайчак ачы була.

— Шул ачы дөреслекне миңа белергә ярамыймыни?

Директор өнсез ачу белән кнопкага баскач, секретарь кыз, керәп, бая үзе укыган хатны һәм рәсемнәрне өстәлгә җәйләп куйды да сокланырлык саф тавышы, дикциясе белән:

— Клуб директоры концерт оештыра алмыйча интегә иде, хәзер сөенер инде,— дип куйды һәм ни буласын, дөресрәге, хәзер килеп чыгачак кызык хәлне үз күзләре белән күрергә өметләнеп бераз көтсә дә, Директорның баш кагуына буйсынып, кабинеттан чыгарга мәҗбүр булды.

Нажар исә үзенең шушы бер-ике минутта ахыргача тар-мар ителәчәгенә эчке бер шомлану белән сизенеп әзерләнде. «Нинди ишарәләр? Ник бөтен кеше миңа мәеткә карагандай карый?»

Директор аны тагын ачулы карашы белән сөзеп алгач, сүзсез генә хат сузды. Нажар каушый-каушый укырга керешсә дә, соңынтын сулышы җиңеләя төште. Имештер, теге көнне ресторанда булган уен шаһите, ниндидер Бәкеров дигән кеше (тикшерә китсәң, андый кеше табылмас та иде әле!) тозлы һәм борычлы хат язып җибәргән. Менә нинди экәмәт икән! Инде директор булып директор спектакльгә катнашамыни?

Нажар хәлнең төбенә тиз генә төшә алмасын белсә дә, болай кешенең бугазыннан ук тотарлык сәбәп юклыгын сиздерү өчен елмаерга тырышып әйтте:

— Һәр җырлаган кеше өстеннән хат яза башласаң...— тик, директорның баягы карашына бәрелеп, тыйлыкты.

Директор вакыйгага үзенчә бәя биреп:

— Җырлавың хак, алайса? — дип турыга ярды.

— Кеше җырламый торамы? Сез үзегез бер дә җырламыйсызмы әллә?

— Кызганычка каршы, көн тәртибендә минем тәртип тормый.

— Җыр — кеше рухының иң изге чыңы, бер дә оят нәрсә түгел ул.

Директор Нажардан һич тә мондый вакыйга булмады дигән җавап көткәнгә күрә, хәтта аптырабрак калды.

— Менә ничек... Төшендек... Һе, оятны ук җуйгач ни...— дип, өстәл аша фоторәсем ыргытты.— Болары да горурланырлык нәрсәме?

Рәсемнәрнең берсендә Нажар авызын киереп ачкан да, әлбәттә, «Качып калма»ны кычкыра, ә икенчесендә өстәл янында изрәп утыра иде. Берсен, залда җырлаган мизгелдә төшереп алганнарын, ул бераз чамалый, ә менә икенчесен... Юк, үтер, хәтерләми. Кайчан, кайда соң әле бу хәтле ямьсез рәвешкә кергәне бар иде аның? Моның чынлыкта булганы юктыр. Шаярыбрак төшелгән сурәткә охшый бу. Шулай булырга тиеш тә.

— Я, сокландыңмы? Я, нәрсә бу?

— Бу, бу...

Сикереп торды Нажар. Торды да яңадан утырды, чигәләрен угалады, ләкин тәгаен фикергә килә алмады. Ярый әле, шушы минутта — гомеренең беренче чиркандыргыч хәтәр мәлендә — үзе соңгы көннәрдә нәфрәт дәрәҗәсендә яратмый башлаган мөдире ярдәм кулын сузды, әйтерсең кислород мендәре бирде. Мөдирнең тыныч һәм калын тавышы ни гаҗәптер Нажарны яклап яңгырады. Максаты нидер, анысын әйтү кыен, әлбәттә. Мөдир — дипломат, сүзнең бер дә үзенә файдасызын сөйләмәс, әмма бераүгә файдалы әйбернең икенче кешегә дә кулай булуы ихтимал түгелмени? Нажарга нәкъ менә шушы сүзләр кирәк тә бит:

— Иптәш директор, минемчә, эшне артык куертмыйча торсак яхшырак булмасмы икән? Ресторанда бәлки ул әле беркемне дә өстерәп төшермәгәндер, бәлки әле җырламагандыр да. Бәлки әле ул: «Мин кояшлы Үзбәкстанның атаклы җырчысы Таһир Закиров булам!» дип бөтен залларга кычкырмагандыр?

Кара инде, бу сүзләрнең күбесен Нажар үзе әйтергә тиеш иде ләбаса! Ялганның ялган икәнен аңлатып, Директорны да, үзен дә тынычландырырга тиеш иде. Ләкин нишләптер Нажарның теле бөтенләй мәгънәсез сүзләр, үзенә зыян гына китерә алган буш сүзләр ыргыта, әйтер-

гә кирәк, үз битенә үзе таш ата. Ә Мөдир? Менә аның көчле ихтыяры кайчан сыналды. Бәлки әле теләкләре, максатлары да моңарчы Нәҗар уйлаганча ук алама түгелдер?

Мөдир лаеклы рәвештә өстәлгә китереп салган дөрес аргументны үз файдасына эшләтү өчен Нәҗар кайнарланып:

— Беркайчан, беркайчан! — дип кычкырып җибәрде... тик тагын каушады, бүтән шәбрәк җөмлә төзи алмады.

— Бәлки, бәлки,— дип уртәлергә үк керешә Директор.— Бәлки әле ул анадан ук тумагандыр? Раслый аласызмы шуны? Нинди дәлилегез бар мине дә ышандыра алырлык? Сездән сорыйбыз, Зәбиров!

— Мин самозванец булып кычкырып йөрмәдем, беркемне өстерәп төшермәдем, ә киресенчә, тезләнергә җитешеп ялваргач кына җырламыйча булдыра алмадым.

Нәҗарның туры сүзләреннән Мөдир ихлас шатланды. Ә иптәшен өчен сөенә белү — әдәп һәм тәрбия билгесе. Әйтерсең Нәҗар аның якын дусты һәм ул аны рәнҗетергә ирек бирми:

— Әнә бит, иптәш директор, ул үзе икенче төрлерәк сөйли ич. Картина ачыклансын өчен бераз көтсәк, бәлки...

— Ә фото? Ул анысын ничек мин түгел дип исбат итә алыр? Моның өчен күпме вакыт кирәк булыр?

— Бәлки ул аның шаярып кына төшкән сурәтедер? Әйтик, сабан туенда, дус-иш арасында уйнаганда?

Директор Мөдирнең акыллы фикере аркасында, креслодан гына түгел, үзенең олпат сабырлыгыннан ук кубып чыкты да кычкырып ук әйтте:

— Шунысын кисәтергә мәҗбүрмен: безнең фәнни институтта штатлар расписаниесе буенча җырчылар да, адвокатлар да каралмаган. Сезгә үз профессияләрегез буенча эш кирәк дисәгез, бүтән җиргә китәргә туры килмәгәе.

— Иптәш директор, Александр Иванович!

Директор, колларын, бармакларын өстән аска суза-суза уйнатып, күкри-күкри, читлектәге аю шикелле йөренә башлады:

— Менә бит ничек килеп чыга. Син кешеләргә ышанасың, алар синең ышанычыңа төкерәләр. Син аларны ил язмышы, бөтен җир язмышы хакында кайгырта алырлык олы галимнәр һәм шәхесләр булып җитешсен өчен ут йотасың. Ә алар? Алар...

Артык кызып китмәгәем дип курыккандай, Директор тиз генә урынына барып утырды. Бу хәтле кайнау үзенә дә ошамады шикелле. Тик кайнамый да булмый иде. Җитмәсә, бәлки үз гомерендә беренче тапкыр, Нәҗар да усаллашмакчы булып карады бугай. Ләкин мәкальдәгечә: «Әгәр ходай куянга җәза бирәсе килсә, ул аңа кыюлык бирә», дигән кебек килеп чыкты. Үзенә чираттагы зыянны гына эшләде Нәҗар:

— Үз исемен куярга да курыккан әдәм нәрсә язмас. Сез шуңа ышанасыз, ә күпме бергә эшләгән кешеләрегезнең кем икәнлекләрен белә алмагансыз.

— Менә хәзер ышандырыгыз инде — раслагыз хатның һәм сурәтләрнең ялган икәнен.

Ярый әле, Мөдир бирешмәде. Аннан тагын Нәҗарныкына караганда акыллырак, колакка ятышлырак мәгънәләр чыкты:

— Безнең коллегабыз үз урынында ихтирамга лаеклы кеше булып калыр. Ә аңа яла ягучылар җәзасыз калмас. Минем актык сүзем шул, — диде ул, гәрчә баягы күтәренке тавышы инде бераз кими төшсә дә.

— Төшендек. Хәл ачыклансын өчен, уйланыр өчен сезгә бераз вакыт кирәк.

— Кирәк, иптәш директор.

Мөдир ихтыяры аркасында тынычланган Директор, ниһаять, Нажарга бүтәнчә күзләр белән карады:

— Сез ни әйтәсез?

Нажар холкы буенча йомшак кеше булса да, чынлыкта, үзенә зыян китерүгә калса, шактый ук ботаклы бәндә. Эш көйләнә язганда, тагын килеп эләкте:

— Дөрес аңласам, — дияргә җөрьәт итте ул, — миңа төп эшемне туктатып, гаепсезлегемне исбат итү эшенә тотынырга тәкъдим итеелә.

— Бәлки совмещать итәргә мөмкин булыр? — Директорның күзләрендә тагын ихлас рәнҗеш очкыннары ялтырады.

— Рәхмәт. Тик дөя түгеллегемне исбат итәргә мин бит куян түгел.

— Куян түгел? Ә кем соң?

Мөдир олы осталык белән суда батмый торган мендәр ыргытмаган булса, каршылыкның шәхси конфликтка әйләнү мөкинлеге, ә Нажарның бөтенләй үк бату куркынычы аермачык күренгән иде. Мөдирнең тыныч фикере тискәре тойгыны уңайга әйләндерә алды:

— Әйтәм бит, иптәш директор, борчылмагыз, мин үз работникларымны үзем яклый алырмын. Тәртип урнаштыруны, иптәшләрнең йөзен аклауны үз өстемә алам.

— Карагыз сез, нинди молодец! — Көлеп әйтелдеме, чынлапмы, бу сүзләр кирәк иде. Директор, мәсьәләгә шушы төштә нокта куеп торырга икәнен чамалап, бүтән сүзгә күчте. — Житте. Төшендек. — Бераз гына уйлап торды да нәтиҗә ясады. — Сезгә уйлар өчен тагын бераз вакыт бирелә. Ә хәзер — икенче нәрсә. Тыңлап карыйк.

Директор өстәлнең икенче почмагында яткан бердәнбер газетаны алып, (димәк, алдан ук әзерләп куелган) укырга керешә:

— «Иген басуларында агулы матдәләрнең фаунага зарар китермәвен тәэмин итәр өчен берничә ел буе барган экспериментлар төгәлләнеп килә. Лаборатория мөдире иптәш...» — Фамилиягезне атап тормыйм, үзегез дә онытмагансыздыр. Минем фамилия дә сезгә таныштыр. Һәм бетте. Сезнең фамилиягез монда юк, иптәш Зәбиров, һәм хатыныгызныкы да. Авторлар икәү генә — мин дә Мөдир генә булып чыга. Шушы ике иптәш дөньякүләм әһәмиятле ачыш ясаганнар. Укыйм: «Ачышның мәгънәсе — басуларга кертелә торган химикатлардан кошлар һәм җәнлекләрнең агулануына чик кую». Ары укуның хаҗәте бармы?

Директорның уртәлүе һич кимемәгәнлектән аның бу яңалыкны да баягысыннан күбрәк дип тапмаганлыгы көн кебек ачык күренсә дә, мөдир әйтерсең ки аның шатлыгын уртаклашып елмайды да бу юлы чак кына дулкынлана төшеп:

— Минемчә, аңлашыла,— дип куйды.

— Ни әйтерсез?

— Әлбәттә, бераз җайсызрак килеп чыга — без мировой фигуралар сыманрак тасвирланганбыз.

— Төшендек. Тыйнаклык кешене бизи. Галимне дә. Тагын ни?

Мөдир, бер кул бармакларын икенчесенеке белән йозаклап кушып, баягы фикерен янасына бәйләргә тырышты:

— Әмма мәкалә миндә оптимистик хисне ныгыта: бөтендөнья симпозиумына шушы конкрет тема буенча без сезгә, иптәш Директор, әйбәт кенә доклад язып бирә алыр идек. Әгәр дә үзегез барырга ризалашсагыз. Зәбировның бару-бармавы инде шик астына куелу сәбәпле, иптәш директор...

— Төшендек. Ә сез, иптәш Зәбиров?

Нажардан, инде тәмам ышаныч һәм абруй җуйган кешедән дә, фикер көтеләмени? Юк, көтмәгез. Фикер кирәк булса, сез аны мондый да күцел болгаткыч шартларга куймаган булыр идегез. Шундый нәтиҗә чыгу аркасында, Нажар, Мөдирнең максатын аңласа да, газета-

дагы «ачыш»ка бәя бирмәскә җай эзләбрәк, үз кайгысыннан ычкына алмаган кыяфәттә кала торды. Бәхетенә каршы, җае да чыкты. Нәкъ кирәк мәлендә ишек артыннан кычкырышкан тавышлар ишетелеп, аңа язмыш үзе ярдәмгә килде: ишектән башта каравылчы, аның артыннан секретарь кыз атылып керделәр. Башкалар әрепләшкән, кычкырышкан арада Нажар чынлап та кайбер күзәтүләрне фикергә әйләндереп, үзенчә эшләп утырды:

Менә ни өчен Мөдир аны якларга булган һәм үзенә каратырга тырышкан икән, һич югы — каршы килмәслек дәрәҗәгә китерергә тиеш тапкан. Кыен чакта сине үз канаты астына сыендырган кешегә, чынлап та, хәзер ничек итеп баш калкытырга, усаллык эшләргә мөмкин? Усаллык кадәресен әйтү кыен, әмма Нажар үзенең принципиаль сүзен әйтергә, Мөдирнең яманрак ис килгән ниятләрен Директор ярдәмендә тиз арада җимереп ташларга тиеш — менә хәзер, шушы минутта... Юк, бер-ике минут элек кирәк иде, хәзер хәтта бераз соңрак та инде...

Бу яклап та нәтиҗә күңел күтәрерлек түгел икән, кычкырышны тыңлау хәерлерәк. Әнә секретарь кызга кара, ничек итеп, еларга җитешеп кычкыра бит:

— Карт башыгыз белән шушылай... ничек оят түгел сезгә!

Тегесе дә махы бирә торган түгел — курыкса монда керми дә инде. Үз хокукларын белеп отпор бирә ул:

— Көтеп торырга минем вакытым юк — автобуска өлгерәсем бар. Хуҗалык көтә, хайваннар, кошлар.

— Милиция чакыртыйм микән әллә? Сугыша прямо. Мөгезсез сыердай керде дә китте.

Яшь кыз белән карт ирнең әрепләшүе үзе бер кызык булса да (ә кыз үзенә җайсыз чакта кызыктан көлми икән), озак юанырга туры килмәде — Директорның кырыс карашыннан икесе дә тиз арада шым булдылар.

— Ни бар, агай, ник дөнья җимереп йөрисең?

— Мин түгел, сез җимерәсез дөньяны.

— Ничек итеп?

— Сезнең җәнлекләр бакчасы бармы? Ярдәмче хуҗалык дигәнегез? Шуларның барлыгын беләсезме? Мин шунда каравылчы.

— Ялгыш кергәнсең, агай, җәнлекләр бакчасы монда түгел, — дип, Мөдир директорга ярдәм итмәкче иде, тик ямьсезлекне куерта гына төште.

Каравылчы яңа сикерешкә әзерләнеп:

— Шулаймыни? — диде дә, канатларын җәеп, аны әйтерсең чукырга кереште: — Ярдәмче хуҗалыкта яңа биналар салырга куштыгызмы, куштыгыз. Төзелеш барамы, юкмы, бармаса ник бармый — кызыксындыгызмы? Төзелешегезгә комны-балчыкны елганың элекке җыпкысыннан алалар. Шуны беләсезме? Бөтенегез дә булмаса, кайсыгыз белергә тиеш?

Каравылчы кулларын җыя төште дә Директор каршына килеп, аннан сүз көтте. Ә Директор исә:

— Ком да балчык — ул нинди проблема? — дип сорауга каршы сорау гына бирде.

— Проблемасы шул — елга иске юлына янадан кайтса, бөтен хуҗалыкны, бөтен җәнлекләрне су күмәчәк.

Мөдир өчен бу игълан фантастик хикәяләрдә генә сурәтләнүе мөмкин булган аваз төсле тоелса, Нажар өчен андый ук мәгънәсез кайгы түгел иде. Директор исә Каравылчы күтәреп килгән яңалыкны хәл итү вәкаләтен Мөдиргә тулысынча тапшырды:

— Менә җәнлекләрдән файда күрә торган лаборатория мөдире бу, бөтенесен үзе белергә тиеш, — дип чын дөреслекне әйтте.

Ләкин каравылчыны алай гына ризалаштыру мөмкинме инде?

— Үзегезгә буйсынган кеше сездән күбрәк белгәч,— диде карт ихлас үртәлеп, — ничек итеп... ничек итеп ул сезгә баш бөксен?

— Төшендек, агай кеше.

— Нәрсә төшендегез?

Директорның яклауга мохтаҗлыгын Мөдир, әлбәттә, тиз аңлады һәм Каравылчының авызын япмакчы булып, эшне коры тотты:

— Киләчәккә карата пессимистик карашлар йоктырып йөрмә, — диде дә, бөтен начальниклык хокукыннан файдаланып, әңгәмәгә нокта куясы итте.— Үзегезгә тапшырылган эшне тыныч кына үти бирегез. Ә башкалар компетенциясенә керерлекләре калсын... Әйе, мин сизеп торам, андый ук хокук та, образование дә юк сездә. Бетте. Шулай.

Каравылчының хәтере калды. Ни дияргә белмичә бераз җәнлекләр бакчасындагы сөекле аюыдай бөтерелеп таптангач, ярдәмгә өметләнебрәктер, Нажарга якын килде:

— И-и, ә-ә, шулай икән алайса. Гыж-гыж курай-тартасың, тал төбендә ятасың. Рәхәт сезнең эшләр. Ә син, Нажар энем, син соң андагы хәл белән бигрәк тә таныш лабаса. Авызыңа су каптыңмы әллә — ник аны ачарга куркасың?

— Минем — үз хәлем хәл, Әмән абый, бүтән кайгылар... — Ул, билгеле инде, хак әйтсә дә Каравылчыны тагын да аптыратыбрак калдырды һәм, ниһаять, абзый тугарылды да:

— Ярый соң... артыгызга су кергәч кузгалырсыз әле, әмма да соң булыр, — дип үрсәләнде.

Директор тиешле кешеләргә, аерым алганда Мөдиргә һәм хуҗалык буенча үзенең урынбасарына бу эш белән шөгыльләнергә кушачакмын дип вәгъдә иткәч кенә, чырае ачыла төште, тик анда да ныграк уйларга кирәген аңлатып, яный-яный чыгып китте.

Болай да бик үк күңелле бармаган әңгәмә бөтенләй таркалды дисәк тә хата булмастыр. Берсен-берсе юатырлык яңа идея берсе дә таба алмаганлыктан, Директор инде чыгып китәргә вакыт икәнен аермачык әйтте:

— Үзегез агайга әйткәнчә, тапшырылганны үтәгез. Юкмы бүтән теләкләр?

Нажар үзенә ягылган ялага каршы яңа сүз өсти алмый. Парижга Мөдирне җибәрү-җибәрмәү хакында әле ныклы фикергә килмәгән, хәзер үк унай тәкъдим кертсәң, Мөдир шатланыр, дуслык тиз арада яңарыр булса да, өйдә Фәнүсәнең ничек каршылаячагын белми. Хәлбуки, Мөдир әнә көтә — Нажарга ялварып дигәндәй карый һәм өмете аклан-магач, сүзне үз адресына кайтармакчы була:

— Мин үз теләгемне әйттем, хәзер сездән...

Гүяки, төп теләге, омтылышының әле күңелендә генә ятканын белмиләр... Беләләр шул, Нажар да белә, Директор да белә:

— Хәзер инде бераз уйларга вакытны миңа бирүегезне үтенәм. Төшендек.

Шулай итеп — бетте, теләгән уңыш беркемгә дә килмәде. Икәүләп секретарь кыз бүлмәсенә чыктылар. Бая пырылдап чыгып китсә дә, ирләр бәлки нинди дә булса уңайлырак фикергә килмәсләрме дип өметләнгәндерме, Фәнүсә яңадан килгән һәм, ирләр чыкканчы ике хатын-кыз арасында менә нинди бәрелеш булып алган иде. Ачуың ничек килмәсен, нәрсә әйтте бит секретарь кыз, нинди эшкә тыгылмакчы:

— Директорга кер дә әйт бер матур сүз! — дип акыл бирә.

— Сүз! Кемгә хаҗәт минем сүз! — Гаҗәпләнми нишлисең.

— Мөдир белән уртак темагыз буенча доклад әзерләсәң, Парижга Мөдирне җибәрик дисәң, ачышка синең фамилияң дә өстәлер иде, мөгаен.

— Иремнең юлын бикләп?

— Үз юлын ул бикләде бит инде.

Фәнүсәнең гаҗәпләнүе шикләнүгә, аннары ачуга ук әйләнеп, кайнап та чыга:

— Слушай, бала,— ди ул күзләрен чебешкә алгасынган карчыга шикелләрәк зур ачып һәм гүяки булачак корбанының бөтен барлыгын шул кискен карашына сыйдырып, — сиңа бу чаклы да нечкә тактиканы кем... кем... Мөдир өйрәттеме? Ул инде сине дә хезмәт иттерәме?

Секретарь кызның гаепсез күзләре исә гел изгелек кенә сирпи, үпкәләү, рәнҗүнең әсәре дә чагылмый анда.

— Ник? Начармыни? Синең исем дә Парижда яңгыраса? Ишетәсеңме, Европаның нәкъ түрендә. Тыңлап кына кара: нинди горур яшетелә — Фәнүсә Зәбирова! Юк, болай: синьора Зәбирова! Юк, менә ничек: мадам Зәбироуа! — Бер нинди каручанлык күрсәтмичә, дусларча киңәш бирә сабый дигәнең.

Ләкин гөнаһсыз иреннәрнең артык та принципиаль мәгънәләр лепелдәве Фәнүсәгә баягынак Директор бүлмәсендә килеп чыккан бәрелештән дә авыррак тәэсир итте. Шунлыктан Фәнүсә Директорга, Мөдиргә һәм Наҗарга булган бөтен ачуын-үрталуен берьюлы шушы бала өстенә сипте:

— Мин синең кем белән нинди мөнәсәбәттә икәнеңне яхшы беләм. Тик бу бәйләнеш-буталышларың сиңа минем белән җитәкчелек итәргә хокук бирми. Шуны белеп яшә, балакаем.

— Ә син ревнуешьмы әллә? Менә кызык.

— Бик каты көнләшәм.

— Подумаешь, горур, күрербез әле сине дә.

Наҗар белән Мөдир алар янына шушындый мәгънәсез, җайсыз мәлдә чыктылар. Наҗарның кәефе ниндирәк икәнен аның соравыннан ук сизәргә мөмкин иде.

— Ә-ә, син китмәдеңмени әле? — дип сорады ул шушыннан да мөһимрәк проблема тапмагандай.

— Киттем.

Тагын Наҗар бер сүз әйтсә, хатыны аның битләренә тырнакларын батырыр сыман ук иде. Наҗарның бәхетенә каршы, тагын аңа Мөдир ярдәмгә килде — Фәнүсә каршына бернинди каршылык булмаган һәм булмаячак та сыманрак вакыттагыча, чын ихтирам белән килеп басты да менә нинди мөһим эш йөкләде:

— Фәнүсә Кадыйровна, сезгә үзегезнең диссертация темасы буенча доклад әзерләргә кирәк.

Янып чыгарга әзер булган Фәнүсә кинәт гөлт итеп яктырып китте:

— Ничек? Парижгамы?!

— Караламаны миңа бирерсез.

— Парижга, Парижга дим мин — кем бара?!

Фәнүсәнең мондый ук кыю дәгъва кылырга оятсызлыгы да, фантазиясе дә җитәр дип башына китермәгән Мөдир үзе ук телдән калды. Киләчәк тынычлыгы хакына, Мөдир белән дуслыкны саклау, сөекле ир тилелегеннән үзенең комга корылган диссертациясен коткару бәясенә берсүзсез ризалашыр дип фараз иткәнлектән иде бу каушау. Шулай, нәфеснең чиге юк. Һәркем — үзе өчен королева! Беркем дә үзен пешка итеп күз алдына китерми, китерсә дә моны вакытлы гаделсезлек дип исәпли. Һәр пешка королевага чыгарга, тактаның икенче ягына омтыла. Мәңге гаҗәп, мәңге кызык омтылыш!

— Әй кызык та инде! — дип юкка гынамыни хихылдый секретарь кыз!

Аптыраштан, бүтән акыллырак шөгыль тапмаганлыктан, Мөдир секретарь кыз өстәлендәге кагазьләрне машиналь төстә, аңсыз рәвештә генә тоткалап, актарып торгач, капыл гына Наҗарга борылды:

— Ә сез, иптәш Зәбиров, шушы минуттан башлап, экспериментны бүтән объектка... әйе, бавырга күчерерсез.

— Бавырга... Бавырга?!

— Парижга дим, Парижга кем бара?!

— Хәзер үк эшкә тотынасыз. Бетте. Шулай.

Мөдир чыгып та китмәкче иде, тик телефон шалтырагач һәм секретарь кызның аңа ымлаганрак карашын күргәч, сискәнгәндәй итте дә туктап калды, чөнки гәп башлангандагы формаль сүзләрдән соң, секретарь кыз җитди кыяфәткә керде.

— Кемнәр? Өчесе дә монда, кайсын бирим? — Фәнүсәгә ымлады. Лаборантыгыз шалтырата.

Трубка — Фәнүсә кулында.

— Әйе. Ниче-ек? Ничек инде ул ү-үлде? — Трубканы куйды да Фәнүсә кычкырып җибәрде.— Кош агуланган! Үлгән!

Мөдир моның белән риза түгел, ул да каушап кычкырды:

— Мөмкин түгел, бу исключено!

— Әй, кызык та инде — диде Фәнүсә секретарь кыз репертуарыннан файдаланып һәм шашып көлде.— Менә болай булгач китәбез инде Парижга! Кайсыбыз бара? Я, кычкырышыйк, шайкалар оештырыйк. Җиңүчегә — хәерле юл!

*

* *

Уйлый Нажар, хәтерли һәм үз уйларын Фәнүсә тавышы сыман итеп ишетә. Әйтерсең ераклыклар һәм вакыт аша үзгәреп кайта тавыш:

... Үзең юкта, ни өчендер, мин сине күбрәк шундый кыяфәттә күз алдына китерәм: берәр төрле җайсызлык килеп чыктымы, син лаборатория янындагы ял итү бүлмәсендә, пианинода бәлки үзеңә дә аңлашылып җитми торган көйләр җыеп утырасың. Мөдир безне төп эшебездән аергач, көн буе диярлек шул бүлмәдә утырдың, ә мин кирәк саен кереп йөрдем...

Нажар, үзенә Фәнүсә күзләре белән карап, якында гына торган, ләкин инде артта калган көннәренә бәя бирә: һәр нәрсәгә үз хакын һәм үз исемен... Көннәрнең шул иң хәерсезләренең берсендә, елар урында җырламакчы булып утыра иде Нажар:

Ачыш — әй, сәер кош:
Куллар сузып үзен куа йөргәннәрне
Адаштыра кача-кача.

Ләкин бу мәлдә кошның инде очар-качар рәте калмаган иде шул. Фәнүсә аны, үлгән кошны, Нажар күтәрелеп тә карамаганга, ахрысы, пианиноның клавиатурасына ук китереп куйды:

— Менә шул. Ә Мөдир аны үлмәскә тиеш ди.

— Тәүфыйксыз кош, начальство сүзен тыңламыйча, рөхсәтсез-нисез үлгән дә киткән! — Нинди вакытта шаяра бит Нажар, әллә юләррәк инде?

— Шулай да... Хәзер нишләргә соң?

— Бераз булса да тынычланып, уйлап карыйк. Бәлки табигатькә каршы бару ихтыяр билгесе түгелдер? Менә шушылай, утыр, башта йөзгә хәтле сана, аннан уйла.

— Утырдым. Саныйм — бер, ике, өч... Мин — сәламәт, мин тыныч, сәламәт, тыныч, тыныч...

— Агу үз гамәлен борынгыча ук башкара килсә дә, без исән — карашлар гына, фикерләр генә үзгәрде, ныгыды, баеды.

— Шул булыр иде Мөдирнең дә, минем дә хурлыклы җиңелүем. Юк, безгә ачышсыз калырга ярамый. Юк, юк, кош терелергә тиеш. Мин исән, мин тыныч...

— Куркынычны юк дип исәпләү — батырлыктан түгел, киресенчә, куркаклыктан килә.
— Мин исән, мин тыныч...
— Юк, сине һәлакәт көтә, тайпылып кал, тайпылып! Яки күзләреңне ач!
Ләкин Фәнүсәнең уй-холкы гомергә шундый иде һәм шул көенчә кала бирә: үзе ышанган, шулай булырга тиеш дип тапкан идеясе нинди генә фактлар-үзгәрешләр белән кире кагылса да, ул барыбер яңа нәтиҗәгә килә алмый, могҗиза көтсә көтә, тик яраткан догмасын ычкындырмый — өреккән тулпарга ябыша да чытырдатып күзен йома, теләсә кая илтеп атсын...
Хәзер ул агу көченә буйсынмаска тырышып тыпырчына: кош терелергә тиеш! Югыйсә, дөньякүләм әһәмиятле гүзәл ачыштан колак кагачак! Аның белән бергә — Мөдир...
Мөдир дә керә-керүгә: «Могҗизага кагылмадыгызмы, хәрап итмәдегезме?» дигәндәйрәк кыяфәт белән карангалады да шундый ук өметсез сорау ташлады:
— Я, ничек?
Нажар аңа игътибар итмәгәнлектән, Фәнүсә җавап урынына кош үләксәсен сузды:
— Менә.
Мөдир, әлбәттә, җирәнүле нәфрәтләнеп, кул аркасы белән кошны читкә этәрде:
— Рәхмәт. Ә нәрсә тәкъдим итәсез?
Эшкә башлау мөмкинлеге тугач, Нажар башын күтәрде:
— Кичәге газетаны кәфен итеп, җеназа укырга һәм ялган өметне таптый-таптый күмәргә. Аннары тыныч кына тыйнак күзәтүләрне дәвам итәргә. Тагын ни көтәсез?
Мөдирнең исә чәчләре үрә торды:
— Ә кем укый коръән? Син? Бер тиен дә сәдака әләкмәс дип куркам. — Фәнүсә аңа җавапсыз баш игәч, тагын да кырысрак тавыш белән әмер бирде. — Фикер дә, тәкъдим дә — мин әйткәнчә: тикшерүләрне хәзер үк бавырга күчерәсез. Эксперимент вакытлыча тукталып тора.
— Ә план? Ә доклад?
— Анысы — минем кайгы.
Ә Фәнүсәнең — үз кайгысы:
— Аңладым: кош — исән һәм... Парижга — сез!
Мөдир аңа күз дә атмыйча чыгып киткәч, акылдан язган кеше төслерәк кая атларга белмичә торганнан соң, Фәнүсә, бер үк сүзне тәкрарлый-тәкрарлый, тагын лабораториягә атлыкты. Нажар үз рәнҗеше белән икәүдән-икәү генә калды.
Нажар нык белә: аннан эксперимент инде төгәлләнде, нәтиҗә уңай дигән йомгаклау көтәләр. Аннары — атылмаган аю тиресен бүлешү, шөһрәт, Париж, диссертация... Күпме тантаналар!
Соныннан ачышның ялган икәнлеге тормышта мең кош һәм җәнлекләр үлеме аша фаш ителгәч, бөтенләй бүтән кешеләр, ихтимал, бөтенләй бүтән институт кешеләре яңадан бөтен бер лабораториягә гаять зур эш хакы түли-түли, әле Нажар әйткән нәтиҗәне кабатлар микән-ни?! Боларга һич нинди зыян килмәячәк, чөнки алар инде ул вакытта кул җитмәс биеклектә булачаклар, юк, алай гына да түгел, агулы химикатларны басуларга күпләп чыгаруга фатиха бирүче сыйфатын аңа күчереп, Нажарны фаш итәчәкләр! Мөгаен, мөгаен, шулай булачак!
Теге хәерсез төндә рестораннан кайтышлый исергән атлы булып кылланган Мөдир: «Ник әле син, әллә кем булган булып, бөтен халык исеменнән эш йөртәсең? Подумаешь, вөҗдан корбаны! — дип юкка гынамыни Нажарны кочаклап алган иде? — Сиңа ни кирәк — бөтенесен

ал, тик миңа аз булса да тормыш калдыр!» дип тә өстәгән иде Мөдир. Юкка гынамыни?

Аңлашылмас нәрсә юк. Нажар аңа ул теләгән тормышны бирә алмады һәм менә ул үзе хәзер чынлап вөждан корбаны. Тик моны беркем белми, яшерен эчтәлек яшерен кала бирә.

Ачыш — әй, сәер кош.
Куллар сузып үзен куа йөргәннәрне
Адаштыра кача-кача.
Түзеп кенә сөйгәннәргә
Бүләк итеп серен ача.
Иңнәргә лә кунып сайрый, әй, сәер кош.

Нажар ул кош артыннан тыны-көне бетеп чапмый, хәтта эзләми дә — көтә генә.... Ләкин күтәрелеп караса, каршында бүтән кош иде.

— Исәнмесез. Кәефләр ничек?

Вәкил кергән икән.

— Кәефләр? Сез теләгәнчә. — Нажарның тагын ничектер күңеле болгангандай булып китте.

— Алайса — шәп! — Шатлыклы елмая Вәкил — күңел төчүе шуннан икән Нажарның. — Фәнүсә белән исәнләшергә килгән идем. Югыйсә, атна буе авылдашны күрмәү әдәпсезлеккә әйләнә башлады. — Нажарның чырае һаман төксе булганга күрә бугай, араны җылытырга чамалап, тагын елмайды. — Атаклы Таһир Закиров! Ышандылар бит тәки, ә? Ну сәләт тә бар икән үзеңдә!

— Хәзер шул рәвешле уйнар өчен Мөдиребезне Парижга җибәрәсез инде, ә? Аңа да ышаначаклар дип уйлыйсызмы?

— Ә мин сезнең тавышыгызга гашыйк булдым. Галим булып әрәм йөрисез икән, дан эчендә йөзәсе урында. Ыһым. Әйе. Ә Фәнүсә? Ул да җырлыймы хәзер дә? Ну элек өздерәдерие. Тавышы гомер буе колак төбемдә яңгырады.

— Тавыш, күзләр тирәнлеге, йөзләр чибәрлеге кебек үк бүтәннәрдән талап та, хәйләләп тә алынмый, ул — табигать бүләге, талант шикелле үк. Тик тора-бара күзләр тоныклана, сүрелә, йөзләр җыерчыклана, ә тавыш... тавыш карлыга, дус кеше. — Шулай дигәч, Нажар пианино капкачын япты да бер кулын шунда куеп, икенчесе белән чигәсен угалады. — Каһәр суккан ангина — бу заманда ашый гына бит бугазны һәм бугазга гомумән эш күп.

— Фәнүсә тавышы... Беттемени Фәнүсәнең тавышы?

— Аныкы бар, минеке бетте.

— Һаман җитми комплимент, ә?..

Вәкил янә нидер өстәмәкче булса да, ишеккә текәлеп туктап калды. Анда пыяла савытлар күтәргән Фәнүсә күренде дә, никтер, ул да аптырабрак калды. Өчесе дә берара уңайсызланып тордылар. Фәнүсә Вәкилне танырга азаплана иде, әлбәттә. Тик таный алмаганлыктан, Нажар аңа ярдәмгә киләсе итте.

— Ышан, күзләрең дөрес күрә, бу кеше — синең яшьлек хатирәң, тавышыңны сагынып килгән.

Вәкил кыюлык күрсәтергә һәм гадәтенчә матур гына елмаерга тырышып:

— Я, курешикме соң? — дигәч, бүтән чара калмагандай гына итеп, Фәнүсә дә:

— Күрешик соң,— диде. Тик исәнләшкәч тә Нажарга борылды.— Мин анда тикшереп караган идем — элементар агулану. Инде яраклашты дигәндә генә...

— Агуга җайлашу җиңел түгел шул.

Вәкил ир белән хатынның ни өчен кәефсез икәнен, әлбәттә, тиз төшенде һәм үзе дә борчылырга кирәк тапты:

— Агуланган дисезме? Безнең химикаттан түгелдер бит? — Фәнүсә уңай мәгънәдә баш каккач, уфтанып ук куйды. — Без исә ул химикатны күбәйтү өчен махсус автомат цех оештырдык тагы.

Хәбәр Нажар өчен яңалык түгел иде, чөнки Мөдирнең үз ачышы, дөресрәге, Фәнүсә диссертациясе хакында житәкче буларак мактанып сөйләгәндә, үз идеяләренең авыл хужалыгына практик ярдәме белән горурланганда, мисал рәвешендә шул автомат цехны телгә ала иде. Шулай да Нажар завод вәкиленең үзеннән ишеткәч, тагын бер үртәлеп алды һәм өмет жуеп:

— Зарарсыз дигән мәкаләләрдән соң бөтен заводыгызны ук шуңа күчерерләр әле, — дип куйды.

Хәерлегә каршы, ялгышкан булып чыкты — цех инде таркалган һәм аны, автоматлар белән эшләргә кадрлар житмәгәнлектән, металлоломга ботарлыйлар икән.

Нажарның чырае ачыла төште.

— Шәп. Автоматлаштыру заданиесен үтәп премия алгач, аюны бүлешкәч, инде бүтән ни кирәк? — дип хәтта көлде дә.

— Аю шактый зур иде.

— Шатлыктан жырлап жибәрмичә булмас. Житмәсә, Фәнүсә, сезнең бәйрәм — яшьлек дустың тавышыңны сагынып килгән. Давай, нинди көйгә? — Шулай дип пианино капкачын яңадан ачты Нажар.

— Нәкъ жырлар чак, шул хәтле күңелле, елаплар жибәрәсе килә.

Фәнүсәнең бу сүзләрен якташы да жөпләргә тиеш тапты һәм:

— Гажәп тә инде, барыбызга да ярдәм кирәк, ярдәм итәргә ашыгучы юк,— дип авыр сулады.

Үз кайгысына буйсыну аркасында, авылдашы белән чит кеше сыман күрешкән Фәнүсә кинәт уянып киткәндәй булды. Ничәмә елдан соң эзләп килгән икән, чынлап та уйнап кына йөрми торгандыр, хәле житди һәм авырдыр инде, мөгаен. Әгәр яшь чактагы тәкәбберлеген искә алсаң, ул монда бөтенләй күренмәскә дә тиештер. Жәрәхәт хәтта ерткыч жанварны да юашлата — ул да ярдәм эзләп кешегә килә...

Фәнүсә килгән кунакка жылы бөркергә тырышып карады:

— Сезгә дә ярдәм кирәкме? — диде һәм авылдашын чын күңелдән кызганды. Якташы керфекләрен калтыратып ничек жавап бирергә белми торган арада йомшак, хәтта назлы тавыш белән: — Әллә сезнең дә өметләрегез агуланып үлдеме? — дип өстәде. — Гафу итегез, нинди жилләр сезне монда китереп ташлады?

— Жил түгел, давыл: корабль батты, ә дулкыннар мине сезнең ярга чыгарып аткан. Һушыма килгәч, Мөдирне күрдем, хәзер — сезне.

Фәнүсәнең куркуы кимесә дә, кызыксынуы арта төште:

— Конкретрак әйтеп булмыймы соң?

— Ну алайса шул: семья жимерелде дә бөтенесен — өйне, эшне, каланы ташлап, хәзер сыеныр урын эзлим.

Кыен чагы икән шул. Ә Нажар, шәфкатьсез, кызганыр урында кунакның кәефен тагын да ныграк боза язды:

— Иң башта үзеңне табарга кирәк. Шуннан соң өй дә, эш тә, кала да, хәтта хатын да табыла, — дип шаяртмакчы булды.

Әйтергә кирәк, хат адресатына житте — Вәкил кызгандыру урынына кызганучы ролен башкаруга күчте:

— Ә Сезгә? Сезгә нинди ярдәм кирәк соң? — дигәч, хәл-әхвәл сорашу шуның белән тәгәлләнде.

Нажар Фәнүсәгә катгый итеп үз карарын әйтте:

— Уйлый торгач, жай табылды бугай — эш сәгатьләрендә Мөдирнең бавырында казынабыз, ә эштән соң үзебезнең төп күзәтүләребезне дәвам итәбез, дөресрәге — экспериментны тәгәлләргә һәм гыйльми советка үзебезнең нәтижәләр белән бергә тапшырырга тырышачакбыз. Килештекме?

— Миңа барыбер.

Фәнүсә сүренке генә ризалашса да, Нажар сәгатенә карады:

— Мөдир вакыты беткән.

Әмма нәкъ шуны сизгәндәй... Әйе, нәкъ шушы вакытта ишек артыннан каты һәм ныклы адымнар ишетелде. Кем икәне — билгеле. Мөдир иде. Кергәч тә ул башта Вәкилгә елмаеп:

— Мин сине югалттым... хәзер, — диде дә шундук Нажар каршына килеп басты. — Я, забастовка беттеме?

— Бетте.

— Соң?

— Хәл иттек: сезнекечә дә, ә эштән соң — планны да үти бирергә. Сарык та тук, бүре дә улый. — Шулай шаярмакчы Нажар!

Әмма үз бүресенең генә улавын яратканга күрә, Мөдир дә үз карары белән кергән икән:

— Мин анда,— диде ул, ачуын ясалма олпатлыкка әйләндерергә тырышкан хәлдә. — Камерага пломба куйдым. Җимерсәгез...

— Җимерсәк, дәүләт милкенә кул сузган булырбыз. Әмма дөньякүләм әһәмиятле ачышны бикләп кенә асрап булмаячак — ул Парижга барыбер очачак, гәрчә үләксә хәлендә булса да!

Әллә үзенең дә, иренең дә Парижга оча алмавына тәмам ышанудан, әллә соңгы көннәрдә бөтен бәлалар аркасында теңкәсе корганлыктан, әллә ире белән Мөдирнең бүтән һич килешә алмаслык хәлгә житүеннән, әллә юкса үз диссертациясенең комга корылганлыгын аермачык күргәнлектән, югалды да калды Фәнүсә — Нажар соңгы сүзләрен әйтүгә ике кулындагы ике пробирка берьюлы төште китте. Пыяла белән бергә, эшне төзәтү мөмкинлеге дә бер секунд эчендә челпәрәмә килде. Юк, ничек тә ирен туктатып өлгерә алмады Фәнүсә. Сүз әйтелде һәм ул, ахрысы — тере: очты китте. Тотып кара син аны хәзер!

Тотып кара!

Аның кая таба очканын күреп торган Вәкил исә, вакытка дөрес бәя биреп, Мөдиргә:

— Дустым, мин сине кабинетыңда көтәрмен инде, — диде дә, Нажар белән Фәнүсәгә баш ия-ия, тиз генә чыгып та сызды.

Иркенләп сөйләшсеннәр, янәсе. Сөйләштеләр!

Мөдир — рәсми һәм салмак:

— Һәвәскәрлек белән шөгыльләнү өчен бүтән урын сайларга киңәш итәм.

Нажар — ачулы һәм өметсез:

— Шушы минутта син чикне уздың... Син, сабан туйда изге көрәш кагыйдәләреннән баш тартып, кагыйдәсез тәпәлешне сайладың. Гафу ит, мин аны кабул итә алмыйм.

Шул сүзләрдән соң ул чыннан да читкә тайпылды. Мөдир нинди генә гаепләр ташласа да, авызына су капкандай тик утырды, хәтта пианинода баягы көйләрне дә такылдатып алды. Мөдирнең шундый тәкъдиме истә калган:

— Кызганыч, бүтән вариант тәкъдим итә алмыйм. Бердәнбере — шушы. Ошамаса, рәхим итәсез — филармониягә!

Мондый ук оятсызлыкны Фәнүсә булып Фәнүсә дә көтмәгән иде. Фәнүсә булып Фәнүсә Мөдирнең битенә ябышмакчы, күзләрен чокып чыгармакчы иткәндәй якынлашкач, тегесе борылды да идән уртасындагы пробирка ватыкларын тешкә тиярлек шытырдата-шытырдата таптап чыгып китте. Ул киткәч үксергә керешкән Фәнүсәне Нажар аркасыннан сыйпап юатмакчы иде, хатыны бөтен ачуын Нажарга күчерде:

— Ир кеше, имеш! Нинди мескен хәлдә калды, хатын-кыз өчен дә оят, оят, оят, адәм көлкесе!

— Фәнүсә, акыллырак бул!

— Хәзер нигә кирәк ул акыл? Хәзер йодрык кирәк, таш, кусәк. Мөдирдә боларның бөтенесе бар, ә синдә — әдәп! Кемгә хаҗәт ул? Әрсезлеге белән Мөдир хәтта хәзер Директорны үзенә хезмәт иттерә башлады, көн-төн кабинетыннан чыкмыйча янадан-яна уңышлар, идеяләр турында мактанып үзен күтәрә, сине яманлап үсә. Көн кебек ачык — алар үзләрен бөтен кешелек алдында җир язмышын саклап калган акыл ияләре дип исбат итәчәкләр, табигатьне, бөтен цивилизацияне саклаучы куәт ияләре булып шаулаячаклар. Бөеклеккә синең кебек тавышсызлар башына баса-баса менәчәкләр. Ә син — ресторанда азыптузып йөргән йолкыш, аларның бер елмаюына мең яна идея бүләк итәргә әзер булып, җыелыш-тантаналарда аларны котлап, аларны мактап кул чабачаксың. Менә сиңа нинди хөрмәтле роль бирелгән, әнә нинди синең булачак профессия! Менә нинди синең якын киләчәгең!

— Син язып биргән тиле доклад белән хур булгач, үзебезнең җиргә нинди вөҗдан белән аяк басар дисең?

— Төкергән ул синең вөҗданыңа! Начар галимне дәрәҗәле симпозиумнарга йөртмиләр. Бөтен халык шулай уйлаячак. Һәм аңа шул җитеп арткан. Төкергән ул синең шикләнүләреңә. Яңа бөек эшләргә тотыначак.

— Нинди якты офыклар, нинди киңлекләр!

— Шулай шул, синең уңышсызлыклар бүген генә башланган түгел. Хәтереңне үк җуймаган булсаң, исеңә төшер: моннан өч ел элек мөдир итеп кемне куймакчылар иде? Сине түгелме?

Монысы — хак, әлбәттә. Оештыру эшенә сәләтем юк дип, Нажар мөдирлектән баш тарткан иде. Ләкин ул чакта эшнең нигә тоташасын — аны иҗат бәхетеннән үк мәхрүм итү кебек оятсызлыкка барып җитәчәген Нажар башына китерә алган идемени? Ах, шул вакытта кеше дәгъваларының никадәр комсыз һәм оятсыз була алуын чамалый алган булса! Фән өчен сәләтсез булса, Мөдир бәлки оештыру эшен шәп башкарыр, аңа да эш кирәк бит, имеш... Ләкин житәкче булгач, кинәт кенә ул галимгә дә әйләнеп китте, мактала, хәтта бүләкләнә башлады... Иң кыены да шунда, Фәнүсә каргап әйткән сүзләр Нажарның үз башыннан чумырып алынган шикелле. Әнә ишет:

— Әйе, ул сиңа башлык булудан бер дә тартынып тормады. Синең белән мин башкарганны үзенеке итеп директорга һәм гыйльми советка житкерә торды. Газета аша — бөтен илгә. Хәзер бөтен дөньяга! Ә син? Син кит тагын җәнлекләрең янына да ялынып, чакырып алганнарын көт. Ләкин бу юлы китсәң, кире чакырмаячаклар — сөенәчәкләр генә. Үзең тәкъдим итеп үз урыныңа утырткан мөдирең инде башка ярдәмчеләр табачак.

Моңарчы көлемсерәр дәрәҗәдә өстән генә карап тыңлаган Нажар соңгы минутларда боега төшкән иде инде. Үзен яклар өчен:

— Ышанган кешең оятсыз булып чыкса, хатаның яңасы бу түгел, — дип кенә аклана алды.

Ә фикерләренең гадел һәм кире кагылмаслык икәнен тәмам төшенгән Фәнүсә, баягы көчсез бөтерелүләреннән, зиһен чуалткыч зәһәрлегеннән котылып, шактый үк салмакланган һәм ниндидер дәрәҗәдә судья вәкаләтләрен кабул иткән иде, һәм менә ул шундый хөкем чыгарды:

— Аннан бигрәк — син оятсыз, аны башта син алдадың. Синең өстән Мөдир итеп куярлык булгач, үз өстенлегенә ничек ышанмасын ул? Әйе, аның ышанмаска хакы да, теләге дә юк иде. Мөдир — синең иҗат!

— Уңышсыз әсәрне юк итәргә мөмкин.

— Директорлыкка тәкъдим ит.

— Вакыйгаларга читтән карап бәя бирик.

— Менә, менә башланды. Чит дигәнебез — җәнлекләр бакчасы. Бар, бар, җәнлекләрең белән, к[illegible]ларың белән киңәш. Аюлардан акыл

сора. Аларның тешләре дә, тәпиләре дә Мөдирнекеннән олырак һәм өткенрәк. Ләкин әзерләнеп бар, алар да сиңа рәхмәт әйтмәячәк. Хәерле юл. Ә иҗади сәләтсез дигән мескен Мөдиребез Парижга очсын. Анa шул да бик җиткән.

*
* *

Ачы һәм шәфкатьсез гаепләүләр өчен Фәнүсәгә хәтере калудан бигрәк, ахрысы, дөреслеккә үпкәләп, Нажар беркем белән саубуллашмыйча, үз гадәтләренә, үз тынлыгына, үз биләмәсенә юл тотты. Һәм менә ул инде берничә көн буе тынлыкта да тынгылык таба алмыйча интегә. Караңгы. Караңгыда Фәнүсәнекеннән дә яманрак тавыш — табигатьнең үз тавышы бугай — йөрәкнең үз тибеше сыман ургылып, төнге дөньяга тарала: «Планетаның могтәбәр галимнәре рәтендә дөнья язмышы хакында сөйләшергә тиешле кеше — ул син идең. Син, изге бурычтан баш тарткан килеш, хәзер дә ихтирам даулыйсың. Гафу ит, моннан соң кем дә сине ихтирам итмәс һәм шулар рәтендә мин дә булырмын».

Алар рәтендә — Фәнүсә, табигать, һәм... хәтта вөҗдан!
Алар рәтендә хәзер янда гына басып торучы Энҗе, Әпә, Каравылчы.
Әпә әнә, каракка күрсәткәндәй, Нажарга бармак төзи:

— А-а-а-ю, пуф, эм-мыһ! Әпә, әпә!

Энҗе исә аның белән килешмичә кычкыра:

— Ул әпә түгел, ул — минем әти, син әпә!

Берәү генә булса да яклаучы калган икән әле. Болай булгач, эш бөтенләй үк өметсез түгел. Димәк...

— Миңа, кызым, шәһәргә кайтырга кирәк. Кайтасыңмы минем белән? — Бу сүзләрне Нажар кызына кабат-кабат әйткәч кенә ишеттерә алды.

Ни дисәң дә ишетүе хәерле... Ләкин җавабы кире иде:

— Юк, әти, миңа монда күңелле, җәнлекләр белән.

— Алайса исән тор. Сак бул, җәнлекләр тотып ашамасын.

Каравылчы, киресенчә:

— Җәнлекләр тимәс, син анда үзеңне кара. Төнге шәһәр, соңгы автобус,— дип Нажарның үзе өчен сагайды.

Автобус китәргә ярты сәгать калган. Нажар бая Әпә алып килгән бөҗырны кагазьгә төреп алды да Энҗене үпте һәм ашыгып китеп барды.

## ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК

Ыржаюны әйләндереп елмаюга,
Атлый кеше, атлый якты бөеклеккә.

Нажарның тәкъдиргә бераз үпкәләргә хакы бар кебек — ул бәхетле йолдыз астында тумады, ә бөтен дөньяны калтыраткан залплар, шартлаулар, дөбердәүләр һәм елашлар астында туды. Бу тавышлар һәм дәһшәтләрне үз колагы белән ишетмәсә, үз күзләре белән күрмәсә дә, алар аның хәтерендә генә түгел, әнисенең аш иканлеге шактый үк бәхәсле булган ризыкларны да аклыкка, күкрәк сөтенә әйләндерә алганлыгы аркасында гына тере калды. Әмма сөт кенә җитми адәм баласына. Тәпи баскач аш күбрәк кирәк. Ә Нажарга дөнья шул тиешлелең йөздән берен генә бирде дисәк тә хата булмастыр. Сугыш аның тәнендә зәгыйфьлек булып гомерлеккә калды, аның нервлары какшау, тиз уалучан, янып чыгучан, чак кына салкын тисә, сулыш юллары, үпкәсе шешеп

чыгучан булып калды. Бәхәсләрдән качарга тырышуы, андый вакытларда, кирәгеннән артык кайнарлануы, җиңү урынына законлы дәреслегеннән дә колак кага килүе аркасында, сүз мәйданнарына карата ихтирамсыз булды. Барлык дәгъваларын, теләкләрен, омтылышларын, хәтта мәхәббәтен дә саф эш, чын иҗади табышлар аркылы гына күрсәтә һәм исбат итә килде. Үзенең Фәнүсә күзләре белән карап табылган шушы кимчелеген төзәтергә кайчак тырышса да, Фәнүсә әйткәндәй, үз микродөньясына ябылып ятуы аркасында, үзен тәки үзгәртә, төзәтеп бетерә алмады.

Моңарчы әллә ни зур кыенлыклар күрмәсә дә, соңгы көннәрдә аның хәле читенләште. Һәм аның кулында — үлгән кош... Ләкин, Фәнүсә әмерен үтим дисә, ул бу кошны терелтергә тиеш. Югыйсә... Моңарчы Фәнүсәне ул күңеленнән гел хаксыз дип, балаларча җинел уйлый дип кенә йөрсә, бүген бөтенләй башкача фикер итә, аның үзенә җитдирәк яшәргә, хатынына колак салырга кирәк булган икән ләбаса... Тик бу фикергә килгәннән соң, Фәнүсәгә ышанганнан соң, Нажар кинәт үзен кимсетелгән, өлешсез калган кешегә охшата башлады. Вөҗданына ниндидер шеш чыкты, бәлки яман шеш...

Авылда үскән малайга дәүләт университетында имтиханнар биргән чакта ук хәзерге сорауларны юри генә биргән булсалар да, бу вакыйгалар көтелмәгәнчә куркыныч борылыш алмас, бәлки җиңелрәк хәл ителер иде. Исемле стипендиат дәрәҗәсендә укыганга күрә, соңыннан ике еллык эш стажы да сорамыйча аспирантурага алынгач һәм шул срокта ук молекуляр биологиянең иң популяр темасы буенча диссертация яклагач, әлеге хәлләр белән очрашу мөмкинлеген әйткән булсалар... Юк, ышанмас иде, мөгаен, анда ул бары тик кычкырып-кычкырып көлгән генә булыр иде. Хәзер көл инде менә.

Хатыны Фәнүсә бергә яши башлаганнан бирле көн-төн туглый торды: «Күзсез таяктан башканы тотмагандай, бар белгәнең, бөтен тормышың — микродөнья, кердең дә бикләндең, чык, җаным, дөньяны бөтен киңлегендә күр — ул искиткеч зур, катлаулы, төрле адәмнәр, җанварлар бар анда — сөйләш, аңлаш, тешләш, ырылдаш!»

Кешеләрне аңлауга караганда, Нажар хайваннарны күбрәк белә иде. Фәнүсәгә каршы аргументы да шул: молекулалар — үзе чиксезлек, ә хайваннар дөньясы, Нажарның хобби дигән мавыгуы — хәтта кешелекне дә сыйдыра.

Дәүләт музеенда төрле җәнлек һәм кошларның карачкылары Нажар кулы белән эшләнгән. Йомшак күнелле дигән Нажарга кайвакытларда, димәк ки, каты куллы да булырга туры килә, җан иясенең хәтта җанын алырга... Шулай булгач, кеше эчтәлегенең, тойгылар дөньясының тарлыгы хакында нинди сүз булырга мөмкин?

Көн-төн тәкрарлый Фәнүсә: «Актив бул, эштә, тормышта, җыелышта. Тантаналарда су эчә-эчә нотыклар сөйлә, бюроларга сайлан, лаборатория мөдире бул, начальник хатыны буласым килә!»

Тыңлатырсың Нажарны, аның үз аргументлары куәтле: «Чын галим үз эшен башкарсын, күренешләрне күзәтә торсын, үзгәрешләр, яңалыклар эзләсен, тапсын, шуларга бәя бирә белсен — шул аның өчен җитеп арткан. Ә кемнең чын фәнгә түземлеге, сәләте җитми, чыгышлар ясасын, мөдир булсын, директор булсын. Министрлыкка үрләсен. Кемнең бәхете күктә, кемнеке — җирдә. Һәркемнең — үз өлеше...»

Нажарның гомер мәгънәсе күптән инде табылган шикелле иде: үзе сайлаган микродөньяда (белгән кеше өчен ул да чиксез!) яңалыкларга иң кыска юл белән, мөмкин кадәр аз вакыт эчендә барып җиту, юл озынайта, вакыт әрәм итә торган вак-төяк мәшәкатьләрдән котыла бару саф фән, чын иҗат. Ә бүтән мәшәкатьләрне администраторлар, мөдирләр үз өсләренә ала...

Ләкин Нажар ялгышты. Нажар, комачаулыклардан котылам дип, аларны үзе үк иҗат итешкән булып чыкты.

Башка шәһәрдән ялварып хатлар яза, ярдәм сорый торгач, хәзерге Мөдир Нажар янына урнашты. Нажар аны директорга тәкъдим иткәндә һәм бергә эш башкарганда, иптәш соклandыргыч тыйнак, әдәпле, ә иң мөһиме — ярдәмчел иде. Мәшәкатьләрне үз өстенә чынлап та ала килде, ләкин, Мөдир булгач... оештыру ягыннан гына түгел, фәнни яклап та Нажардан «күбрәк белә» башлады һәм моңарчы үзенең остазы шикеллерәк булган дустының, ахрысы, авыр тоелган зиһен өстенлеген җилкәсеннән сыпырып төшереп, авторитар рәвештә «җитәкчелек итәргә» кереште. Әдәп-тыйнаклык, ярдәмчеллек җилгә очты, киресенчә, хәзер син аңа ярдәм ит!

Кинәт үзгәрешләргә заман күнеккән.

Адәм баласы күптән түгел генә сәгатенә биш-ун чакрым ара узса, хәзер, ракета тизлеген эшкә кушкач, ул туп көпшәсеннән атылган ядрәдән дә ун тапкыр тизрәк оча башлады. Җир бәләкәйләнде.

Эш тизлеге арту аркасында, кеше гомере озынайды. Гомер еллар белән түгел, гамәлләр белән үлчәнә, күп эш башкару аркасында, ирекле вакыт арта — иҗатка күбрәк вакыт кала — иҗатка, фикергә, тән хәрәкәтенә һәм... мәхәббәткә.

Бәхет иҗат күләме, тән хәрәкәте, мәхәббәт микъдары белән үлчәнә.

Нажар һәм мәхәббәткә, һәм бәхеткә — яшәү дигән шөгыльгә күбрәк вакыт калдырмакчы иде — ялгышты.

Җитештерүчән хезмәт даим тәртип сорый — эштә, тормышта, шәхси мөнәсәбәтләрдә мораль кодекслар һәм рәсми нормалар ачык булырга тиеш. Күнелләребезне иҗат хәлендә тотар өчен бәләкәй максатлы, олы нәфесле кешеләргә каршы чынлап көрәшергә, каты куллы администратор булудан да курыкмаска кирәк икән. Эштә һәм юлда (самолетта, ракетада) — экономияләнгән вакыт шәһәр һәм авыл эчендә, автобус тукталышында, ашханәдә, кибетләрдә чират тору, начар китап уку, алама фильм карау аркасында урланырга мөмкин. Ә барыннан да бигрәк хезмәт бәясеннән үзенә күбрәкне дәгъвалаган кешеләр китереп чыгарган ызгышлар, мәгънәсез бәрелешләр аркасында юл озыная, рәнҗешле рәвештә озыная.

Нажар әнә шундый уйлар белән кайта. Ләкин инде ул тавышын югалткан. Аның кулында — үлгән кош. Кошны терелтү өметен күтәреп кайта Нажар. Кошны Нажар тиздән Директор өстәленә китереп салачак... Ник?

Ләкин менә ник дигәндә үзе дә рәтләп белми әле. Тик бер нәрсә ачык, әгәр Фәнүсә сүзләренә ышанса, ул — өлешсез... Әгәр Прораб дигән бәндәгә колак салса, хәтта мәхәббәттән мәхрүм... Фәнүсә! Инде син дә, син дә хыянәт иттеңмени?! Ышанма, Нажар, дөньяны якты, матур килеш сакла!

Урман.

Урман юлыннан атлый Нажар. Алпан-тилпән, алпан-тилпән.

Дөнья шаулый, ә Нажар — тавышсыз.

Күзсез калу куркынычын күз алдына китергәне бар, ләкин тавышсызлык фаҗигасе булу мөмкинлеге... Юк, монысының хыялга да кергәне булмады. Ләкин монысы да бар икән тормышта, бар икән! Бар!

Урман яңгыратып, әй, бер кычкырсаң иде дә, синең куәтле тавышыннан чыршы-наратлар, бөтен урман калтырап торсын иде. Тавышы бар чакта теге дөньяга да ишетелерлек итеп нигә кычкыра белмәде икән? Үлекләр иленә охшаган мондый да өнсезлек барын ул чамалап кына белгән булса да, табигатьнең бушка биргән бу байлыгыннан ничек файдаланырга кирәген моңа кадәр, һай, белмәгән икән шул...

Фәнүсә һәм Мөдир фатихасы аша кертелгән химикатлар белән тавышсыз-тынсыз килешкән басулар һәм урманнарның өнсез шелтәсен

ишетте Нажар — ярый әле, колаклары сәламәт — яшәү белән бәйләнеш колак һәм күзләр аркылы өзелми калган. Тормышның ничәдән бер өлеше?

Нажар, күптән түшәккә ятарга тиешле кеше, һич киметмичә әйткәндә, тәне кырык градуслы эсселек белән янганда, ятып калганчы атып калыйм дигәндәй, дөньяның бер өлешен мәңгелеккә югалтудан куркып бара, егылмый, басуларны, урманнарны коткарырга ашыга.

Әле кайчан гына — кая карама, кай якка колак салма, бу урманда ботак саен чыпчыклар чыркылдаша, тукран тукылдый, сан-исәпсез вак кошлар чәкердәшә иде. Бүген әллә кая киткәннәр. Ахрысы, бөтенесе һәлак булды — югарыдан, самолеттан чәчкән химикатлар аркасында, зыянлы дип йөртелгән бөҗәкләр белән бергә, юкка чыктылар. Инде тәмам ачыкланды хәл: иген шавы көчәйсә дә, сандугачлар җыры бу тирәләрдә тынган булып чыкты. Ә бит игеннәр никадәр генә куе һәм эре башаклы булмасын, алар да кошлар тавышын сагына, шунсыз алар да җансыз...

Моннан берничә ай элек Нажар сазламыграк җирдә шома көпшә өзеп ашаган иде, авыз эчендә шактый ук зур җәрәхәт барлыкка килде. Рак бугай дип кайбер кешеләргә күрсәтеп, хәтта галим кеше оятка да калды. Җәрәхәт, әлеге дә баягы, корткыч бөҗәкләрне кырып салган, самолеттан сибелгән агу хикмәте икән...

Институт диварлары эчендә: «Агуны сибәргәме, юкмы, югары уңыш бәясенә соңыннан күбрәкне югалтмабызмы?» — дигән икеләнүләрне табигать ишетмәде. Кошлар җырына һичкайчан да дәвам булып өстәлмәячәк бәхәс табигатьнең бушлай бирелгән сәнгатен алыштырды... Алыштырды?

Кошлар тынгач, Нажарның җаны да шым калды. Хәтта калада да шундый ук бер үләксә кошны күрер ул. Ә Фәнүсә бөтенләй дә каршы алмас...

Әмма Нажар, авыруына һәм һәлакәтенә үч итеп, атлый бирә, алга бара. Әгәр соңга калмаса...

Соңламас өчен өйгә кайтып бераз ял итү зарур.

*
* *

Өй дигәне — Фәнүсә теләгәнчә һәм заманча җиһазландырылган квартира, шактый ук матур сурәт: зал, аның ике як диварын буйлаган китап киштәләре. Шуларның бер өлгесеннән Энҗе рәсеме елмая. Фәнүсә шул рәсем белән өйдә икәүдән-икәү. Озак кына доклад язып утырды. Китап-дәфтәрләрен җыярга гына торганда, звонок шалтырады да ишектән, хәерле кичләр тели-тели, Мөдир белән Вәкил килеп керде. Әлбәттә инде, бу хәл Нажар күз алдына китерә алырлык күренеш түгел иде.

— Узып барышлый ут күрдек тә... Нажар өйдә түгелмени? — дигән булды Мөдир елмаюын яшереп.

Әйтерсең белми.

Шулай да Фәнүсә, итагать йөзеннән замечание ясамыйча, көрсенеп кенә куйды.

— Кешеләргә ихтирамы бетсә, гел шулай ул, җәнлекләр арасына китә. Шөһрәт һәм дәрәҗә өчен талашу минем профессия түгел дип, үз белгечлегем буенча эш яңадан чыкса, чакыртырсыз дип китте дә барды.

— Алай икән, алай.— Вәкил китап киштәсендәге рәсемне күрде.— Оһо, монда да бар икән. Фәнүсә, бу — синең яшь чагың бит?

— Бу минем кызым.

— Кит аннан! Суйган да каплаган! Прямо, бу — синең яшьлегең.— Фәнүсә нишләр, әйтү дә кыен, әмма Вәкил үз сүзләреннән канәгать кал-

ды да, ихлас илһамланып, ары омтылды.— Фәнүсә, беләсеңме, мин бит сиңа нәкъ шуны — яшьлегеңне алып килдем.
— Рәхмәт. Безгә шулай әкият белән генә җан юатырга калды инде.
— Юкка алай дисез. Ягез әле, йомыгыз күзегезне.
Вәкил Фәнүсәнең күзләрен капламакчы булып кулларын сузган иде дә, Фәнүсә кискен тайпылды, тик, ни өчендер, авылдашының әмеренә барыбер буйсынып, күзләрен йомды.
Вәкилгә шунысы да җитеп торганлыктан, ул күңелен төшермичә:
— Юк, ике куллап каплагыз,— дип тә боерды.— Менә шулай.— Һәм портфеленнән фоторәсем чыгарды.— Хәзер күзләрегезне ачыгыз, сөекле мадам. Я, кем бу?
Кунак кулында Фәнүсә рәсеме иде. Фәнүсә шуны тиз генә алып:
— Каян килгән ул сезгә?— дип төземсезләнде.
— Бүләкнең каян килгәнен сорау әдәпкә туры киләме соң?— бу сүзләрне әллә шаяртып, әллә чынлап әйтте Мөдир.
— Ә-ә, гафу, онытканмын, сез әдәп каһарманнары бит әле!
— Йә, йә, кем бу?
Вәкил Фәнүсәнең янәшәсенә үк килеп басты, чөнки рәсемнең авылдашына ничек тәэсир иткәнен бик тиз абайлады бит. Әнә, Фәнүсә хәтта тартынганрак кыяфәткә керде.
— Кем дип... Мин бугай.
— Вот именно. Дөресрәге — бая әйткәнчә, сезнең яшьлегегез һәм ул миннән бүләк. Кабул итегез зинһар.— Вәкилнең баштагы икеләнү-җайсызлануларыннан бу вакытта инде, әлбәттә, җилләр искән иде.
— Шулай да, шулай да... Нишләп ул сездә?
— Әйтсәм кызыгы бетмәсме соң?
— Аннан гына бетәрлек булгач...
— Ну, төп йортта калган энем Ташкент ягына китеп барганда, миннән калган барлык кәгазьләр белән бергә моны да җибәргән.
— Ә аңа ничек килеп кергән?
— Монысын әйтә алмыйм, мәңге дә.
— Әйтмәсәгез, фаразлардан интегеп, мин йокыдан калачакмын.
Ниһаять, Фәнүсәгә Мөдир ярдәмгә килде:
— Болай булгач, Вәкил дус, серне тагын ачарга туры килә инде.
Вәкил Мөдиргә дә, авылдашына да яхшылык эшләвен сиздереп, хәйләкәр кыланган булып елмаерга тырышты:
— Ыһымм. Сез мәктәптә укыганда отличник идегез. Бу рәсем коридор диварында, Мактау тактасында эленеп тора иде. Авылда. Хәтерлисезме?
— Хәтерләгән кебекмен.
— Бер заман Мактау тактасыннан сезнең рәсемегез юкка чыкты.
— Әйе, әйе, шулай шул, дөрес. Мин аны укытучылар үзләре алды дип өч көн еладым.
— Ә алар рәсемнең югалганын сизмәделәр дә.
Мөдир Вәкил белән Фәнүсә арасындагы кызыклы әңгәмә башланачагын инде сизде һәм аңа хәтта интим юнәлеш бирергә дә тырышты. Ни өчендер аның күңеле шуны тели иде. Нажардан Фәнүсәне мөмкин кадәр ераклаштыру һичшиксез аңа файдалы бит. Шуңа күрә ул:
— Кит инде син, Вәкил дус, шушындый чибәр кызны яшь түктерә алгач, җан дигән нәрсә булмаган да икән үзеңдә,— диде дә читкәрәк китте. Почмакта магнитофон белән булашмакчы, янәсе.
— Ачуланыгыз, Фәнүсә, тиргәгез юньсез малайны.
Шулай дип Вәкил шаяртмакчы булса да, Фәнүсә, әлбәттә, уенны чынга кушып әйтте:
— Карак! Сез минем үсмер чагымны урлагансыз.

— Мин аны матур килеш сакладым.— Вәкил шулай дип рәсемне китап киштәсенең икенче ягына урнаштырды.— Күрәсезме, бер якта — сезнең яшьлегегез, икенчесендә — киләчәгегез.
— Бүгенгесе юк.
— Анысын кем урлады?
Монысына почмактан Мөдир җавап бирде:
— Нәҗардыр инде, бүтән кем булсын.
— Ә бәлки Мөдир? — Фәнүсә почмакка борылды.
— Юк, юк, киресенчә, мин аны табып, Вәкил дустым кебек үк, сиңа кайтарачакмын.
— Ничек итеп?
Мөдир, күрәсең, үзенә карата Фәнүсәнең начар уйда йөрүенә юл куя алмый, аңа Фәнүсәнең, әйткәнебезчә, якынлыгы, ярдәме кирәк. Һәм шуңа күрә Мөдир почмактан зал уртасына чыгып басты да илһам белән сүзгә керешге:
— Синең бүгенге көнең, нур чәчеп балкыган бәхетең юкка чыкты, чөнки син миңа гына усаллык эшләп калмыйча, максатыңа да хыянәт иттең. Шулай бит? Ә мин ул максатның хыял рәвешендәгесен түгел, тормышка ашкан хәлдәгесен бүләк итәчәкмен.
Фәнүсәдән бигрәк, дустының канатлы сүзләренә Вәкил шат:
— Давай, выкладывай, портфелеңдәме?
— Фәнүсәдән бер сүз көтелә.
Сүз дигәннән, секретарь кыз ясаган мәсхәрәле тәкъдим искә төште дә, Фәнүсәнең тагын кәефе кырылды.
— Бер сүз? Аны Директорга кереп әйтергәме? — диде ул сагаеп.
Фәнүсәнең үзе әйтергә җыенган фикерне алдан ук белүе Мөдирне дә бераз җайсызрак хәлгә куйды. Мондый чакта синең кыен йөкне дус күтәрсә — хәерлерәк. Вәкил, әлбәттә, елгырлык дигәндә, төшеп калганнардан түгел, Мөдир теләгәнне ул ярып кына салды:
— Фәнүсә, якташ, авылдаш, сез үзегез башлы кеше бит, уйлап карагыз. Күрәләтә ничек итеп диссертацияне утка ташлыйсың? Коткарырга кирәк ләбаса. Мин бер генә ысул күрәм: Мөдирегезне, аның идеясен яклап кына киләчәкне җимертми калырга мөмкин. Шул кадәр нык бәйле бит сезнең интереслар, әйтер идем — язмышлар!
Ниһаять, шул рәвешле Мөдиргә дә турыга китәргә шарт туды һәм мизгелне файдага бору өчен йомышын ул исеме белән үк атады:
— Фәнүсә Кадыйровка, иртәгә үк Директорга керергә кирәк, югыйсә, соң булачак, төзәлмәслек хата.
Моңа каршы Фәнүсә шаяртып кына:
— Катастрофа!— дип өстәгән иде, Вәкил аны үзе теләгәнчә аңларга тырышып:
— Фәнүсә аңлады!— диде дә, үзенең мангаена сугып куйды.
Мөдиргә нәтиҗә ясыйсы гына калды:
— Ярый, молодец, димәк — иртәгә,— дип куйды ул.
Фәнүсә, күптән аларча уйлаганга күрә, бәхәс куертмаска, эшне томанлырак хәлендә калдырырга — эндәшмәскә тиеш тапты. Тик җанының ниндидер бер почмагы пешкән шикелле сулкылдап сызлый иде һәм ул хәзер бигрәк тә көчәя төште.
Аның кәефсезләнгәнен чамалаган Мөдир, тәмәке тартырга рөхсәт алып балконга чыгып киткәч һәм тагын да җайсызрак хәл урнашкач, Вәкил, йөрәгендә еллар буе буа суы шикелле җыйналган сагышыннан ничек котылырга белмичә, читлектән күккә баккан коштай, озак кына Фәнүсәгә карап торды-торды да авыр сулады. Фәнүсәгә бу аһылдауның сәбәбе ачык: кайчандыр, бүгенгесе белән чагыштырганда яхшырак кешене ташлап киткән, тиз арада оныткан, хат та язмый башлаган егет үзенең яшьлек хатасын аңларга азаплана... Әйе, Фәнүсә таш сын шикелле утырса да, авылдашының ни өчен килгәнен, нәрсә әйтергә

теләгәнен, тормышның ни өчен бүгенгедәй рәхимсез рәвештә алга үрмәләгәнен һәм бу кешегә ачуланыргамы, әллә юкмы икәнен аңларга тырыша иде. Тик ачулана да, кызгана да алмыйча, бары тик сизелерсизелмәс дәрәҗәдә, күз карашы белән булса да мыскылларга гына һәм үртәргә генә көче җитте: «Өметсезлеккә ачу кушылган бер ярсыну белән вакытны җимереп, без синең белән галәмгә очкандай иреккә очарга тиеш. Аңлыйм мин сине, аңлыйм.»

Ялгышмады Фәнүсә. Мөдир кергәнче өлгерү өчен бугай, бераз ашыга төшеп, телгә килде Вәкил:

— Безнең кебекләр белән дөнья тулы һәм алар ялгышны төзәтүдән курыкмыйлар. Яшерүдән файда юк: мин сине яшьлектә мөмкин булганча яратам, бәлки артыгракты́р да. Әлбәттә, артыграк. Яшьлектә әле бөтенесе алда, бәлки моннан да зуррак яратулар буладыр диген, тел белән әйтелми торган өмет киләчәктән елмая. Бернинди үкенү, югалту булмас шикелле. Бөтен дөнья, бар табигать көлә — өндә дә, төштә дә, җырлый, бии. Ә хәзер? Хәзер киләчәктән бары моннан да зуррак югалтулар синең бүгенге көнеңнән дә ямансурак кыяфәт белән, яшьле күзләр белән карап үзәкне өзә. Ул әле бүген чибәр, яшь, ләкин киләчәктән инде җыерчыклы йөзләр, сүренке күзләр тыныч салкынлык сирпеп карап тора.

Фәнүсә һаман үртәлсә, хәтта мыскыллап тыңласа да, соңга таба ничектер Вәкилнең чынлап та бәхетсез кеше икәнен тоеп, аңа каты бәрелә алмады. Ләкин барыбер:

— Шул кадәр лирика, хәтта елыйсы, хәтта җырлыйсы килә!— дип куйды да урыныннан торды.

Юк, ул бу кешене мыскылламыйча булдыра алмый икән. Әнә ул башта ишетелер-ишетелмәс кенә, сүзләр генә әйтсә, соңынтын көй белән үк үчекләп җырлый башлады:

Ерак яшьлектән тавышың ишетәм:
«Бәгърем, килеп ал!» — Бу тик буш хыял.
Син яшь булып кал, көләч булып кал,
Кал гүзәл булып, изге булып кал.
Әллә йолдызда, әллә син айда —
Юк син, юк анда, инде син кайда?
Син саф булып кал, көләч булып кал,
Кал гүзәл булып, гел яшь булып кал.
Бу бит — син түгел, хис тә бит, төс тә
Адашып калган ерак яшьлектә.
Чибәр булып кал, көләч булып кал:
Кит син, кит кире — гел яшь булып кал.

— Фәнүсә, аңла, ычкындырмыйк калган бәхетләрне. Бүгенгебез матур, шуны күрми калмыйк, югалтмыйк шушы көннәр мәгънәсен. Әйдә, китик, иртәгә соң булуы мөмкин. Әйдә! Менә хәзер син генә коткара аласың, ә сине — мин генә!

Фәнүсә җавап урынына зал ишеген ачса, бу якка узарга базмыйча, Мөдир шунда басып тора икән. Фәнүсә икесенә дә карап:

— Ә хәзергә хушыгыз,— дия алды һәм кунаклар көтелмәгән кискенлеккә ышана алмыйча текәлгәч: — Зинһар! — дип ялварып эндәште.

Кунаклар исә, эш бозылу ихтималлыгын уйлап булса кирәк, бугазларында тукталган төерне тиз йоттылар да ишек катына килеп, шунда Фәнүсәнең кулларын үбә-үбә саубуллашырга керештеләр, тик шул бөкрәйгән кыяфәтләрендә катып та калдылар: чылтырап тәрәзә өлгесе коелды.

— Аһ! — Шулай Фәнүсә кунаклардан кулларын тартып алды да колакларын каплады.

Вәкил залга яңадан кереп, тәрәзә аша кергән ташны күтәреп алырга ашыкты.

— Карагыз әле, таш! Безне кемдер тыштан күзәтте микәнни? Әллә Нәҗармы?

Мөдир тәрәзәгә капланды һәм:

— Анда малайлар йөгерешә, уйнаганда ялгыш тидергәннәрдер, — диде дә өйдән чыгып йөгерде.

Нияте чынлап та малайлар куу гына идеме, анысын әйтү кыен, әлбәттә. Бәлки Вәкил аның файдасына тагын да кайбер сүзләр әйтә алыр дип, аларның үзләрен генә калдырырга тырышкандыр һәм бәлки тагын да бүтәнчәрәк максат беләндер... анысын белмәссен. Ләкин Фәнүсә әйтерсең янында Вәкилне күрмичә үк үз тойгыларына бирелгән иде. Әйтерсең шатланып, Вәкилдән ташны алды да күкрәгенә кысты:

— Ниһаять, таш! — диде ул тилергәндәй. — Ниһаять, Нәҗар катылык эшли алды һәм ул хаклы! Таш! Таш!

Вәкил, әлбәттә, Фәнүсәнең ник шул хәтле һәм нәрсәгә соклануын аңламыйча, аның соңгы өметенә дә каршы төште:

— Мөдир күрде бит, малайлар аткан диде.

— Малайлар? Нәҗар түгелмени?

— Бәлки аны яраткан малайлардыр. Ярый, борчылмагыз, тынычланыгыз.

Фәнүсә, күңеле сүрелеп, ташны Вәкилгә сузды:

— Алайса, бу — сезнеке. Нәҗарданмы! Нәҗарданмы соң!

Мөдирнең әйтелмәгән теләген сиземләп тә, болай үз йөрәге кушканга буйсынып та, Вәкилнең Фәнүсәне юату, тынычландыру, әгәр... (әзме дөньяда көтелмәгән бәхетләр!) Фәнүсәдә хатирәләр терелә төшсә, бәлки иркәләргә дә дигән кыю уй белән бу өйдә бераз гына тагын тоткарланасы килгән иде. Ләкин Фәнүсәнең кискен карашы һич тә күңелле өмет вәгъдә итмәгәнлектән, тавышсыз ыңгыраш белән саубуллашудан да хәерлерәк нәрсә калмады. Чыгып китте Вәкил. Баскычтан төшеп барганда, Фәнүсәнең ташны малайлар атканлыгын кабул итә алмыйча, кабат:

— Нәҗарданмы? Нәҗарданмы соң! — дип сәер уфтануын ишетте.

*

* *

Кичке сәгать тугызларда Нәҗар шәһәрдә иде инде. Өйгә кайтып житә яздым дигәндә, урамның икенче ягында, үзләренең якты тәрәзәләренә карап, ник икәнен үзе дә төшенмәстән, тукталды. Сәбәп менә нәрсәдә икән: аның өендә ниндидер күләгәләр йөри иде. Фәнүсә бу кичтә үзе генә булырга тиеш. Ире дә, кызы да юк вакытта моңаерга исәпләмәгән, рәхәтләнеп ятлар белән сөйләшәмени? Әйе, күр, ят ирләр... Иелеп-бөгелеп, мөгаен, көлешәләр, гәп коралар. Бәлки әле өстәлдә шәраб та утыра торгандыр? Ныклап карый торгач, Нәҗар хәтта таныды да: Мөдир һәм Фәнүсәнең яшьлек юлдашы... Прораб мәлгунь ялгыш лыгырдамаган икән... Ялгыш дигән очракта да, иренә каршы нинди генә этлекләр кылмаган кешеләр белән аулакта кәеф-сафа коруны — үзенә булмаса, эшенә — барыбер хыянәт дип кабул итте Нәҗар.

Аюга тигән ядрә аучының үзенә кире кайтты. Каравылчы хаклы — бер гаепсез җан иясенең җанын ал да, исән дә кал. Булмый ул алай, булмый икән. Хезмәтеңә тиешле әҗерне ал да җәрәхәтеңне тотып җиргә ау.

Ләкин Нәҗарга аварга ярамый — иртәрәк әле. Һәрхәлдә — бүген иртәрәк, ничек тә аяк өсте калырга, ничек тә кулдагы кошны тиешле урынга илтеп җиткерергә кирәк.

Нәҗар коймага сөялде. Шулай торган чакта кемнеңдер: «Шул кадәр эчмәсәләр, юньсезләр!» дигән тиргәүле сүзләрен ишетеп калса да, мин

эчмәдем дия алмады. Дөрестән дә, бәлки ул барыбер аек түгелдер, ә лунатик шикелле йөри-йөри төш кенә күрәдер. Югыйсә, төштә генә булмаса, сөекле хатынының хыянәтенә үз күзләре белән карап, хәзергечә тын тора алыр идемени?! Җир убылыр, күк ярылыр дәрәҗәдә кычкырыр иде. Ә ул ачынуын ачына, ә кычкыра алмый, авызы, балыкныкы шикелле, тавышсыз гына ачылып ябыла. Нишләргә?

Ял, ял итәргә. Ләкин өйгә керә алмый ул, үз өенә керә алмый.

Яннан гына малайлар узып китте. Күрше малайлар, таныш, дус малайлар. Нажарны җитәкләп өйгә кертмәкчеләр иде, Нажар анда керергә ярамаганлыкны аңлаткач һәм тәрәзәдән үзләре дә бераз карап торгач, малайлар да нидер төшенде бугай — тиз генә урамның икенче ягына китеп күздән югалдылар. Соңыннан нәрсәләр булгандыр, анысын көтеп тормыйча, Нажар ары атлады. Гәрчә ул кая барырга тиешлеген үзе дә белми иде әле.

Урам, урам, урам.

Өйләр, өйләр, өйләр.

Тәрәзәләр, тәрәзәләр, тәрәзәләр.

Утлар, утлар, утлар.

Барысы да өмет шикелле якты, чиксез күп, ләкин берсе дә Нажарныкы түгел... Нишләп болай бу?

Хәтсез еллар элек, университетка документлар тапшырырга килгәч, ул бер апаларда фатирда торган иде. Урамны белсә дә, йортны тәгаен хәтерләми. Ләкин ныклап эзләгәч табар бәлки.

Бераз баргач, тагын диварга сөялде, тагын кешеләр шикләнеп уздылар. Әлбәттә, чит-ят кешеләр. Танысалар, алай алама уйламаслар иде дә бит, ләкин ул чынлыкны, күңелендәге изге уйларын, ниһаять, авыр хәлен беркемгә дә белгертә, күрсәтә, исбат итә алмый. Әгәр Фәнүсә янда булса: «Гомер буе шулай булды», — дияр иде.

Болай озак түзә алмасына ышангач, бөтен көчен җыеп, урам читенә чыкты да машиналарга «тавыш бирә», кул күтәрә торды. Ким дигәндә ярты сәгать вакыт заяга китте. Инде тәмам егылам, ахрысы, дип курка башлаган бер мәлдә, бәхеткә каршы — яшел ут... Һәм машина туктады да. Нажар утырганын хәтерли, ә калганын чамалый, нинди дер тойгылар, сиземләүләр, фикернең табигый агышы ярдәмендә генә иҗат итә. Хакмы, ялганмы — ходай белсен.

Шунысы бәхәссез, иртән уянып китсә, ул — больницада... кабул итү бүлмәсендәге агач кушеткада үлгән кош белән бергә ята...

Үзенең кайда икәнлеген төшенгәнче үк ак канатлы фәрештә шикелле бер апа килеп җитте дә канатлар тиз арада халатка әйләнде. Апа әйткәнчә, Нажарны төнге уникедә бер таксист китереп киткән, имеш.

Фәрештә апа врач сезне уянгач карарга вәгъдә итте, хәзер киләчәк дип, бераз көтәргә кушса да, Нажар ризалашмады, хәл алырга мөмкинлек биргән өчен рәхмәт әйтте дә тизрәк чыгып китте. Врач караса, ятарга калдыруы ихтимал, дип курыкты ул. Ә бит аның әле больницаның тышкы ягындагы дөньяда эшләре бар...

Аякларда чайкалмыйча гына торырлык хәл кергән иде. Хикмәт, әллә тамак шешеннән дарусыз-нисез дә терелеп була инде?

Урамга чыкса, дөберди-дөберди яңгыр ява икән. Тагын бер җайсызлык — иртән туктамаган яңгыр кич тә туктамас. Ярый, дөнья сиңа бүген менә шушындый көн генә тәкъдим итә ала, тик кадерен белгән кешегә бәләкәй байлык түгел бу — кырлар суга туена, яфраклар, кыяклар... соңгы агудан арына... Яу, яңгыр, яу, тагын ашыгыч рәвештә таксига утырырга мәҗбүр итсәң ит, әмма яу, озак-озак итеп яу.

Автомобильгә утыра алуның реаль шартларын белү нияте белән кесәләрен тикшерсә, анда бер сум да сиксән тиен вак акча калган иде. Кичтән өч сум иде. Димәк, кичәге таксист акчаны кесәдән үзе алып,

тиененә хәтле дөрес кайтарган, димәк ки, бер сум да егерме тиенлек кенә урам гизгән Нажар. Кайларда булды икән?

Үзлегеннән чыккан беренче нәтиҗә: хәле киткәч, аны таксист больницага китереп куйган. Ярый әле, урамда очраган кайбер кешеләр кебек исерек белән бутамаган да төн буе яуган яңгыр астында калдырмаган. Молодец. Тик аңа хәзер ничек әйтергә рәхмәтне?

Психологик эксперимент биргән икенче нәтиҗә белән чикләнергә, дөньяда рәтле кешеләр күп бит дияргә туры килә. Бу инде кечкенә яңалык түгел, мондый ачышлар күбрәк, күбрәк ясалсын, чөнки алар агудан курыкмый башлаган күзәнәкләр табылудан куанычлырак!

Нажар, Фәнүсә эшкә киткәч, бераз өйдә ял итәчәк, анда аны тынычлык, тынлык каршылаячак. Тик шунысы бар: институтта ничегрәк каршыларлар икән? Анысы секретарь кыз карашыннан билгеле булачак һәм...

*

* *

Һәм кыз күтәрелеп тә карамагач, хәтта сәламгә дә Әпәнекеннән аңлаешсыз ымлыклар белән җавап кайтаргач (сөйләшә алу кадерен адәм баласы, әй, аңламый, белми ләбаса), эшләрнең торышы тиз ачыкланды. Ләкин Нажар монда бу юлы җиңелү белән ризалашыр өчен килмәде, ә хәлне үзенә буйсындыру нияте белән килде һәм ул теләгеннән тиз генә тайпылмас. Үз-үзен сынамак өчен Нажар кызга юри якын ук килде дә сер әйткән шикелле:

— Бүлмәгез шактый ук караңгы икән, — дип пышылдады, ягъни үзенең сакланып калган сөйләшү сәләтен тулысынча дөньяга чыгарды һәм эксперименталь рәвештә аңа бәя көтте. Нәтиҗә куанычлыга охшамагач, ягъни игътибар җәлеп итә алмагач, — җитмәсә, салкын да икән, — дип өстәде. — Әллә котыптан ук кайткансыз инде?

— Котыптан, котыптан!

Ярый, булды, якын киләчәк бөтенләй үк өметсез түгел икән әле. Нажарны секретарь кыз ишетә ала икән, җайсыз булса да көрәшергә мөмкин дигән сүз бу. Нәтиҗә шул. «Рәхмәт, иҗтимагый көзгем, аңлашылды».

Уйларының беркадәр өлешен секретарь кызга баягы ысул белән бераз пышылдаган иде, кыз моны үртәү, мыскыллау дип кабул итте булса кирәк, гарьләнеп, урыныннан ук сикереп торды:

— Тавышын гына карагыз сез аның — ысылдапмы-ысылдый! — дип зәһәрләнде.

«Булды, булды! Моннан да шәбрәк нәтиҗәгә хәзергә исәп тотарга мөмкин дә түгел». Нажар җыелышка соңга калганын чамалап, тиз генә ишеккә чумды.

Директор бүлмәсендә мини совет инде башланган һәм анда күп дигәндә җиде-сигез кеше утыра иде. Вәкил нотык сөйли. Кешеләр үзенә игътибар итмәсен өчен, Нажар башын аска иеп, шома гына кереп, иң якын урындыкларның берсенә утырды да тыңларга кереште. Колак салгач ук башка килгән фикер: «Бу сүзләрне кайда ишеткән идем соң әле?» дигән сорау булды. Ары тыңлыйк.

— Бөек конгресс карарларын тормышка ашыра барган бөтен халык белән берлектә, безнең ашламалар һәм химикатлар заводы коллективы яңа үрләр яулый. Беренче квартал планы йөз бөтен уннан бер процентка үтәлде. Сезнең белән союзда яшәү җимешләре татлы да, мул да. Хөрмәтле дуслар, сезнең галимнәрегез уйлап чыгарган теория буенча безнең завод кешеләре яңа төр химикат — авыл хуҗалыгы корткычларын тоташтан кырып салу белән бер үк вакытта, файдалы микробларга һәм бөҗәкләргә, кошларга һәм җәнлекләргә зыян китерми торган тыл-

сымлы агу житештереп килә. Мондый уңышка дөньяда беркемнең дә ирешкәне юк иде әле. Бу олы һәм уртак ачышыбызның сездәге авторларын — директор исемен, мөдир исемен, Фәнүсә Зәбирова исемен атау миндә зур канәгатьләнү тойгысы уята. Бу хөрмәтле иптәшләргә һәм алар йөзендә бөтен институт коллективына кайнар рәхмәт һәм сәлам тапшырырга рөхсәт итегез, иптәшләр. — Кул чабулар өмет итеп бераз торгач һәм өмете акланмагач, сүренкәрәк тавышка күчте. — Шунысын да хәбәр итәм, иптәшләр, сезнең ачышыгыз нигезендә техниканы үстерү, хезмәт житештерүчәнлеген күтәрү заданиесен үтәү юлында, әлеге химикатны тагын да күбрәк житештерү максаты белән, без автомат цех оештырдык.

Бүлмәдә утыручылар Вәкилне — агуга жайлашкан уникумны — чынлап тыңлыйлармы, әллә кунак булганлыктан әдәп кенә саклыйлармы икәнлеген белү кыен иде. Әгәр чынлап булса, бу мәйданда кылыч күтәрү жайсызлаша—дүрт яклап та сугышырга туры килә. Андый хәлдә жиңүгә исәп тоту жайсызрак. Шуңа күрә Нажар мәжлеснең үзенә карашын сынау өчен кечкенә укол ясарга тиеш булды:

— Бездә ачыш ясалмаса, алар техниканы үстерү турында уйлыйсы булмаганнар — менә бит нинди шәп кешеләр без!

Бөтен мәжлеснең Нажарга борылып каравыннан чамаласаң, мөгаен, аны ишеттеләр. Аңладылармы, юкмы, әйтү кыен, әмма ишеттеләр. Ә аңлатыбрак әйтергә әле вакыт бар... Сөйли бирсен Вәкил:

— Сезнең институт хакында шундый яңа хәбәр ишетеп тә куандык. Мөдир иптәшнең — минем яшьлек дустымның — бөтендөнья симпозиумына баруы бик ихтимал икән. Үзебезнең белгечләр һәм барлык эшчеләр исеменнән мин аның совет фәне абруен тагын да югарырак күтәреп кайтачагына ышанам һәм аны жибәрергә тәкъдим итәм. Институт житәкчелеге бу тәкъдимне яклар дип чын күңелдән ышанам. Әгәр сүзләрем шик тудырса, иркен кырларга чыгыгыз — анда сезнең белән безнең дуслык, фән белән производство дуслыгы мул игеннәр булып шаулый.

Вәкил утыргач, хәерлегә каршы, Директорның залда утыручылардан фикер соравына карамастан, беркемнең дә сүз әйтергә ашыкмавы аркасында, аптырашлы тынлык урнашкач, әйтергә кирәк, жайлы форсаттан файдаланып, Нажар кул күтәрде дә аңа шунда ук сүз дә бирелде.

Бераз ис жыйган мәлендә, Нажарның башында: фикерләремне туплый, аңлата алырмынмы дигән гадәти сорауны «ишетерләрме?» дигән сорау алыштырган иде. Ишетерләрме?

— ,Мин әле генә иркен кырдан, фән белән производство дуслыгы шаулап үскән басулардан кайттым...

Бүлмәдә — жиде-сигез кеше, жидесе жиде яктан пырхылдап жибәрде. Әлбәттә, Нажарның тавышы гажәпләндергәндер аларны. Ләкин нәрсә әйтте ул дип күршесенә колак сузучы күренмәгәч, чебен очкан тавыш яңадан ишетелә башларлык вакытны янә көтәргә тиеш тапты. Секретарь кыз бәяләгәнчә, ысылдау сагайткандыр кайберәүләрне, шом куз-гаткандыр, бәлки әле теге көнне Фәнүсә ваткан пробирка тапталгандай, кемнеңдер теше дә чагылгандыр. Ләкин хәзер нәкъ менә шушы кирәк, шулай кирәк!

— Ләкин анда безнең институт белән сезнең завод дуслыгы бик үк куәтле шауламый.

Нажар тагын да тырышыбрак гыжылдагангамы, күзләрдәге гажәпләнү бер мизгелдә нидәндер курку, сагаю галәмәтләре белән алмашынды. Ләкин барысы да сүз көтеп карый, димәк, аны ишетәләр. Кайберәүләрнең үзара Нажар кебек пышылдашып алуын Нажар ишетмәгән кешегә ишеткән күршесе «тәржемә итә» дип кабул итте. Монысы да ул хәтле үк өмет өзәрлек сәбәп түгел. Аны аңлаячаклар...

Секретарь кыз Директорга ниндидер язулар кертте дә шулай ук пышылдап кына ниндидер хәбәр әйтте. Шул рәвешле, бүлмәдә пышылдап

сөйләшү бик сәер яңгырамый башлады. Нажар дәвам итә ала, бу минутларда — Нажар үзе яңалык, күзләр аңа төбәлгән.

— Кичә газетада бер кызыклы мәкаләгә тап булдым.

Кызык дигән сүз ишеткәч, секретарь кыз каккан казыктай катып калды, шып тукталды, колакларын торгызды. Нажар аның өметен дә акларга тиеш хәзер.

— Базар. Азия базары. Ит сату павильоны.

— Азиядә ит бармыни? — Секретарь кыз уйламаганда мәзәк сүз әйтеп ташлавыннан үзе дә аптырап калды, күзләрен чет-чет йомгалап Директорга карады.

Директор:

— Тсс, абыйларыңа комачау итмә, — дип ачуланмыйча гына әйткәч, әүвәлгечә бик зур игътибар белән тыңларга кереште.

— Павильонга читлектә зур бер бума елан китерәләр. Сатып алучы, әлбәттә, табыла. Хакын килешәләр. Сатып алучы тиздән еланны алып китәчәк һәм иң әүвәл аның мәгърур башын кисеп атачак та, гәүдәсен матур гына кисәкләргә кискәләп, казанга чумдырачак. Күп тә үтми, хуҗабикә елан итен тәрилкәләр белән сөекле балалары алдына тезеп куячак. Еланның киләчәге бәхәссезме?

— Бәхәссез булса соң? Безнең экспериментның монда нинди катнашы бар? — Шулай сорарга ашыкты Нажарның үз файдасына сөйләмәячәген сизенгән Мөдир. Инде бу яңа хәлдә аның калын, көчле тавышы сәер ишетелде.

Зур тырышлык белән яуланган форсатны ычкындырмас өчен, Нажар ашыга төште:

— Сату-алу тәгәлләнде дигәндә генә...

— Әй, кызык та!..

— Рәхәтләнеп көләбез! — дип кызның түземсезлегеннән файда чыгармакчы иде Мөдир дус.

Ләкин башкалар аңа «әдәпсез!» дигәнрәк мәгънә белән карагач, һәм Директор да:

— Тсс! — дип бармаклары белән өстәлгә чирткәләгәч, Нажарның сәер пышылдавы янә законлы көч алды.

— Шушы күренешне читтән күзәткән миһербанлы бер галим, еланның күңелле үк булмаган киләчәген үзгәртмәк булып, ягъни дип әйтик, кызганып, хуҗага әлеге сатып алучыдан күбрәк акча биреп, бума еланны читлеге-нисе белән бая без әйткән кебегрәк кырга, тын дөньяга алып китә дә иреккә чыгармакчы була. Шулай, еланны — иреккә! Читлек капкачын ача да карап тора бу. Бума елан әкрен-әкрен генә шуа, шуа, шуа да һәм... миһербанлы галимне әләктереп тә ала.

— Ай!

Бүлмәдә урнашкан дәһшәтле пышылдау-ысылдауларны үтә кисеп, секретарь кызның ихлас кычкыруы яңгырады.

Кыска гына бер аңлашылмас мизгелдән соң кинәт кенә тагын бөтенесенең берьюлы кычкырып көлеп җибәрүләре Нажарның үзе өчен үк күңелле тоелса да, аны шунда ук: «Ары табан тыңларлармы?» — дигән сорау да каушата язды. Иллә мәгәр каушарга вакыт юк иде инде. Ачу оятнан көчлерәк булганлыктан, ул ярсыну дәрәҗәсендәге кайнарлык белән, баягыдан да зәһәррәк пышылдау белән, шом таратырга керешге.

— Бума елан үзенең мәңгелек гамәлен кыла! Буа, буа, буа кешене. Ә кеше нишли? Нишли кеше?!

Секретарь кыз бөтен мәҗлеснең кәефен бер кычкыруга сыйдырды:

— Кача кеше, качсын тизрәк!

Кешеләр еланга карап сихерләнгән шикелле шым тора биргәнгә, Фәнүсә, иренә ярдәмгә килмәкче булып, шулай ук еламсырап кычкырды:

— Ярдәм сорый кеше, ярдәм!

— Дөрес, ярдәм сорап кычкыра кеше, кычкыра гынамы — акыра, акыра гынамы — үкерә, улый, ләкин ишетүче юк.

— Үтерә, үтерә бит, ай, коткарыгыз! — Бу исәр аваз, әлбәттә, секретарь кызның гүзәл иреннәре аша узган чакыру авазы иде.

Шунда мәҗлесне уенга борырга җай чыкканны дөрес чамалаган Мөдир рәхәтләнеп көлеп җибәрде:

— Менә ичмасам кызык, әй, кызык та инде. Нишләп көлмисез, җәмәгать?

Ләкин Директор, җитди тавыш һәм кыяфәт саклап, киңәшмәне үзе теләгән максатка буйсындыра белде:

— Төшендек. Көлергә — чак кына иртәрәк, өлгерербез. Төшендек. Зәбиров безгә менә ни әйтә: бездә гадел фикерне, табигатьнең үз тавышын күзгә күренми торган бума елан буа, кычкырабыз — ишетүче юк. Монысы — сүз. Ә факт? Бармы факт?

— Факт? Рәхим итегез.

Нажар портфеленнән төргәк чыгарды да ул төргәк, кулдан-кулга күчә торгач, Директорга барып иреште һәм Директор аны чишеп карасa, Маяковскийча әйткәндә, кулына бомбамы, минамы эләккәндәй берара югалып калды да, аклы-күкле булып үзгәреш кичергәч, ачуын көчкә тыеп, дәһшәтле кырыслык белән Нажарга бер генә сорау бирде:

— Нәрсә бу, Зәбиров?

Хикәянең кызык тәгәлләнмәвеннән бигрәк, начальнигының ачулы кыяфәтен күрергә яратмаганлыктан, секретарь кыз тиз генә үз ягына чыгып китте. Мескен баланың кызык ишетергә дигән матур теләге тормышка ашмау бик кызганыч иде.

Вакыйганың үсеш сызыгын дөрес тойган Мөдир аңлашылмаучылыкны үз кирәгенә бору мөмкинлегенең әле өзелмәгәнлеген күреп:

— Иптәшләр, күрәсезме, ул хәтта иптәш Директорга ихтирамсызлык күрсәтә, ә без аны җитди рәвештә тыңлап утырабыз, — дип баш чайкады. — Белмим инде, белмим.

Директор кулында чынлап та үлгән кош иде. Директор чынлап та нишләргә, нинди карарга килергә икән дигәндәйрәк, шактый вакыт аптырап утырды. Хәзер ул ничек әйтсә, мәҗлеснең соңы шулай бетәчәк. Шуңа күрә мәҗлес халкы озак шауламады. Күзләр Директорга текәлеп калды. Ләкин Директор август басуында да агулана алган бәхетсез кошка тиешле бәяне әле бирмәстән соравын гына кабатлады:

— Зәбиров, синнән сорыйбыз — нәрсә бу?

Нажар үзе дә сизмәстән бая (сөйләп бетерергә өмет өзептер, мөгаен) утырган булган икән — яңадан торып басты. Һәм соңгы сикерешкә җай тудырганнары өчен күңелендә рәхмәт тойгысы кичереп, Директор өстәленнән кошны тиз генә үз кулына алды:

— Куркыныч нәрсә — бу түгел! Куркыныч нәрсә...

— Иптәшләр, кемгә сүз бирдек без, туктатырга кирәк! — Мөдир инде кайнарланып ук бара һәм аның тынгысызлануы Нажарга көч кенә өсти иде.

Нажар күкрәгендә җыйналып ташка әйләнгән нәрсәләрне кыюрак атарга тотынды:

— Безнең хөрмәтле мөдиребез, экспериментны инде тәгәлләгән исәпләп, ачыш инде ясалган дип, бөтен дөньяга игълан таратырга кереште.

— Кем сөйли, ник ул кычкыра, ник?! Томаларга кирәк! — Мөдир тәмам каушады.

— Ләкин ашыктың, иптәш мөдир, ялгыштың: бернинди ачыш юк, бары тик метафора гына бар. Яшел тавыш, кызыл тавыш... Музыкада бар бит төсле тавышларны натураль күренешкә күтәрергә тырышкан кайберәүләр, нишләп алар фәндә булмаска тиеш? Безнең дә шундый кешебез бар һәм аңа мәйдан кирәк — бөтен дөньяга күренеп торган фән биеклегенә мүкәйләп булса да менеп җитәргә кирәк аңа!

Нажар сулышын тигезләр өчен тынган арада Мөдиргә Директор ярыйсы ук кырыс караш ташлап:
— Эксперимент төгәлләнмәс борын эшне туктатырга кем сезгә рөхсәт итте? — дип сорады.
— Иптәш Директор, Александр Иванович, ул бит инде төгәлләнгән— Зәбиров юри нәтиҗәсен генә бирми, юри суза. Һәм мин аның максатын сизәм, әлбәттә.— Мөдир бу сүзләрне утырган килеш кенә башласа да, соңыннан басып та ишеттерә алмагач, үпкәләгәндәй тагын утырды.
— Мөдирнең дөньякүләм әһәмиятле ачышы — менә шушы,— дип Нажар кошны өстәлгә куйды. — Хөрмәтле Вәкил сөйләгән тылсымлы химикатның, корткыч бөҗәкләргә үтә дә шәфкатьсез, ә файдалы бөҗәкләргә, җәнлек һәм кошларга искиткеч шәфкатьле химикатның гүзәл гамәле дә — шушы. Нишләргә икәнен үзегез хәл итегез.
Нажар утырган арада ук, башкалар сүз әйткәнче аларга тема бирер өчен Мөдир бераз өметсезрәк хәлдә дә атып калырга ашыкты:
— Нажар дус, син теге ресторандагы шау-шуны сөйләсәң кызыклырак булмас иде микән? — дип көләргә тырышты.
Ләкин уңышка ирешә алмавы мәҗлеснең ул хакта авыз чайкарга теләмәвеннән бик тиз күренде. Директор фикер алышуларга вакыт бирмичә, турыдан-туры тәкъдимгә күчкәч, һәм, җитмәсә, тәкъдимне үзе ук керткәч, Мөдир өстәлгә үк посты.
— Шулай итеп,— диде Директор утырган килеш кенә сүзгә керешеп,— безгә ике тәкъдим керде. Болай: «Эксперимент инде төгәлләнде дип исәпләргә һәм шул хакта доклад ясау өчен бөтендөнья симпозиумына үзебездән бер иптәшне җибәрергә». Бу тәкъдимне Фәнүсә Зәбирова кертте һәм аны тагын бәгъзе берәүләр яклый. Читтән телефон шалтыраулар да булды. Үзегез ишеттегез, хөрмәтле Вәкил чыгышына карaганда, хәтта бөтен завод шушы фикерне куәтли икән. Бусы — бер. Икенчесе — Нажар Зәбиров тәкъдиме: «Организмның агулы матдәләргә җайлашу процессын гомум планда өйрәнүне дәвам итү». Беренче тәкъдимне тавышка куям. Кем аны яклый, кул күтәрүегезне үтенәм. Тавыш бирүче, тавыш... бармы тавыш бирүче? Юк. Кемнәр каршы? — Куллар дәррәү күтәрелә. — Битарафлар кемнәр? Битараф юк. Иптәш Зәбирова, хөрмәтле Мөдир, тәкъдимегез бертавыштан кире кагыла.
Мөдирнең чырае — көл, хәтта ул калтырый да кебек иде. Нажар аны мондый хәлдә беренче тапкыр күрә — димәк, хакыйкать аңа барып җитте — аны ул да ишетте... Әйе, Мөдир инде үзенә хыянәт итәргә — каушарга мәҗбүр:
— Мин яулаган путевка белән симпозиумга Зәбировны җибәрсәгез, мин катгый протестую,— дип куйды ул.
— Нишләп сез яулаган путевка?
— Әгәр мин кайбер кешеләр белән сөйләшмәгән булсам...
— Төшендек. Рәхмәт—без аны лаеклы файдаланырга тырышырбыз. Шулай. Изге вакытны мәгънәсез бәхәсләр, дипломатик интригалар белән харап итәргә тырышучылар безнең үзебездә дә җитеп арткан — яңалары таләп ителми. Шуңа күрә, иптәш Вәкил, сезнең безгә эшкә күчү теләгегезне яклый алмыйбыз.
Директор мондый сүзләрне әйтә алыр һәм тәгаен хәзер әйтер дип көтмәгәндер, әлбәттә, Вәкил, кинәт кабынып, аклы-күкле төскә керде:
— Ничек дидегез? Ничек?
— Киңәшмә тәмам, фикерләрегез өчен, тәкъдимнәргә карата биргән тавышларыгыз өчен рәхмәт, иптәшләр!
Кешеләр кузгала, таралыша башлагач, Вәкил үзен ишетсеннәр өчен кычкырырга мәҗбүр иде:
— Шулаймыни? Мөдир туган, син бит иптәш Директор инде риза, приказ гына бирәсе калды дигән идең түгелме соң?

— Бу хәлдә мин — көчсез, соңыннан сөйләшербез. — Мөдир чыннан да урыныннан кузгалып китәргә дә көч таба алмыйча утыра иде.

— Менә ничек! Сабакташыңны иң авыр чакта, ярдәм итәм дигән булып, яман максатыңа хезмәт иттерден дә...

— Үтенеп сорыйм, ялгышма, ашыкма!

Ялгышларымның бәясен чыгартам болайга киткәч.

— Дустым, кадерле дустым!

Директор әшнәләр кычкырышуын һич тыймыйча, елмаеп ук тыңлаганда, ә Фәнүсә һични аңламыйча һәм аңларга теләмичә аптырап торганда, Нәҗарның башында гаҗәеп яңалык бөтерелә һәм сикергәли иде: «Ишеттеләр, ишеттеләр, аның тавышсыз кычкыруын ишеттеләр!»

Шатлык гомере — бер мизгел. Фәнүсәнең аңлый алмау газабын, житәкченең елмаюын, дуслар якалашуын, җиңүче тантанасын — бөтенесен берьюлы чәлпәрәмә китереп, телефон шалтырады һәм трубканы Директор алды:

— Тыңлыйм. Каян? Подсобныйдан? Нинди хәл? Что сез! Ә?! — Трубканы куеп, янында торган кешеләрнең барысын берьюлы каушатып, яңа хәбәр әйтте. — Анда безнең ярдәмче хуҗалыкны су басҡан, елга ташый ди.

— Елга? Нишләп? — Фәнүсә Директорның беләгенә чытырдатып ябышты.

Нәҗар, күптән түгел генә ничек янына барырмын дип баш ваткан Нәҗар, хатынын җитәкләп алды:

— Тизрәк, тизрәк, киттек!

Мөдирнең:

— Автобус бар микән инде? — дигән соравына каршы Директор:

— Аста — минем машина. Ашыгырга кирәк,— диде.

*

* *

Янгын бер шырпыдан, ә ташкын тамчыдан башлана. Тып-тын торган бер шырпының нинди янгынга, ә бер тамчы суның нинди туфанга әверелачәгенә зиһен башта ышанмый тора. Ләкин соңыннан үзең дә ничек ышанмадым икән дип шаклар катасың. Күз алдында өй яна, авыл, шәһәр. Буа китә — болынны, авылны су баса, каралтылар, өйләр ага.

Елганың иске җыпкысында былтыр ясалган күл, төн һәм көн буе яуган яңгырдан мөлдерәмә тулып, тигез урыннан бәләкәй генә, зәгыйфь кенә ерганаклар ярды да, ким дигәндә илле метр чамасы ара узып, башта биелгы чокырга кушылды. Аннары тагын көн буе яуган яңгырдан икенчесе, өр-яңасы да тулып, анысы да каләм сызган сызык шикелле юлдан, елга ярыннан сикергәли башлады. Тамчылар шулай сикерә-сикерә әүвәл кечкенә гөрләвеккә, ә аннары шактый ук олы шарлавыкка әверелде.

Елганың борылманы яратмавы, шунда ярны туктаусыз сөзә торуы һәркемгә мәгълүм. Шулай сөзә торгач, ул да өске ерынтыларны кочагына ала торуы белән бер үк вакытта, былтыргы күлгә үзе дә бик астыртын гына омтылган, тоташа ук язган булып чыкты — күлләрнең икенче яктагы ерганаклары юл ярган мәлдә үк, ул да иске, урау юлына хыянәт итте, башта әкрен-әкрен, кыюсыз, ояла-ояла гына, ә соңынтын... Соңынтын ни булганы — күз алдында. Тамчылардан, бары тик тамчылардан гына башланды.

Кемнәрдер аларга ышанырга теләмәде...

Ә тагын кемнәрдер хәтта үзенә тәгаен бирелгән әмерне ишетмәскә җай тапты...

Барлык афәтнең башы — шуннан.

... Елга.

Елганы юеш карангылык йотты.

Мыштым су һич үкерми, җәнлекләр чинамый, тик кешеләр генә кычкырыша — колак ертырлык тавышлар ниндидер шәүләләр белән бутала.

Карангылыктан Каравылчы, Прораб һәм Әпә белән Энже чыкты.

— Абый дим, Әмән абый, әйдә тизрәк! Алар исән әле, коткарыйк ничек тә, абый! — Энже шулай көйләп-көйләп, Каравылчы җиңеннән тарта.

Кулларын аңлаешсыз бутап, Әпә ялвара:

— Эһ, ме-эм-эм! А-а-а!

Каравылчы балаларны төрле әмәлләр, өметләр белән тынычландырмакчы, ләкин кая ул, сабыйларга түгел, аның үзенә бу минутларда мең ярдәмче кирәк.

— Төшеп булмады шул, балалар, күрәләтә базга төшәргә йөрәк җитмәде. — Шулай ди дә Прорабка бармак төзи: — Әнә ул гаепле — шуның аркасында бетә дөнья!

Прораб исә оятсыз тынычлыгы белән картны тагын да котырта гына төште:

— Күпме еллардан бирле нихәтле акча түләде сиңа хөкүмәт и институт. Нәрсә өчен? Карап торып бөтен байлыкларны суга батырыр өченме? — Дөньяга төкереп, үз юлы белән китеп тә бармакчы иде бугай, тик Каравылчы аның изүеннән эләктерде.

— Ә сиңа ни өчен? Тугайны җимереп, елганы юлдан яздырып, бакча өстенә ташландырмак өченме?

Әмма Каравылчының өстенлеге Прорабның бер селтәнүе белән юкка да чыкты. Һәм бер аягы белән кай арада җиргә тезләнеп калган картка Прораб инде югарыдан карап үзе сабак бирә иде.

— Миңа бәйләнергә бернинди правагыз юк! Мин каравылчы түгел, минем профессия — бүтән, җәнлекләрегез, кошларыгыз миңа кагылмый.

Олылар мәгънәсез кычкырышса, балалар түземсез шыңшый, сикергәли торса, елга исә һаман шым гына ага бирде. Ниһаять, җәнлек тавышлары бөтенләй ишетелми башлагач, Каравылчы, түземен җуеп, Прорабка мылтык күтәрде:

— Менә минем права! Барасыңмы, юкмы? Төшәсеңме суга?

Прораб мылтыкны күрмәде дә шикелле, баягыдан да оятсызрак акырды:

— Җәнлек ул на то җәнлек — чыксын үзе йөзеп.

— Бикле бит алар, бикле, читлекләр йозаклы!

— Әпә, әйдә киттек, ачабыз! — дип яр читенә килеп басты Энже.— Әйдә!

— Ыһ-ыһ-ым-ыһ!

— Әйдә, берәр ничек җимерәбез, Әпә! — Кыз Әпә каршында кулларын бутый-бутый ялвара иде.

— Ым-ым-ма, уфф!— дип нәрсәдер әйтмәкче була тегесе дә, су салкын бит димәкче әллә?

Юк, ул җиргә бәргәләнә-бәргәләнә еларга тотынды. Ауный-ауный елады-елады да, Энже дә көтмәгәндә кинәт сикереп тә торды һәм... ярдан суга очып та төште. Аның артыннан ук шаулап торган карангылыкка Энже дә шуып китте. Каравылчы зиһененә аларны тотып калырга кирәклеге килеп өлгергәнче, балалар юкка да чыктылар.

— Бетте, беттеләр! — дип бөтен көченә капыл әрнеп кычкырды Каравылчы һәм лып итеп җиргә утырды.

Инде аңа күрәләтә балаларны суга төшергән өчен шул ук Прораб үзе бәйләнергә керешкәч исә, бөтенләй телсез калды. Аннары, әкрен генә торып, яр буена килде, кычкырып карады, арлы-бирле йөренде, лә-

кин тавышы кайтаваз булып та ишетелмәде — бөтен ялвару-вәгазьләре караңгыда бата, чума торды. Тыннары-көннәре беткән Нажар, Фәнүсә һәм Мөдир нәкъ шушы вакытта килеп җиттеләр.

Җитә җитүгә Мөдир барлык тавыш җепсәләрен берьюлы киереп, соңгы тартылышларына хәтле эшкә кушты:

— Ни карап утырасыз, ни көтәсез? Нишли җәнлекләр?

— Җәнлекләр! — Каравылчы, хатын-кыздай үрсәләнеп, җиргә капланды. — Аңа җәнлекләр кирәк!

Прораб кына ирләрчә ныклыгын, дәрәҗәсен төшермичә:

— Тагын бер командир табылды, ә суга берсенең дә төшәсе килми, — дип чәнечтереп куйды.

— Кайда Энҗе, кайда минем балакаем!

Каравылчы менә шушы сорауны калтырап көткән иде һәм ни өчендер балаларның кайда икәнлекләрен нәкъ үзеннән сорарлар дип уйлаган иде. Уйлаган алга килгән, шулай килеп чыкты да. Ул гаепле, бөтенесенә ул гаепле булачак хәзер! Ә Прораб? Бөтен афәтнең сәбәпчесе булган Прораб, тиздән үзенең хөкем алдына барып басачагын әллә аңламый, әллә судан коры чыгачагына ышана — кем әйткәндәй, мыегын да селкетмичә басып тора.

— Энҗе кайда дип сорыйлар синнән, кайда Энҗе? — Нажарның авыз ачып ябылганы күренмәсә дә һәм тавышы чыкмаса да, күзгә тәрәләрдәй булып, бөгелеп төшүеннән Каравылчы барыбер аның ни соравын аңлады.

Мескен ата, яр өстендә әйтерсең — балык, авызын ача-йома, ә су... су юк. Ә Фәнүсәнең хәле чак кына җиңел сыман — анысы ичмасам кычкырып бөтен җан ачысын тышка чыгара ала.

— Кайда Энҗе, балакаем минем!

Ниһаять, Прораб җавап бирергә тиеш тапты:

— Сикерделәр, суга, калганы билгесез, — диде.

Шуны ишеткәч тә Нажар тиз генә өске киемнәрен салды да үзе дә караңгылыкка чумды. Аның урнәгенә иярергә тиеш булган Мөдиргә Каравылчы йозакның кайда һәм ачкычны ничек табарга икәнен аңлатырга керешә. Тик Мөдир ярга якынлашкач та яңадан борылды да үзенә иптәшкә Прорабны — тапты бит ул да! — чакыра, димли башлады — әлбәттә, әүвәл яхшылык белән, ялынып, ялварып диярлек, ә соңынтын үртәлебрәк, ә тагы да бераздан бугазны баягыча бар көченә киереп тә тиргәште һәм ахырда инде:

— Бәдбәхет! — дип бер төкерде дә... эчкә таба йөзүдән башка чара тапмады.

— Бар, бар, су анасы белән әреплә ш! — дип кенә куйды Прораб монысына каршы.

Шуннан соң, әгәр Каравылчы мылтык төзәмәсә, ваемсыз гына кыяфәт белән яр өстенә үк менмәкче иде. Тик карт аның каршысына ук килеп:

— Үрә кат, селкенмә! — дип кычкыргач, тукталды, чөнки Каравылчының үзен белештермәс дәрәҗәдә ярсыганын чамалаганга күрә, эшнең ни белән бетәсе дә билгеле түгел, шушы хәерсез төн шикелле караңгы иде. Әмма билгесезлек озакка бармады. Каравылчының бераз тынычланганын, үз акылына кайтканын тоеп, яңадан кузгалды:

— Атып кара, башың ике булса, — дип куйды.

Каравылчы исә атылмас мескен мылтыгын кочаклап, аптырап утыра бирде. Кешенең көчсезлеген мылтык кына киметә алмаганын тәмам аңлаганга, тамагына су капмаса да, тончыкты һәм йөткерергә үк керешә. Буып торган ачуы Нажар судан чыккач кына ычкындырды.

— Кайда балам, кайда? — Фәнүсә шашкан кыяфәт белән Нажар каршына килеп басты.

Нәкъ шушы хәлне күз алдына китергән иде Каравылчы — Энҗе юк! Ә анасы ярга таба кулларын сузган да, ходайдан ярлыкау көткән гөнаһ иясе шикелле, билгесезлеккә ялвара:

— Кайда минем балам, баламны китерегез, кая куйдыгыз Энҗемне?!

Мөдир дә буш кул белән чыкты. Капкалар ачык икән, әмма, нишләптер, җанварлар урыннарыннан кузгалмаганнар... Һәм Энҗене ул анда шулай ук күрмәгән...

Хәл белән килешмичә, Нажар исә су күмгән утрауның аркылысынбуен кабат-кабат айкады — энә генә булмаса, теләсә нәрсә дә табылырга тиеш иде. Ә бала — юк!

Тәмам хәлдән тайгач, инде таң беленеп килгәндә, үләсен сизгән җәнлек кешеләр янына килүдән курыкмагандай, хатыны янына чыкты, буш кул, буш кул белән... Энҗене әйтерсең су йотты...

Моңа күнә алмаган һәм һич килешә алмаячак Фәнүсә сулыгып-сулыгып елый. Елый торгач, хәлдән таептыр инде, җиргә капланды ул. Бу вакыт хәрәкәт тә, акыл да, тойгы да тукталды — табигать кенә үзенең дәһшәтсез тын сулыш алуын дәвам итә иде. Аның куркыныч мәле инде узды — моннан да аламарак эшкә ул инде сәләтле була алмастыр.

Хәрәкәтне дә, акылны да, тойгыларны да кайгыдан исән саклый алган бердәнбер кеше бу минутларда Прораб кына булгандыр. Ул һәйкәлдәй нык иде. Атылган кош шикелле яткан Фәнүсәгә бераз гаҗәпләнеп карап торды да эре-эре адымнар белән китеп барды. Аны күргән бердәнбер кеше Каравылчы:

— Качты ерткыч, качты! — дип ыңгырашты.

Нажар сулышын ук җуйган хатынының баш очында тораташ шикелле тора бирде. Бу минутта кемнеңдер сүз әйтүе гайре дә табигый булуга карамастан, Каравылчы алар янында әйләнгәли торды:

— Ә мин кая барыйм хәзер? Нәрсә саклыйм? — шулай дигәч, мылтыгын җирдән алды да атып карады. — Бу ядрәләр кемгә тия?

Чак кына әйләндергәләп азаплангач, үртәлеп мылтыкны суга ыргытты да, ни өчен һәм кая икәнен, мөгаен, үзе дә белмәстән, чайкалачайкала атлап та китте.

Кызның табылырына, исәнлегенә өметләнергә һичнинди җай һәм сәбәп тә калмаган иде кебек. Нажар күпме генә интексә дә, хатынын җирдән аера, үзе белән бер рәттән бастыра, хәрәкәткә китерә алмады. Балаларын җуйган ата белән ана бу мәлдә кайчандыр булган рәвешләренең җансыз карачкылары гынадыр шикелле иде. Фәнүсә җиргә капланган башын көче җитсә дә күтәрергә теләмәс, үзенең кызы инде булмаган бу дөньяны күрергә теләмәс һәм үзен бу коточкыч дөреслеккә мәңге ышандыра алмас. Шуны аңсыз рәвештә генә чамалаган Нажар үзенең бармакларын чәйни... Бер иелә, бер тора, тагын хәрәкәтсез кала һәм...

Һәм менә ни булды: ул әйтерсең егылмас өчен, ике кулы белән лепкә турысыннан үзенең башына чатырдатып ябышты да тилергәндәй кычкырып җибәрде:

— Үтерделәр, үтерделәр!

Үзенең элекке, чын тавышы белән кычкырды Нажар. Үзенең элекке чын тавышы кинәт кайткан иде бу минутта. Кайдадыр яшеренеп яткан көчле, куәтле авазы ургылып чыкса да, бөтен тугайны, бөтен урманны, бөтен тирә-якны калтыратса да, ләкин ул ерактан бу төшкә кайтаваз булып та әйләнеп кайта алмады. Аны да, Нажарның дөньядагы иң сөекле, иң кадерле кешесен югалту исәбенә генә кабат бирелгән тавышын да караңгылык йотты. Көчле-куәтле тавышны беркем, беркем ишетмәде һәм ярдәмгә дә беркем килмәде.

Аның өчен бу минутта бөтен дөнья җимерелде, бетте кебек иде.

*
* *

Бер минут — хыял бар, икенче минут — хыял юк.

Лэкин дөнья... дөнья кала килә. Тик анда хәзер ничек ямь, мәгънә табарга? Кайда Энҗе? Исәнме? Кайчандыр булган кеше шулай җиңел генә бөтенләй булмагандайга әвереләмени? Бәлки кайдадыр ул элеккечә көлеп, йөгереп йөридер? Тик аны күрмәгән кешеләр өчен ул барыбер юк... Нишләп болай? Ничек кызның исәнлеген исбат итәргә?

Фәнүсә өстәлгә терсәкләре белән таянган да, кызының рәсеменә карап, аның шаярган, көлгән вакытларын тыңлап, хәтерләп утыра. «Әнием, бүген безнең контроль эш, ничек уйлыйсың, чишә алырмынмы икән? Әнием, бүген безнең мәктәптә танцы — ничек киеним икән? Бөтен кеше платформадан, мин генә... И әни, бердәнбер кызыңны теләгәнчә киендерә алмыйсың. Әни, бүген без походка чыгабыз, минем тәкъдим белән — сезнең бакчагызга. Андагы кебек җәнлекләр, кошлар, болыннар, урманнар бүтән бер җирдә юк, әнием. Әй, ямьле дә инде — гомерлеккә шунда калыр идем, мәңгелеккә!»

Әллә шунда баланың җаны мәңгелеккә калдымы? Бер минут — кеше бар, икенче минут — кеше юк... булмагандыр да кебек...

Лэкин дөнья кала килә, үзенең барча бөеклекләре һәм вaклыклары белән дәвам итә. Ваклыклар әнә ишек кыңгыравы рәвешле, түшәмнән коелган акбур валчыклары төсле коела торыр.

Вәкил икән — кайгы уртаклашырга килгән.

Күзләр теләсәң-теләмәсәң дә шкафлардагы рәсемнәргә төшә. Рәсемнәрнең икесе дә узган гомернең шәүләләре кебек. Кайгы рәвешләре. Югалырга мөмкин булганның барысы да югалды, хәтта өмет тә.

Фәнүсә белән Вәкил — бер өстәлнең ике ягында. Вәкил ничектер каушый, күзләре белән өмет эзләп ялвара һәм сүзләрен дә тизрәк әйтеп калырга ашыга.

— Килүем чит кеше буларак, Мөдирнең үтенече белән генә булса да, ул мине монда коточкыч түбәнлеккә дучар итсә дә, ләкин мин аңа рәхмәт әйтергә тиеш. Күпме еллар буе күрмәгән күзләрем ачылды, ниһаять, мин сине күрдем. — Менә шушы булды кайгы уртаклашырга килгән кеше сүзләре!

Әгәр җаваплашып торыр чак булса, Фәнүсә аның битенә бәреп менә нәрсә әйткән булыр иде: «Син — Мөдир чакыруын тыңлап килгән син, аны яклап иремә каршы тәкъдим кертергә котырткан син, син — ниндидер мизгелдә икеләнүем аркасында вөҗданымның җәрәхәтләнүенә сәбәпче, шул хәлемдә генә мине ярата башлаган кеше, шул ук вакытта үзеңә карата нәфрәт хисе уяна башлады дип күңелеңә уй килмәдеме?»

Лэкин Фәнүсә аның күзләренә сүзсез нәфрәт кенә орды. Әгәр аңлашылып та җитмәгән, хәтта сәбәпсез дә тоелган ачу һәм нәфрәтне аралап тагын ишек кыңгыравы шалтырамаса, тойгылар сүзгә генә түгел, бәлки хәрәкәтләргә дә күчәр иде. Ярый әле, аю карачкысы тоткан Каравылчы керде.

— Уф, ерак торасыз да икән, күзләр акайды, — дип түргә үк узды ул. Аптырабрак калган Фәнүсә аюны күрүгә гаҗәпләнеп, хәтта шатланып куйды шикелле. Карт моны сизми калмады һәм Вәкилгә ятсынып бераз карап торгач, аюның муеныннан кочты. — Хәлегезне белергә килдем, — дип өстәде.

— Рәхмәт, абый, әйдә узыгыз, утырыгыз.

— Энҗе ярата торган җәнлекләрдән бары шушысы гына калды. Кызык бит, әй? Кайда соң үзе, кайтып кермәдеме? — Фәнүсәнең күзләрендә коточкыч каушау күреп, соравын карт төзәтергә ашыкты. — Нажарны әйтәм. Энҗене эзли киттеме әллә?

Карт, әлбәттә, Вәкилне «күрми». Сөйләшүе — бары тик Фәнүсә белән... Фәнүсә үзе дә аңа шатланыбрак җавап бирә иде.

— Эзли шул, һич җуймый өметен. Өч көн буе су төбендә ятып та, исән калыр дип ышана, бичара.
— Ә син соң?
— Мин? Үзем исәндә... ул... — Фәнүсә бүтән рәтле сүз чыгара алмады, бугазына яшь тыгылды.
Аңа ярдәм итәргә тырышкан карт сүзне икенчегә борды:
— Ә бу кем?
— Бу?
— Бу булмыйча, тагын нинди бу?
— Бу...
— Мин — аның балалык дусты, бергә укыдык. — Вәкилнең тавышында горурлык галәмәте сизелгәндәй булды.
— Авылдашлар ягъни. Иллә мәгәр, шуңа да карамастан, ир югында бер бүлмәдә кала аласыз икән... Әгәр тере булса, мин сезгә бу аюны өстерер идем.
Фәнүсә чынлап та өстенә аю өстергәндәй курка калды:
— Абый, алай димә әле син, тыңлап кара. Мин аңлатып карыйм.
Каравылчы аюны кочаклап утырды.
— Тыңламый булмас.
— Мин сигезенчедә чакта, ул унынчыда укый иде.
— Шушы.
— Шушы ук түгел шул. Бүтән төслерәк иде. Минем яшь күңелем шуңарда иде. — Фәнүсә өстәлнең Каравылчы утырган ягына күчте. — Яратышып йөрдек. Шундый чакта ул, мәхәббәтенә түзә алмыйча, минем Почет тактасында торган рәсемемне урлаган.
Вәкил моңа каршы тиз генә:
— Ләкин хәзер дә гафу сорый алмыйм, — дип елмаерга тырышты.
— Урласа да, сурәтемне генә түгел, үземне дә калдырып, шәһәргә китте.
Фәнүсә тагын ни дә булса әйткәнче, Наҗар кайтып керде. Бер ялгызы. Башка сыймас мәгънә, дөресрәге, мәгънәсезлек тагын бар дәһшәте белән берьюлы аңлашылды һәм кешеләрне тагын бер кат ихтыярдан, телдән яздырды. Наҗар сүз башламаса, уйларга, кузгалырга куркып күпме утырырлар иде, әйтү кыен. Тик Наҗар:
— Елганың ике ягын да тикшереп чыктык. Инде калыккан булырга тиешләр иде, бераз хәл алгач, яңадан китәм, кыз исән булырга тиеш, — дигәч, бәлки аның бераз ясалмарак килеп чыккан тыныч сүзләренә каршы Фәнүсәнең:
— Исән булгач, кайда соң? — дип әрнүен тыяр өчен генәме, әллә Наҗарның тавышын ишетүгә чыннан да сөенепме, Каравылчы кычкырып җибәрде:
— Кара, кара, тавышың кайткан ләбаса, Наҗар!
Наҗар көн хәвефләре аркасында үзенең тавышы югалып торуын да, һәм аның табылуын да оныткан иде. Хәзер генә исенә төште.
— Әйе шул.
— Яле, кычкыр әле, бәгъзе бәндәләрнең колак пәрдәләре ертылсын,— дип кеткелдәде карт, сөенерлек бер хәл чыгуга куанып.
Фәнүсәгә генә шушындый зур ачыш та тәэсир итмәде — ул үз кайгысыннан да, Вәкилдән дә котылырга тырыша, хәтта ашыга һәм шунлыктан борчыла иде. Каравылчы тырышлыгына буйсынып, фикерләре зыянсызрак якка борылды. Беркемгә дикъкать итмәстән, менә нинди сәер сүзләр сөйләргә керешге ул:
— Минем беркемнән — иремнән дә курыкмыйча, теләсә кайчан сөйли ала торган гөнаһсыз хатирәләрем бар иде. Күңелемнең изге тынлыгыннан елмаеп торган егет бар иде.

Нажар, Фәнүсәнең үзен тотышы, чырае, соңгы сүзләренә карап, хатынын югалтып бетермәгәнлеген аермачык күрсә дә, күңелендәге ачуны барыбер тыя алмыйча, ачулы сүз ыргытты:

— Синең егетең үз каршыңда әле дә басып тора, тик елмаймый гына, — дип зәһәрләнде.

Әмма икенче яктан караганда, хатынын кыз хакында уйлатмый тору ысулы да иде бу сүзләр. Әнә, Фәнүсә чынлап әрепләшә башлады:

— Юк, бу егет — аны үтерүче.

Вәкил чынлап бирешергә җыенмый һәм шактый кыю (монысы да ясалмарак кыю) кылана иде. Фәнүсәгә якынлыгын иренә юри сиздерү өчен булса кирәк, үз кешеләрчә:

— Уйлап сөйлә, Фәнүсә! — дип кинәт «син»гә күчте.

— Хөрмәтле авылдашым, синең аркада минем хакта гайбәт сөйләделәр. Кайберәүләр хәтта ышанды да.

Ә «кайберәүләр»нең берсе булган Нажарның үз протестын игълан итәргә хакы бар:

— Ник ышанмаска?! Син бит «сугышның» иң кискен чагында дошман ягына чыктың — моннан да зуррак хыянәт буламыни? — Хәлнең нәкъ шулай икәнлегенә ныклап ышанганга һәм хатыныннан җавап та көтмәгәнгә күрә, чын ачу белән үрсәләнде Нажар.

Ә Вәкил үзенең Фәнүсәгә якынлыгы белән үрти бирде:

— Нажар дус, син нишләп шуны аңламыйсың — Фәнүсә үзе мөстәкыйль кеше ләбаса, фикер иреге, хатын-кыз иреге, ниһаять, шәхес иреге синең өчен җинаятьмени?

Үзенең беренче җиңүенә Вәкил ирешә диярга кирәк, чөнки Фәнүсә аның ярдәмен тулысынча кабул күреп:

— Нәкъ менә шул шул, хатынның шәхес буларак үзен яклавы иргә хыянәт булып чыкса, белмим инде, белмим, — диде.

— Ә мин сиңа, — дип, позициясен тиз арада ныгытырга да ашыкты Вәкил, — мин чын ирек вәгъдә итә алам.

Монысының инде артыгракны эләктерү икәнлеге Фәнүсәнең аңа баягыча мыскыллы каравыннан бик тиз һәм ачык күренде. Фәнүсә, ире каршында Вәкил белән үзенең нинди мөнәсәбәттә икәнен ахыргача аңлатырга, ишетелгән гайбәтләргә, тел сузуларга нокта куярга вакыт җиткәнен сизеп, чын мәгънәсендә эшлекле тавыш белән Вәкилгә тиешлесен әйтеп салды:

— Әгәр Мөдирнең курчагына әверелеп ресторанда адәм ышанмаслык кәмит иҗат итмәгән булсаң, ялган хатлар оештыра алырлык пычраклыкка төшмәгән булсаң, әгәр...

— Миемне, йөрәгемне ярып кара, бу гөнаһларның берсе дә миндә юк, — үзенең сентименталь ялганына үзе дә ихлас ышанган Вәкил шулай дип кычкырып куйды.

Ләкин Фәнүсәгә аның карашы инде кызык түгел, аңа соңгы хакыйкатьне ачу мәҗбүри:

— Ниһаять, шушы ялганны күзгә карап әйтә алмаган булсаң, элекке чибәр егет хәзер дә яшәр иде. Хәзер сиңа, нинди генә мескен хәлгә эләксәң дә, беркем дә ярдәм итә алмас һәм теләмәс.

— Гафу ит, Фәнүсә, теләкләрем гел изгелектә иде, гафу ит.

— Әшәкелеккә беркем дә ярдәм итәргә тиеш түгел.

— Фәнүсә, Фәнүсә дим, авылдаш, ашыкма, әйе, авылдашлык хакы да бар бит әле, әгәр яшьлекне инкарь итсәң дә...

— Оятка каршы — авылдаш...

Нажар, Вәкилнең кулбашына кулын куеп, элеккеге көчле тавышы белән:

— Сез дә кеше исемен йөртәсез бит, сезнең өчен безгә оят, — дигәч кенә Вәкилнең еракта калган тәкәбберлегә уяныл китте.

Ни кылырга белми чак кына интеккәч, куллары белән битен һәм күзләрен сыпырып куйды да, хикмәт, әйтерсең бөтенләй яңа битлек киде. Искитәрлек тыныч, рәсми кыяфәтне шул арада каян чыгарды диген! Мөдир дусты гына булдыра ала торган салкын олпатлык белән карап:

— Хушыгыз, әмма тәрәзәгезне саклагыз, тагын бер таш булачак,— диде дә, шулай ук Мөдир генә булдыра ала торган ныклы адымнар белән чыгып та китте.

— Мәхәббәт!

Ихтимал, Фәнүсәнең соңгы мәсхәрәсен дә ишеткәндер ул.

Озак вакытка сузылган гомум аптыраштан соң иң башта Каравылчы хәрәкәткә килеп, Нажар алдына аюны китереп куйды:

— Син аның җанын алдың.

— Нәрсә, нәрсә? — Нажар күзләрен йомгалады.

— Ә үзең энә очы хәтле бөҗәк тә иҗат итә алмыйсың.

— Мин кеше иҗат иттем.

— Син аны үтердең! — дип, кинәт тагын ярсып китте Фәнүсә.

Ә Нажар, гөнаһ шомлыгына каршы, үтермәдем дип кистереп әйтә алмый икән. «Барыбыз бер иш — чинау-янауларны ишетмәмешкә салышып, башларны мендәр астына тыгабыз, эндәшмибез, Әпә шикелле...» Хәтергә Әпә килеп, аны бигрәк тә нык каушатты.

— Әпә кайда? Ул исәнме? — дип сорады Нажар, теге кичтәге кебек үк каушап.

— Кайда соң ул? — Әйтерсең Каравылчы үзе дә белми.

— Су ташканда җәнлекләр янына йөзеп китте дигән идегез бит. Энҗе белән.

— Шуннан соң? Кем аны коткарырга тырышты? Кайсыбыз?

— Әпә? Кем соң ул Әпә? — Фәнүсә исә бөтенләй оныткан икән.

Каравылчы аңлатырга тиеш булды.

— Әпәме? Әпә — телсез, табигатьнең нәкъ үзе. Тик бер көн килер, ул тагын да катырак кычкырыр, өстебезгә аюдай ырылдап ташланыр.

Фәнүсә шулай ук яр буендагыча өзгәләнеп әйтте:

— Нишләргә соң безгә, нишләргә?

— Дөньяга бер Каравылчы кирәк бугай, тик кем ул — кайда? — Нажарның Фәнүсәгә биргән бу аңлатмасы белән Каравылчы ризалашмыйча:

— Минем кебек сизгер,— диде дә ишек янына килде.— Ярый, исән торыгыз.

— Туктагыз әле,— Нажарның күзләре ялварып карый иде.— Без рәтсезләр һаман үзебез турында. Синең хәл ничек соң?

— Билгеле инде, гаскәрен харап иткән генералны трибунал көтә.

— Балакаем!

Фәнүсә тагын Энҗе рәсеменә эндәшә икән. Аңа күз ташлап, Каравылчы баягыдан да ямансурак кыяфәткә керде.

— Вөҗдан атлы трибунал. Көн саен аса, көн саен кисә. Ә зарплата килә. Каравыллый торган бөтен мөлкәт шушы аю, сакласам-сакламасам да, урманга качмады. Аны бүтән беркем атмады да.

— Сиңа ничек ярдәм итәргә соң?

— Ә сезгә?

Каравылчының хушлашуы гүя мәңгелеккә иде... Өйдәге җимерек тормыш ул киткәч отыры таркалгандай тоелды. Шыксызлыкка, күңелсезлеккә, фаҗигагә үлгән аю үзенең кечкенә, ягымлы, елтыр күзләре белән гөнаһсыз җиңеллек сирпесә дә, җаннарны яктырта алмый иде. Шушындый хәлдә, бөтен булганнардан соң... тормышны яңадан башлап кара!

— Арага Вәкил кермәгән булса, бәлки...— Нажар эчтән генә кичерәм дигән уфтануын кычкырып әйткән икән. Аның сүзгә әйләнеп чыккан уйларына Фәнүсә үзенә хас булмаганча ямьсезрәк җикерде генә:

— Ник үзенә әйтмәдең? Ник аны миңа әйтәсең?

— Куып чыгарырга идемени?

— Теләгең булса, ку идең. Бөтенебезне. Нәрсә карадың вакытында? Хәзер философия башланачак — беләм мин сине. Ә бөтенесенә үзең гаепле, үзең тавышсыз!

— Тавышсыз? — Мең кабат ишеткән кушаматын беренче тапкыр ишеткәндәй уйланып, сызланып торгач, Нажар бөтен көченә кычкырды.— Бар, бар минем тавышым, бөтен дөньяга яңгырый!

— Әйе, бу — тавыш, тик син аны артык соң таптың.

Бәхәстә соңгы сүзнең һәр вакыт хатын-кызда кала килгәнен белгәнгә күрә, Нажар бүтән әрепләшмәскә булды һәм үзенә көн саен кирәк була торган вак-төякне җыйнарга, чемоданына тутырырга кереште. Киткән чакта Фәнүсә шуңа ризалык биргәндәй карап:— Шулай дөресрәктер,— дисә дә, Нажар ишекне ачкач, бүтән карарга килде.— Юк, дөрес түгел, без сиңа җәзаны ялгыш сайлаганбыз.

— Кызны югалту, аның истәлегеннән, ул туган өйдән аерылудан, ниһаять, сине җуюдан катырак җәза бармыни? Кайда соң ул?

— Шушында. Кызыбызның елмаюлы карашы йөрәгеңдәге җәрәхәткә көн саен кагылып, тагын да ныграк авырттырып торсын өчен, йөрәгеңне меңгә телгәләсен өчен, бу өйдә калырга тиеш син.— Нажар нишләргә белмичә ихтыярсызланганга күрә, Фәнүсә аны тынычландырырлык итеп боерды.— Минем өчен дә шулай. Утыр, Каравылчы хаклы — яңадан башларга кирәк.

Нажар чемоданын ишек төбеннән түргә күчерсә дә, әйберләрен бушатырга ашыкмады. Тиздән барыбер — юлга...

Ләкин... Ләкин, юлларны яңарту фарыз булса да, тормышны яңадан башлыйсы юк иде. Соңгы көннәр куйган мең сораулы хәлне ачыклау өчен Нажар белән Фәнүсәгә мөмкин булган бердәнбер ярдәм булып, ишек кыңгыравы чыңлады да аннан... аннан... Кем? Ышан, ата кеше, ышан, әни кеше, бу — сезнең кызыгыз, кызыгыз Энҗе керде!

Таныш түгел милиционер белән өсте-башы каралып, ертылып, чәчләре тузгып беткән, күзләре, ахрысы, күп елаганнан шешенгән бала, элекке матур, чиста Энҗенең иләмсез карачкысы (әйтерсең алыштырганнар!) башын игән килеш, түргә узарга теләмәгәндәй, ишек катында басып тора иде.

— Балам, балакаем!

Әнисе, үзен тораташ итеп катырган сихерле ихтыярдан тиз ычкынып, кызын сөя-сөя, үбә-үбә, аны мәгънәсенә кем дә төшенә, иярә алмаслык сүзләр белән күмеп ташлады. Үзе сөйләнә, үзе елый, үзе көлә иде. Милиционер нәрсәләрдер әйтте дә, боларның аңлау-аңламауларына илтифат итмәстән, чыгып та китте. Нажарның тәмам каткан миенә аның: «Бирегә кайтасы килми кызыгызның, үзен коткарган Җирекле авылы кешеләр белән, Әпә дигән малай янында калмакчы иде»,— шикеллерәк сүзләре шәүлә сыман гына булып язылып калды. Нажар кызы белән хатынын берьюлы кочаклады да телефоннан бөтен танышларына: «Кыз табылды, исән, кыз исән!» — дип кычкыра-кычкыра сөенеч таратты. Ахырда, кыз әнисе белән ваннага кереп киткәч, урлекырлы сикерүдән тыела төшеп, ике кулы белән үзенең җилкәсенә асылынып калды. Ваннада бер көй белән шыбырдаган су агымы әйтерсең аның тәнендә аккан канны да үз көенә көйләде дә шунда бөтен дөнья яңадан тотрыклы хәленә кайтты һәм яктырып китте. Күңелдә кинәт нәрсә дә булса эшлисе килү теләге туды һәм Нажар тагын — бу юлы инде ашыкмыйча, табигатенә хас олпат кыяфәт белән — телефонда саннар җыйды.

Директор тавышы. Мин сезне тыңлыйм.

— Исәнмесез. Бу Нажар иде, Зәбиров.

Директор тавышы. Сез отпуск хакындамы? Авылыгызга кайту турында?

— Анда елгабызның башын кисеп, чирәм җир үзләштереп, премия алганнар иде бит. Хәзер шул җирне күлгә әйләндереп, икенче бүләк алсыннар. Шуңа ирешергә кирәк.

Директор тавышы. Куәтебез җитәр дип уйлыйсызмы?

— Җитәргә тиеш.

Директор тавышы. Приказга кул куям — секретарьдан командировка яздырып алырсыз. Хәерле юл. Миңа да шуны теләгез — Парижга үземә барырга туры килә.

— Парижга?

Директор тавышы. Бәлки озатырга төшәрсез. Иртәгә.

— Иртәгә. Әйе, иртәгә. Ярый, ярый, Александр Иванович, әлбәттә төшәрмен. Әлбәттә. Хәзергә исән булыгыз.

Нажар телефонны куйды да аюны кочаклап уйга талды.

Муеныннан сөя-сөя, аюның кечкенә күзләренә карап торды. Тере шикелле ялтыраган акыллы күзләрендә — тормыш һаман бар. Һәм ул күзләр нәрсәдер әйтергә тырышып та газап чигәләр. Ләкин Вакыт һәм Үлем аша ни дә булса ишеттерү, аңлата алу җиңел түгел шул. «Исән чакта, исән чакта өлгерергә кирәк, аю дус, исән чакта...» — диде Нажар.

Аю әле — каравылчы абый калыплаган килеш кенә, төзәтәсе, пөхтәрәк итәсе булыр. Ник дигәндә, бу аю — аю гына түгел, ахрысы, Нажарның үз шәүләсе кебек... Элекке Нажар үлде. Тиешле җәзаны аңа һәм тормыш, һәм Нажар үзе бирде. Үз нәфрәтенә мангаен куйды Нажар. Әмма хәзерге Нажар карачкыны якын итсә дә, бүгенге һәм киләчәк мәгънәсе рәвешендә беркайчан да кабул итмәячәк, чөнки бүгеннән соң бөтенләй бүтән Нажар башлана.

Хәтердә мылтык шартлавы һәм Энҗе тавышы: «Әти, атма, атма!»

1975—1977.

## Эдуард Мостафин

### Атлар китә...

Колыннарын калдырып,
Соңгы юлга атлар китә,
Башлар иелгән.
Ул башкайлар безнең куллар белән
Иркәләнгән, күпме сөелгән,
Бик еш кына күпме төелгән.

Атлар китә.
Күзләрендә сүнеп
Шәфәкъ кала,
Ава чаганнар,
Бу күзләрдә бүген
Туган Айдан
Һәм Кояштан корбан чалалар.
Бу күзләрдә бүген яңгыр яумас,
Үлән шиңәр,
Корыр елгалар.
Ат күзендә үлгән колынкайлар
Тәртәләргә кереп еларлар.
«... Сезнең тарткан йөкләр авыр булган,
Китүегез авыр аннан да...»
Колыннарын юаткандай атлар
Кычкырамы:
«Авыр чакта ятып аунама...»

Атлар белән хатирәләр китә,
Кайтмас өчен китә бала чак,
Атлар белән сабан туйлар китә,
Тәүге сөю китә — изге чак.
Атлар белән тарих китә кебек,
Тәүге буразналар, коммуннар...
Атлар белән Каховкалар китә,
Волочайлар китә, Шамуннар,
Атлар белән Бәхтиярләр китә,
Буденныйлар китә, Шәкүрләр,
Атлар белән кыңгыраулар китә,
Китә алган беренче үрләр.
Нигә әле яулык болгамыйлар,
Озатмыйлар чыгып капкадан?
Атлар китә...
Нигә әле әни
Казан асып учак якмаган?

Ә болында тайлар уйнап йөри,
Бәхетләрен күреп еларсың.
Музейларда тарихиияр туза,
Хуҗасы кем, кайсы еллар соң?

●

Егылалар күккә менеп,
Егылалар тупсада да.
Егылалар унсигездә,
Егылалар туксанда да.

Унсигездә дә авалар,
Мәңгелеккә исем үреп.
Туксанда да егылалар,
Тупсаны да биек күреп.

●

— Кайт! — диеп, еракта, кыр буйлап
Уйнаклап колыннар җилдерә.
— Кайт! — диеп, еракта, урманда
Сагынып җиләкләр өлгерә.

— Кайт! — диеп, еракта, күкләрдә
Җып-җылы болытлар җыела.
— Кайт! — диеп, еракта, күлләрдә
Сагынып аккошлар коена.

Еракта, табында бер читтә
Бүленгән ашларым суына.
Еракта бер сабый тын гына
Әтисе куенын сагына.

## «Көз» циклыннан

Бүген бакча базарларга күчкән,
Суган исе яра борынны,
Чәчәкләре чыңлый акча булып —
Үзгәрми көз, һаман борынгы.

Үзгәрми көз, сары моңы белән,
Яңгырлары белән чылата,
Табыннарга чакырып көлдерә дә
Урманнарга кертеп елата.

Үзгәрми көз, югалтулар булып,
Туйлар булып керә тормышка —
Сөйгәннәрдән аера да алдап,
Ятлар белән дөнья корыша.

Үзгәрми көз, каз канатын кызга,
Ә каз башын бирә ирләргә.
Каурый сипкән кебек кыз-кыркынны
Сибеп чыга төрле җирләргә.

Үзгәрми көз — биргән хәтле ала,
Шыр ялангач кала болыннар.
Такыр башлы егетләрне озатып
Перроннарда тузгый толымнар.

Үзгәрми күз, кабатланмый да ул,
Кабатланмагандай сагышлар.
Һәр вокзалда яңа югалтулар,
Һәр базарда яңа табышлар.

●

Сентябрьгә керәм — үләннәрем,
Алмаларым белән хушлашып,
Салкын йолдызларга өмет баглап,
Сары аем белән дуслашып.

Яңгырларны алып, август аен
Җиргә җәеп керәм тын гына:
Эзләремдә сары сулар кала,
Яфрак ята бөртеп шым гына.

Сукмакларым кала учак ягып,
Көймәләрем кала ярларда,
Тәрәзәдә алсу таңнар кала,
Усал этләр кала арада.

Хыянәтләр, вәгъдәләрең кала,
Синең җылың кала башкага.
Йөрәгемдә исемеңне уеп
Син торгызган кара таш кала.

Бер ялгызым керәм сентябрьгә:
Миләшләрем яна таң булып,
Офыкларым тау артында ята,
Әле беркемне дә җылытмаган
Утлы кочак кебек йомылып.

●

Күпме язларымнан мәхрүм калдым.
Мәхәббәт, дип, матур алдандым, тик түздем.
Яраланган пар йолдызлар сыман
Еракларда торып калды ике күзем.

Мин яралган җиргә көне-төне
Туктамыйча коя салкын яңгырлары.
Оеп барган күлдә китәлмичә
Калган кыр казының моңы яңгырады.

Өй артымда чиный эт көчеге —
Сыенырга юк урыны, юк хуҗасы.
Бу тормышта әле күпмеләргә
Күшексә дә ярдәм кулын бар сузасы.

Ана кебек гадел була күр син,
Дөнья, үлчәвеңдә үлем, гомер ята.
Синдә бар нәрсә дә урынында!
Кемдер тере чәчәк, кемдер агу сата.

Кемдер елый, кемдер көлә синдә —
Тамашамы, язмышмы бу, кем соң белсен?!
Тырнак асларында тычкан елый —
Дөнья булгач мәчеләр дә белеп көлсен.

## Шамил Маннапов

### Сөембикәң белән

Манаралар күптер алар җирдә,
Эйфельләр бар, диләр, күккә тигән. —
И Казаным, керден йөрәгемә
Тыйнак-горур Сөембикәң белән.

Халкым аны үз күңеледәй гүзәл
Легендалар белән бизәп төргән.
Легендага күчкән улларыңны
Күп озаттың Сөембикәң белән.

Мөмкинме соң сине буташтыру,
Алыштыру башка-бүтән белән?!
Һәркем таный, һәркем аңлый сине,
Санлый сине Сөембикәң белән...

## Әхмәт Гадел

### Казан

Таш йортлар, кадими урамнар...
Ни уйлап шаулый бу юкәләр?
Тарихны тетрәткән туфаннар
Саташып чәчләрне сүтәләр.

Мәчетләр, чиркәүләр янәшә,
Көрәштән бер арып тынганнар...
Чал чәчен туздырган кем дәшә? —
Кремль тавында кылганнар...
Язмышлар чаты син, шәһәрем,
Иделнең саф, йомшак җилләре...
Болагың буенда гүя мин
Күрәмен Тукайның килгәнен.
Йөрәккә биредә, һай, рәхәт!
Матур да Кабанның буйлары!
Таң алды. Яр буйлап каршыма
Яшь Ленин килә күк уйланып.
Яратам чәчәкле бакчаның
Яз хушын җилләргә биргәнен,
Яшь гүзәл кызларның каршыма
Ваемсыз елмаеп килгәнен.

Ах, ничек гашыйкмын сиңа мин!
Синсез юк минем бу тормышым,
Шатлыгым-хәсрәтем, шәһәрем,
Казаным — язмышым, сулышым.

## Михаил Скороходов

# ТУНДРА ХИКӘЯЛӘРЕ

### Кеше шатлыгы



Егор Емельянов, кышлау болдырына чыккач, еракtагы тау итәгендә бер кара нокта күрде. «Болан булса кирәк» дип уйлады ул һәм бүлмәгә сак кына кереп, хатынын, балаларын уятмаска тырышып, карават өстендә эленеп торган бинокльен алды.

Юк, бу болан түгел — кемдер чаңгыда килә иде. Карт аучы яр буенда кышлаучы бөтен кешене белә, әмма күпме генә караса да, чаңгычыны танымады. Чаңгычы уйсулыкта күмелде, Егор баскычка утырып тәмәке кабызды һәм көтә башлады.

Баемый торган кояш су өстендәге зәңгәр томан пәрдәсе аша әкрен генә күтәрелеп килә. Бу төнне елга тамагындагы боз да кузгалган. Көньяктан эссе җил дулкыннары тәгәри. Яз...

— Хатын-кыз! — дип гаҗәпләнде янадан бинокльдән караган Егор. Ниһаять, ул аны таныды: бу — күршедәге яшь аучы Антонның хатыны Галя Морозова. Болай иртәләп кузгалмас иде, әллә берәр хәл булганмы?..

Галя калкулык итәгеннән кыеклатып шуганда мәтәлеп китте дә бер мизгелгә кар өермәсе эчендә югалды. Аннан көч хәлгә торып басты һәм таяклары белән төрткәләп, яр буйлап елганың әле бозы кузгалмаган җиренә таба китте.

Егор, көтелмәгән кунактан күзен алмастан, тәмәкесен тартып бетереп төпчеген кырга атты. Галя болдырга килеп җитүгә, хәлсезләнеп баскычка утырды. Аның кардан юешләнгән йөзләре яна, кысык соры күзләренә тәшвиш һәм хәвеф тулган иде. Ул әкрен генә:

— Егор Иванович... — диде дә битен каплап елап җибәрде.

— Ни булды? — диде хуҗа, йөткереп һәм янадан тәмәке тарта башлап.

Сырмасының җиңе белән күз яшьләрен сөртә-сөртә һәм үкси-үкси, Галя кичә иртән Антонның ауга китүен, кичен өйдә булырга ниятләвен, әмма этләрнең тундрадан нартасыз-нисез үзләре генә кайтуын сөйләп бирде.

— Этләрнең барысы да кайттымы?

— Барысы да.

— Җигемне чәйнәп өзгәннәрме?

— Юк. Сарбай элмәгән сөйрәп кайтты.
— Ничә эт?
— Дүртәү.
— Кайсы яктан кайттылар?
— Белмим, күрмәдем.

Этләрнең кайсы яктан кайтуын эз буенча да белеп булыр, төньякта әле беренче елын гына торучы бу кошчыктан ни көтәсең инде?

— Үзе белән ниләр алган иде?
— Винтовка. Бераз ашамлык.
— Ә кая юнәлде? Кайсы якка, күрмәдеңме?
— Тегендә таба, яр буйлап.— Галя кулын көнчыгышка болгады.— Озата барган идем.

Егор дулкынлануын яшерергә тырышып уйга калды. Тере хуҗасын этләр калдырып китми. Әллә... Антон җиңелчә чыккан, бөз өстендә нерпа ауларгадыр, күрәсең. Көньяк җиле өченче көн исә инде... Әйе, Антонны, мөгаен, бозы кубып, диңгезгә алып киткәндер. Ә нартасы!? Боз кантары яки кыяга эләгеп калгандыр да, этләр җигемнән ычкынгандыр. Яр буена барып, эзләрен карарга кирәк. Аннары ары таба, аучылар станциясенә хәбәр итәргә. Аннан аэропортка шалтыратып була. Тик станциягә хәтле йөз чакрым, тундра исә менә-менә йөгерек бозлы су ташкыннары белән капланмакчы — юл өзелер. Галяга монда түгел, каршы якка, күршедәге бүтән кышлауга юнәлергә булган, анысы станциягә якынрак, анда ике аучы, берсе яр буен карар, икенчесе ярдәм сорарга китәр иде. Шулай да, башына кайгы төшкәч, танышлыклары да чамалы гына булган Егорга ашыккан. Дөрес, монда якынрак... Станциягә көймәдә барырга мөмкин. Кире катерда кайтарырлар иде.

Галя бүреген салды да, сулышын тыеп, Егорга төбәлде. Күперенке чәчләре таралды, аксыл бөдрәләре юешләнгән маңгаена ябышты.

— Өйгә кер, җәмәгатемне уят. Мине шушында көтеп тор.
— Тиз кайтырсызмы соң?
— Белмим. Суның тоткарлавы мөмкин. Бер атнадан да соңламам. Кайтып китәргә уйлама, үзем илтеп куярмын. Аягың каймыкса, табып кара аннары сине тундрада.
— Мин сезне көтәчәкмен.

Егор яхшырак биш этне сайлап алып җигә башлады, Галя булышырга тотынды.

— Аю харап иткәндер аны.
— Аюны җиңә ул.
— Я учак янында ут капкандыр. Йокыга киткәндер дә...
— Тундрада ничә ел яшәсәм дә, учак янында янып үлүчеләрне ишеткәнем юк.
— Ни булды икән соң?
— Ярар, сабыр ит.— Ул нартага ашамлык тутырылган рюкзагын атты да кулын селтәде.— Табармын Антонынны, бер кая да китмәс.
— Баш тартырсыз, эзләмәссез, дип курыккан идем.
— Нишләп алай?
— Антон «ул миңа үпкәләде» дигән иде.
— Ни өчен? Үпкәләсәм соң... Юк сүз. Ярый, сау булып тор...

Антонның кышлавы торган Гөрләвекле елга тамагына егерме чакрым иде. Егор сакланып кына, төбендә кар сулары җыелган, язын хәлиткеч һөҗүмгә әзерләнгән чокыр һәм казанлыкларны урый-урый барды.

Әй, күгәрченкәем, ни генә булмас дисең бу төньякта. Шуның өчен дә ул төньяк, әз генә авызыңны ачып, ялгышлык җибәрсәң, ул, һичшиксез, тәнеңә тырнагын китереп батырачак. Балалы аюны очратып яраласаң, беттем дип исәплә, икенче кат атарга өлгермәячәксең. Яки ярык аша сикергәндә аягың тайса. Әгәр бозда калса, зыян юк, вертолет җибәрерләр дә коткарырлар. Нәрсә дип ачу куарга ди, ул миңа начарлык та,

яхшылык та эшләмәде. Былтыр, Мәскәүгә барганда бер кило әфлисун алып кайт әле дигән идем, тыңламады. Шуны күздә тоталардыр, бүтән ни? Кысыр хәсрәт...

Кышлауга төш уртасында килеп җитте, нартасынан төшмичә, өйне еракган әйләнеп чыкты Егор. Тимер чана табаны эзен таба алмыйча азапланмады — ул диңгезгә таба юнәлгән иде.

Кышлаудан дүрт чакрымда Егор Антон тукталган урынны күрде. Җигемне калдырып боз беткәнче барды да, кире борылып ары китте. Ярты чакрымнан — тагын тукталыш.

Егор, нартадан төшеп, игътибар белән эзне тикшерде. Шикләнеп торасы да юк иде: Антон моннан Гөрләвекле елга буйлап югарыга, эчкәре тундрага юнәлгән. Яр буенда сунар уңышлы булмаган, карда бер генә кан тамчысы да, җәнлек тизәге дә күренми.

«Менә әкәмәт, — дип уйлады Егор, җигемне эзгә таба борып, — ни өчен тундрага сугылган бу?»

Бару торган саен кыенлаша, һәр җирдә диярлек кар астыннан су саркый иде.

Ул ташларга эләгеп җиргә капланган нартаны ерактан ук күреп алды һәм нәрсә булганын төшенде: Антон Гөрләвекле елга бозына текә ярдан тәгәрәгән!

Җигемне туктатып, Егор Антон нартасы янына килде һәм аска карады. Алты метр чамасы тирәнлек. Ташлар... Антон исән калган — елга юлы буйлап шуышкан эзе ап-ачык күренә. Аягын сындырган-дыр, ахры.

— Анто-о-н!

Егор, учын колагына куеп, озак тыңлап торды.

Тынлык.

Антон нартасын үзенекенә тагып, Егор җигемне яр буйлап әйдәде. Әледән-әле тукталып, ярга якын килде һәм аваз салды. Эзне инде ике җирдә су күмгән иде.

Менә елганың соңгы борылышы, моннан инде ул тамагына кадәр күренә. Кая соң бу Антон? Елгада юк, димәк, ярга менгән.

Егор янадан кышлауны әйләнеп чыкканда, кинәт, болдырга утырып, пычак белән аягындагы унтаны ярып ятучы Антонны күрде.

— Исәнме, мәргән!

Антон сискәнеп башын күтәрде.

— Егор Иванович! Сәлам... Нартаны алып килдеңме? Менә рәхмәт. Ул маңгаеннан юеш чәчләрен сыпырды. — Ничек тә булса Галяны күрмәдеңме?

— Нигә ничек тә булса? Чынлап та күрдем.

Антонның агарынган йөзенә төс керде.

— Кайда ул?

— Тундра буйлап йөри, сине эзли. Без аның белән моннан егерме чакрымнарда очраштык. Курыкма. Безнең кышлауда ул. Чәй эчә. Каян башыңа килде бу сәфәр?

— Болан юлыкмасмы дип чыккан идем, томан харап итте. Ярдан тәгәрәдем менә. Аягым имгәнде.

— Аяк нәрсә ул, башыңны да яру мөмкин иде. Уңай тәгәрәгән әле син, туганкай. Этләрең менә бернигә ярамый. Яхшы эт хуҗасын гына түгел, нартасын да ташламый. Сине, кем әйтмешли, язмыш ихтыярына калдырганнар. Анысы гына ярар. Мал табылыр, баш исән булсын. Ә хатының менә дигән. Чаңгыда да чемпион шикелле чаба.

Ул Антонның имгәнгән аягын бәйләде, аңа караватка ятарга булышты. Аннары мичкә якты, плитәгә чәйнек куйды, болдырга чыгып, тынгысызланган тундрага хәвефле караш ташлады. Нурга күмелгән тигезлек, буланып һәм ялтырап, диңгезгә таба шуыша иде. Еракта-

еракта яр өстендәге калкулыклар тезмәсе күгелҗемләнеп тора — анда Егорның кышлагы.

— Я, мин киттем,— диде ул урындыкка чәйнек, кружка һәм шикәрле савыт куеп. — Иртәгә көн бозылмаса-үзгәрмәсә, Галяны китерермен.

Антон аңа исе китеп карады.

— Хәзер тундра аша кайтып буламыни? Җебетте ләбаса.

— Ә мин көймәдә. Үз җаем белән йөзәрмен. Син ял ит, йокла.

— Сиңа да ял комачауламас. Чәй эчәр дә ятар идең.

— Хатының борчыла, чиктән тыш. Тынычландырырга кирәк аны. Учак янында ут капкандыр, ди.

Икесе дә көлеп җибәрделәр.

— Рәхмәт инде, Егор Иванович.

— Аптырама. Йокла әйдә...

Ул көймәне суга этеп төшерде дә аңа нарта, этләрне төяде һәм диңгезгә чыгып, бозлы яр буйлап йөзеп китте. Әмма җил кинәт кисәк-кисәк, минут саен көчәебрәк исә башлады. Егор озакламый кышлагына болай кайтып җитә алмаячагын төшенде. Ярдагы бозлар күз алдында чәрдәкләнеп, артык йөктән чума төшкән көймәгә килеп бәреләләр иде.

Ул, бушка күпме вакыт әрәм итүенә уфтанып, кире борылды, яңадан этләрен җикте дә, өйгә кереп чыкты. Антон йокыга киткән иде. Тешләрен кысып тирән-тирән сулый һәм ыңгырашып куя. Төшендә үзен әле һаман мәкерле елганың бормалы юлыннан шуыша кебек тоя иде, ахры.

Төн таңга авышып килә иде. Егорны йокы басты, тик хәзер һәр сәгать кадерле иде: тундра тиздән тоташ ташкынга әйләнәчәк.

Этләр көчкә сөйрәлә, Егор нарта белән янәшә атлый. Тиздән аларның юлын киң, шаулы елга бүлде, этләр хуҗаларына гаепле карап, туктап калдылар. Егор аларны бер-бер артлы күтәреп чыгып, билдән юешләнде, аннары нарталарны чыгарганда таеп китеп, башы белән бозлы суга чумды.

Ике этне нартага салырга туры килде — алар ары атларлык түгел иде. Каешны җилкәсе аша салып, Егор нартага үзе җигелде.

«Хәзер тундрадан бара алмаячаксың, ди. Ә үзе сынап карамаган, хаҗәте төшмәгән. Һәркемнең хәленнән килми, анысы хак.

Галяга учагын таптым диярмен, Антонның янып беткән, дөрес шикләнгәнсең икән, диярмен... Әгәр теге кышлауга китсә, мөгаен, озаграк җәфаланыр иде. Юлга чыгып булмый, бетте-китте диюләре ихтимал иде. Алай җиңелрәк. Ә минем исем китми. Сугышта, буранмы, давылмы, чакырып алалар иде дә, менә шулай, Егор Иванович, синдә генә өмет...»

Еракта кышлавы күренгәч, ул хәл алыр өчен кышлакка утырды. Кар сулары кояшлы төнне тыйнак челтерәүгә күмеп, тыелгысыз рәвештә диңгезгә омтылалар. Кайдадыр биектә тансык каңгылдашу, шатлыклы авазлар яңгырады. Бу беренче киек казлар оча иде. Егор, каш өстенә кулын куеп, аксыл болыт астындагы карачкыл өчпочмакларны шәйләде, тавышсыз гына көлеп куйды. Һәм бер-бер артлы өч мәртәбә төчкерде.

— Ары таба теркелдик, — диде ул дәртле генә, тагын нартага җигелеп.

Төш чагында елгага килеп җитте. Астында су чыпырдаган һәм бозлар кетердәгән карлы басмадан этләрне күтәреп чыкты. Болдырга килеп җиткәч, тәмам хәлдән тайганлыктан, туп-туры бу күтәрелгән юеш җиргә чүкте. Ишектә ябыккан, күз төпләре шешенгән Галя күренде.

— Өеңдә Антоның. Чәй эчә... Җәмәгатьне чакыр әле.

Аның хатын-кыз йөзендә хәзер Галя чыраена бөркелеп чыккан кебек шатлыкны беркайчан да күргәне юк иде әле. Галя башта ишеккә

ургылды, әмма аннары кисәк борылып, болдырдан сикерде дә Егорның башын күкрәгенә кысты. Шуннан соң юеш баскычларга ялан аяк баса-баса, болдырга очып менде, өйгә кереп югалды. Ул да булмады, алар хуҗа хатын белән килеп чыктылар.

— Мария, тәмәке табып бир әле миңа. Кояшта утырып төтәтим әле бер...

Егор калтыранган бармаклары белән тәмәке төреп, шырпы сызды. Әмма инде аның тартасы килми иде. Ул инде ял итә. Шушы өч баскычка күтәрелергә көче җитмәвен хатыннарга сиздерәсе килми иде аның,

## Кар тузаны

Диңгез порты идарәсенең өч катлы агач бинасы алдына бер хатын утырган җигүле этләр килеп туктады.

Хатын камчысын нартага ташлады да болдырга кызу гына менде. Иркен, йомшак мех киеме аша көчле, сыгылмалы гәүдәсе беленеп тора иде. Билендәге сөяк кыныда сабы болан мөгезеннән ясалган озын пычак күренә. Ак төлке тиресе белән каймаланган башлыгы маңгае һәм ияген капласа да, хатынның кысык кара күзләре, кискен йөреше миңа таныш сыман тоелды.

Нарта тирәсендә чем-кара күзләрен ялтыратып, телләрен асылындырып, арыган алты эт утыра иде. Алар байтак юл узган: үзләре дә, нартадагы тире йокы капчыгы да кар тузаныннан апак булганнар. Җигемнең алдындагы зур бәдәнле, төтен сыман соры этнең ялыннан сыйпарга ымсынган идем дә, тыелып калдым, хуҗасы аны ничек тәрбияләвен кем белсен?..

Шулай да кайда күрдем соң мин аны?

Ун минуттан поселок советы председателе кабинетына керсәм, баягы хатын монда утыра икән. Ул кулындагы «Герой ана» медаленә елмаеп карап тора иде. Инде ул башлыгын салган, әмма шома итеп таралган чәчләре дә, юеш каш-керфекләре дә хәтеремне яңарта алмады.

— Сезне кайдадыр очратканым бар, тик исемә төшми,— дидем, юлаучының хәтере шәбрәк булуына өметләнеп.

Тик ул иңен генә сикертте дә безнең белән саубуллашып чыгып та китте.

— Менә, ичмасам, хатын! — диде председатель трубкасын кармалап. — Дүрт йөз чакрымны җилдергән, ә үзе әле дә баскычтан йөгереп кенә төшә. Кызлары янына ашыга.

— Нинди кызлары? — дидем мин. — Кайдан ул?

— Нинди кызлары булсын, үзенекеләр, билгеле. Бездә интернатта яшиләр. Анна Буторина бу. Боланлы утравында нинди вакыйга булганын ишеткән иденме?

Менә хәзер хәтерләдем! Анна Буторинаны былтыр язын шифаханәдә күргән идем. Ул чакта янымнан ак халатта узып китте. Председательдән Боланлыдагы хәлләрне тәфсилләбрәк сөйләп бирүен үтендем...

... Бу вакыйга өченче елгы августта, поселок советына килгән телеграммадан башланды. Анда Коршунов, Петров, Синицин фамилияләре белән бергә атаклы бандит Гречкинның качуы хәбәр ителгән иде. Ул карабин белән коралланган һәм безнең поселокка таба юнәлгән икән.

Бердәнбер милиционерыбыз Гречкинны эләктерә алмады, бандитның поселогыбызга керүе дә икеле иде. Әмма озакламый аның бу як-

ларга кагылуы ачыкланды. Бу хакта көймәсе һәм балыкчылар алачыгындагы бинокле юкка чыккан аучы хәбәр итте. Бандит хакында бөтән ым-шым ишетелмәде. Елга буйлап өскә йөзеп киткәндер, дидек тә, тиешле кешеләрне кисәткәч, оныттык.

Соңыннан ачыкланганча, Гречкин елга буйлап өскә таба түгел, ә ачык диңгезгә — йөзмә бозлар ишле булганга катерлар да ел саен бармый торган Олы Боланлы утравына юнәлгән икән.

Утрауда борын-борыннан аучылар станциясенең ике өе тора. Кышлаучыларның берсе — Игнат Худяков, анда инде унбиш еллап яши, икенчесе — аучы Федор Буторин, гаиләсе белән бер ел чамасы элек кенә урнашкан иде.

Төньяк аучылары — ышанучан халык. Гречкин кышлаучыларга да, ак төлке тотарга өйрәнер өчен мине сезгә станция башлыгы җибәрде, дигән. Ни теләсә кулыннан шул эш килә торган Гречкинны карт Худяков үзе янына алган һәм алар бергәләп кышкы сезонга әзерләнә башлаганнар.

Көз авышкан чакта Гречкин Анна белән Федорның күз алдында диярлек картны суга батыра. Гречкин белән Худяковның ятьмәне тазартуын, иске көймәнең каплануын алар күреп тора. Ярга Гречкин гына йөзеп чыга.

— Бабакайны коткарырга өлгерә алмадым, — ди ул Буториннарга, — күрәсең, аны көзән җыерды.

Гречкин Худяков өендә үзе генә тора башлый, төлке тозакларын рәтли, капкыннар әзерли, күршеләренә сирәк керә. Анна аны башта ук яратмый, моны сизенгән Гречкин аңа беркайчан да сүз катмый, бары сирәк-мирәк кырын караш кына салгалый.

Бервакыт кыш башында ул хатынны абзар янында туктата да йөзен читкә ящереп:

— Миңа керик әле. Сүз бар иде, — ди.

— Монда да сөйләшеп була ич.

Гречкин хатынга берничә минут төбәләп тора, аның карашындагы нindидер усаллык Аннаның күкрәгенә салкын йөгертә. Федор өйдә юк чак, ул таң алдыннан тозакларны карарга киткән була.

Анна бер ыргылу белән абзарның ишеген ача да кычкыра:

— Төтенкәй!

Унлап эт аңа таба ташлана.

— Бер атна вакыт бирәм, — ди Гречкин салмак, нык тавыш белән. — Көтәрмен. Килсәң — үкенмәссең, килмәсәң — үзеңә үпкәлә. Федорга әйтсәң, аны Худяков шикелле дөмектерәм. Кызларыңны да. Үзеңне генә исән калдырачакмын.

Шаккаткан Анна аңа күзләрен тутырып карап тора. Гречкин читкә атлый. Ун адымлап киткәч, көчле, сагышлы тавыш белән җыр суза:

— Ярат мине, кызкай, мин иректә,
Мин иректә чакта синеке...

Федор төн уртасында кайта. Анна берни әйтми, тыштан юаш күренгән иренең Гречкинга ташлануыннан һәм тегесенең аны үтерүеннән курка.

Бәлки Гречкин аларның өенә керер, шул чак аяк-кулларын бәйләрләр дә, аннары аны Федор портка яки балыкчылар станциясенә илтер.

Иртә белән Федор үз эше белән китә. Хәвефне сизгәндәй, Аннаның йөрәге сыкрый.

Гречкин вакыйгаларны тизләтергә карар итә. Кышлауга якынрак бер урында Федорны очрата да, утрау уртасында мин аткан ике боланны алып кайтыйк әле, ди. Шатланган Федор этләрен шунда бора.

Анна өйдән берничә тапкыр чыгып, таныш җигем күренмәсме дип,

томанлы соры офыкка карый. Җигем күренә... Этләр бар көчләренә элдерә, бозлы калкулыктан буш нарталар җиңел шуа.

Анна хәрәкәтсез кала. Зарлы чинаган этләр аның тирәсенә чүгәли. Хатын күзләрен йома, тик аңа нартадагы кар тузаны каплаган канлы таплар керфек аша да күренгәндәй була.

Ул винтовка, бинокль ала да кышлау түбәсенә менә. Китеп барыр иде — балаларын ялгыз калдырырга базмый.

Гречкин Аннаның инде күптән аны мушкага алуын сизми, кышлауга тәрәзәләр карамаган көнчыгыш яктан кайта. Егерме адымлап калгач, Анна ата. Утрау тынлыгын карлыккан әче тавыш өзә. Анна тагын ата, Гречкин егыла.

Этләр юлны белә. Анна ерактан ук кулларын җәеп карда яткан Федорны таный. Бандит аның аркасына карабиннан аткан икән. Каннан кар кып-кызыл булса да, Федорның әле җаны чыкмаган була. Анна аны өйгә алып кайта.

Тиреләрне кышкы сезон тәгәлләгәндә аучылар үзләре илтеп тапшырганлыктан, станциядән кемнең дә булса утрауга килеп чыгуын көтү өметсез. Федорга да, балаларга да яңа ит кирәк. Нишләргә? Бервакыт Анна бинокльдән болан күрә, эт ала да сунарга китә.

Җанвар ерак була, хәлсезләнгән куллар калтырый, ул тидерәсенә үзе дә ышанмый, тәвәккәлләп атып җибәрә. Җиңелчә яраланган болан котылырга омтыла, тик эт аны куып җитеп аяктан ега.

Котып төннәре беткәндә Федор савыга башлый, әмма Анна үзе зәңгелә чиреннән ава. Әгәр нерпа эзләүче ике аучы егет ненец утрауга аяк басмаса, бу тарих ничек беткән булыр иде — билгесез. Аларның берсе портка юнәлә, икенчесе ниндидер мүк һәм тамырлар төнәтмәсе әзерли һәм аны Анна белән Федорга эчерә башлый...

Буториннар гаиләсен поселокка самолетта алып килеп, Федорны шифаханәгә салганнар, менә шунда мин Аннаны очраттым. Җәен Буториннар яңадан утрауларына киттеләр.

«Герой ана» медален искә төшереп:

— Балалары күпме соң? — дип сорадым.

— Бишәү. Икесе — кышлауда, өчесе — монда, интернатта.

— Яшь күренә.

— Утыз биштә.

— Кыяфәте яшьрәк.

— Тумыштан төньякныкы.

Иртәгәсен бүлмә тәрәзәмнән таныш җигемне күргәч, сөенеп болдырга чыктым. Котып кояшының тоңдырылган төсле нәзберек нурлары каты кар өслегенә төшеп, якты тузанга әвереләләр. Аңа кара күзлексез озак карарга ярамый. Җигем инде еракта — бугазның якты кар яланында, поселогыбыз читендә, меңнәрчә чакрымга сузылган башка әкияти дөньяда иде.

ТӘҮФИКЪ ӘЙДИ тәрҗемәсе.

Герберт Уэллс

# ТӘВӘ КОШЛАРЫ БЕЛӘН СӘҮДӘ

ХИКӘЯ

Төрле кошларның нинди бәяләргә сатылу-алынуларына килсәк, минем үземнең, мәсәлән, өч йөз фунт-стерлингка сатылган тәве кошы да күргәнем бар, — дип куйды кошлар, хайваннар карачкысы ясаучы мактанчык оста. Дөньяны аркылы-буйлыга гизгән яшь чакларын исенә төшерде булса кирәк бу минутларда, — беләсезме шуны, өч йөз фунт-стерлинг!

Ул миңа күзлеге аша түгел, күзлегенең өстеннән бер мәл карап торды.

— Алайга китсә, мин дүрт йөз фунт-стерлинг бирсәләр дә, хуҗасының сатудан баш тартканын күргән кеше. Менә нинди тәвә кошлары да була, сэр.

— Ә бит мин әйткән тәвә кошларының искитәрдәй бер җире дә юк, алар гап-гади тәвә кошлары иделәр. Хәтта, әйтергә кирәк, яхшы ук йолкынганнар-шәрәләнгәннәр, күпме көннәр корабта ачлы-туклы килсәң, йолкынырсың да шул. Аннары бит әле ул елларда тәвә кошлары белән кызыксыну да ул чаклы кызган чак түгел, кайдан килгән мондый котырган бәһа диген син. Юк, җаным, моның сере бар, шул йолкынып беткән биш тәвә кошы арасыннан берсе бриллиант йоткан, имеш. Менә кайда аның сере.

Бәлагә тап булган ул кошта болай үзе кыяфәт юк түгел, сэр Мохини диярсең, королева, бер сүз белән әйткәндә. Аягыннан башына, дөресрәге, аягыннан иңбашына хәтле күздән үткәр, Пиккадилидан чыгып кына килгән франт кебек. Ә иңбашыннан өстәрәк калку баш, кара-кучкыл, иләмсез һәм чикләвек хәтле шешле баш, чын булса әгәр, әнә шул шештә утыра, ди, инде бриллиант ташы. Җен алыштырган тәкатьсез җан иясе, ачлыктандыр инде, күреп алуы була түгәрәк кисәкне, йотып җибәрүе була. Соңыннан, йотып җибәргән арты ук, сизенеп ала: әш тикмә түгел монда, тамакны ертып узгандай итте, кинәт бер разбой сала һәм, үзенең серле кошка әверелгәнлеген белдермәс өчендер инде, тизрәк ырургдаш дүрт юлдашы белән аралашып, эз югалтырга ашыга. Бөтенесе күз ачып йомганчы була бу хәл. Мин әлеге вакыйга урынына иң әлек йөгереп килүчеләрнең берсе. Ишетәм, теге мәҗүси, үзенең әллә кем түгеллегенә, башка тәвә кошларыннан ни белән дә аерылмаганлыгына ышандырырга тырышып, шаһитлеккә барлык мәҗүси аллаларын чакыра. Шунда шул ике матрос һәм ул тәвә кошларын алып баручы егет шаркылдапмы-

шаркылдыйлар. Башыңны җүләрлеккә салмасаң, көләрлек эш тә бар монда, синең кесәгә керәчәк затлы ташны югалтуның моннан да әкәмәтрәк очрагы булуы мөмкинме! Әлеге тәвә кошларын карап алып баручы егет вакыйганы, әлбәттә, үз күзләре белән күреп өлгермәгән. Кыйммәтле ташның ничек югалганлыгын абайламый калган. Дөресен әйткәндә, мин үзем ул затлы ташның кинәт болай юкка чыгуы өчен әллә ни борчылмадым. Ник дисәң, белеп торам, тәвә кошларын алып баручы франт мактанчык, корабка утыруы белән үк шул бриллианты белән урынлы-урынсыз шапырынып, тәмам туйдырып бетергән иде.

Аңлашылса кирәк, бу хәбәр, әлбәттә, минуты-секунды белән бөтен корабка таралды. Бөтенесе, төрлесе төрле яктан, фараз кылырга, уйдырма корырга тотындылар. Ә тәвә кошларын алып баручы кияз егет чак кына елап җибәрмичә, үзенең каютасына китеп күздән югалды. Көндезге аш вакытында (ә арабыздагы падиша дигәнебез, үзенең ике егете белән һәр вакыт аш өстәленең бер як читендәрәк утыра торган иде) корабның капитаны падишаны җиңелчәрәк кенә үртисе итте, теге бичараны бу да чыгырыннан чыгарды булса кирәк. Капитанның шаяртып әйткән сүзләре әле дә булса минем колагымда яңгырап тора: янәсе, бер бриллиант кисәге өчен ул әлеге өтелгән тәвә кошларын үз акчасына, әлбәттә, сатып ала алмый. Курыкма, үзенә тиешле бриллиантны да ул болай да алачак. Ник дисәң, Британия гражданины, үзенең хокукларын яхшы белә. Бриллиант табылырга тиеш. Теләсәң ничек тап та, чыгар да сал! Юкса, капитан лордлар палатасына шикаять белән китәчәк.

Тәвә кошларын алып баручы егет тумранның да тумраны икән, аның туң башына ни дә булса чүкеп кертү мөмкин түгел иде. Йолкыш кошлары янына врачны якын да җибәрмәде. Имештер, аңа тапшырылган тәвә кошларына фәлән-фәлән төрле ризыклар гына ашатырга, аларны фәләнчә-фәләнчә итеп кенә алып барырга кушылган. Әгәренки кушылганча эшләмәсә, аны көне-сәгате белән эшеннән өреп атачаклар. Шулай да тәвә кошларының ашказаннарын чайкатуга каршы түгел, хәтта әлеге кошларның ашказанарын чайкау мөмкин түгеллекне белгәне хәлдә, моны үзе таләп итә иде. Җүләр саткан барлык бенгалиялеләргә хас булганча, төрле законнарны һәм хокук тәртипләрен белгәнлеген күрсәтергә тырышты, әгәр ул әйткәнчә эшләнмәсә, тәвә кошларын закон сагына куйдырачагы һәм бүтән шундый әкәмәтләр белән өркетергә маташып карады. Шунда ук тагы, имештер, улы кайдадыр Лондонның үзендә адвокат булып эшли торган бер картлач остарырга тотынды. Аныңча, болай килеп чыга икән: кошмы, хайванмы тарафыннан йотылган нәрсә — нинди генә нәрсә булмасын ул — әлеге кошның яки хайванныңмы анда органик бер кисәгенә әверелә, бу — закон буенча шулай, димәк ки, падишага монда тик бер генә юл: йотылган бриллиантның тияр бәһасен кайтаруны таләп итү юлы гына кала. Тик ул очракта да җавап бирүче якның таптыручы якны саксызлыкта гаепләп, котылып калу ихтималы юк түгел, имеш.

Монда инде безнең падиша дип йөртелә торган кешебезнең дә борыны яхшы ук салынып төште. Шулай булмыйча соң, бөтенесе дә картлач китергән дәлилләрне куәтләп торалар ич. Корабта чын законны белүче юрист булмаганлыктан, без барыбыз да — белсәк тә, белмәсәк тә — әлеге четерекле вакыйганы үзебезчә юрарга, хөкем чыгарырга тотындык. Соңыннан, Аденны узып киткәннән соң, падишабыз, күрәсең, үзе дә бүтәннәр белән уртак бер фикергә килде булса кирәк һәм без, әкренләп-әкренләп булса да җыйнаулашып, тәвә кошларын бишесен дә уптым-иләйһи сатып котылу ягын карарга киңәш иттек.

Иртәгесен, иртәнге аш өстәле янында дуамал шау купты. Тәвә кошларын карап алып баручы егетнең аларны сатарга, әлбәттә, бернинди дә хакы юк һәм ул моңа барачак та түгел иде. Ләкин Поттер дигән бер субъект бу сату-алуны шау-шусыз гына да башкарырга мөмкинлек барлыгын, күрәсең, падишага сиздереп өлгергән иде булса кирәк, падиша шундук Поттер әфәндене җир күтәреп тормаслык алама сүзләр белән сүгәргә тотынды. Хәлбуки, без барыбыз да бер фикергә килдек: Поттер ачык авыз түгел, нәрсәдән нинди ис килгәнлеген белә һәм әфәндебез моны яшермичә әйтеп үк бирде. Ул инде тәвә кошларын сатарга рөхсәт сорап Аденнан Лондонның үзенә телеграмма сугарга да өлгергән, Сүәештә җавап алырга тиеш, имеш. Моны ишетеп мин, яшерен-батырын түгел, шундый төшемле очракны кулдан ычкындырганлыгым өчен, үземне ачык авыз булуда гаепләп, эчемнән генә битәрләп тә куйдым.

Сүәештә Поттер әфәнде тәвә кошларының хуҗасы булып әверелде, ә падиша чак кына елап җибәрмәде, әйе-әйе, чын күз яше белән елый язып калды. Аннары ул алны-артны карап тормыйча, Поттер әфәндегә әлеге тәвә кошлары өчен ике йөз илле фунт-стерлинг, ягъни Поттер түләгән акчага караганда ике йөз процентка арттырып түләргә тәкъдим ясады. Ләкин Поттер нык торды, әйтте кычкырып: әгәр биш тәвә кошының берсенең, һич югы, сыңар канатын гына булса да сатардай булсам, билләһи менә, аягымнан асып куйсыннар. Ул аларның, ягъни биш тәвә кошының бишесен дә суячак һәм, әлбәттә, бриллиантны табачак. Әмма соңыннан, уйлана торгач булса кирәк, шулай да тәвә кошларын сатарга риза булды. Нишләмәк кирәк, сату-алуга хирес кеше, җитмәсә тагы, чак кына «мать якасына!» дияргә дә, алдашырга да ярата иде булса кирәк. Тәвә кошлары өчен түләгән бәягә ияреп яхшы гына «сюрприз» да килгәч, малны ычкындырудан курыкмады. Ничек кенә булмасын, шулай да тәвә кошларын барысын берьюлы түгел, кызык өчен һәр башка сиксән фунт-стерлинг исәбеннән берәмләп сатарга, ә үзенә, бәхетен сынап карау өчен, берсен калдырырга карар кылды.

Әйтсәк әйтик, бриллиант дигәне дә бик кыйммәтле мал шул. Безнең арада, корабта затлы ташлар белән сәүдә итүче бер сәүдәгәр бар иде, кәрлә генә бер кеше шунда, еврей, шул адәм башта ук, әлеге бриллиант кисәге тәвә кошларының берсе тарафыннан йотылганчы ук, падиша дигәнебез затлы ташны кулында уйнатып, кеше саен күрсәтеп, мактанып йөргән чагында ук, дәррәү өч-дүрт мең фунт-стерлинг бәя биргән иде. Шунлыктан, үзегез уйлап карагыз, тәвә кошлары белән ясалган бу «лотерея»ның кешеләрне кызыктыруы, утсыз-шырпысыз күзләрен яндыруы гаҗәпмени!

Мин кичә, тәвә кошларын алып баручы егеткә сүз каткач, егет, аны-моны абайламастан, ычкындырып салган иде. Тәвә кошларының берсе үзен кәефсез тота, ашказаны бозылганга охшый, дигән иде. Әйтүенә караганда, үзенә күрә тамгасы да бар, ди, анысының — койрык канатларының берсе ак, бөтенесе түгел, берәве генә. Икенче көнне, аукцион башлану белән, нәкъ әнә шул җанвар сатыла башлагач, бәясе сиксән биш фунт-стерлингка сикергән ул тәвә кошына мин шундук берьюлы тагы биш фунт-стерлинг арттырган идем, югыйсә. Ашыга төштем, ахрысы, күрәсең, мине алдан ук нәрсәнедер белә бугай бу төлке, дип уйладылар, бөтенесе дә койрыгында әлеге шул бер генә ак каурые булган тәвә кошына ябырылдылар. Ә падиша, әйтергә кирәк, теше-тырнагы белән сырышты ак каурыйлы тәвә кошына — арттырган саен арттыра, тәмам саташты акай күз. Ниһаять, еврей йөз җитмеш биш фунт-стерлингка бәреп алды кошны — бетте шуның белән эш. Падиша «Йөз дә сиксән!» дип кычкырып карады, ләкин соңга калды, чүкеч төште, сделка бетте, дип игълан

итте Поттер. Кыскасы, койрыгында бер генә ак каурые булган тәвә кошы затлы ташлар белән алыш-биреш итүче сәүдәгәр еврейга эләкте һәм ул, озак уйлап тормастан, кулына пистолетын алып, кошка атып җибәрде. Поттер дигәнебез, шайтан алгыры, ай-һай, тавыш күтәрде шунда — бу килештән сез миңа калган өч кошымны сатарга комачаулыйсыз, янәсе,— ә падиша, шундый дәрәҗәле башы белән, шатлыгыннан тәмам тилерә язды. Хәер, без барыбыз да диярлек чак кына кызмага биреллек кебек. Яшермичә әйтәм, атылган кошның, ниһаять, эчен актарып, аннан бернинди дә затлы таш чыкмагач, мин үзем дә иксез-чиксез куандым. Шул өтеккә бәя өсти-өсти, мин дә бит йөз кырык фунт-стерлингка хәтле җиткән идем — алла саклады бу юлы.

Кәрлә буйлы еврей, барлык еврейларга хас булганча, өзгәләнмәде-сугылмады, хәтта тыныч калды дияр идем мин. Туры килмәгән икән — туры килмәгән, нишләтәсең аны, бәхетең шундый булгач. Ләкин Поттер, әгәр аның шартын искә алмасалар, аукционны шундук туктатачагын белдерде, аның шарты: тәвә кошларының сатылырга дигәннәре бөтенләй сатылып бетмичә, товарны кулга биреш юк, имеш. Кыйммәтле ташлар белән алыш-биреш итүче сәүдәгәр, бу очракта андый шарт куелу һич урынлы түгел, дип бәхәс күтәрде. Тавышлар төп-төгәл диярлек икегә аерылды, кыскасы, шул: аукционны икенче көнгә хәтле туктатып торырга булдылар.

Ул көнне кичке аш бик җанлы узды, сәбәбе аңлашылса кирәк, ничек кенә димә, Поттер сүзе сүз булды: болай бит аның өчен җиңелрәккә килә, ничек булып бетәр дип башны катырасы юк, ә без барыбыз да бу ходны уйлап тапканлыгы өчен аңарга бурычлы идек. Әлеге теге, улы кайдадыр Лондонда адвокат булып эшләүче картлач, бу эшне төрле яклап уйлаганнан соң, тәвә кошларының кайсының булса да берсенең эченнән бриллиант килеп чыканнан соң да, ул кыйммәтле ташны төп хуҗасына кире кайтармыйча калу законга сыйганлыгы яки сыймаганлыгы турысыннан үзенең шиге барлыгын белдерде. Ә мин исә, әле дә исемдә, кыйммәтле табылдыкны законсыз үзләштерү дигәнне юк сүз дип таптым, асылда бу чынлап та шулай булып чыгачак та. Кызу бәхәс кузгалды һәм, ниһаять, без корабта чакта ук тәвә кошларының барысын да үтереп бетерү ахмаклык булыр иде, дигән карашка килдек. Теге, Лондонда адвокат улы булган карт джентельмен тагын закончалыкны боргычларга кереште: имештер, аукцион — лотерея дигән сүз ул, ә лотерея закон тарафыннан тыелган нәрсә, димәк, бу килештән аңарга тик бер генә юл — капитанга дәгъва белдерү юлы гына кала, имеш. Ә Поттер моңа каршы үз дәлилен китереп куйды: мин тәвә кошларын болай гына сатам, ә аларның эчләрендә нинди дә булса бриллиант барлыгын белмим һәм белергә дә теләмим. Ул яктан мине алдап сата дип әйтергә берәүнең дә хакы юк. Киресенчә, сатылачак өч тәвә кошының эчендә бриллиантның юклыгында аның иманы камил, булса тик үзенә алып калачак кошта гына булуы ихтимал, имеш. Ничек кенә сүз куертмыйк, икенче көнне тәвә кошларының бәяләре нык күтәрелде. Каһәр төшкән коткы, икенче көнне кошларның һәрберсе уртача ике йөз егерме җидешәр фунт-стерлингтан ашып китмәсенме! Шунысы тагы гаҗәп, падиша дип атала торган дәрәҗәле әфәндегә бер тәвә кошы да эләкмәде. Тамагын ерта-ерта кычкыруы гына калды аның, бүтәннәр бәя арттыра-арттыра бәхет сынаганда, акырыпмы-акыра: имештер, ул — аз да түгел, күп тә түгел — тәвә кошларын төрмәгә яптырачак. Ә Поттер юри аны котырта-котырта эшлисе эшен эшли бирде. Бер тәвә кошы аз сүзле, тыныч характерлы чиновникка китте, икенчесе әлеге шул кыйммәтле ташлар белән алыш-биреш итүче сәүдәгәр еврейга, ә өченчесен, акча салышып,

корабның механиклары уртакка алдылар. Ул арада Поттер, ник сатып әрәм иттем кошларымны, дип сыкранырга-еларга тотынмасынмы! Янәсе, күренеп торган меңнәрне җилгә очыруы булды бит бу, ә аның үзенә дип калдырганы, мөгаен, буш карачкыдыр әле, һәр вакыт ул, Поттер, ахмак булып кала. Мин аңарга, алайса, үзенә дип калдырганны миңа сатмасмы, дип сүз кушып караган идем дә, соңга калдым, ул инде Һиндстаннан кайтып килүче һәм анда җәмгыять, әхлак проблемаларын өйрәнеп, башына дөнья хәтле акыл туплаган политик бер эшлеклегә соңгысын да сатып җибәрергә өлгергән иде. Бу соңгысы өч йөз фунт-стерлингка киткән.

Ниһаять, Бриндизидә ул шайтан кошларын пароходтан төшерделәр. Гәрчә бу очракта да Лондонда адвокат улы булган карт джентельмен таможня тәртипләрен бозуда гаепләп, дәгъва белдерергә маташса да, аның сүзенә игътибар итүче булмады, төшерделәр. Шунда ук, тәвә кошлары артыннан ук диярлек, Поттер үзе дә, аның артыннан падиша да төште. Тәвә кошларын алып килгән һиндле егетебез, күңеле изләшкән кадерле җан ияләренең күз алдында төрлесе төрле якка таралышуын күреп, чак кына акылын җуймыйча калды һәм, әгәр бриллиант чыга калса, ул затлы ташны кая җибәрергә дип тәвә кошын сатып алган кешеләрнең һәрберсенә тиешле адресны бирә торды. Ләкин тегеләрдән берсе дә аның исеме, адресы белән дә кызыксынмады һәм үз адресларын әйтергә дә ашыкмадылар! Аннары алар төрлесе төрле якка китеп бардылар. Ә мин пароходта Саутгемптонга хәтле сәфәремне дәвам иттем һәм анда, ярга чыкканнан соң, тәвә кошларының берсен, пароход механиклары җыелышып сатып алган өтелгән кошны янә бер күрдем. Ул шөкәтсез кош шул тирәгә җыелышкан ачык авызлар арасында, читлектә, сыңар аягын яшерә биреп, сыңар аягында гына басып тора иде. Һәм уйладым мин шунда: ул кыйммәтле бриллиант ташын саклау өчен бу өтелгән кош эченнән дә әйбәтрәк савыт табылмады микәнни? Әлбәттә, бриллиант дигәнең чынлап та аның эчендә булса!

Болар барысы да нәрсә белән бетте соң? дип соравыгыз мөмкин. Ничек булган булса, шулай бетте бугай... Хәер... Әйе, шуңарга охшашлырак. Монда, әгәр беләсегез килсә, бу эшкә бер әкәмәт хәл шактый гына ачыклык кертә. Атна-ун көн узганнан соң, инде өйгә кайткач, мин шулай бер көнне Риджент-стрит урамында үземә кирәкле кайбер вак-төякләр алырга йөргәндә, беләсезме, кемнәрне күрдем? Падиша һәм Поттер — эшнәләрчә култыклашканнар, икесе дә яхшы ук сәрхушләр... Шуннан инде уйлап карыйк...

Әйе, бу уй минем башыма теге чакта ук бер килгән иде. Әмма бриллиант мәсьәләсендә шөбһәгез булмасын, бриллиант чын бриллиант булгандыр. Падиша дигәнебез дә, әлбәттә, дәрәҗә иясе кеше, бу яктан да минем шигем юк. Мин аның исемен газеталарда да укыдым, хәтта бер генә тапкыр да түгел. Ә менә тәвә кошларының бриллиантны чынлап та йотулары яки йотмаган булулары — анысы инде, ничек әйтәләр әле, икенче мәсьәлә.

**ФАТИХ ХӨСНИ** тәрҗемәсе.

≈≈≈≈≈≈

Марсель Зарипов

# МОҢЛЫ КАЗАН, НУРЛЫ КАЗАН

*Башкалабызның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турында уйланулар*

## Саумы, шәһәр!



Синең шәһәрне ташлап киткәнең дә, аның белән озакка аерылып торганың да юк. Гел яхшылык кына теләүче, киң күңелле дустың төсле, ул гомереңбуе синең юлдашың булды. Син аны кичә дә күрдең, бүген дә ул синең күз алдында, моннан бер генә сәгать элек урамнарын урап кайттың, дулкыннардан күзең алмыйча Идел ярында басып тордың, канатлары белән иңеңә кагылырдай булып баш очында очкан акчарлаклар тавышын тыңладың. Монысы шулай. Ләкин шәһәр белән һәр очрашуыңда, рухи халәтең нинди булуга карап, — шат күңелле яки бераз ямансу чагыңмы, әллә галәмнең, вакытның чиксезлеге турында фәлсәфи уйларга чумган вакытыңмы, — син андагы үзгәрешләрне күрми, сиземләми калмыйсың.

Кояш, күз чагылдыргыч аяз көн вәгъдә итеп, әле офыктан күтәрелеп кенә килгән, әле көндезге ыгы-зыгы башланмаган тымызык иртәләрдә шәһәр борын-борыннан килгән могҗизаны — тереклекнең уянуы-яңаруы могҗизасын түземсезләнеп һәм сөенеп-зарыгып көтеп алучы сабый баланы хәтерләтә, һәм аның бу халәте анда яшәүчеләргә — яңа көн туу белән гадәти эшләренә, тормыш мәшәкатьләренә чумучы кешеләргә дә күчә, бу көндә аларга да уңыш вәгъдә итә төсле. Ә менә көндәлек ыгы-зыгы башланып, кешеләргә як-якларына карарга, үз тирәсендәгеләрнең бу дөньяда нинди максат белән яшәүләре турында уйланырга ара калмый торган, һәркем бүген үз файдасына, җәмгыять файдасына үзе башкарырга тиешле эшләр белән генә мәшгуль булып, дөньяның колач җитмәстәй киң һәм мәһабәт икәнлеген, әмма ком бөртегедәй генә тоелган адәм баласының да бу бипиһая иркен галәмдә нинди зур урын тотуын аңы-фикере белән булудан бигрәк инстинкты белән генә сиземли алган бер вакытта шәһәр бөтенләй икенче булып күренә. Җиде төн уртасында, ерактагы галактикалардан иңгән серле тоныкнурлар якты-

лыгында исә шәһәр өченче бер төсле гәүдәләнеш таба: мәшәкать һәм бетмәс ваем-шөгыльләрдән талчыккан булып түгел, яңа казанышлар, яңа эш-тырышлыклар, яңа кайгы-борчулар өчен яңа көч туплаучы булып күренә.

Менә шул чакларда күңелдә аңа баш иеп сәлам бирү теләге туа: «Саумы, шәһәр!»

Бер үк агымсуга ике тапкыр кереп булмый, диләр. Шәһәргә карата да бу шулай. Аңарда бернәрсә дә үзгәрмәгән кебек: һәйкәлләр һәм таш-тимер сыннарда элеккечә үк үткән заман төсмере сакланган, тупыллар элеккечә үк шаулаша, кешеләр һаман шулай каядыр ашыгалар, дөнья куалар. Ләкин кеше дигәненнең үзенчәлеге дә шунда шул: аның күңел түрендәге хатирәләр җебе беркайчан да өзелми, һәм шул хәтер дигән нәрсә кешене, аның теләгеннән һәм ихтыярыннан тыш, үткән заманнарга алып китә, һәм ул, үз тормышының сәхифәләрен актарган төсле, шәһәр тарихындагы билге һәм тамгаларны күңелендә яңартырга тотына.

Менә үз гомерендә күпне татыган, алдан күрергә өйрәнгән борынгы бабабыз сызып калдырган беренче эз. Ул кара урманнар белән капланган Идел ярларына килгән дә, бу урыннарның «хайван асрамага яраклы, умарта кортларына, яшелчәләргә, киек-җәнлеккә һәм балыкка бай»[1] булуын тиз шәйләп алган һәм урманнан арындырып сөрелгән беренче басуга беренче уч орлык чәчкән.

Кеше хәтере — ул календарь кәгазенә битараф куллар төшергән тамгалар түгел, салкын мәрмәр һәйкәлләр һәм колонналар да түгел. Хәтер ул — һәрберебезне дулкынландырган теләк, үткән еллар һәм гасырлар ераклыгына фикер карашы белән үтеп керү теләге, ул — бүгенге яшәешебезнең асылын һәм мәгънәсен аңларга омтылу, ул — алдагы елларны каплап торган пәрдәнең бер почмагын гына булса да күтәреп, киләчәкне күзалдына китерергә тырышу. Әгәр без бүген шәһәрне «Саумы, чал кала!» дип сәламлибез икән, бу безнең аның үткәненә, бүгенгесенә, аның эшчән кыяфәт белән кабатланмыйча гына алга, яңа үрләргә таба баруына ихтирам күрсәтүебез генә түгел, бу безнең аңа киләчәктә дә яңа уңышлар теләвебез.

Башкалабызны минем төрлечә, төгәлрәк итеп әйтсәк, һәрчак бер үк дәрәҗәдә зур кызыксыну белән төрле урыннардан күзәткәнем бар һәм һәр очракта аны яңача итеп күрәм. Я ул алдыңа ачып салынган китап битләредәй ярылып ята, аның бар нәрсәсе синең күз алдыңда, бар нәрсәсе аңлашыла. Я үзгәрүчән гасырларның үсеш кануннарын аңларга тырышуы белән ничектер серле, аңлаешсыз кебек тоела. Ничек кенә булмасын, аның кыяфәтендә күз белән күреп, акыл белән аңлап бетереп булмый торган ниндидер бер нәрсәсе кала төсле.

Көмеш коштай болытларга тикле очып менгән самолеттан караганда шәһәр уч төбендәгедәй: анда-санда яшел таплар булып чәчелгән парк-бакчалар, уктай сузылып киткән урам-проспектлар, күгелҗем тасма булып яткан Идел һәм Казан елгалары, сирәк очрый торган табигать бүләге — якташыбыз, русның бөек җырчысы Федор Иванович Шаляпин Адриатик диңгезенең гүзәллекләренә дә алыштырмастай матур күл дип мактаган, бөек Тукайны күп кенә шигъри юлларга рухландырган Кабан күле. Ләкин югарыдан караганда шәһәрнең күңелдә туган образында, — рәссамның бер генә урынында буяу төшерелми калганга күрә төгәлсез булып күренгән картинасындагы төсле, — нидер җитенкерәми.

Ә шәһәр аша, юл күрсәтүче кызыллы-яшелле утларны, урамнарны һәм тыкрыкларны саный-саный, тиз йөрешле машинага утырып узганда янсә салмак адымнар белән атлап үткәндә, киресенчә, күзәтү киңлеге

[1] «Казан тарихы». Текстын хәзерләүче һәм кереш мәкалә язучы Г. И. Моисеева, Мәскәү, 1954, 47 бит.

дип әйтимме, шул җитми төсле: игътибар аерым детальләргә юнәлгәнлектән, гомуми тәэсир тулы ук булмый.

Менә биредә, элекке Арча кырында, Себер башланган урында «Пугачевтан да хәтәррәк җинаятьче» Александр Николаевич Радищевның богауларын салдырганнар. Әлбәттә, географ күзлегеннән караганда, болай әйтү дөрес түгел. Иксез-чиксез Себер ул чакта да Урал аръягында башланган. Ләкин ул вакытта Радищевны сөргенгә озатучы сакчылар, Екатерина патшаның аны Себергә җиткәч кенә богаудан азат итәргә мөмкин дигән катгый күрсәтмәсен истә тотып, Казанны үткәч тә богауларны кирәксез тапканнар.

Менә зур-зур таш пулатлар белән чолгап алынган бер генә катлы бу кечкенә агач өйдә вакыт дигәнең үзе ук артка чигенеп, безне үткәннәргә илтә төсле. Биредә кайчандыр халкыбызның бөек мәгърифәтчесе, батыр рухлы Каюм Насыйри яшәгән.

Рух бөеклеге кайчак үзенең тулы чагылышын ялтырап үткән яшендәй кыска гына бер мәлдә, кеше үлем һәм газаплар аша үзенең үлемсезлегенә таба атлаганда таба. Ә менә кайберәүләрнең тормыш батырлыгы болай ялтырап үтми, аларның беренче карашка күзгә бәрелеп тормаган бөтен аңлы тормышы, ул тормышның һәр көне — замандашлары өчен генә түгел, киләчәк буыннар өчен дә эшләнгән бөек, тыйнак батырлык. Каюм Насыйри шундыйлардан. Бу өйдә хәзер дә кешеләр яши, шуңа күрә анда һәркем кереп йөрми. Ләкин шәһәргә, аның үткәненә бу тирәдән торып күз ташлаганда күпләрдә үлгәннән соң гына аңлау тапкан бу кешенең истәлеге һәм тормышы алдында ихтирам белән баш иясе килә. Тәбәнәк кенә бу өйдә яшәгән какча гәүдәле ул кешенең күкрәгендә көрәшче һәм әзләнүче, мәгърифәтче һәм галим, рәссам һәм шагыйрь йөрәге типкән. Мулла-мунтагайның каһәренә, әзәрлекләү һәм мыскыллауларга дучар булган бу бөек көрәшче соңгы сулышына кадәр төп максатына — халкын агарту максатына турылыклы булып калган. Ул ирекле тыңлаучы булып университет лекцияләренә йөргән, үзе мәктәпләр ачкан, үзе шуларда дәрес биргән, алар өчен табигать белеме, тарих, математика, география буенча дәреслекләр төзегән, повесть һәм хикәяләр язган, дини гореф-гадәтләргә каршы көрәшкән. Бу агач йорт янында уйланганда, фани дөнья кешедән өстен була алмый, дигән борынгы хакыйкатьнең ни дәрәҗәдә зирәк булуына тагын бер кат төшенәсең.

Александр Сергеевич Пушкинның Казанга килүенә бәйле урыннардан үткәндә дә безнең күңелне шундый ук кичерешләр били. Биредә мин «Капитан кызы» авторының Пугачев восстаниесе турында материаллар туплап йөрүенә кагылышлы инде безгә мәгълүм нәрсәләргә берни дә өстәргә җыенмыйм. Шагыйрьнең Казанга 1833 елда 6 сентябрьгә каршы төндә килеп төшүе, биредә лицейдагы сабакташы, хәзерге Биектау районының Каймар авылына, кайнатасы имениесенә баручы танылган шагыйрь Евгений Баратынский белән очрашуы, шулай ук шигырьләр язгалаучы Эраст Перцов өендә шахмат уйнавы, университет профессоры Карл Фуксларда кунакта булуы, анда Фуксның хатыны Александра Андреевнаның шигырьләрен тыңлавы, Пугачевта әсирлектә булган сәүдәгәр Л. Ф. Крупенниковның башыннан үткәннәрен игътибар белән тыңлавы һәм язып алуы, Казанда вакытының бушка үтмәвенә шатланып, хатынына: «Фәрештәм минем... бу якларга килеп чыгуыма канәгатьмен»,— дип хәбәр итүе күпләргә билгеле.

Ләкин эш даталарда һәм вакыйгаларда гынамыни?! Конкрет фактларны читкәрәк куеп торып булса да, бөек шагыйрьнең ул вакыттагы уй-фикерләрен, йөрәк газапларын аңлыйсы, күз алдына китерәсе килә. Сакланып калган кәгазьләргә, патшаның үз рөхсәте белән бирелгән юл документларына караганда, бу елны А. С. Пушкин Емельян Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар восстаниесенең тарихын язар өчен Орен-

бург далаларында булган. Болары билгеле. Ә менә шуннан сигез ел элек дуслары — декабристлар: Кюхельбеккерлар, Пущиннар, Якуниннар үтеп киткән Себер трактына — кайгы-газап юлына аяк басканда шагыйрь күңелендә нинди уйлар кузгалуын, бу кичерешләрнең ни дәрәҗәдә тирән булуын кем генә әйтә алыр икән? Бәлки шагыйрь ирләре артыннан Себергә киткән батыр йөрәкле декабрист хатыннары турында, беренче тапкыр унике яшьлек кызый чагында этисе — Ватан сугышы каһарманы генерал Раевский гаиләсендә күреп, гомере буе ихтирам һәм самими мәхәббәт белән йөрәк түрендә йөрткән Мария Волконская турында уйлангандыр? «Полтава» исемле поэмасына багышлаудагы менә бу юлларны хәтерлик:

Сиңа — ләкин серле музамның
Колагыңа өне житәрме?
Йөрәгемнең омтылуларын
Тыйнак күңелең аңлап бетәрме?
Я шагыйрьнең багышлавы да,
Үткәндәге сөюе кук, тагын
Җавап тапмый синең алдыңда,
Танылмастан үлеп китәрме?
Бел, ичмасам, минем моңнарым
Сиңа бер чак якын булганын —
Һәм аерылгач, уйла шуны да,
Минем көйсез тәкъдир юлымда
Синең ерак, хәсрәт яланың,
Әйткән сүзең, соңгы авазың,
Тик шул минем күңел байлыгым
Һәм шул гына гыйшкы җанымның[1].

*(Н. Исәнбәт тәрҗемәсе.)*

Бу юллар саф мәхәббәтен тугрылык хисе, рух батырлыгы белән баета белгән Мария Волконскаяга багышланган. Ул чакларда башкалада еш була торган балларның берсендә, — бәлки яшь княгиня катнашканнарының соңгысындадыр,— А. С. Пушкин Мария Николаевна янына килә дә болай ди: «Әгәр мин, княгиня, сезнең язмыштан көнләшәм дисәм, сез, бәлки, миңа ышанмассыз да. Сезне авыр тормыш көтә, әмма ул фидакарьлеккә, батырлыкка бай тормыш булачак. Сез заманыбызның иң яхшы кешеләре арасында яшәячәксез, ә без...»[2]

Күрәсең, кеше күңеленең, кеше хәтеренең үзенчәлеге шунда: мондый очрашулар, аларга бәйле уйланулар, хатирәләр кайчакта шәһәрнең үзен бераз томалап торалар. Нишләмәк кирәк!?

... Казанның иң зур байлыкларыннан берсе — су дәрьялары! Бәлкем чыннан да шәһәргә су өстеннән торып карау яхшырактыр? Иртә, әле бик иртә. Кояшның яңа гына чыгып, әйләнә-тирәгә түм-түгәрәк күз булып текәлгән чагы. Һава тып-тын, җилсез, кояш нурыннан су өстендә утлар кабына да житез, шаян ялкын белән дөрләп яна башлый. Син алсу су көзгесенә караган килеш сирәк очрый торган бу искитмәле гүзәллеккә хәйран калып утырасың.

Кечкенә катер, талгын дулкыннарны икегә ярып, ашыкмый гына алга бара. Берниндн җыерчыксыз су өсте әле һаман тылсымлы көзгене хәтерләтә. Ә шәһәр — зур, мәһабәт шәһәр — үтә күренмәле алсу ераклыктан сиңа карап тора. Очлы башлы мәчет манаралары, соборларның алтын гөмбәзләре... Борынгы корылмалар белән аралашып, бетон һәм пыяладан эшләнгән бүгенге көн биналары башларын күккә чөйгән. Яшел бүрекле агачлар, кара нокталар, сызыклар булып каядыр ашыгучы кешеләр, машиналар күренә... Корылмаларның иң биекләре — ак

---

[1] А. С. Пушкин. Сайланма әсәрләр, ике томда. Татарстан китап нәшрияты, Казан, 1954 ел, 232 бит.
[2] А. Гессен. 3 томда. Дәүләт матур әдәбият нәшрияты, 1955, 165 бит.

могҗиза — Кремль һәм милли архитектурабызның, бөтендөнья архитектурасының җәүһәре — җиде катлы Сөембикә манарасы.

Җырлый башлар стеналар. Ак моңы чынлап чыгар,
Якты көндә сез могҗиза ясагыз, буяучылар!
Һәм Кремль ялтырасын кара күздә яшь булып.
Төшләрдә күренсен Казан, кадерле ак төш булып.

*Рөстәм Кутуй.*

Казан чыннан да ак төш хатирәсе сыман. Борын заманны белүче, аңа кагылышлы һәр нәрсәгә ихтирам белән караучы кеше өчен шәһәр элек татарлар, марилар, чувашлар гына яшәгән бу крайга рус архитектурасы традицияләре үтеп керүнең сирәк очрый торган чагылышы буларак, шәһәрнең тышкы кыяфәтендә эз калдырган, кеше күңеленә тәэсир көче ягыннан кабатланмас архитектура стильләренең бер-берсенә үзара йогынты ясауларының, бер-берсе белән кушылуларының ачык үрнәге буларак кадерле.

Кремль — ул биредә яшәгән халыклар тарихында кискен борылыш тудырган уналтынчы гасыр корылмасы. Рус җиренең иң яхшы архитекторлары Постник Яковлев һәм Иван Ширяй янгыннан соң хәрабәләр өеменә әверелеп калган Кремль калкулыгында ул заманнарда иң ышанычлы һәм популяр саналган Псков стилендә төзелеш эшләре башлыйлар. Искә төшереп үтик: борынгы рус шәһәрләре Суздаль, Владимир, Бөек Ростов шул стильдә төзелгәннәр.

Заманында аңа охшаш биналарның бик сирәге, — Мәскәү тирәсендәге Фили соборы һәм Нижний Новгородтагы Строганов чиркәве генә,— тиңдәш була алырлык Петр һәм Павел соборы — Россияне үзгәртеп коручы исемен алган, Рус дәүләтен көчле диңгез державасына әверелдерү турында кайгыртып, безнең шәһәребездә верфь һәм адмиралтейство оештырган Петр Беренче патшаның Идел буенда булуы истәлеге, ул вакытларда киң таралган, купшы бизәкләргә бай барокко стиле белән мавыгу нәтиҗәсе.

Петр Казанда нибары 12 көн тора. Эше-мәшәкате гаять күп булуга карамастан, ул борынгы Болгар шәһәре хәрабәләренә барып килергә вакыт таба, Кече манарага менеп төшә һәм «... туздырылган шәһәр калдыкларын, андагы зарарланган һәм җимерелергә торган корылмаларны һәм монументларны төзәтү өчен һич кичекмәстән бернечә ташчы җибәреп, аларны җитәрлек кадәр известь белән тәэмин итәргә, аларны саклап калу турында кайгыртып торырга... моннан да артыграк зыян күрмәсеннәр өчен аларны карарга ел саен кемне дә булса җибәреп кайтарырга»[1] куша. Әмма патшаның бу әмере үтәлми, коры фәрманның бәясе, халык әйтмешли, сукыр бер тиенгә кайтып кала.

Ул чак Петр дәүләт казнасын ничек тә булса тулыландыру турында баш вата. Һәм менә, елъязмалар хәбәр иткәнчә, көннәрнең берендә патшага аны ниндидер сәүдәгәрнең күрергә теләвен әйтәләр. Башта Петрның бик нык ачуы килә, ул әрсез сәүдәгәрне куып чыгарырга куша, ләкин соңрак ачуын баса, кызыксынып китә һәм тегенең ни йомыш белән йөрүен белергә тели.

Сәүдәгәр үзен Михляев дип тәкъдим итә, мануфактура хуҗасы мин, ди, ә теләгем шул була: үз патшама байлыгым белән ярдәм итмәкче булам, ди. Патша тегенең предприятиесен карап чыга һәм, күрәсең, анда эшнең куелышы белән канәгать кала, ә инде сәүдәгәр һәм аның хатыны поднос белән алтын һәм көмеш акчалар, энҗе һәм кыйммәтле ташлар тулы миски дә китереп тоттыргач, ул бөтенләй эреп китә һәм Михляевка тәмам таркалу хәленә килгән казна постау мануфактурасын бүләк итә. Петр әлеге сәүдәгәр турында башкаласына киткәч тә оныт-

[1] А. Формазов. Очерки по истории русской археологии. Москва, 1961, стр. 28.

мый, аңа: «... әгәр ул заводта сезгә ярдәм кирәксә, ул турыда турыдан-туры безнең кабинетка һәм мануфактур коллегиягә язып җибәрегез, без исә сезгә ярдәм итеп кенә калмабыз, бүтәнчә дә шәфкатебездән калдырмабыз», — дип хат та яза.

Тәхет иясе кешенең үзеннән шундый хат алгач кем генә битараф кала алыр икән? Башы күккә тиярдәй булып шатланган сәүдәгәр патша алдында бурычлы булып калырга теләми. Петрның Казанга килүе истәлеге итеп изге собор салдырырга карар кыла. Әгәр шундый зур корылманың дүрт елда әзер булуын искә алсак, аны салучы осталарның ничек тырышып һәм ашыгып эшләүләрен күз алдына китерүе кыен булмас. Дүрт ел — хәтта безнең көннәр өчен дә зур ара түгел, ә монда тагын шуны да искә алырга кирәк: соборны ике тапкыр салырга туры килә, чөнки беренчесе уңышсыз чыга, инде бетте дигәндә генә ишелеп төшә. Эшне бүтән осталарга тапшырырга туры килә. Әмма Петрга бу бүләкне күрү насыйп булмый. Фин култыгында һәлакәткә очраган корабны коткарам дип нык кына салкын тидерә һәм 1725 елның 28 гыйнварында дөнья куя.

Татарстан Дәүләт музеенда Петрның билгесез автор тарафыннан ясалган рәсеме саклана. Дөрес, патшаның йөзен уратып, артык тасма телләнеп язылган түбәндәге шигъри юлларны исәпкә алмаганда рәсемнең искитмәле бернәрсәсе дә юк:

> Каралыкны давылдай куып-таратып,
> Россияне Петр акылы агартты[1].

Әгәр Петр Беренчегә багышланган бу юллар шигъри яктан камил булудан ерак торсалар, шул ук патша хөрмәтенә шулай ук билгесез архитектор тарафыннан төзелгән собор — сокландыргыч гүзәл, нәфис. Ул инде ике ярым гасыр буена тора, шулай да аның белән һәр очрашу — үзе бер зур бәйрәм.

Шәһәрнең үзендә Идел әллә ни зур түгел, Казан елгасын да кертеп исәпләгәндә Россиянең бу төп урамын тиз йөрешле катерда бер сәгать эчендә аркылы чыгып була. Ләкин кеше хәтерендә, кеше күңелендә тизлек үлчәве, тәэсир үлчәве бөтенләй башка. Шәһәргә якынлашканда беренче карашка кечкенә генә, беленер-беленмәс төсмерләр буенча аның үткәнен күз алдына китереп бастырасың, бүгенгесен барлык нечкәлекләре белән күреп куанасың, киләчәге турында уйланасың. Хәер, Казанга охшаган, Казан кебек үк шәһәр-һәйкәл дип атап була торган бүтән торак урыннары да кешегә шулай тәэсир итәләр булыр...

## Язмыштан узмыш

Ил буйлап сәяхәткә чыккан һәм безнең шәһәргә вакытлыча гына килгән туристны да, анда күптән яшәүче кешене дә бер үк дәрәҗәдә кызыксындырган беренче сорау: Казанга ничек нигез салынган? Безнең заманда яңа шәһәрләр еш салына, аларның төгәл язылган туган көннәре була, алар, вакыты җиткәч, чирек, ярты гасырлык бәйрәмнәрен уздыралар. Аларның, әйтик, мең еллыклары да шундый ук төгәллек белән билгеләп үтеләчәк. Тарих өчен мең ел күпмени ул — вакыт дәрьясында бер тамчы су кебек кенә!

... Ә менә Казанның метрика кәгазендә андый төгәл әйтеп куйган көн әле билгеле түгел кебек. Аның каравы, шәһәрнең барлыкка килүе турында риваятьләр шактый. Менә аларның берсе. Европаның көнчы-

[1] Рәсем сәнгате галереясе. Каталог. Татарстан АССР Дәүләт музее. Казан, 3—4 бит.

гышындагы беренче дәүләтләрдән саналган Идел буе болгарлары иленең башкаласы җирән сакаллы Батый хан урдалары тарафыннан яулап алынганнан соң шәһәр ялкын кочагында кала. Кара төтен таралгач карасалар, янгын хәрабәләре өстендәге калкулыкта патша хатыны яшь бикәч басып тора. Бикәчнең ике абыйсы да дошман явыннан исән калган. Һәм менә алар кеше аягы басмаган куе урманнар аша үтеп, еракеракларга, юрга атлар барып җитә алмас, очар кошлар очып җитә алмас урыннарга китәләр һәм шунда бер крепость, ягъни бүгенге Казанны нигезлиләр.

Шул ук риваятьләр шәһәрнең исемен болай аңлата: яр буена килеп житкәннән соң беренче тукталыш вакытында ук кешеләр, имеш, казаннарын суга ялгыш төшереп җибәрәләр. Менә шуннан киткән, имеш — Казан, Казанка...

Бу турыда бәет сымак бер нәрсә дә бар:

Төшеп киткән кыз кулыннан инешкә алтын казан,
Һәм калыккан шул урында зур кала — шәһри Казан...

Сүз дә юк, риваятьләр барысы да кызыклар, матурлар, ләкин, кызганычка каршы, күп очракта алар хакыйкатьтән шактый ерак булалар һәм шәһәрнең паспортын тутыру өчен фәнни нигез булмыйлар. Бу очракта да шулай: Казанның паспорты шушы көнгә тикле тутырылмаган һәм аның туган көненең дә билгеләп үтелгәне юк.

Һәм менә, ниһаять, борынгы гасырлар авазыдай, гүя үткәннәрне безнең көннәр белән тоташтыру өчен билгесез елъязмачы тарафыннан махсус сузылган нечкә генә җеп, шәһәребезнең ничәмә-ничә еллар эзләү нәтиҗәсендә табылган һәм археологик экспедицияләр, казынулар, әдәби чыганаклар белән расланган метрика кәгазе. Әлеге билгесез Пименны тыңлап карыйк:

«Бысть же на Каме реке старый град, именем Брягов (Ибраһимов — автор искәрмәсе), оттуда же прийде царь, именем Саин Болгарский. И поискав по местам проходя в лета 6685 и обрете место на Волге, на самой украине русской, на сей стране Камы реки, концом прележаху к Болгарской земле, другим же концом к Вятке и к Перми... царь вознаградил на месте том Казань.»[1]

Инде «Ка-зан» — «Каз-ан» сүзенең үзенә килгәндә, бу атамадагы «каз» («каш», «кас», «кәс») сүзе борынгы төрки телләрдә «чик», «кырый» мәгънәсен аңлаткан. Болай булганда чыннан да исем җисемгә туры килә бит. Казан — Болгар дәүләтенең кырыенда, чик буенда салынган катау, кала. Бу тирәдә яшәүчеләр исә — каз кабиләсе, ягъни чик буе кабиләсе кешеләре. Хәзер галимнәр «казак» та — шул ук «каз» тамырыннан килеп чыккан сүз булырга тиеш дигән фикердә торалар. Чыннан да, теге вакытлардагы Дон казаклары, Җаек казаклары, Запорожье казаклары да дәүләтнең чигендә яшәүчеләр, ул чикләрне дошман явыннан саклаучылар булган бит.

Бу урында безгә бераз гына чигенеш ясарга һәм тарих битләрен актарырга туры килердер төсле. Инде телгә алынган елга кадәр нәрсәләр булган соң? «Рус җирләре чигенә үк» килеп, анда шәһәр салган кешеләр кем булганнар да, аларны бирегә, «хайван асрау өчен уңайлы», «киек-җәнлеккә, умарта кортларына, байлыкка бай» урынга нинди җилләр китереп ташлаган соң?

Мәгълүм булганча, VI гасырга тикле болгарлар Кара диңгез буе далаларында күчмә тормыш алып барганнар, Иделнең, Донның түбәнге

[1] «Кама елгасында Брягов (Ибраһимов) исемле иске шәһәр бар иде, әнә шуннан Саин Болгарский исемле патша килде. Эзли торгач, төрле җирдә йөри торгач, ул 6685 елда Иделдә, рус җирләре чигендә үк, Кама елгасының бу як ярында, бер ягы белән Болгар җирләренә, икенче ягы белән Вяткага һәм Пермьгә караган бер урын тапты... Патша шул урында Казанны салды».

агымнарында яшәгәннәр, ләкин, хазарларның, сугышчан гарәп кабиләләренең кысрыклавына каршы тора алмыйча, бүтән җирләргә күчеп китәргә мәҗбүр булганнар. Аларның бер өлеше Дунай якларына, хәзерге Болгария урнашкан җирләргә килеп чыккан, анда төпләнеп калган һәм христиан динен кабул иткән. Икенче өлеше исә Иделнең урта агымына, Кама тамагы тирәләренә күчеп килгән. X гасырда Идел буе болгарлары мөселман динен кабул иткәннәр. 922 елда Болгар дәүләтенең башкаласына Багдаттан күп кенә илчеләр килә — алар арасында укымышлылар, архитекторлар, һөнәрчеләр дә була. Шуңа булса кирәк, Идел буе болгарлары дәүләтенең шәһәр корылмаларында, бизәнү, көнкүреш әйберләрендә һәм археологик казылмалар вакытында табылган бүтән нәрсәләрдә Көнчыгыш культурасының йогынтысы, Урта Азиянең борынгы шәһәрләрен бизәгән осталарның эш алымнары да сизелә.

Идел-Кама болгарлары чыныккан, чыдам, көчле кешеләр булганнар. Төньякта алар Кама-Чулманның югары агымына кадәр, көньякта хәзерге Жигули тауларына, Урал елгасына кадәр барып җиткәннәр, көнчыгышта исә Агыйдел буйлап йөзгәннәр, ә төньяк-көнбатышта Нижний-Новгород тирәләренә кадәр барып, аучылык белән шөгыльләнгәннәр, балык тотканнар. Матур-матур таш диварлар төзи белүче, су үткәрү өчен катлаулы корылмалар ясаучы осталары булган, зур шәһәрләрне дә, кечерәк авыллардагы өйләрне дә җиренә җиткереп, зәвык белән сала белгән, үзара дус яшәгән, эш сөючән болгарларның даны ерак-еракларга таралган булган. Россия дәүләтенең күп томлык тарихы авторы В. Н. Татищевның язуына караганда, Болгар иленнән килгән төзүче-осталар монголлар явына кадәр күп элек үк Юрьев-Польской, Владимир кебек билгеле рус шәһәрләрен төзүдә катнашканнар.

Болгарлар металл койганнар, каен тузына яза белгәннәр, оста сугышчылар, иген игүчеләр саналганнар, югары культурага ия булганнар. XII йөздә Якуб ибн Ногман исемле галим-кади үз халкының тарихын язып калдырган. Монголлар һөҗүм иткәнгә кадәр үк Кол Гали әле бүген дә поэзия сөючеләрне образларының саф, фикеренең тирән, теленең төгәл һәм камил булуы белән таңга калдыра торган «Кыйссаи Йосыф»ын **шул** чакта язган.

Күп җирләрдә, күп илләрдә зур сәүдә үзәге буларак даны чыккан Болгар иленә Кама, Чусовая, Вятка елгалары буйлап төньяк сунарчылары, Идел буйлап гарәп илләре һәм Византия сәүдәгәрләре килә торган булган, Новгородтан төшүче зур-зур көймәләр туктаган.

Тынгысыз булган ул вакытлар, шомлы булган: кеше иген басуына да җәясен-угын кулына алмыйча йөрмәгән. Һәр авыл үзенә күрә бер ныгытма итеп корылган, ә сугыш, ау, балык тоту, бал җыю, иген игү, терлек үрчетү кебек үк, гадәти бер нәрсә саналган. Шуңа күрә болгарлар, Владимир кнәзе Андрей Боголюбский һәм аның боярлары арасында низаг чыгудан файдаланып, үз җирләренең төньяк чигендә ныгытма төзегәннәр...

Шәһәрләр язмышын гадәттә кешеләр язмышы белән чагыштыралар. Һәм бу очраклы хәл түгел. Яшь чакларда алар да зур дәрт белән, хыялга чумып яшиләр, ә олыгая төшкәч, чәчәк ату вакытларында, киләчәкнең какшамас булуына чын-чынлап ышанган хәлдә, бизәнә, байлык туплый башлыйлар. Әмма беркемнең дә теләк-омтылышлары белән исәпләшми торган тарих бөтенесен үзенчә хәл итә, әле генә чәчәк аткан, гамь белми яшәгән шәһәрләр юкка чыга, онытыла, кайчандыр дан-шөһрәткә күмелеп яшәгән башкалалар күңелләрдә ачыну уята торган фаҗигале язмышка дучар була.

Шул ук язмыш дигәнең болгарлар башта чик буенда кечкенә генә бер катау итеп салган шәһәрчеккә дә катлаулы тормыш, бай киләчәк

билгеләп куя. Ул, тарихның текә сикәлтәләре аша үтеп, башкала дәрәҗәсенә җитә, дөньяның ике зур кисәген — Европаны һәм Азияне тоташтыручы шәһәргә әверелә. Ныгытманың салынуына чирек гасыр үтәр-үтмәс, шәһәрне Всеволодның көчле дружинасы тар-мар итеп ташлый. Ә 1273 елда Казанга Алтын Урда ханы Минге-Тимер гаскәрләре ябырыла. Моннан соң ызгыш-низаглар белән алмашынып торган чагыштырмача тыныч еллар уза. Һәм, һич көтмәгәндә, 1370, 1391—1395 елларда Казанга Нижний Новгородтан ушкуйниклар һөҗүм итәләр. Ә 1445 елда шәһәр өстенә тагын бер бәла килә: Алтын Урда ханнарының соңгысы Олы Мөхәммәт аны хәрабә итә...

Әйе, еракта калган дәһшәтле гасырлар агышында, янгын хәрабәләрендә Казан үзенең туган көнен югалткан дип тә уйлыйк ди. Әмма Идел белән Казан елгасы кушылган урындагы калкулыкны һәм аның тирәләрен үзләренең көн күрү җирләре итеп сайлаган соңгырак буын кешеләре әле Чыңгыз хан урдалары басып кергәнче үк корыч кою, таш пулатлар салу, аларга махсус торбалар аша су үткәрү осталары булларак танылган, галимнәре һәм шагыйрьләре булган болгарларның варислары икәнлекләрен бер вакытта да исләреннән чыгармаганнар.

Еллар, гасырлар үткән, Идел һәм Казан сулары ага торган. Шәһәр дә үзгәргән, зурайган, тирә-юньгә, ерак-еракларга танылган. Анда матур-матур сарайлар, биек-биек манаралар, базарлар белән ул чит илләрдә дә дан казанган. Шәһәр стеналары янына Иван Грозныйның йөз илле меңлек гаскәре килеп туктаганда патша воеводалары Казан корылмаларының «бик тә биек, таштан салынган» булуларын әйтми кала алмаганнар.

Әмма тарихны үзгәртеп булмый. Аңардан өйрәнергә, бүгенге көн һәм киләчәк файдасына сабак алырга гына мөмкин. Иван Грозныйның күп меңләгән гаскәрләренә җитәкчелек иткән воеводалар арасында да тискәре патшаның ихтыярына каршы төшәргә, яулап алынган һәр шәһәрне хәрабәгә әйләндерү ул әле дәүләт башлыгының көчен һәм куәтен раслаучы бердәнбер чара түгел, бәлки рух көчсезлегенең дәлиле генә икәнлеген аның исенә төшерергә җөрьәт итүчеләр табылмаган.

Хәер, бу очракта артык катгый булуы кыен. «Грозный», («Дәһшәтле») кушаматының тикмәгә генә бирелмәгән булуын да онытмыйк. Россиянең баш опричнигы үтә чыккан каты куллы, кызу канлы, авыр холыклы адәм булган. Ачуы чыкканда ул теләсә кемнең башын кистерү янсә дарга асудан гына түгел, бөтен-бөтен шәһәр-авылларны күз яшенә һәм канга батырудан да тартынып тормаган. Моның өчен борынгы Новгород һәм аның халкы белән булган хәлне искә төшерү дә җитә. Шәһәр дәһшәтле Иванның теләгенә каршы килергә батырчылык иткән өчен генә алкын сулы Волхов елгасы җәзага тартылганнарның каныннан һәм үле гәүдәләреннән кап-кара төскә кергән. Ә бит, ни генә әйтсәң дә, Новгород ул әле башкала халкы белән бер үк динне тотучылар шәһәре, чын рус шәһәре.

Гомеренең дүртенче гасырын тутырып килә торган Казанга да үзенең яңа тарихын, кем әйтмешли, беренче казыктан башларга туры килә. Чөнки яңа шәһәрнең беренче корылмасына — Иван Грозныйның зур җиңүенә багышланган һәм бүгенгәчә сакланып калган Благовещение соборына — нигез салмас борын патша шәһәрдәге элекке барлык биналарны җир белән тигезләргә боерык бирә.

Һәм менә безгә, хәзерге буын кешеләренә, ул замандагы Казанның кыяфәтен, борынгы осталарның иҗат җимешләрен гасырлар томаны аша якынча гына булса да күз алдына китереп бастыру өчен ничәмәничә еллар буе шундый катлаулы сәбәпләр һәм вакыйгаларның чуалчык төенен чишеп азапланырга, хәрабәләр һәм янгын көле катламнарында казынырга туры килә.

Әмма язмыш дигәнең дә сукыр ук түгел икән ләбаса. Без язмыш кушкан эш дип санаган нәрсәләрдә дә кайчак зур мәгънәне төсмерләргә мөмкин икән. Әйтик, 1552 елда хәрабәләр өеменә әверелеп калган Казанны яңадан торгызу эшенең русның ул замандагы иң яхшы осталарына тапшырылуы үзе шундый бер бәхет түгелмени? Ачуы басылып, бераз аек акыл белән эш итәр хәлгә килгәч, Иван Грозныйның Постник Яковлев һәм Иван Ширяй кебек атаклы осталарга,— сүз уңаенда шуны да әйтергә кирәк: Казан ханлыгының Россиягә кушылуы истәлеге булган Василий Блаженный соборын салган кешеләргә,— «Казан шәһәрен таштан төзергә» дип әмер бирүе бу Идел буе шәһәренең икенче дәрәҗәдәге шәһәр итеп каралмавын раслаучы бер дәлил. Янсә менә тагын шундый бер мисал. Әдәбият сөючеләрдә Россия шагыйрьләренең патриархы дип атап йөртелгән Гаврила Романович Державинга Казанда һәйкәл кую теләге уянып, бу һәйкәлнең проекты эшләнгәч һәм җәмәгатьчелек моңа рөхсәт алу өчен югарыга мөрәҗәгать иткәч, художество академиясендә бу турыда кәгазьгә менә нинди резолюция салалар: «Һәйкәлне шундый итеп салырга кирәк ки, ул сурәтенең нәфислеге һәм буе-сыны белән шагыйрьләрдән иң беренчесенә Россиянең ихтирамын чагылдыру максатына туры килерлек һәм бер үк вакытта империянең Казан кебек шактый мөһим шәһәре өчен бизәк булып хезмәт итәрлек булсын». Төрле елларда шәһәребездә Х. Крами, Г. Руш, К. Мюфке, И. Ефимов кебек архитекторларның эшләве, ул заманнарда сирәк очрый торган хәл: хатын-кыз скульптор Мария Диллонның бөек математик Николай Иванович Лобачевский һәйкәлен иҗат итүе үзе зур бәхет түгелмени?!

Безнең көннәрдә — элек күз алдына да китереп булмаган мөмкинлекләр чорында — үзеңне күрсәтүе чагыштыргысыз җиңелрәк, әлбәттә. Уйлап карыйк. Әлмәткә 100 мең кешеле зур шәһәр булып җитешер өчен чирек гасыр кирәк булды. Түбән Кама шул ук санга 15 елда иреште. Ә менә гасырыбызның индустриаль гиганты — Кама автомобиль заводына нигез салынган көннән соң җиде ел үткәндә Чаллының халкы 250 мең кешедән артып китте. Элек, колачлар мондый зур була алмаган бер заманда, гомере һәм иҗатының санаулы гына еллары дәвамында архитектор күп нәрсә майтара алмаган, билгеле. Шулай да ул үткән елларның чын осталары, кем әйтмешли, тамчылап, мыскаллап булса да, шәһәребезнең йөзен бизәгәннәр, оныкларына үзләренең автографларын калдырганнар. Үз эшләренең чын осталары, югары идея өчен фидакарь көрәшчеләр булган бу кешеләрнең һәркайсы турында аерым-аерым тукталырга кирәк иде дә бит, урын чикле булу сәбәпле, моны эшләү мөмкин түгел. Шулай да ике кеше — Петр Гаврилович Пятницкий һәм Михаил Петрович Коринфский турында әйтми мөмкин түгел. Аларда үз-үзләренә ихтирам, иҗат эшләренә мәхәббәт хисе, халыкка хезмәт итү теләге шул тикле көчле булган ки, бу аларга, материаль һәм техник мөмкинлекләрнең чикләнгән булуына карамастан, иреккә һәм азатлыкка омтылуның һәртөрле чагылышын сүндерергә тырышучы патша чиновниклары куйган күп санлы киртәләрне җиңеп, бүгенге Казанны әле дә булса бизәп торучы, алай гына да түгел, күп милләтле ватаныбызның архитектурасы тарихында зур күренеш булган иҗат җимешләрен калдырырга мөмкинлек биргән.

Сез инде, шөт, төшенгәнсездер: сүз П. Г. Пятницкий белән М. П. Коринфскийның хәзерге республика башкаласына университет бинасы бүләк итүләре турында бара. Бу сүзләрдә һич арттыру юк. Чөнки алар, университет биналарының бөтен бер ансамблен төзү белән генә чикләнмичә, бу уку йортының үзен юк ителүдән саклап калган кешеләр дә.

Билгеле булганча, Казан университеты — илдәге моңа охшаш уку йортларының иң өлкәннәреннән берсе: ул бары тик Мәскәү, Петербург һәм Дерпт (хәзерге Тарту шәһәре элек шулай дип йөртелгән) укыту үзәкләреннән генә яшьрәк булган. Университет ачылган чакта аның бинаса без бүген шәһәребезнең һәркем өчен иң кадерле булган урынында, унҗиде яшьлек Володя Ульянов һәйкәле каршында күрергә күнеккән төсле булмаганнар. Ул икесе кварталның ике башына бер-берсеннән шактый ерак урнашкан икешәр катлы йортларга урнашкан булган. Ачылып эшли башлавыннан соң күп тә үтми, шәһәр тормышында, Идел буе халыклары тормышында, ил тормышында, фән һәм мәгърифәт тарихында, азатлык өчен көрәш тарихында шул тикле зур урын тоткан бу университетның язмышы чыннан да кыл өстендә кала. Аны япмакчы булалар.

Әйе, чак кына япмый калалар. Нижний Новгородтан Астраханьга кадәр бөтен Идел буен, Уралны, Кавказ һәм Себерне эченә алган Казан уку-укыту округының җитәкчесе итеп Магницкий дигән кеше куелгач, ул Казан император университетындагы эшләр белән таныша да, аны... ябарга кирәк дигән нәтиҗәгә килә. Патша исеменә җибәргән кәгазендә ул менә болай дип яза: «...Ул зарарлы университет елына 134 меңнән 247 мең кадәргә төшә... Гадел һәм катгый хөкем йөрткәндә, ул юкка чыгарылырга тиеш. Бу юкка чыгаруны ике төрле: а) университетны ябу һәм б) аны кеше күзе алдында җимереп ташлау төсендә эшләргә мөмкин. Мин үзем соңгысын кулайрак күрәм».

1820 елда университетка архитектор һәм архитектура укытучысы итеп художество академиясен тәмамлап чыккан Петр Гаврилович Пятницкий билгеләнә. Кешенең тавышы, килеше-килбәте, чәче-бите һәм гомумән тышкы кыяфәте кебек үк, талант дигән нәрсә дә атадан малайга, анадан кызга дигәндәй, әллә ни күзгә ташланмыйча гына буыннан-буынга күчеп килә дә кинәт кенә шуларның берсендә үзен күрсәтеп куя, диләр. Белмим, бу очракта ничегрәк булгандыр: әлеге кагыйдә раслангандырмы, әллә киресенчәме. Чөнки Петр Гаврилович руханилар семьясыннан чыккан һәм яшьлегендә артиллерия инженеры булырга укып йөргән кеше. Минемчә, монда тумыштан килә торган сәләттән битәр талантның тулы чагылышы өчен зарури булган бер сыйфат — кешедәге характер көче һәм рух батырлыгы турында әйтергә кирәк. Чөнки менә шушы ике канаты булмаса, художник көрәшче була алмый, һавага күтәрелә алмый.

Петр Гаврилович Пятницкий, әлбәттә, Магницкийның фикерен-карашын белгән, әмма аның алдында баш иярга теләмәгән, каушап калмаган гына түгел, бу фикергә каршы чыккан, университетны саклап калу, аны киңәйтү кирәклеген, моның мөмкин булуын раслаган һәм моңа ирешү юлларын да күрсәтеп биргән.

— Әлеге ике йортны тоташтырсаң,— дигән П. Г. Пятницкий үз карашын аңлатып,— тоташ бер бина килеп чыгачак... Һәм ул Казандагы иң яхшы корылмаларның берсе булачак.

Пятницкий барысын да кичергән: ревизияләрне, тикшерүче комиссияләрне дә, шымчыларның берөзлексез күзәтеп йөрүләрен дә, ваккатөяккә бәйләнүләрне дә,— ләкин үз максатыннан чигенмәгән һәм университетның төп бинасын менә без бүген күрә торган хәленә җиткезми туктамаган.

Ташчылар ике бинаны бер-берсе белән тоташтырганнар. 160 метр озынлыгындагы, кирәкмәгән озын, төссез, эчпошыргыч яссы бернәрсә килеп чыккан. Инде нишләргә? Пятницкий, бинаның урта бер җиренә 12 колонналы, ә ян-якларына алтышар колонналы портиклар куйдыра һәм шул килбәтсез бинага, әйтерсең, җан өрелгәндәй була, ул искитмәле бер тантаналы төс ала. Колонналар үзенчәлекле: алар өскә таба тарая барганга, кешедә, гомумән, бөтен бина күккә омтыла төсле тәэ-

сир кала. Бу колонналарның иңен-буен дигәндәй Н. И. Лобачевский исәпләп чыгарган булуны раслаучы кәгазьләр сакланган. Ул бит күп еллар буе университетны төзү комитетының рәисе булган һәм, оста оештыручы буларак, бу эшләр белән үзе җитәкчелек иткән, максатына ирешүдә архитекторга зур ярдәм күрсәткән.

Нәкъ менә Н. И. Лобачевский аркасында, аның теләктәшлеге һәм ярдәме белән университет бинасы талантлы Пятницкий теләгәнчә төзелә. Ләкин архитекторның үзенә эш урыныннан китәргә туры килә. Бөек сатирик М. Е. Салтыков-Щедрин соңрак «Мерзицкий» дип атаган әлеге Магницкий архитекторның үзбелдеклелеген гафу итми һәм, форсатын табып, аны «университетта эштә киләчәктә түзеп торып булмаячагын» кисәтә.

П. Г. Пятницкийдан соң архитектор итеп Михаил Петрович Коринфский кабул ителә. Талантлы, оста архитектор моңа кадәр үзенең туган җирендә — Арзамаста, аннан соң бераз Нижний Новгородта эшли, Сембер шәһәрендә элек һәркемгә билгеле булган Троицкий соборын сала. Казан университеты — Коринфскийда булган архитекторлык талантының канат җәюе, аның иң гүзәл һәм иң соңгы чәчәге. Бик тиз арада — нибары ярты ел эчендә — ул анатомия театры, китапханә, химия лабораториясе, физика кабинеты, астрономия обсерваториясе, оранжерея биналарының проектын эшләп өлгертә. Булган бит шундый заманалар: һәр кем, эшнең рәтен беләме-белмиме, аны башкаручыга күрсәтмә бирә алган. Язучыны — әсәр язарга, рәссамны — рәсем ясарга, архитекторны йортлар салырга өйрәткән. Николай патша да шундыйларның берсе. Әлеге биналарның инде әзер сызымнарына күз ташлаган да барысы белән дә ризалашуын әйткән, бары тик обсерватория проектын гына үзгәртергә кирәк дигән.

Төзелешне университетның төп корпусы артындагы бушлыкта башлап җибәргәннәр. Патша галиҗәнабләренең бу бина проекты белән аерата кызыксынуын искә алыптыр инде, обсерваториядән тотынганнар. Аның төп фасады батынкы ярым түгәрәк булып урнашкан. Анатомия театры бинасы да бик үзенчәлекле: матур-матур колонналар аны күршесендәге бүтән корылмалардан аерып тора. Анатомия театрыннан уңдарак — өч катлы китапханә бинасы. Аның ян-ягындагы биек баскычлар колонналар белән бизәлгән. Хәзер бу бинада дүрт миллионнан артык китап бар. Югары уку йортлары китапханәләре арасында ул Мәскәү университетыныкыннан гына калыша. Биредәге китап саклагыч университетның үзеннән элегрәк туа. 1799 елда Казанга, 18 арбага төяп, князь Потемкин-Таврическийның 429 пот авырлыктагы китапларын китерәләр. Алар шул елларда ачылырга тиеш булган Екатеринослав университеты өчен билгеләнгән була. Китапханәдә тупланган кулъязмаларның күбесе уникаль гына түгел, алар бәһасез. Биредә, мәсәлән, Потемкин китапханәсеннән калган чын хәзинә — бозау тиресеннән ясалган илле күн кисәгенә сигезенче гасырда ук төшерелгән кулъязмалар саклана. Шунда ук болгар чоры истәлеге — Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы, Сараи, Котби, Курсави, Мәрҗани, Каюм Насыйриларның, бүтән шагыйрьләр һәм галимнәрнең әсәрләре — күп гасырлык тарихы булган татар әдәбияты җәүһәрләре. Н. И. Лобачевский тарафыннан ул заман өчен шактый кыйммәт бәягә — 45 сумга сатып алынган хәзинә — Россиядә чыккан беренче басма — кулъязма түгел, басма! — китап — Иван Федоровның «Апостол»ы, атаклы Әбугалисинаның, Бирунинын, борынгы Көнбатыштагы һәм Көнчыгыштагы бүтән фикер ияләренең әсәрләре, Н. В. Гогольнең автор тарафыннан чак кына утка ягылмый калган «Ганс Кюхельгертен»ы, А. С. Грибоедовның «Акыллылык бәласе»нең кулъязмасы һәм башкалар беркемне дә битараф калдырмыйлар. Сүз уңаенда шуны да әйтергә кирәк, Грибоедовның бу кулъязмасы әсәрнең беренче басмасыннан ун елга өлкәнрәк.

Билгеле булганча, комедия 1833 елда, автор һәлак булгач кына цензура рөхсәте алып, дөнья күрә. Тагын шунысы кызык: әсәр башта Ревельдә нәшир һәм тәрҗемәче Карл Кнорринге тарафыннан немец телендә чыгарыла, ә бу китапка цензор буларак рөхсәт бирүче кеше Казан университетында күпмедер вакыт профессор булып торган Фридрих Эрдман була.

Казанда бу комедияне моңа кадәр дә укыган булганнар. Аның әле цензор кулы тимәгән кульъязмасын шәһәребезгә Петербургта Сенат мәйданындагы восстаниегә кадәр үк якташыбыз — декабрист Дмитрий Завалишин алып килә. Ул чакларда Казан университетында студентлар инспекторы булып эшләгән атаклы язучы И. Лажечников болай дип яза: «Мин Казанда чакта ике күренекле вакыйга булды: берсе — күктәге коточкыч шау-шу, шатырдау, икенчесе, җирдә булганы,— Грибоедовның үлемсез комедиясе».

Комедиянең профессиональ театрдан элгәрәк һәвәскәрләр тарафыннан сәхнәләштерелүен раслаучы дәлилләр бар. Казанда Чацкий ролен соңрак патша самодержавиесе тарафыннан тыелган «Колокол» журналының актив хәбәрчесе булып киткән шагыйрь Эраст Перцев уйнаган.

Борынгы Рим кешеләре әйтмешли, һәр китапның үз язмышы була. Университет китапханәсенең сирәк очрый торган кульъязмалар бүлегендәге меңләгән китапның һәркайсы — культура, тарих, әдәбият, политика өлкәсендә күренекле бер вакыйга. Хәзер китапханәгә дөньяның барлык дәүләтләреннән диярлек меңнән артык журнал килеп тора. Вакытлы матбугат басмаларын алдыру өчен генә ул елына егерме биш мең сум акча тотыла.

Университетның төп корпусы белән янәшә, урам аша гына, 1973 елның көзендә физика факультеты өчен төзелгән 16 катлы яңа бинада укулар башланды. Хәзер төп бина каршында 20 катлы тагын бер корпус өлгереп җитте. Монысында китапханә һәм гуманитар факультетлар урнашачак.

Пятницкий һәм Коринфскийның элекке корылмаларын белгечләр пропорцияләре искиткеч төгәл, композициясе гаҗәеп камил булган бик матур ансамбль дип бәяләгәннәр. 20 катлы әлеге яңа бина төзелеп беткәч, яңа һәм элекке биналарны эченә алган университет шәһәрчегенең тәэсир көче тагын да артты.

Тагын бер нәрсәне әйтеп үтәргә кирәк. Университетның мәдәният, фән, мәгърифәт өлкәсендәге даны, биналарын төзегән атаклы архитекторларның җиңел кулыннан башланып киткән шөһрәте-популярлыгы аны тәмамлаган, аны горурлык белән үзләренең альма-матерлары дип санаган кешеләр тарафыннан, аларның хезмәтләре белән арттырылазурайтыла килә. Университетта аталы-уллы Ульяновлар — Илья Николаевич һәм Владимир Ильич укыганнар. С. Т. Аксаков, Л. Н. Толстой, П. И. Мельников-Печерский аның студентлары булган. Бөек геометр Н. И. Лобачевскийның даһи ачышлары шунда эшләнә. М. П. Коринфский төзегән лаборатория бинасын бүген җиде истәлек тактасы бизи: алар химия өлкәсендәге ачышлары Ватаныбызның горурлыгы, даны булып әверелгән Н. Н. Зинин, А. М. Бутлеров, А. М. Зайцев, А. Е. Арбузов, К. К. Клаус, В. М. Флавицкий, В. В. Марковников кебек күренекле галимнәр хөрмәтенә куелган.

Шәһәр салынганнан соң күп, бик күп еллар үткән, күп вакыйгалар, бик күп социаль, экономик, иҗтимагый үзгәрешләр булган. Менә инде Идел дә элеккегечә шәһәрдән җиде чакрым еракта акмый, дулкыннарын Кремль стеналары янында ук шаулата. Шәһәр төзүчеләрнең хыялга иң бирелүчән булганнары да элек мондый киң колачны, мондый адымнарны күз алдына да китерә алмаганнардыр. Канатлы фантазия, нечкә зәвык җимеше булулары белән һәркемне таңга калдырылык тарихи корылмаларга күз салганда борынгыларның «чама белән эшлән-

сен, җыйнак һәм матур булсын» дигән акыллы таләпләре искә төшә. Бу кагыйдә үткән буын кешеләре тудырган нәрсәләргә ихтирамны гына түгел, аларның оныклары турында кайгыртуларын да, аларга иҗат итү өчен шартлар тудыру турында уйлануларын да эченә ала. Мең-мең рәхмәт аларга моның өчен!

Тарихи тетрәүләр борын-борыннан архитектураның явыз дошманы булып килделәр. Бихисап сугыш-бәрелешләр Казанга да шактый күп зыян-бәла китергәннәр. Шулар өстенә тагын шәһәр тыныч елларда да ничәмә-ничә тапкыр иҗенче бер коточкыч афәткә — янгыннарга дучар булган, көл өеменә әйләнеп калган. Әйдәгез, иренмичә санап карыйк: 1579 ел — бер, 1598 ел — ике, 1672 ел — өч. Аннары зур янгыннар 1694, 1742, 1757 елларда була... Шуларга тагын 1774, 1815, 1842 елларда булган афәтләрне дә өстик. Ут-күз бит бәлаләрнең дә иң куркынычлысы. Иң явыз дошман күңелендә дә кайчак мәрхәмәт хисе уятырга, аңардан акча биреп, мал-мөлкәт биреп котылырга мөмкин. Ә уттан алай котылып булмый, ул — коточкыч нәрсә. 1815 елда булган янгын вакытында, мәсәлән, Казанда мең ярымнан артык йорт юкка чыга.

Үткәнне кире кайтарып булмый, әмма аннан өйрәнергә, сабак алырга мөмкин. Һәм хәзер, мөмкинлекләребез һәм тәҗрибәбез чагыштыргысыз арткач, бүгенге Казанны, дөресрәге, иртәгәге Казанны төзегәндә «чама белеп эшләнсен, җыйнак һәм матур булсын» дигән таләп искә тотыламы соң?

Элеккедән калган һәр корылма алдында аның борынгы нәрсә булганы өчен генә баш ияргә кирәкмидер, мөгаен. Әйтик, инде без телгә алып үткән сәүдәгәр Михляевнең, безнең буын кешеләре генә түгел, оныкларыбыз да сокланып караячак гүзәл бина — Петр һәм Павел соборын салдырып калдырган Михляевнең үзе яшәгән йорты да бүгенгәчә сакланган. Ул Казандагы торак биналарның иң өлкәне буларак атаклы. Әмма үзе бер ягы белән дә искитмәле түгел — кеше яшәргә яраклы гап-гади бер йорт.

Университеттан киткәннән соң Петр Гаврилович Пятницкий, Петербургка күчү турындагы чакырудан баш тартып, үзенең калган гомерен дә шушы күп милләтле Идел буйлары белән бәйләргә була. Казанда кала, тагын ике дистә ел буе йортлар сала. Ләкин талантлы останың университет бинасы кебек ватаныбыз архитектурасы тарихына керәп калырдай бүтән бер нәрсәсе дә сакланмаган. Нишләмәк кирәк, сәнгатьнең һәр тирәндә шул хәл: бер җәүһәргә йөзләгән, кайчакта хәтта меңләгән урта кул нәрсә туры килә.

Ә шулай да күңел дигәнең моның бүтәнчә булуын тели, чөнки сүз бер генә кешенең язмышы турында түгел, синең өчен кадерле, синең күңеленә якын шәһәр турында бара, үз балаларыңның, оныкларыңның, киләчәк буын кешеләренең гасырлар үткәннән соң да менә хәзер, бүген салынып ята торган корылмаларга, бөтен-бөтен кварталларга, урамнарга карап соклануларын, «менә, ичмасам, булган оста кешеләр, шәп төзегәннәр!» дию.ләрен күз алдына китерәсе килә.

Әйе, хыялда гына булса да шәһәрнең киләчәген күз алдына китереп бастыру теләге бик көчле. Әмма монда ялгышу ихтималы да зур. Тарихта андый хәлләр дә булгалаган. Әйтик, мәсәлән, үткән гасырның азагында рәсми статистика: үлүчеләр саны туучылар саныннан өстен булганга күрә Казанның халкы 1960 елга үлеп бетәргә тиеш, дигән нәтиҗәгә килгән. Шуңа күрә хыялларны калдырып тору һәм ышанычлы документларга таянып фикер йөртү хәерлерәк. Россия Федерациясенең Министрлар Советы республикабыз башкаласы үсешенең генераль планын раслады. Ул план нигезендә 2000 иче елда Казан халкы 1 миллион 200 мең кешегә җитәр дип исәпләнә. Шәһәр биләп торган җир мәйданы 10 процентка гына зурайса да, аның торак фонды 3 тап-

кыр артачак. Димәк, шәһәр биеклеккә таба үсәргә, хәзерге күп кенә иске йортлар урынына 9, 12, 16 катлы яңа биналар калкырга тиеш. Менә тагын бер кызыклы чагыштыру: материаль җитештерү сферасында эшләүчеләр саны 31 процентка гына артса да, промышленность продукциясе күләме 3,7 тапкыр зуррак булачак.

Әйтәсе дә юк, колач киң. Ләкин мәсьәләнең икенче ягы да бар бит әле: мондый киң колач, мондый темплар ашык-пошык эш итүгә китермәсен иде, көндәлек ыгы-зыгы алдан күреп, уйлап-чамалап төзүгә комачаулык итмәсен, һәр яңа адым, үтелгән һәр ел шәһәрнең үсешен күрсәтә торган коры саннар өстәү белән генә чикләнмәсен, бу өлкәдә чын казаныш-табышларны, чын уңышларны да арттырсын, яңа төзелгән һәр бина бүгенге ихтыяҗларны канәгатьләндерергә яраклы корылма булып кына калмыйча, шәһәрнең чын бизәгенә әверелсен, аңа ямьматурлык өстәсен, иң югары зәвыкка да җавап бирерлек булсын, камил булсын, тәэсирләндерерлек булсын иде.

Бәлки бу кирәгеннән артык таләпчән фикердер. Безнең буынга үз җәүһәрләрен калдырган осталар конвейердагыча эшләмәгәннәр. Үз гомерләрендә телгә алып сөйләрлек бер-ике бина төзеп калдыра алсалар, алар өчен бу ярыйсы булган. Ә хәзер мөмкинлекләр чагыштыргысыз артыграк. Проектлар институтларда, лабораторияләрдә эшләнә, төзелеш мәйданнарында — куәтле техника. Биналарны төзүдән бигрәк әзер детальләрдән, конструкцияләрдән җыялар-монтажлыйлар.

Әйе, мөмкинлекләр артты. Тик менә шәһәрнең үсеш тарихында вакыйга булырдай, бәйрәм булырдай уңышлар саны ничектер әкренрәк арта. Чыннан да шәһәрдә архитектураның: аек акыл белән, әмма матур итеп төзергә кирәк, дигән төп кагыйдәсен бозып салынган нәрсәләр юк түгел. Әйтик, миңа, мәсәлән, чагыштырмача күптән түгел салынган «Татарстан» һәм «Идел» исемле кунак йортларында тукталган танышлар, каләмдәш дуслар алдында гафу үтенергә туры килгәне бар. Аларның бу биналарның бер ягына урнашкан номерларында трамвай яисә поезд тавышына йоклап булмый дип зарлануларына каршы мин гадәттә: «Ни хәл итмәк кирәк, техника заманы бит»,— дигән булам. Үзем аңлыйм: машинаның монда бернинди катнашы юк. Кунак йортларын юллардан читтәрәк, шау-шусызрак урынга салырга техника комачаулаганмыни?!

Республикабыз башкаласының үзәк магистральләреннән берсе Татарстан урамының проектын эшләгән архитекторларның ни уйлап эш итүләрен, аларның эстетик зәвыгын аңлау, күз алдына китерү шулай ук кыен. Елга порты янында ук тугыз катлы биналар калыккан. Анна- ры түбән катларында пыяла витриналы кибетләр, аптекалар, парикмахерскаялар урнашкан шундый ук биек, зур-зур балконлы өйләр тезелеп китә. Ә менә шулар арасында, нәкъ күз төбендә, соры төстәге казарманы хәтерләткән иләмсез озын, биш катлы яссы бер корылма сузылып ята. Әгәр бу һәр иҗат эшендә очрый торган гади бер уңышсызлык кына булса, гаепле кешесен гафу итмәсәң дә, аңлар идең. Әмма бу очраклы уңышсызлык яисә хата түгел, бу — камил булмаган зәвыкның ашыгыч җимеше, кем әйтмешли, булсынга түгел, гомер үтсенгә йөри торган битараф булган кеше эше.

Зур шәһәр кебек катлаулы социаль һәм иҗтимагый организм турында фикер йөрткәндә болай плюслар һәм минуслар куеп чыгу иң дөрес юл түгел, әлбәттә. Шулай да мин күзгә бәрелеп торган уңышсызлыкларны бер баганага тездем дә шунда ук икенчесенә казаныш дип әйтердәй нәрсәләрне санап киттем. Һәм, әйтергә кирәк, соңгыларын табуы кыенрак булды. Әйтик, күз явын алырлык гүзәл опера театры. Эченә керсәң чыгасы килми, нечкә зәвык белән башкарылган чын художестволы бизәкләргә карап, сокланып туймыйсың. Һәм шуның янында гына, мәйдан аша — консерватория концерт залының яссы «пыяла

тартмасы». Дәүләт циркының очып баручы тәлинкәне хәтерләткән сокландыргыч бинасы янында да — Себер, Үзәк Россия, Идел буе шәһәрләренең күбесендәге шундый ук биналардан бернәрсәсе белән дә аерылып тормый торган, тышкы кыяфәтенә караганда исеме җисеменә һич туры килми торган Спорт сарае. Кремль калкулыгында Ольга Александровна Кашинцева җитәкчелегендә «Гипровуз» институты архитекторлары проекты буенча эшләнгән бина — университетның мәһабәт физика корпусы басып тора. Ә шуннан бер квартал гына түбәндәрәк, Бауман урамы чатында — Татар ашлары йорты. Күзең бер иялəнгəч карап торырга ярыйсы да кебек. Тик шунысы начар: аның пыяла стеналы залларында җәен миең кайнарлык эссе була, ә кышларын җил уйный. Яисә тагын бер мисал. Хәзер Казанда зур мичкәгә яисә имән кәүсәсенә охшатып ясалган, ишек өсләренә әллә ниткән хикмәтле фонарьлар эленгән сыраханәләр бер-бер артлы туып тора. Анда сиңа, керү хакын түләсәң, ике кружка «ак бүрекле» сыра агызып бирәләр, кулыңа сыр кисәге, яисә балык-мазар тоттыралар. Монысы аңлашылсын да ди. Тик минә икенче бер нәрсәне аңлавы кыен: ни өчен Казан тикле Казанда чын самавары шаулап торган нибары бер генә чәйханә? Чәй онытылырга дучар ителгән эчемлеккә әйләнеп барамы әллә?!

Әлбәттә, һәр бина үзенә бер максат белән салына һәм шул максатына хезмәт итә. Концерт залында, әйтик, орган моңнарын ишетергә, үз башкаручыларыбызның һәм гастрольгә килүче артистларның уйнаужырлавын тыңларга мөмкин. Спорт сараенда хоккей уйныйлар, штангистлар яисә көрәшчеләр көч сынаша. Татар ашлары йортына кеше милли ризыкларыбыздан авыз итәр өчен керә. Ләкин шуны да онытмыйк: һәр бинаның тышкы кыяфәте, архитектурасы да кешегә тәэсир итә, аның зәвыгын тәрбияли бит. Хәлбуки, ашык-пошык эшләнгән, берберсенә игез балалар кебек охшаган стандарт биналар кеше күңелендә нинди генә матур тойгылар уята алыр икән?!

Казан — мәңгегә онытылырга, юкка чыгарга дучар ителгән шәһәравыллар язмышын читләтеп үтә алган, күп тапкырлар хәрабәләрдән калыккан һәм үз киләчәгенә ышанган хәлдә алга бара килгән шәһәр. Менә хәзерге зур чикне атлап чыкканда безнең һәрберебез шәһәрнең бүгенгесе, иртәгәсе өчен икеләтә, өчләтә җаваплылык сизәргә, башкалабыз илнең төрле почмакларындагы бүтән шәһәрләргә охшаш булмасын өчен көчебезне кызганмаска, шәһәрнең үзенә, аның шундый өлкән яшенә, яшьләрчә кыю хыялларына хас үзенчәлеген саклау, бу үзенчәлекне арттыру юлында тырышырга тиеш. Юкса, әгәр без үзебездән элек яшәгән кешеләрнең якты истәлеге алдында баш имәсәк, алар үрнәгендә эшләмәсәк, аларның иҗат җимешләренә карап коры соклanудан гына ни файда?!

## Тамырлар һәм ябалдаш

Ничек кенә булмасын, Казанның иң күркәм өстенлеге, бүтән бер җирдә дә кабатланмый торган иң мөһим үзенчәлеге шунда: анда төрле архитектура стильләре бергә кушылган, төрле милли культураларның бер-берсенә үтеп керүе, бер-берсен баетуы чагылган. Россиянең үзәк бер җирендә, җырларда җырлана торган Агыйдел, төньяк гүзәле Вятка, хезмәт сөючән Чулман-Кама һәм рус елгаларының анасы Идел бергә кушылган урында яшәүче күп кенә халыкларның һәм милләтләрнең гореф-гадәтләре биредә янәшә яши.

Әнә карагыз: совет чорының беренче елларында салынган йортлар һәм безнең көннәр корылмалары, тәрәзә яңаклары милли орнамент белән матур итеп бизәлгән тәбәнәк бистә өйләре һәм өр-яңа культура

сарае, манараларын куккә чөйгән мәчетләр һәм түгәрәк гөмбәзле чиркәүләр — болар барысы да бер китап сәхифәләре, һәм аларны һәркем кызыксынып укый.

Бөтен гомерен читтә йөреп үткәргән Александр Иванович Герцен Вяткага сөргенгә барышлый Казанда була, ул гына да түгел, язгы ташкын вакытында жандармнар күзәтүе астында Идел аша чыкканда чак кына батмый кала. Шәһәр урамнарында йөри, күзәтә, чагыштыра, Казанның үзенчәлеге турында уйлана. Соңрак «Провинциядән хатлар»ында ул болай дип яза: «Әгәр, Петр алдан күргәнчә, Россиягә Көнбатышны Европа белән таныштырырга язган икән, ул чак, һич шик юк, Казан — Европа идеяләренең Азиягә һәм Азия характерының Европага үтүе юлында төп кәрван-сарай».

Николай Васильевич Гоголь: архитектура — ул гасырның елъязмасы, дигән. Җир йөзендә берничә культураның бер-берсенә йогынтысы, күп кенә милләтләрнең, төрле социаль группаларның гореф-гадәтләре бергә кушылу үзен нык кына сиздерә, төрле чорларга кагылышлы иҗтимагый һәм социаль мөнәсәбәтләрнең эзләре ярылып ята торган шәһәрләр аз түгел, әмма рус, татар һәм Идел буенда яшәүче башка милләтләр архитектурасы бер-берсе белән үзара аеруча якын мөнәсәбәттә булган бүтән кала юк.

Нишләмәк кирәк, заманасы шундый булган: архитекторларның сәләте һәм осталыгы үзләренең тулы чагылышын төрбәләр, изге храмнар салуда гына таба алган. Җир йөзендә кеше күңеле өчен гүзәллек-матурлыктан да якын нәрсә бар икән?! Әмма шәһәрләр җирлегенә күчереп караганда гүзәллекнең әһәмияте ләззәт чыганагы булу белән генә чикләнми, ул безгә халкыбызның, күп милләтле дәүләтебезнең тарихыннан сабак бирә, ул безгә биредә, Рәсәйнең үзәк бер җирендә илебез архитектурасының ничек үсүе, камилләшүе турында сөйли. Бүгенгәчә сакланып калган уникаль һәйкәлләр, аларны иҗат иткән осталарга карата рәхмәт хисе уяту белән бергә, иртәгәге көн турында, илебез халыклары культурасының бер өлеше булган архитектураның киләчәктә үсеш юллары турында уйландыра. Үткәннәрне белми торып бүгенгене аңлап, киләчәкне күзаллап булмый.

Бүген борынгы Казанның нинди булганын берәү дә тәгаен генә әйтә алмый. Тик ару-талу белмәүче археологлар гына, үткәннең югалган эзләрен һәм билгеләрен эзләп, күп тапкырлар җимерелгән шәһәрне күз алдына китереп бастырырга тырышалар. Үткән еллар патша самодержавиесе политикасының төп кагыйдәсе милли тигезсезлек, халыкларны экономик һәм рухи изү икәнлекне раслыйлар, ике гасыр буена шәһәрдә Псковтан китертелгән осталарның корылмаларыннан башлап Россиягә читтән кертелгән классицизм, барокко, «византия-рус» стильләре кануннары буенча салынган биналарга кадәр төзелеп тә татар милли архитектурасы үрнәкләренең ни өчен бөтенләй булмавын аңларга ярдәм итәләр. Ул гына да түгел: унҗиденче гасырның урталарында фанатик булганы өчен Аксак Каратун дигән кушамат тагылган архиепископ Лука Канашевич сакланып калган татар архитектурасы корылмаларын да җимерү турында указ чыгарттыра. Ул чакта хәзерге Татарстан җирендә дүрт йөздән артыграк дини корылмаларны җир белән тигезлиләр. Билгеле, аларның барысы да оста куллар белән күз явын алырлык матур итеп салынган булгандыр дип әйтеп булмый. Шулай да араларында кабатланмас могҗиза дип атардайлары да аз булмагандыр кебек.

Унсигезенче гасырда Екатерина II мөселман дине корылмалары салырга рөхсәт бирә. Билгеле, монда да ул үз файдасын күздә тота. 1767 елда Әби патша үз дәүләтенең көнчыгыш төбәкләрен карап кайтырга була һәм Казанга да килә. Культуралы императрица булып күренергә тырышкан, Вольтер, Дидро кебек француз мәгърифәтчеләре

белән хат алышып торган Екатерина аны французларга хас нәзакәтлелек белән «Төньяк Семирамидасы» дип атаган бу кешеләрнең берсенә Казан турында болай дип яза: «Кадерле Вольтер! Мин сезгә нинди дә булса бер Азия авылыннан хат язармын әле дип янаган идем, менә хәзер шул сүземне үтим...» Аннан ул, тәэсирләрен уртаклашып, болай дип дәвам итә: «Бөтен Идел буенда халык бай яши, тамагы тук... беркем дә зарланмый, мохтаҗлык чикми», «мине бик әйбәт каршылыйлар, менә дүртенче атна инде һәркайда бер үк төсле шатлык — ...әгәр рөхсәт бирсәң, шәһәр кешеләре аяк астына келәм урынына үзләре ятарлар иде».

Ай-һай, бу гади ялагайлыкны, тәлинкә тотуны чын ихтирамның чагылышы дип кабул итүче тәхет иясе адәмнәрнең гомер төзәлмәс сукырлыгы!

Әби патша булып киткәннән соң сигез ел үткәч, Казан «крестьян патшасы» Пугачев гаскәрләрен шатланып каршы ала. Татарстан Дәүләт музеенда билгесез рәссамның бер эше саклана. Анда Пугачевның сурәте Екатерина патша портреты өстенә төшерелгән. Ачлык-хәерчелектән, изелү-рәнҗетелүдән интеккән крестьяннарның баш күтәрүе Әби патшаны шул тикле куркыткан ки, ул дәүләт җинаятьчесе дип игълан ителгән Пугачевны Казанга алып килергә җөрьәт итмәгән, шәһәр халкы күз алдында Пугачевның тик... карачкысын гына җәзалаганнар.

Крестьяннар арасында булып узган чуалышлардан, аларда татарларның, башкортларның, чувашларның, чирмешләрнең рус ярлылары белән бер сафта булуларыннан борчуга төшкән патша хөкүмәте кечкенә милләт халыкларын бераз тынычландыру нияте белән кайбер дипломатик адымнар ясый. Аерым алганда, Россиядә ислам дине буенча махсус духовный управление оештырыла. Аның башында торучы мөфти һәм бүтән дин әһелләре дәүләттән акча алып тора башлыйлар. Идел буе мөселманнарына мәчетләр салырга рөхсәт бирелә. Әби патша православие дине попларының да, мөселман муллаларының да, католик-пасторларның да һәртөрле диннең нигезен тәшкил иткән нәрсәгә — хосусый милекчелеккә каршы бармаячакларын, дога-вәгазьләрендә дингә ышануларны, хакимлек ул алла тарафыннан бирелгән нәрсә, аңа тел-теш тидерү — зур гөнаһ, дип, яхшылык та, яманлык та алланың үзеннән, дип ышандырырга тырышачакларын, аларны күндәм булырга, сабыр булырга өндәячәкләрен яхшы аңлаган.

Казанда бүгенгәчә сакланган милли архитектура үрнәкләре нәкъ менә шул вакытларга туры килә дә. Шәһәребезгә, А. И. Герцен әйтмешли, Азия Көнчыгышы төсмерең биреп торган Мәрҗани, Әҗем, Апанай мәчетләре безнең өчен төзү осталарының борынгы бабаларыбыз традициясен сакларга, тормышны бизәргә, кеше күңелендәге иң нечкә кылларның хәрәкәтен ташта гәүдәләндерергә омтылуларының ачык дәлиле.

Тагын шунысы игътибарга лаеклы. Нишләп соң шул мәчетләрнең берсен халык Мәрҗани мәчете дип атаган? Ул бит баштарак аны салу өчен акча биргән Юнусов бай исеме белән йөртелгән булган. Хәзер исә Казанда бу исемне белүче кеше сирәк, ә менә Мәрҗанине беләләр. Бу кеше шул мәчеттә күпмедер вакыт мулла булып торган өчен генәме? Билгеле, дингә хезмәт иткән кешеләрнең барысы да, әйтик, Бэкон, Спиноза, Джордано Бруно кебек олы фикер иясе булган дип әйтеп булмый. Шулай да алар барысы да тискәре, надан булган дию дә дөрес булмас. Шиһабетдин Мәрҗани, мәсәлән, зур гыйлем иясе кеше, халыкны агарту өчен күп көч куйган мәгърифәтче булган. Заманында ул Бохараның бөтен Көнчыгышта дан тоткан «Мир-Гарәп» мәдрәсәсендә белем алган. Ул намаз укыту, вәгазь әйтү белән генә чикләнмичә, мәчеттә мәдрәсә ачып, үзе шунда балаларны укырга-язарга өйрәткән, тарих белән кызыксынган, бабаларыбыз болгарлар, Казан хан-

лыгы турында, Россиянең үсеш тарихы турында, Көнчыгыш халыкларының мәдәнияте турында күп кенә әсәрләр язган. Димәк, исемен мәңгеләштерү өчен кешегә зур байлык иясе булу, мәчетләр салдыру гына аз ул. Дөньяда кеше шәхесенә, аның эшләренә бәя биргәндә бүтән төрле үлчәүләр кулланыла икән.

Үткән заманны кире кайтарып булмый, әмма еракта калган, инде онытылган бала чагың урамына кире кайтып була. Татарстан Дәүләт музеенда шәһәрнең үткәненә багышланган күргәзмә залларында йөргәндә мин нәкъ менә шул турыда уйладым. Казан музее илдәге иң бай музейлардан санала. Анда алты йөз меңнән артык экспонат бар: төрле гасырларның кәгазь һәм металл акчалары, рус һәм татар театрларының беренче афишалары, Путилов заводы чыгарган «Фордзон» тракторы, Идел буеның җир асты хәзинәсе-нефтьтән ясалган беренче каучук... Биредәге һәр өченче экспонатны музейга, борынгы каберлекләрдән, кешеләр яшәгән элекке авыл-шәһәр казылмаларыннан табып, тарихчылар, археологлар биргән. Кувшин һәм чүлмәк, бакыр савыт һәм бронзадан эшләнгән көзге, алкалар, көмеш-бакыр акчалар, исемнәре билгесез рәссамнар тарафыннан зәвык белән бизәлгән меңнәрчә бүтән нәрсәләр үткәндәге тормышны күз алдына китереп бастырырга ярдәм итеп кенә калмыйлар, кешедә ватанга, туган җиргә мәхәббәт тә тәрбияләләр.

Менә шуңа күрәдер инде, борын заманнардан сакланып калган һәр нәрсәне без кулыбызга зур дулкынлану белән алабыз. Күңелебездә күп төрле хисләр уяна. Ни өчен дисәң, менә шул чүлмәкләр, Болгар иле осталары металлны мичтә эретеп искитмәле төгәллек белән ясаган әйберләр булмаса, бүгенге житлеккәнлек тә булмас иде. Борынгы нәрсәләрдә — чигелгәннәрендә, гравер яисә ювелир кулы белән бизәлгәннәрендә, алтыннан, көмештән, энҗедән, асылташтан, яшмадан, ахактан гаҗәеп осталык һәм зәвык белән эшләнгәннәрендә — никадәр бай фантазия, күпме төсмер бар!

Менә шул борынгы осталарга карата ихтирам хисе саклау белән бергә, без тагын бер җитди нәрсәне дә онытмаса идек: үткән буыннар иҗат иткән бу җәүһәрләрне туплау, саклау гына аз, алардан өйрәнә дә белергә, аларның ишен арттыру өчен тырышырга, соңыннан үкенерлек адымнар ясаудан саклана белергә кирәк.

Туган шәһәренең әдәби биографиясен яратмаган, аңа ихтирам сакламаган кеше, мөгаен, юктыр. Константин Паустовский әйтмешли, әдәбият ул зурайткыч пыялага охшаш — халыкның тормышын һәм күңелен ачыграк итеп күрергә ярдәм итә. Зур көрәшчеләр һәм олы шагыйрьләр булган Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил һәйкәлләре белән очрашу бездә нинди якты хисләр уята! Ә исемнәрен йөрткән бакчаларда безне Лев Толстой һәм Максим Горький көтә. Аларны күреп, бездә дөньяга менә шундый фикер һәм сүз титаннары күзе белән күз ташлау теләге туа. Ышанырга кирәк, килер бер көн, шәһәребездә Хөсәен Ямашев, Мулланур Вахитов, Гафур Коләхметов кебек революция көрәшчеләренә, Каюм Насыйри, Галимҗан Ибраһимов, Һади Такташтай акыл ияләренә һәм әдипләренә дә һәйкәл куелыр.

Һәм менә шулар арасында Гаврила Романович Державин һәйкәле дә үз урынында торса, ничек яхшы булыр иде?! Кызганыч, бик тә кызганыч, әмма нишләмәк кирәк, искене юк итми торып яңаны төзеп булмый дигән ялгыш һәм зарарлы фикер өстенлек алган заманнар да булган, арада кайберәүләребез Ленинның: «Без йөз еллар буена артта калуыбызны куып житәргә тиеш»,— дигән сүзләрен, без сынлы сәнгать өлкәсендә кирәгеннән артык «бәреп төшерүчеләр» булып киттек, дигән кисәтүләрен онытып җибәргәннәр. Зур осталар саналган архитектор Карл Тонның һәм скульптор Самуил Гальбергның сирәк

очрый торган иҗат җимеше, Казан татарлары арасында «Бакыр бабай» дип дан казанган Г. Державин һәйкәле дә әнә шулай юк ителгән.

Хәлбуки, Гаврила Державин — Россия шагыйрьләренең шаһы, Пушкинны илһамландырган әһел, патша сарайларында, хөкемдарларның күзенә карап, алардан өстен булып, үз карашларын менә ничек кыю әйтә алган шагыйрь:

Җир хакимнәре, көчлеләр,
Боеручылар, ишетегез,
Сез әле һич бөек түгел,
Кайгылар кичмәсәгез!
(*«Бөеклеккә».*)

Бу юллар югары даирәләрдә ялагайлык, чиннарга табыну, икейөзлелек чәчәк аткан, кешедә киң күңеллелек, кыюлык кебек сыйфатлар түгел, түрәләргә ярый белү, үзеңнән өстеннәрнең теләген түбәнчелек белән берсүзсез үти белү югары бәяләнгән бер заманда язылганнар.

Әмма Казан кешеләренең Державинга мөнәсәбәте моның белән генә дә билгеләнми. Аларның шагыйрьне бүтәннәргә караганда ныграк үз күрергә, күбрәк ихтирам итәргә нигезләре бар. Беренчедән, ул Казанда яшәгән, Казан гимназиясендә укыган. Икенчедән, аның әле бөек князь Василий Васильевич заманында ук мөселман диненнән баш тарткан ерак бабасы Баһрам морзаның тамырларында татар каны аккан.

Тормыш дәвам итә. Аңарда гармония, гүзәллек ахыр чиктә барыбер тантана итә. Тормыш шуның белән көчле дә. Хәзер Татарстан Дәүләт музеенда Г. Р. Державин почмагы бар. Анда шагыйрьнең рәсеме, язу өстәле, кара савыты, кәнәфие куелган.

Шәһәребез аша үткән Александр Герцен аның тышкы кыяфәтендә Европа һәм Азия культуралары чигендә торучы кәрван-сарай билгеләрен күреп кенә калмаган, ул заманда ук университетлы культура үзәге булган Казанда яшәүче төрле миллләт вәкилләре арасындагы мөнәсәбәтләрнең рухын, асылын да төсмерли алган. Идел буе төбәгенең башкаласын ул замандагыча итеп күз алдына китерергә тырышып карыйк. Күп булса йөз мең кеше яши торган шәһәр. Сәүдәгәрләрнең күп санлы кибет-алачыклары. Урамнардан әледән-әле «барабызлар» үтеп китә, вәкарь белән атлап городовойлар йөреп тора. Губернатор йортына якынлашкан саен алар ешрак очрый. «Усия» исеме белән билгеле пристаньда йөк ташучыларның интернациональ телдәге: «Раз-два взяли»лары яңгырый. Урамнарда студентларны, хәтта профессорларны да очратырга мөмкин.

Без Казанны ничектер илебезнең химия бишеге дип, математика өлкәсендә атаклы Александрия шәһәре көндәше дип санарга күнеккәнбез, һәм табигать фәннәре күгендәге бу яктылык тарих, хокук, әдәбият, тел белеме кебек өлкәләрдәге эзләнүләрне һәм уңышларны ничектер күләгәдәрәк тә калдырган шикелле. Хәлбуки, Казанда 1814—1853 елларда эшләгән әдәбият сөючеләр җәмгыятенең бер утырышында профессор Петр Сергеевич Кондырев, ул вакытларда шәһәрдә хөкем сөргән рухи атмосфераны чагылдырып, болай дигән: «Без бүтән миллләт халыклары арасында, борынгы татар патшалыгында, элекке Болгар башкаласы якынында яшибез. Безне татарлар, чувашлар, чирмешләр, мордвалар, вотяклар, зыряннар (коми халкын элек шулай дип йөрткәннәр.— М. З.) чолгап алган. Әрмәннәр, фарсылар, башкортлар, калмыклар, бохаралылар һәм кытайлар бүтән җәмгыятьләргә караганда безгә якынрак торалар. Безгә тел ямсә әдәбият мәсьәләсендә алар белән бәйләнешкә керү һәм бу хәлне үзебез өчен файдалану ансатрак. Бу халыкларның төрле җырларын, риваятьләрен, язмаларын, повестьларын, китапларын... җыю нинди файдалы».

Россиядә тагын нинди шәһәр үзендә төрле телләрнең шулай янәшә яшәүләре белән мактана алыр иде икән? Университетта гарәп һәм фарсы телләре кафедрасы ачылгач ук татар һәм төрек телләрен өйрәнү кафедрасы оештырыла, шулар өстенә тагын Россиядә беренче булган кытай һәм санскрит (Һиндстанда әдәби тел шулай аталган.—М. З.) телләре кафедрасы эшли.

Ватаныбыз әдәбиятын сөючеләрнең алда инде телгә алынган җәмгыятен оештыручы кеше Нигъмәт Ибраһимов була. Кин катлау укучылар белә булыр: бу татар гимназиядә һәм университетта дәресләр биргән. Ләкин менә руслар гына түгел, бүтән миллләт кешеләре дә яратып җырлый торган, хәтта белгечләр дә күп еллар буена рус халкы тарафыннан иҗат ителгән дип санап йөрткән:

Во поле березонька стояла,
Во поле кудрявая стояла.
Ой, люли-люли стояла,
Ой, люли-люли стояла,—

дигән җыр сүзләренең нәкъ менә шул Нигъмәт Ибраһимовныкы икәнен барыбыз да беләме икән?!

Революциягә кадәр йөз елдан артык яшәү дәверендә нибары берничә дистә татар егетен укытып чыгарган император университетында шушы милләт кешесенең дәрес бирүе үзе үк гаҗәеп хәл. Һәм әгәр Нигъмәт Ибраһимов анда укыту белән шөгыльләнеп кенә калмыйча, шагыйрь буларак та танылган икән, әдәбият сөючеләр җәмгыяте оештыру фикерен алга сөргән генә түгел, гаять зур мәгърифәтчелек эше алып барган, соңыннан үзен узып киткән әдипләр тәрбияләгән икән, әгәр танылган язучы, рус теленең чын остасы Сергей Тимофеевич Аксаков күп еллар үткәч аның турында: «Минем әдәби юнәлешемдә бу кешенең әһәмияте зур булды», дип язарга кирәк тапкан икән, димәк, ул чыннан да олы җанлы кеше, зур талант иясе булган.

Халыкның, һәр аерым шәхеснең рухи тормышы, рухи эшчәнлеге логика һәм статистика кануннарына буйсынмый. Күп милләтле Ватаныбыз халыклары культураларының бер-берсен баетуларын, бер-берсенә үтеп керүләрен раслаучы мисалларны чагыштырып карыйсың да, бабаларының тамырларында бөтенләй икенче милләт каны аккан әдипнең Россиядә беренче шагыйрь булып китүе кебек яисә Казанда Әби патша рөхсәте белән ачылган милли типографиядә татар язучыларының әсәрләре белән беррәттән Лев Толстойның, Лермонтовның, Некрасовның цензура тарафыннан тыелган китапларының тәрҗемәсе дә басылу кебек фактларга һич гаҗәпләнмисең.

Поэзиясенең милли рамкалар белән һич чикләнмәгән булуына, бөтен Россия поэзиясен туендырып торган тамырлардан үзенең дә көч һәм илһам алуына басым ясап, бөек Тукай менә ничек язган:

Хәзрәти Пушкин вә Лермонтов әгәр булса кояш,
Ай кеби, нурны алардан икътибас иткән бу баш.

Менә «Татар поэзиясе антологиясе» — халкыбызның шигърият өлкәсендәге иң матур казанышларын үзенә туплаган калын китап. Сигез гасырлык тарихы бар бу шигъриятнең. Кол Гали, Мөхәммәдъяр, Дәрдмәнд, бөек Тукай... Алар — Октябрьга кадәр үтелгән зур һәм авыр юлдагы якты маякларның бары тик кайберләре. Аннары Такташ, Исәнбәт, Кәрим... Батыр рухлы Җәлил — илебездәге шагыйрьләр арасында бердәнбер Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты. Болары совет чоры талантлары. Антологияне актарып чыккач, барыннан да элек, бүтән халыклар әдәбиятларыныкы кебек үк, татар әдәбияты әсәрләренең дә күп милләтле илебез культурасының уртак казанышы бу-

луы турында уйлыйсың. Һәр шигырьнең үз халкы рухын, йөрәген рус укучысына ачып бирүче икенче авторы — тәрҗемәчесе бар. Владимир Луговской һәм Самуил Маршак, Анна Ахматова һәм Демьян Бедный, Евгений Винокуров һәм Михаил Исаковский, Михаил Светлов, Евгений Евтушенко, Ярослав Смеляков һәм Павел Антокольский — татар шагыйрьләренең әсәрләрен русчага менә нинди атаклы кешеләр тәрҗемә итә.

Казан турында сөйләгәндә, аның турында бик күп төрле матди һәм рухи байлыкларны, традицияләр һәм гореф-гадәтләрне үзенә җыйган һәм җыя барган үзәк буларак уйланганда, тагын шуны да өстәп үтәргә мөмкин. Тормыш үзе, күп милләтле совет дәүләтебезнең үсеш баскычлары бөек рус художнигы Ф. М. Достоевскийның хыял-өметләрен бик ачык раслый. Ул: «Һәр культура башка барлык милләтләрнең азат һәм мөстәкыйль үсүләре юлында һәм алар белән туганнарча бердәмлектә генә, үзара тулыландырылып, үзенә башкаларга хас үзенчәлекләрне үзләштереп һәм үзендәге үсентеләрне аларга биреп, бер-берсе белән рухи уртаклык табып, үзара сабак алышып яшәгәндә генә күтәрелә алачак», дип язган иде.

Без кысыр хыялыйлар түгел, нык нигезле оптимистлар. Шунысы куанычлы: тормыш сабаклары бушка китмәгән, үткәннәр белән кызыксыну һәм шушы кызыксынуларны бүгенгебез һәм киләчәгебез файдасына кулланырга омтылулар матур өметләр кузгата.

Еллар бер-бер артлы үтә тора. Бер төрле стильләр юкка чыга, яңалары туа, гореф-гадәтләр үзгәрә. Машиналар, конвейерлар киң таралу аркасында һәр өлкәдә, хәтта художество-сәнгать әйберләре җитештерүдә дә, бертөрлелеккә, формалар гадилегенә омтылыш көчәя. Кайбер бизәкләр төссезләнә, стандартлаша.

Кайчак менә нәкъ шуның аркасында дөньяга бер-берсенә игезәкләрдәй охшаган, җанга ләззәт, күңелгә шатлык бирми торган әйберләр дә тугалый. Бөтен дөньяга билгеле Хохлома һәм Палеха. Гәрәбәгә бай Балтик буе. Искитмәле матур челтәрләр эшләүче Вологда шәһәре. Һәм борынгы, һәм бүгенгечә яшь халык һөнәрләре буыннан-буынга саклап ган урыннар күп түгел алар.

Шәһәребездән ерак түгел, бөек Тукай: «Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл Кырлай диләр. Җырлаганда көй өчен тавыклары җырлай диләр», дип мактаган урыннарда милли аяк киемнәре фабрикасы эшли. Бирерә матур-матур читекләр, бәрхет һәм күн туфлилар, чүәкләр тегәләр. Аларның һәркайсы болгар чорыннан бирле камилләштерелә килгән милли нәкыш-бизәкләр төшереп чигелгән була. Борын-борыннан Идел буенда гына түгел, барлык тирә-юнь илләрдә билгеле булган чигүле читекләрнең беренче «авторлары»— болгар осталары. Әле X гасырда ук болгарлар төрле төстәге йомшак күннән читек-кәвешләр теккәннәр. Йомшак хром-юфть әле хәзер дә Урта Азиядәге «болгар» артикулы белән йөртелә, калмыклар һәм алтайлылар әйбәт күнне «пулгайры» дип, ә венгрлар «багария» дип атыйлар. Болгар осталарының, ә соңрак казанлыларның чигүле аяк киемнәре борын-борыннан Урта Азия, Кавказ, Көнбатыш Европа ярминкәләренә чыгарылган.

Хәзер дә җәйге-көзге эшләр бетеп, кырларны ак кар юрганы каплагач, Казан арты авылларында борынгыдан килгән шушы шөгыльгә тотыналар, рәссамнар ясап биргән бизәкләрне булачак читек кунычларына, үкчә артларына, чүәк башларына күчерәләр. Арчадагы, Дөбъяздагы, Яңаширмәдәге махсус цехларда меңнән артык чигүчеләр, тегүчеләр хезмәт итә. Биш йөздән артык кеше бу эшне өенә алып башкара. Бабаларыбыз сәнгате яшь, вакыт үткән саен яңа эчтәлек белән байый, зуррак тәэсир көченә ия була бара. Рәссам һәм архитекторларыбызның ата-бабалар тәҗрибәсенә, алар осталыгына торган саен ешрак мөрәҗәгать итүләре, алар калдырган мирастан, хәзинәләрдән хәзерге фикер-

ләрне җиткерү өчен буяу һәм образлар эзләүләре — бик куанычлы, хуплауга һәм игътибарга лаек нәрсә.

Бәлки белгечләр, үзләренең һәрнәрсәдән хәбәрдар икәнлекләрен күрсәтү-раслау өчен, архитекторлар И. Гайнетдинов һәм Н. Скворцовларның Татар дәүләт опера һәм балет театры бинасын бизәгәндә татар милли орнаментларыннан тыш тагын әле Урта Азия халыклары бизәкләре белән дә мавыгып китүләрен әйтми калмый торганнардыр. Ләкин чын сәнгать әсәре белән очрашканда — зур рәсемме ул яисә нәни генә сынмы, зур сарайммы яисә җентекләп шомартылган-чарланган асылташмы — без бит стильләр һәм классификацияләр турында уйламыйбыз, әйбернең үзенә, аның камиллегенә карап сокланабыз, аңардан ләззәт алабыз, аны иҗат иткән кеше кичерешләренең үз күңелебездә дә кузгалуын тоеп шатланабыз, үз-үзебезне дә шәбрәк аңлый башлагандай булабыз. Андый чакларда без үзебезне күп көннәр һәм төннәр буена коры чүлдә адашып йөреп, ниһаять, су буена килеп чыккан кешедәй хис итәбез һәм чын гүзәллек чишмәсеннән туймастай булып эчәбез.

Театр бинасында да шулай. Стеналарга, түшәмнәргә, баскыч култыксаларына, рәшәткәләргә төшерелгән басымлы рәсем-бизәкләр күзне камаштырмый, киресенчә, бөтен бина эченә ниндидер җиңеллек, иркенлек, күркәмлек биреп тора һәм, аларга карап, һәркемнең күңелендә: мин дә үз эшемне шулай яратып, шундый осталык белән башкараммы икән? дигән сорау туа төсле.

1973 елда рәссамнардан Е. В. Киселев, Г. А. Зяблицев, П. К. Макаров, Р. Апиев, В. В. Киселев, Ю. А. Ефремовлар «Акчарлак» ресторанын бинасын бизәделәр. Тыштан карашка бина үзе әллә ни искитмәле түгел. Ә шулай да ресторанны «бик яхшы» билгесе белән кабул иттеләр. Төзүчеләрнең эшенә мондый югары бәя бирелүнең төп сәбәбе, минемчә, йорт эченең ак керамика белән искиткеч уңышлы бизәлүендә. Һәр нәкышта, һәр рәсемдә осталарның сәләтен, талантын, үз-үзләренә, үз иҗатларына, эзләнүләренә карата таләпчән булуларын сизәсең.

Хәер, монда гаҗәпләнерлек берни дә юк. Элекке традицияләрне бүгенге хисләр белән, яңа алымнар белән чама белеп, зәвыклы итеп, дөрес нисбәт саклап бергә кушу иҗатта һәрвакыт уңыш китерә. Музыкасында бабаларыбызның һәм замандашларыбызның уй-кичерешләрен бер үк дәрәҗәдә оста чагылдыра белгән, чын мәгънәсендә тылсым көченә ия булган Салих Сәйдәшевнең фантазиясе белән, Рөстәм Яхинның нәфис романслары, Нәҗип Җиһановның опералары һәм симфонияләре белән баетылганнан соң татар халкының чал милли культурасының нинди киң колач, нинди көчле яңгыраш алуы һәркемгә билгеле.

Дөресен әйткәндә, без соңгы вакытта милли керамика дигән нәрсәне бөтенләй оныткан булганбыз кебек. Һәм менә, шәһәребезнең бәхетенә каршы дип әйтикме, Казанга талант иясе бер кеше килде, һәм сәнгатьнең сүнеп бара торган шушы төренә җан өрелгәндәй булды. Мин илдә бик сирәкләрдән булган Абрамцев художество училищесын тәмамлап, моннан унөч ел элек безнең шәһәргә эшкә җибәрелгән Борис Шубинны күздә тотам. Зур талант һәм чын илһам, нечкә зәвык һәм тырышлык, халык иҗатының язмышы өчен җаваплылык хисе һәм үз эшенә мәхәббәт — чын художник булу өчен зарур бу сыйфатлар Борис Шубинга элекке осталарның «серләренә» төшенергә генә түгел, ә гадәти бер кирпеч заводында художестволы керамика цехы оештырырга, тамырлары белән борынгы осталар һөнәренә барып тоташкан хәзерге заман производствосын оештырып җайга салырга мөмкинлек бирде. Узган берничә ел дәвамында ул инде уналты күргәзмә оештырды, аның продукциясе 1 миллион «тираж» белән эшләп чыгарылды.

Безнең матбугатта һәм галимнәр арасында Кремль калкулыгындагы гүзәл корылма — Сөембикә манарасы турында күптәннән инде бәхәс бара. Аның кем тарафыннан һәм кайчан төзелгән булуы әлегәчә бил-

гесез. Берәүләр, Казан Россия империясе составына кертелгән вакытта, ягъни 16 гасырның урталарында, бу манара инде булган дип, җиде катлы булып күтәрелгән һәм очлы башы белән күккә ашкан бу корылмада мөселман архитектурасы алымнары ярылып ята, дип баралар. Ләкин шундый ук төпле дәлилләр белән раслана торган икенче бер гипотеза да бар: манара Казан Россиянең Идел буе төбәгендәге үзәк шәһәре булгач салынган, шуңа күрә ул үзенең тышкы күренешләре белән Мәскәү Кремле корылмаларын хәтерләтә. Бу фикер дә нигезле яңгырый, аңа да каршы сүз әйтүе кыен.

Фәнни бәхәсләрнең төрлесе була. Кайчак аңа катнашучылар әле кичә генә аяк терәп яклаган нәрсәләрен бүген юкка чыгарып ташлыйлар һәм, киресенчә, моннан бер генә атна элек яраксыз дип саналган дәлилне берсекөнгә күккә чөеп мактый башлыйлар. Мондый бәхәсләргә сагаеп карау хәерлерәк, чөнки алар хакыйкатьне ачасы урынга кайчакта мәсьәләгә буталчыклык кына кертәләр.

Татарларның исеме белән бәйле хәлне дә фәндәге шундый буталчыклык үрнәге дип күрәм мин. Шуның нәтиҗәсендә күптән кырып бетерелгән татар кабиләләре, кабердән күтәрелеп, ярты Европаны яулап алганнар булып чыкты лабаса! Хәлбуки, Чыңгыз ханның явыз ниятенә буйсынып, Урта Азия, Россия һәм Европа шәһәрләренә, авылларына кара яу булып ябырылган урдаларда, «Дөньяны буйсындырырга уйлаган Темуҗинның тормышы» дигән китабында (Мәскәү, «Наука» нәшрияты, 1973 ел, 62 бит) Е. Каганов язганча, «чын татарлар... аз булган, аларның дәһшәтле исемнәре генә калган, ә алар үзләре, монголлар кылычы белән туракланган хәлдә, туган олысларында җир куенында ятып калганнар». Татар-монгол явы шул тикле бәхәссез реаль факт булып киткән ки, төрле риваятьләр, легендалар, үзләре ишеткән һәр имеш-мимешне киләчәк буын өчен теркәп калдырган билгесез кешеләрнең елъязмалары бәхәссез хакыйкать буларак кабул ителгән, төрле телләрдә, әдәбиятның, сәнгатьнең төрле жанрларында яктыртылган, гәүдәләндерелгән. Һәм шулай итеп, Идел һәм Кама буйларында, Россиянең үзәк бер җирендә гасырлар буе яшәгән, чагыштырмача югары материаль һәм рухи культурага ия булган зур халык — болгар халкы тарихның сикәлтәле юлларында кинәт каядыр югалып калган да аның урынына каяндыр икенче бер милләт — татарлар барлыкка килгән?!

Казанның иң калку бер җирендәге җиде катлы бу могҗизаны, Сөембикә манарасын кем салганлыгы хакында кызу бәхәс купканда, мин ул кешенең барыннан да элек зур һәм бөек оста булуы турында, бер үк вакытта галим дә, инженер да, художник та булуы турында уйлыйм. Кем генә булса да — дан һәм зур хөрмәт аңа. Әгәр Сөембикә манарасы «тегe заманга кадәр» салынган икән, аны төзүчеләр, һичшиксез, рус архитектурасы кануннары һәм алымнары белән таныш булганнар, алардан бик оста файдаланганнар. Әгәр «шуннан соң» салынган булса,— осталар мөселман архитектурасының алымнарына, формаларына ихтирам белән караганнар. Нәкъ менә шул нәрсә: үзендә ике культураның — Көнчыгыш Европа һәм Азия культураларының казанышларын туплаган булуы Сөембикә манарасына ниндидер тылсым көченә ия булган аерым бер үзенчәлек биреп тора, аны бөтен дөнья архитектурасының кабатланмас җәүһәре итә. Һәм әгәр Казанга килүче туристлар, кунаклар саны елдан-ел арта икән, моның сәбәбен бәлки бу кешеләрдә Ленинградтагы Исаакий соборына, Сәмаркандтагы Бибиханым һәм Гүр-Әмир мавзолейларына тиң искитмәле иҗат җимеше булган шушы Сөембикә манарасын үз күзләре белән күреп китү теләгенең көчле булуыннан да эзләргә кирәктер?!

Тормыш дигәнебез көннән-көн тизрәк агыла тора. Совет Сәмаркандь Урта Азия шәһәрләренә генә хас тышкы кыяфәте белән матур. Арагва

һәм Кура елгалары кушылган урында урнашкан Мцхета ачык һавадагы музей булып кына калмаган, элекке традицияләрне файдаланып, аларны үстерү юнәлешендә төзелгән бүгенге көн корылмалары белән дә баетылган.

Узган дәверләрдә дә, хәзер күп милләтле Татарстан республикасының башкаласы булгач та, Казан географик яктан Идел һәм Кама елгалары чатында, бабаларыбыз сайлаган шул ук урында, Герцен әйткәнчә, «Европа идеяләренең Азиягә һәм Азия характерының Европага үтүе юлында төп кәрван-сарай» булып кала бирә. Мөмкинлекләребез артканнан-арта. Матди һәм рухи культура казанышларын сайлап үзләштерергә, милли традицияләребезне ишәйтергә һәм үстерергә шартлар күбәйде. Куәтле тамырлардан куәтле ябалдаш үсмәве мөмкин түгел!

## Беренче биеклек

Беренче тау, Икенче тау, Өченче тау — бер-бер артлы тезелеп Кабан күленә таба төшә торган элекке урыннарга исем биргән бу биеклекләр, әлбәттә, Эльбрус, Монблан кебек таулардан күп тәбәнәк. Ләкин эш топографлар билгеләгән нокталарның диңгез тигезлегеннән ничә метрга югарырак булуында гына түгел. Өскәрәк менәргә, менгән саен күбрәк нәрсәләр күрергә омтылу кешегә гомумән хас нәрсә. Һәм ул, шушы табигый теләгенә буйсынып, шул хыял белән канатланып, егылаүрмәли булса да, һаман биеккә үрмәли. Ниһаять, теләгенә дә ирешә. Аңа чиксез киңлекләр, океан-диңгезләр, урман-кырлар, авыл-шәһәрләр ачыла. Барысы да синең күз алдыңда. Әмма — гаҗәеп хәл!— дөнья элеккечә үк серле һәм аңлаешсыз булып кала бирә.

Хәер, монда гаҗәп бер нәрсә дә юк. Эш күз күреме җитә торган җирнең киңрәк, ераграк булуында түгел, кешенең үз акылы белән вакыт дигәненнең эчтәлегенә, асылына үтеп керә белүендә, тормышның, җәмгыятьнең кая таба баруын еллар аша күрә, аңлый һәм төшенә алуында.

Миңа калса, Казандагы Беренче тау — кеше акылы әле моңарчы ирешә алмаган рух һәм фикер киңлекләре ачыла торган иң югары биеклекләрнең берсе. Унҗиде яшьлек Володя Ульянов нәкъ шушы тау башыннан иске дөньяның җимерекләре өстендә калкачак яңа Россияне күргән.

1888 елның көзендә, унсигез яшьлек Володя Кокушкино авылыннан сөргеннән кайткач, Мария Александровна хәзер Владимир Ильич Ленин музее урнашкан Беренче тау урамында квартирга керә. Бу Ульяновларның Казандагы беренче адреслары түгел. Патшаның үзенә каршы чыккан гаиләгә торыр урын табуы ансат булмагандыр, әлбәттә. Сембер шәһәрендә яшәүче бер дус кызына хатында Оля болай дип язган: «Бу квартирлар белән бәла... берничә көннән тагын күченәчәкбез». Һәм шунда ук яңа адресын да күрсәткән — Беренче тау урамы.

Хәзер шәһәрдә күп урыннар элеккечә түгел. Урамнарда асфальт, конкалар урынына трамвайлар йөри, троллейбуслар йөгерә, газ фонарьларын электр яктырткычлары алыштырган. Бәлки без бүген патша хәзрәтләренең үзенә һөҗүм итүдә катнашкан дәүләт җинаятьчесенең энесе Володя Ульяновның ул чакларда бу тирәдә ниләр күргән булуын күз алдына да китерә алмаган булыр идек. Әле дә ярый, шул ук Беренче тау урамында Ульяновлардан биш кенә ел элек университетка керү турында хыялланып йөргән Алеша Пешков яшәгән. Һәм үзенең автобиографик повестьларында бу тирәләрнең ул вакытта ниндирәк булганын тасвирлап калдырган. «Евреиновлар йорты (ул Ульяновлар торган Орлов йортының күршесендә.— М. З.) фәкыйрь генә, тар гына урамның очында ялгыз калкып тора иде, аның бер стенасы янгыннан соң калган

бушлыкка карый. Бушлыкта куе булып чүп үләннәр үсә, әрем, тигәнәк, ат кузгалагы, бузина куаклыклары арасында җимерек кирпеч йорт калкып тора, ә ул җимерекләр астында — зур подвал. Анда хуҗасыз этләр яши һәм үлә иде»[1].

Сембер гимназиясен тәмамлаганнан соң, 1887 елның көзендә Володя Ульянов Казан университетының юридик факультетына укырга керү нияте белән Казанга килә.

Моның сәбәпләре берничә. Беренчедән, олы улы Саша үтерелгәннән соң Мария Александровнага, Володяның гимназияне бик яхшы аттестат алып, алтын медальгә тәмамлаган булуы берни тормый, дәүләт җинаятьчесенең энесенә ике башкаланың берсендә дә укырга рөхсәт булмаячак, дип турыдан-туры әйтәләр. Икенчедән, Казан Ульяновлар өчен ят шәһәр түгел. Казаннан 40 кына чакрым җирдә, бәләкәй генә утарында Мария Александровнаның этисе Александр Дмитриевич Бланк яши. Өченчедән, Володяның этисе Илья Николаевич үзе дә Казан университетының физика-математика факультетын тәмамлап чыккан кеше. Ниһаять, тагын бер нәрсәне, Казанга килергә карар бирелүнең төп сәбәбен, Владимир Ильичның язмышында һәм биографиясендә зур роль уйнаган фактны — Казанның интернациональ шәһәр булуын, анда пролетариатның инде оешып килүен, революцион хәрәкәтнең тууын да истән чыгарырга ярамый.

Володя Ульянов Казанга университетка укырга керергә килгәндә, Степан Тимофеевич Разинның кан эчүче боярларга, алпавытларга каршы көрәше, бу көрәштә «бергә булыйк!» дигән чакыруы Идел буе халыклары күңеленнән әле җуелмаган була. Разин үзенең гаскәрләрен Мәскәүгә Идел ярлары буйлап алып бара, үзе үткән җирләрдә крестьяннарны азат итә килә. Ләкин Сембер шәһәрен беренче һөҗүмендә ала алмыйча, бу шәһәр тирәсендә туктап кала. Сембергә ярдәмгә ашыккан һәм шунда камалган патша гаскәрләре башлыгы князь Борятинский тиз хәрәкәт итә алмавыннан, Казан елгасы тамагында угры татарлар, чувашлар һәм мордвалар белән бәрелешергә туры килүеннән зарлана. Казандагы бик атаклы вакыйгадан — Россиядә социал-демократлар хәрәкәтенең булачак оештыручысы Владимир Ульянов та катнашкан студентлар сходкасыннан берничә генә ел элек шәһәрнең укучы яшьләре алпавытларга каршы баш күтәргәннәре өчен граф Апраксин җәзалаган Бездна авылы крестьяннары истәлегенә җеназага җыелалар. Анда Н. Г. Чернышевскийның фикердәше, Казан университеты профессоры А. П. Щаповның ачу һәм нәфрәт белән әйтелгән: «Сез, дуслар, бөтен халык күптән тилмереп көткән азатлык хакына көрәштә деспотизмның беренче корбаннары булдыгыз»,— дигән сүзләре зиратта гына яңгырап калмаган. Аларны бар халык ишеткән. Аларны үзенең «Колокол»ында Александр Герцен күтәреп алган.

Аерым-аерым караганда, бу фактларның очраклы нәрсәләр булып күренүе дә ихтимал. Ләкин алар — бер гомум закончалык чагылышы. Тарих Идел буе төбәгенең башкаласы Казанны иҗтимагый һәм политик көрәшнең иң алгы сызыгына чыгара. Александр патшага аткан Дмитрий Каракозовның, Россия императорына һөҗүм итүдә гаепләнеп, Александр Ульянов белән бергә җәзаланган Василий Осипановның Казан университетында укыган булулары, Шлиссельбург казаматларында озак еллар тоткында яшәгән атаклы революционер Вера Фигнерның намуслы, киң күңелле профессор Франц Лесгафт лекцияләренә йөрүе — болар берсе дә очраклы хәл түгел.

Һәр биография, һәр язмыш — югары максатка илтүче күперчек ул, язмыш каршында, хакыйкать каршында һәркем тигез булсын өчен көрәшкә өндәү ул! Оешмаган чыгышлардан — сыйнфый көрәшкә! Һәм

[1] М. Горький. Әсәрләр, 18 томда. 1962, 9 том, 420 бит.

шушы тарихи тенденция Россияне Николай Федосеевның беренче марксистик түгәрәкләренә алып килә.

Ул чактагы унҗиде яшьлек гимназист Николай Федосеев ярыйсы ук хәлле гаиләдән чыккан. Казанга университетка керү нияте белән килгән һәм монда марксизмны өйрәнүгә керешкән. Ул яңа, ирекле тормыш турында хыялланган һәм революцион тәгълиматның Маркс әйтеп биргән асылы: философлар дөньяны аңлату белән чикләнделәр, ә бурыч аны үзгәртүдән гыйбарәт, дигән сүзләре һәркемгә барып җитсен, аңлашылсын дип тырыша. Федосеев народникларга каршы көрәшә, алар белән бәхәсләр оештыра, зур көрәшнең бөек хакыйкатен аңлата торган листовкалар язып, үзе үк шуларны бастырып тарата.

Алеша Пешков инде бу вакытта Евреиновлар йортыннан китеп, Марусовкага күчкән һәм анда корректор булып көненә унбиш тиен хезмәт хакы алучы Гурий Плетнев исемле егет белән бергә яши башлаган була. Плетнев булачак пролетар язучыга Федосеев тарафыннан язылган листовкаларны тарату бурычын йөкли, ә тегесе, зур эш башкаруын аңлап һәм шуңа чиксез шатланып, Казандагы Алафузов һәм Крестовниковлар заводларында эшләүчеләр янына йөри. «Мин ул кешеләргә, шайтан белсен, ниләр генә сөйләгәнмендер,— дип яза Горький, үзенең Казандагы тормышын исенә төшереп.— Әлбәттә, сөйләгәннәремнең барысы да аларда бүтән төрле, җиңелрәк һәм мәгънәлерәк тормышның мөмкин булуына өмет уята ала торган нәрсәләр булгандыр. Кайчак мин моңа ирешә идем һәм, шешенгән йөзләргә кайгы өртелүне, күзләрдә гарьлек һәм ачу кабынуны күреп, мин үземне бәйрәмдәгечә хис итә идем һәм горурлык белән: мин бит «халык арасында эшлим... аны агартам...» дип уйлый идем»[1].

Көнелләрдә менә шундый ачу һәм гарьлек кабынган, яхшы тормышка өмет уянган заманда Владимир Ульянов Казан университетына укырга керә.

Абыйсы Сашаның һәлак булуы уңае белән кайгылы уйлар кичерә Володя, тирән уйлана һәм патша үтерү, аерым шәхесләрнең батырлыгы гына уңыш алып килмәячәк, җиңүгә бары тик самодержавиегә каршы көрәшкә халыкны күтәрү юлы белән генә ирешергә мөмкин дигән нәтиҗә ясый.

Университетка керергә җыенганда ук ул Казан кебек культура һәм промышленность үзәгенең мөмкинлекләрен исәпкә алмый калмаган. 140 мең кешелек шәһәрдәге 10 мең пролетарий, йөзләрчә студент — бу инде көрәштә чын таяныч булырдай зур көч.

Һәм Володя Ульянов беренче көннәрдән үк революцион караштагы студентлар белән якын элемтәгә керә, полиция «гадәттән тыш зарарлы» дип санаган Яков Богораз түгәрәгенең актив члены була.

Николай Федосеев патшага һөҗүм итүдә катнашкан Александр Ульяновның энесе турында күп ишетә, аны ихтирам белән телгә ала: «Аның белән якыннан танышырга кирәк. Гаять зур файда булачак»,— ди. Ләкин, кызганычка каршы, моны эшләргә өлгерә алмый.

Икърар итми булмый: иске Россиядә шымчылык югары дәрәҗәгә куелган булган, жандармнар аз гына шик астында булган кешенең дә һәр адымын күзәткәннәр. Охранканың нәкъ менә шулай шәп эшләгәнлеге аркасында, без бүген Володя Ульяновның университетта үзен ничек тотуын беләбез: «Занятиеләргә сирәк йөри иде... тантаналы актта булмады... Нииндидер начар эшләргә җыенып йөрде...»

Ә 4 декабрьда унҗиде яшьлек Володя Ульянов беренче чыныгу кичергән, аңа тормышының төп максатын билгеләргә — революцион көрәш юлына басарга төп этәргеч булган сходка башланып китә.

---

[1] М. Горький. Әсәрләр. 18 томда. М., 1962, 9 том, 440 бит.

Владимир Ульяновка университетка кире кайтырга рөхсәт итмиләр. Шуннан соң ул Казанда үтеп барышлый гына була. Ә Казан исә Россия социал-демократлар хәрәкәтенең төп үзәкләреннән берсенә әверелә. Партия заданиесе белән монда бернichә тапкыр Н. Э. Бауман, Я. М. Свердлов, В. В. Адоратский, Н. А. Семашко, А. С. Кулеша, И. А. Саммер һәм В. И. Ленинның башка көрәштәшләре килә. Казанда беренче татар большевиклары Хөсәен Ямашев, Мулланур Вахитов, Гафур Коләхметовлар яши һәм революцион эш алып бара. Петербургта «Аврора» залпы яңгырагач, революция сигналын беренчеләрдән булып Казанда ишетәләр, һәм прапорщик Николай Ершов кызылгвардиячеләр отрядын совет власте өчен көрәшкә күтәрә. Казан — Россиядә Октябрьнең кызыл әләмен күтәргән икенче шәһәр.

...Хәзер университетта В. И. Ленин мемориалы эшли. Анда бөтен нәрсә 1887 елдагы хәлгә китерелгән. Шул ук актлар залы. Тик аның стеналарында тәхет иясе затларның портретлары урынына Толстой, Лобачевский, Аксаков, Бутлеров һәм университетны тәмамлап чыккан, Ватаныбыз фәненең горурлыгы булып танылган бүтән бөек кешеләрнең рәсемнәре эленгән.

Булачак юлбашчы тарих, хокук буенча лекцияләр тыңлаган аудитория яңадан ачык. Стенасында — сходкада катнашкан өчен университеттан чыгарылган студентлар исемлеге. Анда утыз тугызынчы кеше — Владимир Ульянов. Аудиториядә — ул утырган парта.

Һәр иртәдә бу тирәдән, кулына китаплар тоткан, тужуркасын иңбашына салган бронза һәйкәл янынннан, дәрескә ашыгучы студентлар уза. Һәм менә хәзер әлеге бронза егет үзе дә постаментыннан төшәр дә, аудиториягә кереп, үз партасына утырыр төсле тоела...

Беренче тау дип аталган урамда В. И. Ленин музее ачылды. Дмитрий Ильич һәм Мария Ильинична өйдәге бөтен хәләтне элеккечә итүдә булышты. Кухня, Мария Александровна бүлмәсе, балалар бүлмәләре. Володяныкында — тимер кровать, китап киштәсе, өстәл өстендә — керосин лампа, пыяла кара савыты. Урындык артына гимназист курткасы эленгән... Бирелән, Беренче таудагы өйнең тәрәзәсеннән, Володя Ульянов әрем, тигәнәк үскән бушлыкка, җимерек йорт калдыкларына карап торган һәм киләчәкне ул чакта әле каплаган пәрдә аша иске дөнья хәрабәләрендә калкачак бүгенге Россияне күргән.

Ульяновлар гаиләсенең Казандагы тормышы турындагы истәлекләрендә Анна Ильинична «таныш-белешләр безгә килеп йөрмиләр иде» дип яза. Бу аңлашыла да: Казан мещаннары Сембер мещаннарыннан бер яклары белән дә аерылмаган, берәү дә «патшага каршы» булган гаилә белән дус булырга теләмәгән. Ә менә хәзер Ульяновлар урамы дип йөртелә торган элекке Беренче таудагы элекке Орлов йортында В. И. Ленин музее ачылганнан соң үткән 40 ел эчендә анда дөньядагы 105 илдән 4 миллионнан артыграк кеше булган. Монда килүчеләр гади язу өстәле янында, бөтенебез өчен кадерле кеше укыган һәм битләре ачык калдырылган китапка карап озак басып торалар һәм бирелән, бу бөек кешенең революцион көрәш юлы башланган урыннан бүтән бер генә биеклектән дә күрергә мөмкин булмаган нәрсәне күрергә тырышалар.

## Идел өстендә могҗиза

Казан өстендә кичке шәфәкъ сүнеп, Иделнең яр сызыклары караңгылык эчендә югалып калгач һәм елга тигезлегендә бер-берсенә күз кысышучы утлар җемелди башлагач, Кремльнең Спасск манарасы әле кабынып, әле сүнеп китә торган куе кызыл төстәге нур эченә чума. Шул ук вакытта искиткеч тәэсирле итеп металл чыңы яңгырый. Сәгать суга.

Казанлылар бу күренешне үзләренчә «малиновый звон» дип атыйлар. Сәгать чыңы, дулкын-дулкын булып, урамнарга, мәйданнарга тарала. Бер сугу саен манарада әлеге нур кабына. Искитмәле күренеш!

Бу күренеш — Казанның горурлыгы, аның сере, могҗизасы. Александр Николаевич Скрябинның «Прометей» дигән поэмасы нәкъ Казанда беренче тапкыр тавыш һәм төсле яктылык ярдәмендә башкарылды. Кешеләр хакына, аларга изгелек итү хакына иң авыр җәзага барган, Зевсның нәфрәтеннән һәм үченнән курыкмыйча, аларга ут табып биргән мифик титан, бөек Прометейга багышлап язылган бу әсәрне, бу гимнны 1911 елда беренче тапкыр башкарганда аның яктылык партитурасын уйнау өчен инструментлар әле булмаган. Аны гади оркестр гына башкарган.

Шуннан соң ярты гасыр үткәч, Казан авиация институтының «Прометей» дип аталган конструкторлык бюросы энтузиастлары, махсус аппаратура иҗат итеп, А. Н. Скрябин поэмасын яктылык һәм музыка ярдәмендә башкардылар. Казан — ничәмә-ничә буын музыкантларының хыялын тормышка ашырган, аваз-аһәңне «күрсәтә» белү бәхетенә ирешкән беренче шәһәр. Ә Казан Кремленең Спасск манарасында сәгать суккан саен кабына торганы әлеге «малиновый звон»— прометейчыларның икенче җитди адымы. Ул кешеләрне тавышны «күрергә» генә түгел, архитектура формаларын «ишетергә» дә өйрәтә.

Әйе, кайчандыр, моннан күп еллар-гасырлар элек Казан үзенең туган көнен югалткан. Күрәсең, метрикалар һәм календарь даталары турында уйларга вакыт та, мөмкинлек тә булмаган ул заманнарда. Ләкин моннан күп гасыр элек тормыш итү өчен Идел һәм Казан елгалары кушылган урынны сайлаган кешеләр, бу тирәләргә соңрак күчеп килгән, үз илләренең чигендәге бу ныгытманы шәһәр иткән, зур дәүләтнең башкаласына әверелдергән буын вәкилләре бабаларының чуен кою, торбалардан су җибәрү, матур-матур таш пулатлар салу осталары булуларын, фәннәр белән шөгыльләнүләрен, шигырь-поэмалар язуларын онытмаганнар.

Мәсәлән, күпме вакыт Европада кешеләр чуен кою һөнәрен тик XVI гасырда гына үзләштергәннәр дип саналган. Ә менә археологлар Идел буе болгарлары илендәге домналарның нәкъ ике гасырга өлкәнрәк булуларын расладылар. Болгар дәүләте башкаласының җимерекләре астында галимнәр — күз алдыбызга китереп карыйк!— бүгенге домна мичләренең бабаларының бабалары булган егерме алты тимерче учагы таптылар. Әйтүләренә караганда, искитмәле уңайлы мичләр! Аскы өлешендә мичтәге ялкынны көчәйтү яисә киметү өчен махсус һава өрдерү җайланмасы, ә өстә, тирән чокырда — руда. Мич янәшәсендә әзер продукция — металл җыела торган базлар.

Тәгаен әйтүе кыен, үткән тормышның бу мөһим эзләрен тапкан ул кешеләр әлеге домналар янында басып торганда нәрсә уйлаганнардыр. Әмма, һич шикләнмичә, шуңа ышанырга кирәк: аларның шатлыгы инде югалган дип исәпләнгән атаклы Тутанхамон төрбәсен тапкан америкалы Говард Картерныкыннан ким булмагандыр!

Шундый фикер туа: инде бар нәрсә дә ачылган, табылган, ачыклангандип санап, без кайчак эзләнүләрне иртәрәк туктатмыйбызмы, кайчандыр югалган истәлекле урыннарны, шәһәрләрне, цивилизацияләрне тапкан кешеләр турындагы китапларны кызыгып уку белән чикләнмибез микән?

Җиде яшьлек малай вакытында әтисенә әкиятләрдә сөйләнә торган Троя шәһәрен табарга вәгъдә иткән Генрих Шлиман картлык көнендә, эшен-шөгылен ташлап, бала чагындагы хыялын эзләргә чыгып китә һәм уңышка ирешә. Ул элиннар патшасы Приамның хәтта белгечләр дә бөек Гомерның шигъри уйдырмасы гына дип санаган легендар башкаласын ача. Белеме буенча юрист кеше, америкалы Джон Ллойд Сте-

фенс һәм инглиз рәссамы Фредерик, Казервурд Кортесның конкистадорларыннан соң гасырлар үткәч, джунглиларга китәләр һәм Төньяк Американың төп халыкларыннан булган майя кабиләләренең борынгы цивилизациясен раслаучы дәлилләр табып, бу Яңа дөньяны безнең өчен яңадан ачалар. Ә менә инглиз Вильям Хайклинг Прескотт, бүтән тикшеренүчеләрдән үзгә буларак, эш бүлмәсеннән чыкмыйча гына — ул сукыр була — аңа кадәр күзлеләр дә күрә алмаган нәрсәне күрә. Сәяхәт итү мөмкинлегеннән мәхрүм булган бу галим борынгы манускриптларны тикшерергә керешә һәм майялар кебек үк борынгы халык — ацтеклар цивилизациясенең серен ачып, замандашларын шаккаттыра...

«Троя шәһәренең, майя һәм ацтек халыклары культураларының эзләрен тапкан әлеге кешеләр кебек үк, безнең тарихчылар һәм археологлар да Болгар дәүләте башкалаларының берсе бөек Биләр серләре турында озак еллар хыялланып яшәделәр,— дип сөйләде миңа Г. Ибраһимов исемендәге тарих, тел һәм әдәбият институтының сектор мөдире, тарих фәннәре докторы, бөтен гомерен борынгы тормыш эзләрен эзләүгә багышлаган галим Альфред Хәсәнович Халиков. — Шәһәрнең кайда урнашкан булуы турында мәгълүматларыбыз шактый иде. Ә Биләр үзе юк та юк. Әйләнә-тирәдә — иген басулары, авыллар, шәһәрләр. Ә төгәл «адресны» белми торып җир казу эшләренә керешү — ул печән кибәне эчендәге энәне эзләү белән бер. Шуннан без авиациягә мөрәҗәгать итәргә булдык. Шул төбәкне самолеттан торып төрле биеклекләрдән фоторәсемгә төшердек. Ә рәсемнәрне зурайтып карагач үзебез дә шаккаттык — менә ич ул шәһәр, күз алдыбызда ич! Казый башлагач, дөрес юлда булуыбызга тагын бер кат ышандык. Менә бит алар, җимерек стеналар, торак йортларының, кәрван-сарайның, урамнарның калдыклары. Бөек Биләр ул вакытта Милан, Генуя, Париж кебек зур шәһәрләр биләгән кадәр мәйдан биләп торган икән — 7 миллион квадрат метр...

Без бераз читкәрәк киттек бугай. Хәер, мондый чигенүләрдән башка хәзерге Казанны, аның холкын, бүгенге шәһәрнең үзенчәлекләрен аңлавы кыен булыр иде. Үткән заманнар шаһиты булган матди истәлекләр белән берррәттән, Казан үзенең иң гүзәл үзенчәлеген — заманны узып китеп, тирән мәгънәле, эчтәлекле тормыш белән яшәргә омтылышын саклап кала килгән.

Геометрия фәненең Коперникы саналган, «математика — ул фәннәр патшасы» дигән борынгы кагыйдәне тагын бер тапкыр раслаган Николай Иванович Лобачевский үзенең ачышлары белән вакытны ким дигәндә бер гасырга узып киткән. Ул чакларны искә төшерик. Фәндә күп гасырлар буена атаклы грек галиме Эвклид геометриясе хакимлек итеп килә. Әмма кайчандыр фәннең иң югары ноктасы булып саналган нәрсә тора-бара кеше акылының мөмкинлекләрен чикли башлый. Һәм менә 1826 елның 11 феврале. Казан университеты. Гыйльми совет утырышы бара. Анда атаклы галим һәм шундый ук атаклы оештыручы-төзүче, университетның колонналы мәһабәт бинасын төзүне яңа гына төгәлләгән кеше математиканың чикләрен галәм киңлекләренә кадәр җиткезә торган ачышы турында доклад ясый. Безгә, аның оныкларына, күп нәрсәне инде мәгълүм хакыйкать дип кабул итүчеләргә, хәзер бары да аңлаешлы. Ә ул чакта Лобачевский сүзләре бик сәер яңгыраганнар. Аны тыңлап утыручылар аптырашта калалар: ничек инде ул, житди галим, өстәвенә, университет ректоры, студентларның яраткан профессоры, иптәшләренең ихтирамын казанган тикшеренүче бөек Эвклидның кануннарына тел-теш тидерергә җөрьәт итә?!

Яңа геометриянең принциплары турындагы бу доклардан соң «Ватан улы» («Сын Отечества») дигән журнал галимне мыскыллый торган мәкалә белән чыга: янәсе, акылга сыймаслык хәл: Лобачевский,

профессор кеше, мәхәллә мәктәбе укытучысына да шәһәрәт китерә алмастай китап язарга батырчылык итә алган, янәсе, аның бу китабын «Геометриянең нигезләре» дип түгел, мәсәлән, «Геометриягә сатира» яисә «Геометриягә карикатура» дип атарга кирәк иде.

Хезмәт урыныннан китәргә мәҗбүр булып, сукыр хәлендә мохтаҗлыкта калгач та, Лобачевский үз тәгълиматының дөрес булуына тамчы да шикләнми, үз сүзеннән кайтмый, математиканың һәр вакыт фәннең бүтән өлкәләрендә яңа ачышлар өчен этәргеч булачагына ышанычын югалтмый, галим буларак, профессор буларак үзенең шәкертләренә еллар буе тукып килгән принципларыннан чигенми.

1828 елда Лобачевский университетны тәмамлаучылар алдында ялкынлы речь белән чыга. Аның бу сүзләрендә уңышсызлыкка очраган кешенең ачынуы түгел, даһиның киләчәккә ныклы ышанычы яңгырый: «Халыклар тарихыннан сез шуны күрдегез,— ди ул.— Һәр дәүләт сабыйлык, балигъ булу һәм картлык чорларын үтә. Безнең сөекле Ватаныбыз белән дә шул ук хәл булачак. Язмыш кушуы буенча ул әкренләп булса да мәһабәт югарылыкка күтәрелә һәм җир йөзендәге бер генә кабилә дә әле җитә алмаган биеклеккә менә. Петр, Екатерина, Александр чорлары атаклы чорлар булдылар, әмма Россиянең иң бәхетле көннәре әле алда».

Лобачевскийның ачышына нәкъ бер ярым гасыр булды. Бу вакыт эчендә яңа математиканың үсүе һәм тантана итүе турында язып торуның кирәге бар микән?!

Югарыда китерелгән юллар СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының физика-техника институтында бөтен илгә билгеле булган механика мәктәбенә нигез салучы һәм аның башлыгы профессор Хәмит Мозаффар улы Мөштәринең лабораториясендә башыма килде.

Казанда уннан артык югары уку йорты, күп санлы проект-конструкторлык һәм фәнни-тикшерену учреждениеләре, дүрт академик институт бар. Менә шушы зур фән агачының барлык ботаклары бер үк тамырдан — университеттан үсеп чыккан. Медицина, авиация, химия-технология институтлары мөстәкыйль вуз булып турыдан-туры университетның элекке факультетларыннан, лабораторияләреннән үскәннәр, икенчеләренә университет үзенең галимнәрен биргән. Фәннәр академиясенең физика-техника институты да үзенең тамырлары белән Казанда математика һәм физика өлкәсендә электән үк билгеле булган тикшеренүләргә барып тоташа. Мин, мөгаен, профессор Мөштәри һәм аның шәкертләре китереп чыгарган теориянең асылын, әһәмиятен аңлап та җиткермимдер, бүтәннәргә дә аңлатырга җыенмыйм. Тик бер генә нәрсәне әйтәсе килә: фәнни идеясенең үзе исән чакта ук киң танылуына, шөһрәт казануына ирешү өчен галим кеше ни дәрәҗәдә тырыш һәм эзлекле булырга тиеш!

Профессор Мөштәри — гасырыбыз яшьтәше. Ул Бельтрами, Гельмгольц, Пуанкаре, Дарбу, Кэли, Клейн, Ляпунов, Менделеев, Столетов, Зинин кебек исемнәре бөтен дөньяга билгеле булган галимнәр заманында, хәтерегездәдер, иң урта кул мәхәллә мәктәбе укытучысы белән тиң куелган бөек геометр Николай Лобачевский йөз еллыгын билгеләп үткәч дөньяга килә, совет чорында югары белем ала, фән белән шөгыльләнә башлый, гомерен саннар һәм механика законнары арасындагы үзара элемтәне ачуга багышлый. Аның бу өлкәдәге ачышлары бик тиз кулланыш таба, һәм шул нигездә фәндә тагын бер әһәмиятле юнәлеш туа.

Хәмит ага Мөштәри хәзер инде үзе бу институтта директор түгел. Җитмеш алтысын тутырган кешегә андый йөкне күтәреп бару кыенлаша. Ул шунда ук гади фәнни хезмәткәр булып эшли, әмма аның тәҗрибәсе, аның белеме, Казан механика мәктәбенең остазы дигән югары исеме — яшь галимнәр өчен зур таяныч. Нефть промыселларында ку-

этле производстволар барлыкка килә, нефтьчеләр технологик аппаратларны саклаучы мембраналарын исәпләп чыгаруны сорыйлар. Математиклар моны эшли. Экономик файда — елына 15 миллион сум. Горькийдагы канатлы «Ракета»лар төзүчеләргә яңа проектлар эшләү өчен математик таблицалар кирәк. Алар да эшләнә. Алар да зур файда китерә. Һәр ай, һәр ел шулай дәвам итә.

Һәм мин Иделдә яки башка суларда дулкыннар өстеннән очып диярлек узган канатлы корабларны күргәндә, иң башлап, бу могҗизаларны эшләп чыгарган осталар турында түгел, фәннәр патшасы — математика турында, аның белән хыялланып, аны хәзерге биеклекләргә күтәргән галимнәр турында уйлыйм.

Әле күптән түгел генә, 1976 елның башында, Дубна физиклары Менделеев таблицасының яңа, йөз дә җиденче элементын табалар. Дөрес, табылганнан соң ул секундның ике меңнән бер өлеше кадәр вакыт кына «яши» дә шунда ук таркала. Ләкин яңа ясалма элементлар булдыру мөмкин икәнлеген тагын бер тапкыр раслау өчен шул мизгелләр дә бик җиткән. Менә шулай, әле кичә генә уйларга да мөмкин булмаганча, табигатьтәге искитмәле үзгәрешләрнең серенә төшенергә омтылганда физиклар Лобачевский геометриясе законнарына таяналар. Ул кануннар әле кичә генә мөмкин түгел дип саналган нәрсәне — яңа элементлар төшләрен, димәк, материянең үзен кулда тотарга мөмкин итәләр. Ә бит әле сугыштан соң чыгарылган дәреслекләрдә дә атом төше — ул матдәнең бүленми торган иң кечкенә кисәкчәсе дип язылган иде.

Кешелек тарихы — ул берсе артыннан икенчесе килә торган еллар, гасырлар тезмәсе генә түгел, ул — кыю хыяллар, шул хыялларның тууы белән тормышка ашырылуы арасындагы вакытны кыскарту өчен көрәш тә. Россиянең бу төбәгендә, чал Идел Чулман-Кама алкын суларын үз кочагына ала торган урында кешеләр һәр вакыт кыю фикерле, теләкләренә ирешүдә нык торучан булганнар.

Бу уйлар минем башка университет ишегалдындагы бинада, Александр Михайлович Бутлеров лабораториясендә килде. Пробиркалар тулы шкафлар белән җиһазландырылган бүлмәдә тынлык. Шәһәр шаушуы биредә ишетелми. Монда, бөек галимнең исемен йөрткән фәнни-тикшеренү институтында, хезмәткәрләр күп түгел. СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының органик һәм физик химия институты төп лабораторияләре хәзер биш катлы зур бинада. Ә бирегә күбесенчә укучылар, яшь химиклар олимпиадасында катнашучылар йөри.

Атом чорына әле ерак була, кешелек әле электр энергиясен дә белми. Шулай да кеше акылы табигатьнең, материяне тәшкил иткән матдәләрнең серләренә торган саен тирәнрәк үтеп керә. Һәм, ниһаять, галимнәр сан ягыннан елдан-ел арта барган химик ачышлар алдында каушап калалар. Алар моңа кадәр билгесез матдәләр барлыкка килүне күрәләр, әмма аларны китереп чыгаручы үзгәрешләрнең серен аңлый да, аңлата да алмыйлар. Бу серләрнең ачкычын Александр Михайлович Бутлеров таба. Әле яңа туган яшь органик химия алдында нинди зур мөмкинлекләр ачылачагын алдан күреп, ул: кешеләр теге яки бу матдәнең ничек барлыкка килүен генә түгел, аның составын һәм үзлекләрен дә һич хатасыз алдан әйтеп бирә алачаклар, ди, тынгы белмәүчән тырыш акыл ияләре өчен нинди киң «мәйдан» ачылачак, дип яза.

Хәзер Казан химикларының эш «мәйданнарының» бер «очы» — Иделдән еракта, Ык буенда, Баулы тирәләрендә, илебезгә ел саен йөз миллион тонна чамасы «кара алтын» бирә торган нефть промыселлары башланган җирдә, уртасы — Түбән Камада, куәтле реакторлар егерме меңнән артык скважинадан алына торган җир маен эшкәртә торган, ясалма каучук җитештерә торган, бүтән төр химия продукциясе өчен

чимал бирә торган җирдә, икенче «очы»— биредә, Казанда, «Органик синтез» берләшмәсе заводларында. Бөтен республиканы биләп торган бердәм промышленность комплексының соңгы баскычы менә шунда.

Әйләнә-тирәдә — биек-биек колонналар, торбалар. Реакторлар, машиналар гөрелтесе. Без партиянең XXV съезды делегаты, аппаратчы Гөлсинә Җантимерова белән янәшә атлыйбыз. Ул ашыкмыйча, төпле итеп сөйләшә. Күренеп тора: минем өчен могҗиза булып тоелган күп нәрсә аның өчен гап-гади бер нәрсә. Алар — Гөлсинәнең көндәлек эше.

Элементларның периодик системасын тудырган Дмитрий Иванович Менделеев әле нефтьтән мазут, керосин гына аерып алынган вакытларда: нефть ягу — ул кәгазь акчаны дөрләп янган мичкә ташлау белән бер, кешеләргә «дүрт тиенлек нәрсәне биш сумлык» әйбергә әйләндерергә өйрәнергә кирәк, дигән. Гөлсинә Җантимерова яше буенча Менделеев бабайга аның оныгының оныгы гына. Күрегез: буыннарның язмышлары бер-беренә ничек килеп бәйләнде!

Могҗизачы-аппаратчыларның реакторлар белән ничек идарә итүләрен сөйләп тормыйк. Дөресен генә әйткәндә, һәр останың, — алмаз шомартучымы ул, җир сөрүчеме, барыбер,— эше турында сөйләү гомумән кыен нәрсә. Казанда нефтьтән нәрсәләр алуларын гына әйтеп үтик. Ацетон, фенол, этилен окисе, моноэтиленгликоль, полиэтиленгликоль, синтанол, полиэтилен, лаурила перекисе... Әле кичә генә күбебезгә билгесез булган, шуңа күрә исемнәре ничектер сәер яңгырый торган бу әйберләр мех, тукымалар, буяулар, уенчыклар, машиналар, корабльләр ясау өчен китә. Шуңа күрә Казан химиклары илебезнең һәм дөньяның төрле почмакларындагы меңнән артык заводлар, фабрикалар белән бәйләнештә тора.

Көндәлек ыгы-зыгыга бирелеп, без еш кына күп нәрсәгә игътибар итмибез, кичәге белән бүгенге арасындагы аерманы күрми калабыз. Әйтик, балабызның бер көндә ничек үсүен кайсыбызның күргәне бар? Ә менә шул ук баланы берничә ай буена күрми торсак, очрашканда шаккатабыз: күр әле, янәсе, танырлык та түгел, ничек үскән!

Казан да шулай. Әмма шәһәрнең үткәненә күз ташлап, аны бүгенге көн белән чагыштыра башласак, бу «аралар» торган саен кыска була баралар. Чөнки бүгенгенең бер көне элеккенең гасырларына тиң!

Бервакыт архивта утырганда гасырыбызның башында Казанда үткәрелгән күргәзмә турындагы хәбәргә игътибар иттем. Бик кызыклы хәбәр. Бер завод хуҗасы күргәзмәгә трактир макетын куйган. Әлеге макетны ул, ничек башы җиткәндер, пыяла шешә эченә утырткан. Һәм шундый тапкырлыгы белән дан казанган.

Хәзер республиканың Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә йөздән артык тармакның әйберләре куелган. Күп кенә компрессорлар, суыткыч машиналар дөньяның 40 тан артык иленә җибәрелә. Хирурглар яраларны, операция урыннарын тегә торган могҗизалы җеп — кетгут салынган пыяла пробиркалар, кибернетик машиналар, ислемай, самолетлар. Кинопленка. Приборлар...

Хәер, хәзер кешене саннар белән шаккаттырып булмый. Бүген төп нәрсә — күпме эшләнгән түгел, ничек эшләнгән, төгәл итеп эшләнгәнме, ышанычлымы, матурмы. Сыйфат — менә нәрсә белән мактанып һәм мактапып була!

Казанның мотор төзүчеләре бу яктан матур үрнәк күрсәттеләр. Узган бишьеллыкта заводта, эшне туктатмыйча, реконструкция үткәрделәр, лазер, ультратавыш кебек нәрсәләрне киң файдалана башладылар, детальләрне әзер модельләр буенча, өстәмә эшкәртүне таләп итми торган итеп коюга күчтеләр. Ә самолет моторында мондый детальләр йөзләп, меңләп. Биш ел эчендә заводта шәхси клеймо белән эшләүчеләр саны өч тапкыр артты. Конвейердан хәзер дә шул ук моторлар төшә,

тик аермасы шул — аларның гарантияләнә торган эшләү ресурсы элеккедән өч-биш тапкыр артыграк.

Бу санны аңлаешлырак итеп ничек әйтергә соң? Һәр двигательнең үзенең эшләү срогы була. Әйтик, ул бер мең сәгать эшләргә тиеш, ди. Ә менә Казан мотор төзүчеләре хәзер элеккеге өч-биш машинага тора торган моторлар чыгара башладылар, чөнки аларның эшләү срогы — 3—5 мең сәгать. Экономистлар исәпләп чыгарганча, бу нәрсә елына 220 миллион сум файда китерә. Әгәр моторларны элеккечә чыгарып килгән булсалар, хәзер двигательләр санын берничә тапкыр арттырырга, моның өчен тагын шундый берничә завод салырга кирәк булыр иде.

Заманалар үзгәрә, талант, осталык бүтән мыскаллар белән үлчәнә: сан гына түгел, сыйфат та! Узган бишьеллык башында продукциянең бөтен дөньядагы һәм илебездәге иң яхшы стандартларга туры килүен аңлата торган Дәүләт сыйфат билгесе Казанда эшләнә торган өч дистә әйбергә бирелгән иде. Хәзер исә мондый әйберләр саны ярты меңнән артык.

Заводлар, фабрикалар, аларда эшләнә торган машиналар, приборлар гына түгел, аларны тудыручылар, алар арасындагы мөнәсәбәтләр дә үзгәрә.

Күптән түгел самолет төзүчеләрнең культура сараенда Әхәт абзый һәм Хәтимә апа Мусиннар хөрмәтенә бәйрәм кичәсе үткәрелде. Әхәт ага заводта 39 ел эшләгән, Хәтимә апа — аңардан өч елга кимрәк. Әтиәниләре белән бергә заводта алар гаиләсеннән тагын унбер кеше самолет җыя. Аларның гомуми эш стажы — 200 елдан артык! Халык күп җыелган иде. Мусиннар белән бергә залда бөтен илебезгә билгеле хезмәт коллективына нигез салган ветераннар да, яшьләр дә утыра иде. Социалистик Хезмәт Герое, СССР Верховный Советы депутаты фрезерчы Галимулла Әсхәдуллин Мусиннар гаиләсенә яңа паспортлар тапшырган вакытта, юбилярларга хөрмәт йөзеннән, яшьләргә үрнәк булсын өчен, бөтен кеше аягүрә басты.

Тагын бер бәйрәм истә калган. Республикабыздагы иң өлкән иҗат коллективларының берсе — Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры артистлары Хәким ага Сәлимҗановның һәм Галия ханым Нигъмәтуллинаның алтын туйларын үткәрделәр. Туй булгач, туйдагыча иде. Котлаулар, изге теләкләр. Бәлки бу котлауларда, яшьләр туендагыча чәчрәп торган шатлык-шаяруларга караганда, өлкәннәргә карата сабыр ихтирам күбрәк булгандыр. Нишләмәк кирәк! Аның каравы, бу туй икенче бер ягы белән аеруча игътибарга лаек: бөтен аңлы гомерләрен театрга багышлаган бу мөхтәрәм кешеләрнең шәхси тормышларындагы зур вакыйга театрның үз тарихындагы дата — аның җитмеш еллыгы белән бер вакытка туры килде.

Һәр кешенең — картмы ул, яшьме, даны ерак таралганмы, әллә ул гомере буе, кеше күзенә артык чагылмыйча, тыйнак кына эшләп йөргәнме — ике биографиясе була: берсе — шәхси биография, икенчесе — халык белән уртак биография. Ләкин: «минем тормышымның һәр көнендә һәм һәр сәгатендә мине тудырган халкымның язмышы чагылды» дип барыбыз да әйтә аламы соң? Ә менә Хәким ага Сәлимҗановның һәм Галия ханым Нигъмәтуллиналарның шулай дип әйтергә хаклары бар.

Галия ханым татар профессиональ театры туган елны, ишан-муллалар беренче актерлар өстенә бар белгән бәддогаларын яудырган елны дөньяга килгән. Ә Хәким ага ул елны өч яшендә булган. Алар бу коллективка, театр училищесының беренче чыгарылыш актерлары буларак, 1926 елда бергәләп киләләр. Бергәләп милли сәнгатебезне үстерәләр. Туган йортлары булып киткән театрны профессиональ осталык, иҗат осталыгы үрләренә бергәләп күтәрешәләр. Театр яшь вакытта алар да

яшь булалар. Ә үзләренең алтын туйларын республикабыздагы милли театрларның иң өлкәненә 70 яшь тулганда, ул чын мәгънәсендә профессиональ өлгергәнлек дәверен кичергәндә билгеләп үттеләр.

Казанның данлы үткәне, бүгенге казанышлары, иртәгәге планнары, хыяллары турында күп язарга, күп сөйләргә мөмкин. Мин биредә үзем белгәнне, үз йөрәгемә якын һәм кадерле булганны гына яздым. Икенче берәүләр бүтәнчә язар, бүтән нәрсәләр турында сөйләр, шәһәрнең тышкы кыяфәтендәге һәм рухи тормышындагы бүтән нәрсәләрне күрер һәм тасвирлар бәлки.

Теләк шул: бу язмаларым һәм күзәтүләрем шәһәребезне, аның тарихын өйрәнеп-белү эшенә кечкенә генә өлеш булып керсеннәр иде. Аларны укып, кешеләрдә тагын да күбрәкне белү, күбрәк нәрсәне ачыклау теләге тусын иде.

Казанның борынгы гербында елан сурәте төшерелгән. Риваятьләргә караганда, ул елан бүген шәһәр урнашкан урыннардагы хәзинәләрне саклаган, анда ят кешеләрне җибәрмәгән.

Борынгы язмаларның берсендә мондый юллар бар:

Хәтта якын киләлмәгән кешеләр
Яткан җиренә явыз аждаһаның,
Читтән, урап узганнар гел куркып
Дәһшәт белән ыславыннан аның.

Минемчә, Мәскәүдәге Казан вокзалы бинасының иң биек җиренә архитектор Щусев куйдырган елан сурәтен күрмәгән кеше сирәктер. Елан Уралга һәм Себергә, Урта Азиягә һәм Идел буена китүчеләрне озатып кала, аннан килүчеләрне каршы ала. Хәзер шул елан төшерелгән шәһәр гербы кешенең чиксез иҗади мөмкинлекләре символы булып гәүдәләнә. Кешеләр ул аждаһадан куркып калмаганнар, аны җиңгәннәр һәм элек ул хакимлек иткән җирдә бүген могҗизалар тудыралар.

**Р. И. Нәфиков,**
тарих фәннәре докторы, профессор

# БЕРЕНЧЕЛӘР БЕРЕНЧЕ САФЛАРДА

Идел буенда да азатлык хәрәкәтендә революцион традицияләрнең дәвамчанлыгы зур әһәмияткә ия булган. Самодержавиегә каршы гомумроссия көрәшенә периферияне дә катнашын тәэмин итеп, бөек рус революцион демократларының шәкертләре «заманнарның җанлы бәйләнеше»н саклап килгәннәр. Илнең барлык почмакларыннан яшьләрне үзенә җыя килгән һәм Ватанга бөек галимнәр генә түгел, бәлки күренекле революцион эшлеклеләр дә биргән Казан университеты бу процесста зур роль уйнаган. I Интернационалның Рус секциясе барлыкка килүгә Казан революцион подпольесы аның белән, соңрак исә барлык марксистик түгәрәкләр һәм төркемнәр, беренче эшче союзлары белән бәйләнеш урнаштырган. Җирле подпольеның дәрәҗәсен бу һичшиксез күтәрә, ә вакыты-вакыты белән, кайбер объектив шартлар уңаеннан, марксистик чорга кадәр аны гомумроссия масштабында җитәкчелек югарылыгына менгерә.

Көрәштә күренекле урында студентлар да була.

XIX гасырның 80 нче еллары икенче яртысында революцион студентлар патша хөкүмәте политикасына, «йөгәнсез, бөтенләй мәгънәсез һәм ерткыч реакция» хакимлегенә каршы (В. И. Ленин. Әсәрләр. Дүртенче басмадан тәрҗемә, I том, 284 бит) ачыктан-ачык чыгыш ясаучы реаль көч булып танылa. Мөстәкыйль фикерләүче студентлар, шушы акыл хезмәте пролетарийлары белән Н. Е. Федосеев, А. М. Горький, В. И. Ленин биографияләре тыгыз бәйле.

Ленинның 1887 елда студентлар хәрәкәтендә катнашына кагылышлы истәлекләрендә А. И. Ульянова: «Народная воля» инде тар-мар ителгән, Россиядә әле социал-демократик партия туып өлгермәгән һәм әле халык массалары көрәш аренасына чыкмаган шушы торгынлык һәм билгесезлек елларында, җәмгыятьнең башка катлауларындагыча, канәгатьсезлек хисе кимемәгән һәм аерым кабынып китүләр күренгәләп торган бердәнбер катлау студентлар катлавы иде»,— дип язды. (А. И. Ульянова-Елизарова. Воспоминания о Ленине. I часть. М., 1956, стр. 18.)

Россия студентларының чыгышларын кузгатырлык хәлләр 1887 елның көзендә шактый күп була. Укучы яшьләр 1884 елда университетлар өчен яңа реакцион устав һәм 1887 елда «кухарка балалары» турындагы циркуляр кертелү уңаеннан катыланып киткән полиция режимы кысаларында тончыга иде.

Казан студентлары рус революцион хәрәкәтендә һәрчак күренекле урын алып торды, революцион яшьләр отрядларының иң алдынгы сафларында булды. Казан университетында 1887 елның 4 декабрендә булган сходка-демонстрация, кайбер башка шәһәрләрдәге кебек үк, бөтен Россия студентларының демократик катлаулары туплана баруын күрсәтте һәм гомумроссия демократик хәрәкәтенең бер өлеше булды.

Сходкага 17 яшьлек Владимир Ульянов актив катнашты, һәм ул аның революцион эшчәнлек юлында беренче тапкыр көч сынап каравы булды.

Казан подпольесында ул чакта А. Желябовны, Н. Кибальчичны, С. Перовскаяны, И. Мышкинны, В. Фигнерны шәхсән белгән кешеләр — аларның фикердәшләре яшәгән. Шундыйлар арасыннан С. Перовскаяның дусларын — О. Сахарова белән С. Субботинаны аерып күрсәтергә кирәк. Алар «Хезмәтне азат итү» группасы члены Дейчның Казанда яшәгән бертуган сеңелесе М. Фесенко-Пеньковская белән таныш булганнар, Петербургтагы элекке яшерен хәрби оешма җитәкчесенең сеңелесе О. Сухановны белгәннәр. Шәһәрдә шуннан уездларга сөрелгән «зарарлы кешеләр» — А. Корнилова-Мороз, В. Зотова-Яковлева һәм башкалар яшәгән.

Аларның Петр Алексеев, Софья Перовская турында сөйләүләре яшьләр күңеленә тирән эз салган, аларны яңа батырлыкларга өндәгән. В. Н. Фигнерның туганнан-туганы Ю. Головня В. Ульянов белән бергә 1887 ел 4 декабрь сходкасында катнашкан. О. И. Сахарова белән бер фатирда Казан яшерен оешмасының күренекле эшлеклесе И. П. Чарушников яшәгән, аның сеңелесе Клавдия Софья Субботина белән дус булган.

Казанда үз вакытында Одессада (1875 ел) «Эшчеләрнең көньяк рус союзы» членнары белән элемтәдә торган Ф. М. Цомакион яшәгән, биредә ул революцион яшерен оешма членнары П. Неволин, А. Жарков һәм башкалар белән дуслык мөнәсәбәтләрендә булган. Шуларның танышы М. П. Четвергова фатирына студент В. Ульянов килеп йөргән.

Яшерен революцион эштә Идел буендагы рус булмаган җирле халыклар вәкилләре катнашы да сизелерлек: Казан подпольесында Герман Лопатинның яхшы танышы Салигаскар Муратов эш алып барган, А. М. Пешков, З. Невзорова, Л. Красиннарның дусты Гөлсем Алкина булган. 70 нче еллар революционерлары бертуган Аитовларның туганнары аларның эшләрен 80 нче елларда да, 90 нчы еллар башында да дәвам иттерәләр. Алар Россиядә революцион хәрәкәтнең күренекле эшлеклеләре — апалы-сеңелле бертуган Фигнерлар, II Интернационалның оештыру конгрессында катнашкан М. П. Лебедева белән бәйләнештә торганнар[1]. Шулай ук Казандагы яшерен революцион оешма эшендә катнашкан, В. И. Ульяновның ветеринария институты буенча иптәшләре белән студент Хәсән Акъегетов (язучы Муса Акъегет-Задәнең бертуганы) таныш булган. Сходканы оештыручыларның берсе Н. А. Мотовилов белән мордва укытучысы Григорий Ульянов дуслык мөнәсәбәтләрендә торган. Казан университетындагы 1887 ел 4 декабрь сходкасында башкорт Мирсәяф Бишев катнашкан.

Казан подпольесының С. Степняк-Кравчинский белән дәвамлы һәм тыгыз элемтәсе булуы билгеле. Казан университеты каршындагы акушерлар курсларында тыңлаучы З. Ф. Плетневада Степнякның «Подпольедагы Россия» дигән китабы булган һәм ул аны дус-ишләренә укырга биреп торган. Лондон белән Казан «нигилистлары» арасында хатлар йөргән. 1887 ел 4 декабрь сходкасында катнашкан В. Васильевның агасы шулай ук Лондон эмигрантлары белән язышкан, В. Васильев аркылы Н. Е. Федосеев китаплар алып торган.

Шунысы да игътибарга лаек: Н. Е. Федосеев белән бер класста В. И. Ленинның туганнан-туганы Владимир Ардашев укыган. Ул гына да түгел, шул ук класста Ульяновларның тагын бер туганы — Николай Веретенников белем алган. В. И. Ленинның энесе Д. Ульянов та шул ук гимназиядә укыган.

В. И. Ульянов, Н. Е. Федосеев, А. М. Пешковның карашлары «җирле» шартларда формалаша. Ә бу шартлар башкалалар, илнең башка төбәкләре һәм революцион эмиграция белән дә бәйле киң Идел буе районын эченә ала. 80 нче еллар азагына таба революцион хәрәкәттә К. Маркс һәм Ф. Энгельс идеяләре, беренче марксистик түгәрәкләр эшчәнлеге, Париж Коммунасы һәм Бөтенроссия эшчеләр союзлары тәэсире сизелерлек көчәя.

Казан студентлары А. И. Ульянов группасы белән аның гимназия буенча классташлары Д. Гончаров, В. Волков, В. Бурлаков аша бәйләнеш тоталар. Сходкада катнашкан С. Ферафонтов җирдәшлек (землячество) китапханәсен Бурлаковтан кабул итеп ала.

Группа А. Ульяновны кулга алу уңае белән прокламацияләр чыгара, соңрак, аны җәзалагач, листовкалар бастырып тарата. Революцион эчтәлекле өндәмәләрне Советлар Союзы Герое Д. М. Карбышевның бертуганы В. Карбышев та яза. Тагын шунысы да игътибарга лаек: 1887 елның 4 декабрь сходкасында В. И. Ленин белән бергә шул группада катнашкан М. Листов та булган.

Казан университетына лекцияләргә Владимир Ульянов 1887 елның 25 августында йөри башлый. Аның 1887 ел 4 декабрь сходкасына кадәр студентлар хәрәкәтендә катнашуы хакында сүз алып барганда, шуны әйтергә кирәк, бу катнашу ике юнәлештә булган. Бер яктан, җирдәшлектә актив катнашу, икенчедән, властьлар тарафыннан «искиткеч зарарлы юнәлештәге» дип саналган Мотовилов-Богораз-Скворцовлар

---

[1] Аитовларның берсен — Исмәгыйльне, А. Орлов-Соколовский (Ольга Ильиничнаның укытучысы) оркестрының беренче скрипкачысын, Казан операсын тыңлаган Владимир Ильич, әлбәттә, белгән.

яшерен түгәрәгендә эшчәнлек күрсәтү. Анда революцион әдәбият, шул исәптән марксистик әдәбиятны, аеруча К. Маркс «Капитал»ының беренче томын өйрәнәләр. Алдынгы карашлы аерым эшчеләр белән бәйләнеш урнаштырыла. 1888 елда П. Е. Столяровның дус эшчесе М. Голубевны тентегәндә сходкада катнашучыларның гектографта басылган листовкалары табылуы шуңа бик ачык дәлил булып тора.

В. Ульянов Казан университеты галимнәре белән горурлана. Абыйсы Саша кебек үк, студент Владимир табигать фәннәре белән кызыксына, Д. И. Менделеевның «Химия нигезләре»н өйрәнә. Студент Ульяновның мондый кызыксынулары махсус тикшерүне сорый, чөнки, инде билгеле булганча, В. И. Ленинны атомның бүленеше идеясе кызыксындыра, яшүсмерне дөньяның күренекле табигать галимнәре эшкәртә башлаган проблемалар җәлеп итә. В. И. Ленинның соңыннан «Материализм һәм эмпириокритицизм» исемле хезмәтендә әйтелгән даһи ачышлары, күрәсең, проблеманы дистә еллар өйрәнү нәтиҗәсе. Әлбәттә, без боларның барысын да В. И. Ленинның яшьлек шөгыльләренә кайтарып калдырырга һич теләмибез. Әмма бу идеяләр аны шул чакта ук һичшиксез кызыксындырган һәм моны, әлбәттә, махсус өйрәнергә кирәк.

Самодержавиегә каршы көрәш исә аны бөтен барлыгы белән үз дулкынына бөтереп ала. Сембер — Самара җирдәшлеге Владимир Ульяновны шундый оешмаларның союз советына үзенең вәкиле итеп сайлый. Беренче курс студентына мондый җаваплы эш тапшыру сирәк күренеш булуын да әйтергә кирәк.

80 нче елларның икенче яртысында студентлар патша хөкүмәтенә каршы ачыктан-ачык чыгышларын дәвам иттерәләр. Казан студентларының да ачуын китергән сәбәпләр, әйткәнебезчә, күп була. 1884 елда университет автономиясе бетерелә, сходка һәм җыелышлар законнан тыш дип игълан ителә, студентларның җәмгать оешмалары тыела, шпион инспекторларның хокуклары киңәйтелә.

Шымчылык итү һәм эзәрлекләүләргә карамастан, яшьләр актив көрәшәләр. 1887 елның 5 ноябрендә университетның чираттагы еллыгына багышланган рәсми тантаналы актка бойкот ясала. Владимир Ульянов та тантанада катнашмый.

Бәйрәмне өзү студентлар чыгышларының башы була, соңгы көннәрдә алар ешая, киңәя бара.

Мәгълүматлар күрсәткәнчә, сходка уздыру мәсьәләсе университет студентлары судында хәл ителә. Шушы вакыйгаларны әзерләүдә Л. Балль һәм А. Амбарова зур роль уйный. Шунысы да мәгълүм: алар Сембер студентлары белән якыннан таныш булалар һәм аларны яшәп килгән тәртипләргә каршы эшләргә өндиләр (жандарм полковнигы Гангардт күрсәтмәсе).

Сембер — Самара җирдәшлеге Владимир Ульяновка уңай тәэсир ясамый калмый. Аның эшендә социал-демократлар түгәрәге члены, Петербургтан куылган Анна Амбарова, Александр Ильич Ульянов белән янәшә торып 1886 елның 17 ноябрендә атаклы Добролюбов демонстрациясендә катнашкан. Юлия Белова катнашалар. Бу түгәрәк әгъзалары Казан студентлары арасында марксистик әдәбият тараталар, укучы яшьләрнең хөкүмәткә каршы чыгышларын әзерлиләр.

1887 елның 1 декабрендә Воротников өендә университет һәм ветеринария институты җирдәшлекләренең яшерен киңәшмәсе була, анда мәскәүле студентлар да катнаша. 4 декабрь сходкасын әзерләүдә һәм үткәрүдә бу киңәшмәнең роле гаять зур. Анда демонстрациянең программ документлары: прокламацияләр һәм петицияләр тикшерелә, сходканы үткәрү көне билгеләнә. Бу җыелышта Владимир Ульянов үзенең җирдәшлеге һәм Мотовилов-Богораз-Скворцов түгәрәге вәкиле буларак катнаша. Алдан ук әзерләнгән прокламацияләрне, петицияләрне тикшергәч, гектографта басып күбәйтәләр һәм студентларга тараталар. Ул документлар сходка көнендә аларның кулларында була. Петиция тексты 3 декабрьда раслана.

В. Ульяновны яшерен рәвештә күзәтеп киләләр. Аның ноябрьда дәресләрне калдыруы, тантаналы актта катнашмавы искә алынган була. Округ попечителе Масленников, инспекция мәгълүматларына нигезләнеп: «Сходкага кадәр ике көн алдан ук үзеннән ниндидер начарлык әзерләүдә шикләнергә мөмкинлек бирде: аеруча шикле студентлар белән әңгәмә корып, вакытын тәмәке тартучылар бүлмәсендә үткәрде, өенә кайтып, кабат әйләнеп килде, башкалар үтенече буенча нәрсәдер алып килде һәм гомумән үзен бик сәер тотты», дип яза.

Сходка әзерләнүе шымчы студент тарафыннан ачылган була һәм властьлар саклык чаралары күрәләр: студентларны күзәтү көчәйтелә, хәрби частьларның дежур торуы билгеләнә.

Шулай да сходка башлана. Беренче курста укучы бер төркем юрист-студентлар сәгать 11 дә тәмәке тарту бүлмәсенә җыела. Владимир Ульянов та шулар арасында була. Бу хәл инспекцияне алай ук борчымый, чөнки сәгать 12 дә ректор-профессор И. А. Кремлевның рим хокукы буенча лекциясе башланырга тиеш була.

Сәгать уникеләрдә берничә студент тәмәке тарту бүлмәсеннән университет вестибюлена чыга. «Әзер!» дигән чакыру авазын ишетеп, алар «Сходкага!» дип кычкырып актлар залына юнәләләр. Кайбер студентлар лекцияләр бара торган аудиторияләрдән бүтән студентларны да чакырып чыгаралар. «Залга!», «Ура», «Ректорны — бирегә!», «Инспекциянe — долой!», «Туганнар, иптәшләрнең хаклы эше өчен торыйк!» дигән чакыру авазлары ишетелә.

Демонстрациячеләр ике төркемгә бүленә. Берсе Каменский, Аргентовский һәм Огородников җитәкчелегендә, залга керер өчен, геология кабинетына юнәлә. Бик күп студентларны иярткән икенче төркемне Ульянов, Полянский, Подбельский җитәкли. Әмма ишекләр бикле була. Студентлар, аларны ачып, залга кереп тулалар. Сходка башланып китә. Бу вакытта университет каршында өч йөзләп кеше җыелган була.

Залга инспекция хезмәтчеләре белән берлектә Потапов килеп керә һәм студентларга таралышырга боера, югыйсә, полиция чакыру белән яный. Бу хәл студентларның ачуын тагын да кабарта төшә, чөнки аны алар, реакцион университет уставын тырышып яклаганы һәм шул тәртипләрне урнаштырганы өчен, болай да яратмый торган булалар.

Кемдер шул чак «кыйна!» дип кычкыра һәм беренче курс студенты Алексеев инспекторның яңагына сугып ала. Студентлар инспекторны камыйлар. Потапов залдан көч-хәл белән чыгып кача. Бу бәрелеш аның күңелендә озакка уелып кала. Бер елдан соң, студентларга характеристика биреп, Потапов: Кузьма Ионов һәм Сергей Полянский дигән студентларның да аны хурлау хәрәкәтләренә әзер булуларын әйтә. Архив мәгълүматларыннан күренгәнчә, бер Алексеев кына түгел, бәлки барлык студентлар диярлек, кулларында сынган урындык һәм кәнәфи аякларын тоткан хәлдә, Потаповны залдан озатып кала.

Инспектор белән бәрелеш барган чакта залга клиникадагы студентлар килеп керә. Сходкада катнашучыларның саны икеләтә ишәя. Сходка комитеты төзелә, петиция һәм «җәмгыятькә» мөрәҗәгать укыла һәм аларны шундагы барлык студентлар кайнар яклый.

Сходкага ветеринария институтының йөзләгән студенты килеп кушыла. Алар да үз ректорларына петиция биргән булалар. Университетта аларны шатлыклы авазлар белән каршылыйлар. Барысы бергә зур күтәренкелек белән «Хвала тому, готов кто к бою» дигән студентлар җырын җырлыйлар. Ул җырны шушы сходкада катнашучы студент Виктор Воробьев чыгарган була.

Җырдан соң чыгышлар башланып китә. Залга ректор Кремлев, аның белән бергә медицина факультеты деканы Щербаков, профессорлар Штукенберг һәм Васильев керәләр. Алар студентларны тынычланырга берничә сәгать буена үгетлиләр, ләкин уңышка ирешә алмыйлар. Шул арада залга студентларның сөекле профессоры Преображенский керә һәм университет тәртипләренә ризасызлык белдереп бирелгән үтенеченең канәгатьләндерелүен — үзенең отставкага чыгуын хәбәр итә. Студентлар профессорның бу хәбәрен алкышларга күмәләр.

Хөкүмәткә каршы юнәлдерелгән бу сходка-демонстрация дүрт сәгатькә сузыла. 3 сәгать 45 минутта ректор округ попечителенең залны полиция ярдәмендә бушатырга әмерен ала. Кирәге чыкса, гаскәри часть көченнән файдаланырга тәкъдим ителә.

Ректорның шушы хактагы хәбәрен ишеткәч, кан коеш китереп чыгармас өчен, студентлар залны бушаталар. Китешли алар үзләренең студентлык билетларын ташлап калдыралар. Шундый 99 студентның берсе Владимир Ульянов була. 4 декабрь кичендә укыту округы попечителе кушуы буенча университеттан куылырга тиешле студентлар исемлеге төзелә. Университеттан шунда ук 39 студент, шул исәптән Владимир Ульянов та, ветеринария институтыннан 36 студент чыгарыла. Владимир Ильич, үзен университеттан куууларын белмәгән килеш үк, аннан чыгаруларын сорап гариза яза. Барлыгы 40 кеше кулга алына. Шул ук төнне Владимир Ульяновны да кулга алалар.

Соңрак, тәмамланмый калган автобиографиясендә В. И. Ленин болай дип язган: «1887 елның декабрендә студентлар чуалышында катнашкан өчен Казан университетыннан чыгарылдым һәм, кулга алынып, Казаннан сөрелдем» (В. И. Ленин. Полн. собр. соч., т. 32, стр. 21). РКП(б) ның XI Бөтенроссия конференциясе делегаты шәхси анкетасын тутырганда, революцион эшчәнлек өчен репрессияләргә юлыктыгызмы (кайчан) дигән сорауга җавап рәвешендә: «1887 елда кулга алыну һәм сөрелү, берничә көн төрмәдә утырдым», дип язган (Ленинский сборник, XXXVI, стр. 374—375). Владимир Ильичның шулай искә алуы студентлар хәрәкәтендә катнашуның үзенең революционер буларак җитлегүендә мөһим роль уйнавын тануы һәм биографиясенең мөһим чоры итеп раславы була.

Студентларның 1887 ел 4 декабрь сходкасында Россиядәге күп төрле милләт һәм халык вәкилләренең: руслар, белоруслар, украиннар, грузиннар, башкортлар, әрмәннәр, еврейлар, немецлар һәм башкаларның катнашуын ассызыклап билгеләп үтәргә кирәк. Сходкада катнашучылар арасында сөрелгән полякларның уллары — Воротынский Бронислав (Тобольск гимназиясен тәмамлаган), В. Н. Фигнерның туганы Головня Георгий, Каминский Владислав (Томск гимназиясеннән), шулай ук Пежарский Болеслав-Владислав (Слуцк гимназиясеннән), бертуган Демьян-Владислав һәм Людвиг-Вацлав Цыглерлар, литвалы Мартинкус Яков һәм Купревич Николай булган. Бу фактлар сходкада катнашучыларның әйдәүче төркеменең политик һәм әхлак йөзләрен тулырак тасвирларга, әеруча студент В. И. Ульяновның танышларын, иптәшләрен, фикердәшләрен ачыкларга мөмкинлек бирә.

Казан студентлары сходкасының илнең башка шәһәрләрендә һәм университет-

ларында нинди яклау табуы әлегә аз өйрәнелгән. Кимендә 15 губернада һәм 60 шәһәрдә — Минскидан Тобольскига һәм Астраханьнан Вяткага кадәр җирләрдә сходкага караган документлар табылды. Бу «декабристларның» тавышы, әйтеп үтелгәнчә, чит илләргә дә ишетелгән.

1887 елның 22—24 ноябренда Мәскәүдә, 2 декабрьда Новороссийск университетында, 3 декабрьда Харьковта һәм 4 декабрьда Казанда сходкалар булуы турында хәбәрне бөтен ил укучыларына «Вестник Европы» журналы җиткерә. «Свет» һәм «Гражданин» газеталары кебек рәсми органнардан, аларның студентлар чуалышларының сәбәбен «чит ил интригасы» һәм «бушбугаз педагоглар»ның пешмәгәнлеге белән аңлатырга маташуларыннан редакция ачы көлә. Бу фактлар, безнең карашыбызча, 80 нче елларда революцион хәрәкәтнең аз өйрәнелгән якларын ачыкларга мөмкинлек бирә. Алар ярдәмендә Казан университетында 4 декабрь сходкасының тәэсирен, революцион листовкалар һәм прокламацияләр таралуын күзалларга мөмкин. Шулай ук, язылганнардан күренгәнчә, сходканы әзерләүдә һәм үткәрүдә Сембер гимназиясен тәмамлаган укучыларның роле зурлыгы раслана.

Казанлыларның беренче марксистик группалар белән бәйләнеше булуын, аларның мөстәкыйль карашлы студентларга тәэсирен дә билгеләп үтәргә кирәк. Сходкада катнашкан 23 кеше тиз арада Н. Е. Федосеев түгәрәкләренә керә һәм «Хезмәтне азат итү» группасы белән бәйләнеш урнаштыра. Кайберләре Берлин һәм Польша чиге аша Россиягә яшерен әдәбият кайтаруны җайга сала. Аларның бер өлеше соңрак көрәшне большевиклар партиясендә дәвам иттерә. Сходкада катнашкан Н. Шемаев белән гимназист Н. Бауман дуслык мөнәсәбәтләрендә тора.

Нинди искиткеч күренеш булган 1887 ел! Шул ук елны дөнья күргән «Иванов» пьесасында А. П. Чеховның «авыру заман» интеллигенциясе язмышы турында уйланулары гыйбрәтле. Безнең замандашыбыз О. Кучкина бик дөрес әйткәнчә, пьесада җәмгыять килеп төртелгән тупик, революция юлы белән генә чишелергә мөмкин булган ситуация чагылдырыла.

Өч бөек кеше, Казаннан өч егет: Владимир Ульянов, Николай Федосеев, Алексей Пешков шушы хәлдән чыгу, дөрес революцион хәрәкәт юлын эзлиләр. Аларның берсе җиңү сәгатенә кадәр яши алмады. Ә бит сходкадан соң 30 ел үткәч, бөек Октябрь социалистик революциясе җиңде. Аның юлбашчысы В. И. Ленин, беренче язучысы А. М. Горький булды. Алар яшьлек елларыннан ук беренче сафларда беренчеләр иделәр.

Казан университеты үзенең фәнни һәм революцион традицияләрен кадерләп саклый, аларны һәр яңа буын хезмәте белән баета бара. Һәр елны 16 декабрьда Актлар залында шәһәр югары уку йортлары студентлары һәм бөтен илебез студентлары вәкилләренең очрашуы уздырыла. Яшьләр тантаналы төстә һәр вакыт Ленинча укырга, яшәргә һәм көрәшергә сүз бирәләр һәм вәгъдәләрендә нык торалар. Университетның Ленин мемориалында дөньяның йөздән артык иленнән дүрт миллионнан артык кеше булып китте.

*Мохтар Әүэзов хаклы рәвештә казакъ совет әдәбиятын башлап җибәрүче иң күренекле әдип, социалистик ватанга армый-талмый хезмәт иткән җәмәгать эшлеклесе булып санала. Алай гына да түгел, ул безнең Тукайлар, Ибраһимовлар шикелле, илебезнең төрки һәм башка тугандаш халыкларының иң яраткан язучыларының берсенә әверелде. Аның әсәрләреннән иң әһәмиятлесе булган «Абай» романының беренче кисәге татар телендә инде күптән басылып чыкты, ә соңгы елларда бездә аның берничә хикәясе тәрҗемә ителде. Үз чиратында М. Әүэзов үзе дә тугандаш халыклар әдәбиятларыннан өйрәнде. Үзенең күп мәртәбәләр әйтүенә караганда, татар әдәбияты, татар әдипләре аның төп укытучысы булган.*

*1897 елның 28 сентябрендә Казагыстанның Семипалат өлкәсе Чыңгыз өязендә күчмә казакъ гаиләсендә туган Мохтар яшьтән үк белемгә, русча укуга омтылучы бала була. Шуңа ул Семипалатка барып биш классны рус мәктәбен тәмамлый, укытучылар семинариясенә керә. Революциядән соң, укуга, яңача тормыш коруга аеруча дәртләнеп киткән Мохтар Ленинград университетының тарих-филология факультетын тәмамлап, Ташкенттагы Урта Азия халыклары университетында аспирантурада укый.*

*Мохтар Әүэзов беренче әсәре булган пьесасын 20 яшендә, ягъни утлы 1917 нче елда яза. Шуннан соң аның киң колачлы, продуктив һәм талантлы әдәби эшчәнлеге башлана. М. Әүэзов үз гомерендә бик күп хикәяләр, повестьлар, пьесалар, мәкаләләр язды. «Абай» романы язучыны бөтендөнья аренасына алып чыкты. Бу роман 1949 елда партиябез һәм хөкүмәтебез тарафыннан Беренче Дәрәҗә Дәүләт премиясенә лаеклы дип табылды.*

*Быел көз илебез җәмәгатьчелеге Мохтар Әүэзовның 80 еллык юбилеен уздырды. Шул уңайдан редакция укучыларыбызга язучының бер хикәясен тәкъдим итә.*

**Мохтар Әүэзов**

# ӨЙЛӘНҮ

ХИКӘЯ



Көн урталары. Һава тын, эссе. Күк йөзендә ник бер болыт кисәге күренсен: көн аяз, кояш нәкъ баш түбәсендә туктап тора сыман. Сулыш алырлык та түгел, бөркү һава. Я алла, талгын гына җил исеп куйгаласа бит, әлсерәгән тәннәргә нинди рәхәт булыр иде!

Мондый көндә ышыкта ятуың хәерле. Зур, иркен ак тирмәдә утыруы тагын да рәхәтрәк. Әз генә җил йөрсен дип ишек белән төннек өстендәге киезләрне кайтарып та куйсаң, һава бөркүлеген бөтенләй дә сизмисең.

Байбосын Хаҗи авылы әле шушы көннәрдә генә бу җәйләүгә күчеп утырды. Биредә көтүлекләр иркен, тугайларда үлән мул, су күп. Еракта күкшелләнеп утырган биек таулардан башланган елгачык бу тирәгә килә-килә киңәя, зурая, акрыная. Талгын сулы елга ярына сибелеп утырган ак тирмәләр, анда-санда күккә күтәрелгән сыек төтен күңелләрне җилкетеп, үзенә тартып тора сыман.

Әйе, Хаҗи бай авылы, башка ырудашларыннан аерылып, читләшеб-рәк, бу тирәнең иң бай, иң яхшы җәйләвенә килеп утырган иде. Кая карама — байның ишле малы, көтүләре булыр. Текә ярлы елга артындагы сөзәк калкулыкларга күтәрелү белән Хаҗи авылының ун тирмәсе күренер. Аларның бишесе зур, ак тирмәләр: берсе Байбосын Хаҗиның үзенеке, икесендә аерым чыккан ике улы. Ә дүртенчесендә, матурлап, бизәкләп сугылган яңа киезле биш канатлысында, байның кызы. Авыл — туй көтә. Бай кызы — туй кәләше. Ә бер читтәрәк шундый ук зур йортны буласы кияүгә дип куйганнар. Ә инде бер-беренә сыешыбрак утырган ике-өч кенә канатлы кечерәк тирмәләр — байның ярлырак кардәшләре белән ялчыларыныкы булыр.

Киез өйләрдән ике йөз адымнар читтәрәк ат бәйләр өчен баганалар утыртылган. Тик әлегә ат заты анда күренми, бәйдә берничә колын гына. Дәү атлар су буенда. Төркем-төркем өерелешкәннәр дә елга эченә үк кереп басканнар. Ни чыдам ат хайваны да түзми шул бу эссегә. Хәер, атларга кешеләргә караганда да авыррак: кигәвен дә интектерә аларны. Ул бызылдыклардан һич ничек котыла алмый малкайлар. Атларның бер өше суга сырттан ук кереп баскан. Шулай да тынгылык юк мескенгә. Теге бәйләнчек затларны әле пошкырып, әле баш чайкап, сырт буена койрык белән шап-шоп суккалап куркытырга туры килә.

Сыерларга исә атлардан да яманрак әлегә. Сыер малы үзе дә түземсезрәк шул, эссене дә, суыкны да алар авыр кичерәләр. Кигәвен аларның җан дошманы, тәмам шаштыра ул аларны. Кигәвеннең быз-быз итеп килүен ерактан ишетеп алу белән сыерлар нишләргә белми котырына башлыйлар, шуннан бер түземсезрәге койрык чәнчеп я авылга, я суга таба чабарга тотына. Башкалары аңа иярә.

Бүген дә, эсседән һәм кигәвеннән котылырга теләп, атлар да, сыерлар да суга кереп баскан, тын гына торалар иде.

Ә авылда исә, киресенчә, көтелмәгән бер җанлылык сизелә. Шулай булмый ни, кичә кич бит бирегә кияү үзе килеп төште. Яучы һәм якыннары белән килде кияү. Шуңа күрә тышта никадәр генә эссе булмасын, җәйләү халкы иртәдән үк аяк өстендә. Яшь-җилкенчәкнең, аеруча яшь килен белән яшь кызларның йөзе шат, күңелләре хуш күренә. Кияү чатырының киез ишеге бер дә төшеп тормый: берсе керсә, икенчеләре чыга. Байбосын авылыннан гына түгел, якын һәм ерак авыллардан килә кешеләр кияү белән танышырга дип. Иртәдән бирле килгән-киткәннең сөйләшкән, көлешкән авазыннан җәйләү тынмый. Олысы-яше, кызыкилене кияүне хөрмәтләп сүз әйтә, туйны котлый.

Байның киенеп-ясанып алган үз киленнәре дә, аларга булышчы кызлар да кияү тирмәсе тирәсендә. Туктаусыз кереп-чыгып йөриләр, кадерле кунакларны сыйлыйлар. Тик әлегә кияүнең үзенең дә, кияү егетләренең дә җәйләүдә күренгәннәре юк: яңа кымыз, уен-көлке, шаян сүз белән юанып өйдә утыралар. Инде ничә табак кымыз чыгарылганын да хәтерләүче юк. Савытлар бушый тора, кымыз өстәлә бара, телләр язылә төшә, сүз-бәхәсләр куера бара. Егетләрнең кызураклары инде әңгәмәдән эзләп табынның бер очыннан икенче очына җиткәннәр. Менә берәү кулына домбра алып кылларын чиртә башлады, аннары салмак кына итеп нечкә, йомшак тавышы белән көй сузып, җырлап җибәрде. Тирә-якка мәгълүм җырчы Матай тавышы иде бу. Аны әйтер сүзенне онытып, онытылып тыңламый мөмкин түгел!

Бу күңелле шау-шуга бары тик олылар гына катнашмыйлар. Кияү янында булу аларга килешми. Алар авыл кырыенда, су буенда сөйләшеп, хатирәләргә бирелеп утыралар. Бик күбесенең үз-үзен бик дәрәҗәле, эре тотарга тырышуыннан ук боларның бик мөхтәрәм кунак икәннәре чамалана. Аларның Хаҗи бай белән кияүгә хөрмәт йөзеннән генә килгәнлекләрен дә бик белгертәселәре килә. Кияү дә бит бик мөхтәрәм кеше, шушындый ук бай авыл кешесе. Быелгы сайлауларда аның «шир-

кәте» җиңеп чыкты, аның үзен «башкарма» иттеләр. Дөрес, болай карап торышка аның башкалардан бер аермасы да юк: ни батырлык, ни берәр төрле осталык белән алдырмаган. Булган даны да ата даны гына. Әйтәләр бит: «Авызы чалыш булса да, бай баласы һәр чак туры, хак сөйли», — дип.

Кияү бүген, булган бу дан-дәрәҗәләрем генә җитмәсә дигән кебек, үзе белән Усман түрәне дә алып килгән. Ә инде сайлау «йоласын» белгән һәркем Усман түрәнең Касыймны «башкарма» итүдәге өлешен аңлый иде. Гап-гади бер мөгаллим генә булса да, Усман түрәнең инде бу дүртенче өяз башлыгын күтәрүе иде. Әнә бит шуңа күрә Касыйм да аның алдында ничек кенә яхшы атлы булырга белми, җаена туры килсә дә, килмәсә дә, һаман мактарга гына тора. «Усман түрәдән дә галим кеше юк бездә» дип җибәрә. Касыйм «башкарма» үзе дә остазыннан күп нәрсәне отып калмакчы. Аңа бигрәк тә остаз түрәнең үз-үзен кешеләр белән тотышы ошый. Үзен Усман шикелле үк дәрәҗәдә тоткан бер генә бай түрәне дә әле аның күргәне булмады. Менә ичмасам түрә! Әлбәттә, Усманның кияү егете булып килүе туйны бермә-бер күтәрәчәк иде. Шул өмет белән чакырды да инде Касыйм аны үзе белән.

Дөрес, Усман түрәнең бер кимчелеге дә бар, ул дала тормышын белеп бетерми. Әмма «казакъ халкына булган мәхәббәтен» истә тотып, ул Касыйм тәкъдимен кире какмады.

Яңа өяз башлыгы шулай ук изге теләк белән йөри, аның тукаллы, ягъни икенче хатынлы буласы килә иде. Ашына күрә табагы дигәндәй, бу хәлендә аңа Байбосын Хаҗи кызыннан да ким кәләш килешми иде. Шуңа күрә ул аны башта яучылады, ата-анасының ризалыгын алды. Инде үзе килде.

Касыймга хәзер кырык яшь чамасы. Чәчәк авыруы кайчандыр аның бераз битен бозган, шадралаткан иде. Ә болай ул үзе таза гына гәүдәле, дәүрәк башлы ир затыннан. Сыек кына сакалы да бар. Сүзгә артык осталыгы булмаса да, үзен, кирәк чагында, шактый тапкыр кеше дип белә. Әнә бит әле шул тапкырлыгы аркасында ул Усман түрәне тапты... Әйе, Усман түрәне ул нәрсәсе белән алдыргандыр инде. Бәлки остазы әйткән һәр сүзне дөньяның биек ачышы итеп кабул итүе аларны шулай якынайткандыр.

Берникадәр вакыт утырганнан соң Усман түрә йөреп кермәкче булды. Аңа үзенең «адъютанты» һәм башкалар иярделәр. Әмма һава бик бөркү иде. Усман тиз әлсерәде. Ләкин тирмәгә шундук кире кайтып керүне хуп күрмәде. Башкалар ни әйтер, ни уйлар? Әле бит аның авыл белән танышасы бар. Йорттан йортка йөреп киттеләр. Кушәп яткан сарык очраса да, чәбәләп чапкан сыер күренсә дә, бик озаклап, нинди-дер мәгънә эзләгән кебек итеп карап тордылар. Түрә бәйләүдәге колыннарны күреп бөтенләй гаҗәпләнгән итте: «Бу бичаралар ничек түзә эссегә... Бигрәк каты бәгырьле инде безнең казакъ халкы!» — диде.

Урам уртасындагы учак өстендә эремчек кайнатучы карчыкка юлыгу зур вакыйга булды.

— Сез ни кыласыз, гой, кәмпер? — диде түрә, тукталып. Аннары җентекләп бу эшнең ничек башкарылуын сораштырырга керешге. Түрәне озатып килүче егетләр астан гына елмаешып-көлешеп торсалар да, ара-тирә түрәнең сүзен җупләп: «Эремчек-кортсыз булмый инде ул безнең казакъ тормышында»,— диешкәләделәр. Әй, Усман, Усман! Әнисенең дә шулай кайнатуларын, аптыратма дип ара-тирә үзен казан тирәсеннән аш чүмече белән кууларын онытканда лабаса.

Шулай туктала-туктала җәйләүне бер әйләнеп чыккач кына кияү янына кайттылар. Касыйм Усманны көткән икән. Шундук бер читкәрәк чакырып: «Сөйләшәсе сүз бар», — диде. Җиләс һавалы тирмә эченнән чыгасы килми иде. Мәгәр, аулак эзләп, тагын дала карап киттеләр. Авылдан илле-алтмыш адым ераклашкач, чирәмгә утырыштылар. Ка-

сыйм күтәрелеп карамый, киресенчә, дәү бүреген каш өстенәрәк тартып, башын тагын да ия төшеп сүз башлады.

— Түрә! Миңа бик күңелсез хәбәр ишеттерделәр әле. Бер дә күңелгә ятмый торган сүз. Нишләргә? Үзегезгә мәгълүм, мин Байбосын Хаҗиның кызын алдан яучыладым. Ата-анасы миңа ризалык бирде. Калымның да байтак өлеше — аяк малы — аларда инде. Хәзер аптыраган, ата-анага бу хакта белгертүче булгандырмы, юкмы, кызлары миңа кияүгә чыгудан баш тарта, имеш. «Заманалар башка хәзер, без ирекле, ул миңа өмет итмәсен. Хатыны, гаиләсе бар, үзе миннән карт», — дип әйтә ди. Тутасына тагын әйтеп чыгарган: «Әйткәннәремә генә күнмәсә, бу хакта Усман түрәгә җиткеремен, закон нигезендә яклау табармын», — дигән.

Моңа син ни әйтәсең? Ни киңәш бирәсең? Без бит инде ярәшкән дип кичә дә, бүген дә үзен аулакка чакырып карадым. «Бармыйм»нан башка җавап ишетмәдем. Инде килешенгән, малы түләнгән, туйга дип җыелып килгәнбез. Шул исәптән сезне дә бик мәшәкатьләдем — каладан китерттем. Туйны күтәрерсез дип хыялланган идем. Инде бар ышанычым Сездә. Сез бит... болай мәсхәрә булырга ирек бирмәссез. Үзе дә бит Сезгә зарланырга, Сезгә ышыкланырга уйлаган. Сез генә аны үгетли алачаксыз. Зинһар, ахмаклык эшләмәсен. Үгетләгез, тыңлар ул Сезне!

Усман түрә бер ара тирән уйга чумган сыман башын иеп утырды. Аннары:

— Ярый, мин аның белән сөйләшермен. Замана башка булса да, кыз кешегә әдәп саклау кирәк. Казакъның ата-бабадан килгән йоласына кул селтәргә ярамас! — диде.

— Дөресен әйтәсең, түрә,— дип, аның сүзләренә сөенүен белдерде кияү. — Ул ирек дигән законда ярәшкән кыз кияүдән баш тартырга хаклы диелмәгәндер бит. Һич тә алай булырга тиеш түгел!

Усман эшне озакка сузарга ниятләми иде. Турыдан кәләш тирмәсенә юл тотты. Кызны әле ул күрмәгән иде, күңелендә аның белән кызыксыну уянды. Кызның өе кияү чатырыннан ерак түгел. Кыз тирмәсе ишеге төбендә тукталып тиз генә өс-киемен каккалап, чәчен тарап алды да, килгәнен белгертү өчен тамак кырып алгач, эчкә үтте. Кыз түшәкләр өеме янында, машина белән ниндер тегеп утыра иде. Янында башка һичкем күренмәде. Җәмиләнең бөтен яктан да килгән матур кыз икәнен аңлау өчен ике карап торасы түгел иде. Кара чәч үремнәре өстендә затлы чиккән калфак. Йөзе ап-ак, ачык. Бит алмалары чак кына алсуланып торалар, уртада сөйкемле, туры борын. Кара бәрхет камзул белән озын ак күлмәк сын-буена сарылып, килешеп кенә тора.

Башта Усман, дустының кәләшен күрү белән бераз каушап, аптырап калды. Хәтта кыз алдында нинди дә булса яхшылык эшлисе килеп китте. Үз кадерен белеп кенә кунак урынына үтте, Җәмилә белән танышып күреште. Кыз да шундый ук осталык, тыйнаклык белән аңа җавап бирде, күз сирпеп кенә бер карап алды.

Усман, берникадәр вакыт төрле юк-бар, шаян сүз белән мавыкканнан соң, мәсьәләнең асылын, Касыймның рәнҗүе хакында сөйли башлады. Җәмилә бу үзгәрешкә гаҗәпсенгән төсле итеп аңа текәлеп карап тора иде.

— Әти-әниегез инде сезне ярәшкән. Кияү буласы кеше ихтирамга лаек, бик зур начальник. Уйлап, барын да чамалап әйттегезме икән аңа бармыйм дип белдергәндә? Ялгышмадыгызмы икән? Бәлки һич тә алай итәсе түгелдер, — дип үгетләргә тырышты Усман. Дөрес, Җәмиләгә боларны әйтү аңа җиңел булмады. Җәмилә исә бер дә каушап та калмады, бүлдермәде дә. Усман түрә бутала-бутала сүзен тәгаллләгәч, күзенә туп-туры карап әйтте:

МОХТАР ӘУЭЗОВ ◆ ӘНЛИК ◆ МӘНӘН

— Боларны сез чын күңелдән сөйлисез дип ышануы кыен. Сез кияүнең кунагы, шуңа аның сүзен сүз итмәкче буласыз.

Усман ни дияргә дә белми аптырап калды. Үзен ике ут арасында кебек тойды. Шулай да ягымлы елмаеп дәвам итте:

— Бәлки сез дә хаклыдырсыз. Әмма мин үз сүзләремә әле туры җавап алмадым. Ни дип әйтергә кияүгә? — диде.

— Бу тәкъдим белән башка берәү килсә, мин бер дә аптырамас идем. Сез боларны әйтеп карагач, мин ни дим? Без бит сезне бу мәсьәләдә хатын-кызны яклаучы дип, таянычыбыз дип белә идек. Хатын-кыз ирке хакында сездән күпме ишеткән идек. Инде бүген димче булу сезгә килешерме? Мин белмим...

— Ул кадәр үк рәнҗетмәгез мине, Җәмилә. Димче, имеш. Арадашчы... Юк.

Җәмилә күз карашы белән генә елмаеп куйды.

— Рәхмәт бу сүзегезгә. Мин бит сезгә таяныч итеп... олы ышаныч багладым, югыйсә. Аңларсыз хәлемне дип уйладым. Сез бит зур кеше, түрә. Үзегез шундый яшь икәнсез... Сез дә аңламагач...

Усманның каршы әйтер сүзе калмаган иде. Бу юлы ул үзен җиңелгәнгә санады. Кызның кыюлыгы, тапкыр сүзләре аңа ошады. Ә инде кызның аны үз тиңедәй күреп «сез шундый яшь, сез дә аңламагач» дип бетерүе бөтенләй фикерен чуалтып җибәрде. Әһ, ул караш, ул күзләр! Һәрьяклап уңган, сөйкемле икәнсең, Җәмилә! Акыл дисәң дә, төс-бит дисәң дә бар үзеңдә. Нишләп әле ул шуны күрми утыра?

Каладагыча киенгән, ыспай, «галим» егет Җәмиләнең күңеленә дә хуш килгән, кыз күңелен дә кузгаткан иде шул. Алар бер ара сүзсез генә бер-берсенә карашып утырдылар. Күз карашлары күңел түрендәген әйтеп салды. Кияү Касыйм кайгысы онытылды.

Ә бу вакыт «кияү» үз тирмәсендә ут йотып, түрәнең үз язмышын хәл итүен көтеп утыра иде.

Усман белән кыз күптәнге танышлар кебек сөйләшеп киттеләр. Торган саен Җәмилә түрәгә ошый төште. Торган саен Усман түрә тәвәккәлләнә барды. Хатын-кыз алдында югалып калучылардан түгел иде шул ул! Сүз иярә сүз чыгып, күңел түрендәген әйтер җае да табылды. Кыз да моны күптән көтә иде. Ул:

— Тик без мәңгегә, мәңгегә бергә булырга сүз куешсак кына... — диде.

Усман аңа әйтеп бетерергә дә ирек бирмәде, биленнән кочып тотып, суырып үбеп тә алды. Җәмилә каушап калды. Ялт итеп ишек ягына карап алды. «Килеп керсәләр», — дип пышылдады.

Ике сөйгән ярга тагын ни калды — ничек кавышу хакында уйлашасы, «туй» мәсьәләсен хәл итәсе бар иде. Ашыкмаска, алдан беркемгә берни сиздерми эш итәргә уйлаштылар. Башта Касыйм «кияүне» ризалык бирми кайтарып җибәрергә кирәк. Шуннан соң Усман түрә, ерак каласына кайтышлый, Җәмилә артыннан керәчәк тә үзе белән алып китәчәк. Шулай килештеләр, тагын бер кат кочаклашып үбештеләр дә аерылыштылар.

Кияү тирмәсенә кайткач, Усман түрә, әлбәттә, кыз белән үзенең вәгъдәләшүен әйтеп тормады. Җәмиләне төрлечә үгетләп каравын, шулай да берничек тә күндерә алмавын аңлатты. Бик тискәре кыз икән диган булды. «Инде миннән дә бу эш барып чыкмагач, кемнең дә булса Җәмиләне ризалаштыра алырына өметем өзелде», дип бетерде ул сүзен.

Касыйм моңа ышанды да, ышанмады да. Ничек инде ул алай, ата-ана ризалыгы белән ярәшкән кыз аңа кияүгә чыгудан баш тарта алсын, ди. Кияү һаман шул хакта уйланды.

Ул арада авыл буйлап Байбосын Хаҗи кызының «башкарма» Касыймга кияүгә чыгудан баш тартуы турындагы хәбәр таралып өлгерде.

Ерактан урап, бу хәбәр ата-ана колагына да барып иреште. Ай аллам, ата-анага монның хурлыгы ни тора! Кеше күзенә хәзер алар ничек күренер, килгән кунак, туган-тумача ни дип әйтер? Алар күбрәк шул хакта борчылды. Шулай да заманалар башка, күрәләтә үз кызыңны көчләп кияүгә бирә торган чак түгел.

Иртәгә билгеләнгән туй таралды. Авылда моңсу бер тынлык урнашкан кебек булды: яшьләр, туйга дип төрле тарафтан килгән егетләр-кызлар, шыпырт кына таралыша башлады. Җәмиләне төрлечә үгетләүләр дәвам итте. Кардәш-ыру да, кунаклар да сүз катып карадылар. Җәмиләдән «юк», «бармыйм»нан башка сүз ала алмадылар. Ярәшкән кияүгә: «Бераз көтәргә туры килер инде. Кызыбыз никтер киреләнә. Күңелегезгә авырга алмагыз. Ике атнадан соң хәбәрләшербез... Күнәр, ата-ана сүзенә дә күнмәсә», — дип белдерергә мәҗбүр булдылар.

Касыйм «кияү» белән кияү егетләре шул төнне үк үз авылларына таралыштылар.

Бу вакыйгалардан соң тагын биш көн үтеп китте. Көннәр шулай ук эссе, аяз тора иде. Эсседән әлсерәгән авыл халкы йокыга талу белән Байбосын Хаҗи җәйләвенә яхшы атлар җигелгән зур тарантас килеп туктады. Алдан вәгъдәләшкән буенча Усман түрәнең Җәмилә артыннан дип килүе иде бу.

Түрә үз теләгенә ирешү өчен хәйләне нык корган иде. Башта ул Касыйм белән бергә китте. Биш көн буе «кияү» авылында «кияү»нең кайгысын уртаклашып, аны юаткан булып йөрде. Түрә болай астыртын эш йөртә дип кемнең башына килсен!

Тарантас авылдан бер читкәрәк килеп тукталгач та, җәйләүдә ике шәүлә күренде. Дөрес, бу минутлар түземсезләнеп көткән Усманга сәгатьләр булып тоелды. Өстә, биектә аерым-аерым йолдызлар җемелдәшә, кайдадыр терлек-хайваннар кыймылдап куйгалыйлар, ә тирмәләр ягыннан берниндн дә тавыш килми иде. Әллә... Әллә...

Берәр сәгать чамасы шулай газап чиккәннән соң, колакка чак кына чулпы чылтыраганы ишетелеп киткән сымак булды. Җиргә нелебрәк карагач, ике шәүлә күренеп калды. Менә бераздан алар якын ук килеп җиттеләр. Үзара әкрен генә сөйләшүләре дә ишетелә хәзер. Хатын-кыз тавышы. Менә берсенең өстендәге ак күлмәге ялтырап күренеп калды. Җәмилә!

Усман канатланып аңа каршы йөгерде. Куллар-кулга тотыныштылар. Җәмилә, кеше-кара күзенә чалынмас өчен дип, башына кара чапан бөркәнгән икән. Чапанны озата килүчегә салып бирде. Тиз генә саубуллашты да кузгалып та киттеләр. Ашыгырга кирәк иде. Шәһәргә кадәр йөз чакрым кайтасы бар. Таң атыр, авыл халкы уянып кәләшнең юкка чыгуын чамалар. Якын-тирә авылларга чапкыннар чаптырырлар. Ул чакны инде бәхетле Җәмилә белән бәхетле Усман ерак калада булырлар.

Байбосын Хаҗи җәйләвендәге тәшвиш шул кичне үк Касыйм «кияү» авылына да барып җитте. Хаҗи байныкылар башта ни дип уйларга да белми аптырашта калдылар. Төш вакытлары авышкач та, Җәмилә табылмагач, кызның кемгәдер «ябышып» китүен абайладылар. Тик кемгә? Кем ияртеп киткән аны — бу кадәресен әле тагын бер көн белми аптырашта тордылар.

Баксаң, бу — галим түрә эше икән.

1923 ел.

**ЛИРОН ХӘМИДУЛЛИН** тәрҗемәсе.

Нури Арсланов

# АХИРӘТЕМ ӘЛ-ИСКӘНДӘР

Моннан кырык биш еллар элек үк инде мин Александр Сергеевич Ключарев белән таныш идем. Мин аны төрле кичәләрдә күреп, тыңлап беләм, ә ул мине — Казан сәнгать техникумының художество бүлеге студентын, залдагы тамашачылардан берсен — каян белсен. Ул чагында әле мин унсигезе дә тулмаган яшүсмер, ә ул инде буй җиткән егет иде.

Татар академия театры спектакльләренә, торак йортта бергә торгангадыр инде, театраллар белән беррәттән безгә дә контрамаркалар эләгә иде. Художниклар арасында бу форсаттан иң актив файдаланучыларның берсе, әлбәттә, мин булдым. Ерак Казагыстаннан килгән, татар мәдәниятен әдәбият аша гына белгән яшүсмергә татар язучылары, артистлары белән якыннан танышу: «Татар мәдәнияте йорты»нда Такташларны, Кутуйларны тыңлау, театрда, концерт я спектакльләрдә Зәйни Солтанов, Ситдыйк Айдаров, Рокыя Кушловская, Фатыйма Ильская, Шакир Шамильскийләрне, үзенең гаҗәеп халыкчан, талантлы музыкасы белән ул вакытта барлык сәхнә әсәрләрен диярлек бизәгән Салих Сәйдәшевне үз күзең белән күрү нинди зур бәхет булуын сүз белән әйтеп-аңлатып бирү мөмкинме соң!

Шундый бәхетле кичәләрнең берсе: Татар академия театры бинасында, нинди уңай беләндер, концерт бара. Мин, гадәттәгечә, дөньямны онытып, галеркада тыңлап утырам. Менә конферансье яшь музыкант Александр Ключаревның фортепианода үзе эшкәрткән төрле халык көйләрен уйнап күрсәтәчәген игълан итте. Сәхнәгә урта буйлы, кара-кучкыл, чибәр, зыялыларча нәфис, бик пөхтә киенгән яшь егет чыгып, халыкка сизелер-сизелмәс кенә баш иде дә рояль алдына утырды. Пианистларга гына хас булган хәрәкәтләр ясап, берничә тапкыр урындыгын төзәткәләп алды. Аннан... аннан миңа гаҗәеп таныш булган, мине тәмам аулап алган, киң казакъ далаларыдай иркен, салмак, йөрәкләрне тибрәтер рәхәт, көчле тәэсирле моң, талгын гына җәелеп, бөтен залны тутырды. Мин бу көйнең җырларын исемә төшердем:

**Һай, ике җирән, ялын төйгән,**
**Җан сәүләм, ярым идең җаным сөйгән...**

Ике җирәнгә атланып бергә йөргән бәхетле чакларын оныта алмыйча, гадәт-йолалар коллыгында рәхимсез язмыш аерган ярын эзләп ерак далаларны буйлаган тынгысыз егет җырын ишеттем мин анда. Менә көйнең соңгы аһәңнәре:

**Һай, заты башка — җирән кашка,**
**Җан сәүләм, сөйгәнем юк синнән башка.**

Көй үзенең казакъчалыгын, халыктагыча гадилеген, шул ук вакытта хикмәтен, якты колоритын, эмоциональ көчен шул кадәр саклаган иде ди, миңа — туган якларын сагынган студентка җитә калды: күземдә яшьләр мөлдерәде, бугазга нидер тыгыл-

ды... миңа бу минутта бик сагышлы да, бик шатлыклы да иде. Бу халәттә мин, әлбәттә, к е м уйнавын, к а й д а уйнавын тәмам онытып, тик н ә р с ә уйналу гына бөтен күңелемне биләп алды. Ә соңыннан рус музыкантының казакъ халык көен шулай түкми-чәчми, бернинди ялган акцентсыз гаҗәп оста уйнап бирүенә ни гомерләр таң калып йөрдем. Аның тылсымыннан озак вакытлар айный алмадым.

Шуннан соң күп еллар үтте. Бер чәчәк бәйләме булып кинәт күтәрелеп-үсеп чыккан татар композиторлары тавышы елдан-ел көррәк, көчлерәк яңгырый башлады. Шул көр авазлар арасында Александр Ключарев та, милли композиторыбыз буларак, югарыга күтәрелгәннән-күтәрелә барды. Аның симфоник әсәрләре, балетлары, татар, башкорт фольклоры буенча күп хезмәтләре, җыр һәм бию музыкасы өлкәсендәге уңышлары мине кызыксындыра, шатландыра килде.

Ләкин без иҗат кешеләре буларак таныш булсак та, әле һаман да бик күп вакытлар якыннан дуслашып китә алмыйча йөрдек. Фәкать илле бишенче елларда гына безнең аралар якыная төште. Чөнки мин әдәбият юлына сугыш елларында гына аяк басканга күрә, җырларны да, әлбәттә, сугыштан соң шактый вакытлар үткәч кенә яза башладым. Җыр язу исә миңа композиторлар белән турыдан-туры аралашырга ярдәм итте. Алай да, без дуслар сайлауда табигатебез белән икебез дә шактый салмак һәм сак булганга күрәдер, барыбер тиз генә үзләшеп китә алмадык әле.

Менә шулай сынаулар дәвере дә салмак-сабыр гына узды. Иҗади утырышларда, тикшерүләрдә, бәхәсләшүләрдә фикерләр уртаклыгы ачыла барып, ниһаять, без чын дусларга, гади дусларга әйләнеп киттек. Безнең арабыздагы тәкәллефсез мөгамәлә, әйбәт юморга нигезләнгән шаян тәнкыйть, уен-көлке белән эчтәге тирән яраларны дәвалау — бер-беребезнең күңелен күтәреп рухландырулар безне бер-беребезгә кирәкле шәхесләргә әйләндерде. Тора-бара шәхси дуслык гаиләви аралашуларга да сәбәпче булды.

Александр Ключарев белән безнең бергәләп язган җырларыбыз бар. «Табын җыры», «Рус балалайкасы», «Андый партия бар!», «Миләүшә» кебек җырларны иҗат иткән чакларда ул киңәшләшеп эш итәргә ярата иде. Музыка язылу процессында көйнең эшләнгән өлешен уйнап күрсәтә, сүзләрдәге мәгънә көйдә ни дәрәҗәдә әйтелә алганлыгын читләтеп кенә сораша, фикерләреңне игътибар белән тыңлый. Мондый вакытларда ул, күрешкәндә яки шаярышып бер-береңнән көлешкәндәге шикелле күзләрен кыса төшеп, каш астыннан карамый, ә күзгә туп-туры итеп тотырып карый. Аның бу ачык, җитди карашы музыка турында синнән ниндидер билгесез бер яңа уй, фикер, бәя көтә. Әгәр әйткәнең ошаса — йөзе ачылып китә, тирән бер канәгатьләнү сиздереп: «Безнең карашлар бу урында гаҗәп адекват бит әле!» яки «Әнә син нәрсә телисең икән!» дип куя.

Ләкин музыкага салыр өчен шигырь сайлаганда ул бик таләпчән булып, бу турыда бер дә дуслык, танышлык белән исәпләшеп тормыйча, яравын, ярамавын яки, ярарлык булса да, үзенең рухына, табигатенә туры килмәвен күзгә карап шундук әйтә торган гадәте бар иде. Шунысы кызык, аңа беркем дә моның өчен үпкәли алмый, чөнки ул әсәрне кире кагуын тупас формада түгел, ә дипломатларча сабыр, тыйнак, дәлилле итеп һәм зур такт белән аңлата белә.

Александр Сергеевич кеше хәленә керүчән, кайгыны да, шатлыкны да уртаклаша белә торган, киң күңелле, изге теләкле җан иде. Бервакыт шулай булды. Минем ниндәндер бик борчылган чагым: уйлыйсы да, эшлисе дә, тик утырасы да килми. Башымны кая куярга белми бик алҗып, аптырап калдым. Бу халәттән ничек чыгарга икәнне эзләгәндә уема Әл-Искәндәр (мин Александрны, гарәпчәләп, бик еш шулай атый идем) килеп төште. Шалтыраттым. Телефонда ул. Мин, бераз тотлыгып торгач, үз хәлемне әйттем. Ул миңа: «Тавышың ук үзгәргән, танымый торам. Әйдә, хәзер үк безгә кил. Киңәшербез. Хәзергә бездән дә иплe-җайлырак урын булмас. Көтәм», — диде. Мин бардым. Ишектән керүгә ул мине сынаулы караш белән, гадәтенчә каш астыннан күзен сирпеп, йомшак елмаеп каршы алды. Аш өйдән кыздырылган ит исе килеп тора. Ул арада аның яраткан попугае белән песие бергәләшеп коридорга чыктылар. Хуҗа сөйләнә-сөйләнә минем чишенгәнне көтә: «Менә хәзер үзем яраткан ак соус ясап җибәрәм, шуның белән сыйлыйм үзеңне», — ди. Александр Сергеевич бик кунакчыл, аш-суга оста. Мондый чакларда ул җиңнәрен сызганып, алъяпкычын ябып, менә дигән аш остасы сыман барлык шартларын китереп эш итәргә

ярата иде. «Аш пешерә белү үзе бер зур сәнгать. Ул, минемчә, җыр, бию сәнгатьләре кебек үк, кешелекнең бик борынгы иҗади казанышыдыр...» — дип әйтә торган иде.

Шулай ишектән кергә миңа сүз әйтергә дә бирмичә, берни турында да сорашмыйча, үзен берни дә булмаган кебек гади, тыныч тотуы, халәтемә кинәт капма-каршы шартлар тудыруы мине шактый тынычландырды. Әә соңгарак, аш алдыннан, иштиһа өчен генә, бераз шәраб та авыз итеп, тамак ялгап алгач, фортепиано янына барып яңа көй тыңлагач, мин тәмам гадәти хәлемә кайттым. Ә әлеге кечкенә тутый кош исә, песине бер почмакка кысрыклап куып, җиңү тантанасы иткән кебек, парад адымнары белән безнең якка килеп чыкты. Мин аның шулай фортепиано тавышын ишетсә беркадәр дәртләнеп китүен күптән үк сизенеп йөри идем инде.

Тутый кош дигәннән, ул бер заман бераз югалып торды. Ничектер, тәрәзәдәнме, чыккан да киткән, күрми калганнар. Менә шунда Александр Сергеевич бик борчылды. Үзе түгел — баласын югалткан ана кебек тәмам хәсрәткә талып, аптырап калды. Кайларга гына шалтыратмады да кемнәр белән генә сөйләшмәде. Хәтта ул вакытта бу вакыйганы бер көнне өлкә газетасы да кечкенә игълан итеп бастырып чыгарды. Кечкенә вакыйганың нечкә күңелле композитор өчен зур борчуга әйләнүе гаҗәп түгел: җылы як кунагы — чит җир кошы, безнең шартларда һава тәэсиреннән дә, кош-корт һөҗүменнән дә бик тиз һәлак булуы бар!.. Попугай табылгач, соңыннан бу кичерешләрне искә төшереп көлешкән чаклар да булды. Ләкин соңыннан гына!

Вафат булыр алдыннан берәр ай элек Александр Сергеевич белән яңа бер җыр язарга сөйләштек. Ул «Минем балдыз» дигән шаян шигырьне кызыксынып сорап алды. «Бу минем зәукыма бик туры килә, язам мин моны, Нуришка, язам!» дип вәгъдә бирде. Авыруы гел борчып торганга, күрәсең, җырга тиз генә тотына алмады. Сырхавының бераз басылуын, үтүен көтте булса кирәк. Әмма... ни әйтсәң дә, җыр язылмый калды. Ул гынамы, Александр Сергеевичның күпме җырланмаган җырлары калуы турында фәкать ул үзе генә белгәндер!..

Дустым Александр Ключарев вафатын мин бик авыр кичердем. Бу кичерешне аңа багышлап язган «Көзге җилләр кагыла күңелгә» шигыремдә (1972) әйтеп бирергә теләдем. Ул минем күз яшьләремә манчып язылды...

Радиода, телевидениедә татарча тапшырулар башланыр алдыннан яңгырый торган, талантлы дустыбыз Александр Ключаревның «Казан» җырыннан алынган позывной моңнары авторның җанлы образын һәр вакыт искә төшереп тора. Шул вакытларда аның якты чырае, мөлаем елмаюы, күрешкәндә кулны каты итеп кысулары, юмор яудырырга әзер торган нечкә иреннәре, шаян нурлы күз карашы... барысы-барысы кинәт күз алдына килә. Син аны тере итеп, шунда — яныңда гына торгандай хис итәсең.

Инде сүзне әлеге «Көзге җилләр кагыла күңелгә» шигыре белән тәмамлыйк:

**Еракта үк каберең күренә...**
**Рус зираты буйлап барган чакта**
**Сагышларым сарыла күңелгә:**
**Элеккедәй, каш астыннан карап,**
**Каршыларсың кебек бүген дә.**

**Нуришка дип, сөеп атадың,**
**Ә миңа син Әл-Искәндәр идең,**
**Ахирәте идең татарның.**
**Җырламыйча тынгы табалмадың,**
**Тыныч микән моңсу ятагың!..**

**Бер баласы идең Казанның.**
**Юк, үги дә, җик тә булмадың син,**
**Илдә хөрмәт һәм ат казандың, —**
**Җан эретер милли моңнарыңны**
**Син татарча уйлап язалдың!**

Нигә, сагыш, болай борчыйсың!!.
Мәңге җырлар өчен туган җанны,
Татар җанлы чын рус кешесен,
Бик юксынам сине, Әл-Искәндәр,
Сагынам сине — татар җырчысын.

Каберең бигрәк моңсу күренә...
Безнең җамнар төсле мөлдерәмә,
Ике күзем яшькә күмелә,
Ямансу шул, дустым, синнән башка,—
Күзгә җилләр кагыла күңелгә...

## Мөхәммәт Садри

#ҺӘРЧАК ХӘТЕРДӘ

Татарстан АССР Халык комиссарлары советының Сәнгать эшләре идарәсе янында оештырылган музыка фольклоры кабинетына мине эшкә билгеләгән вакытта анда секретарь-машинистка гына бар иде. Кабинетка директор итеп алынган композитор А. И. Эйхенвальд үз эшенә керешә алмаган, опера яза башлаган һәм Казаннан китеп барган.

1937 елның июль ае. Музыка училищесының беренче катындагы кечкенә генә бүлмәбезгә урта буйлы, ябык, чандыр йөзле, яшь чырайлы матур бер иптәш килеп керде һәм татар телендә:

— Исәнмесез, дуслар! — дип йомшак кына исәнләште дә үзе белән таныштырды, безгә директор булып килгәнлеген әйтте.

Бу — композитор Александр Сергеевич Ключарев иде.

Күз карашыннан үзенә бер җылы нур сибелеп торган бу ачык йөзле иптәш белән яңа һәм җаваплы эшне башлап җибәргәндә уртак тел табуы читен булмады. Аның тырышлыгы белән Татарстан хөкүмәте безгә, ике штат арттырып, бер композитор белән бер тәрҗемәче алырга рөхсәт бирде. Ключаревның ярдәмчесе булып эшкә «Сания» операсын язуда катнашкан, яшь музыка көчләрен тәрбияләүгә ярдәм иткән, үзе дә шактый көйләр, җырлар язган өлкән яшьтәге композитор Василий Иванович Виноградов килде.

Башлап шуны әйтергә кирәк, А. С. Ключарев әлеге кабинетка җитәкче булып килгәнче, Оренбург һәм Казанда музыкаль белем алган, Мәскәүдә П. И. Чайковский исемендәге дәүләт консерваториясенең композиторлар факультетын тәмамлаган, татар телен дә яхшы ук өйрәнгән иде. Өстәвенә ул ике ел Башкортстанда эшләгән, башкорт һәм татар көйләрен язып алган һәм эшкәрткән композитор иде. Казан музыкаль фольклор кабинетында эшне башлап җибәргәндә аның тәҗрибәсе бик файдалы булды.

Башта без халкыбыз җырларын, көйләрен Гөлсем Сөләйманова, Мөхәммәт Яушев, Мөхәммәт Йосыпов, Габдрахман Уральский, курайчы Исмәгыйль Мусин һәм башка музыкантлардан, җырчылардан язып алдык. Аннары безгә Казаннан завод-фабрика эшчеләре килә башлады. Мәсәлән, Фатыйма Исхакова белән Гани Мусин иптәшләрдән генә дә фонографка көйләре белән бергә илледән артык җыр язып алдык. Фонограф дигәннән, А. С. Ключарев, әзли торгач, Казанда тагын бер фонограф табып алды һәм без ике фонографлы булдык. Аның бирсе кабинетта эшләргә, ә икенчесе республикабыз районнарына, авылларына йөрер өчен бик кирәк иде. Электрга көйләнгән бу фонографларның берсен ерак юлларга чыгарга уңайлы итеп — пружина белән эшләтә торган иттек. Ул елларда фонограф бик кадерле аппарат иде: балавыз валикка язып алынган җырны шунда ук яңадан уйнатып, тыңлап,

тикшереп карап була һәм аннан нотага салуы да уңай. Ул чакта магнитофон дигән нәрсә төшкә дә керми иде әле.

Шулай итеп, безнең эш көйләнә, халык талантлары белән элемтә ныгый башлады. Әледән-әле яңа җырлар, көйләр табылды.

Директор инициативасы белән, фольклор әсәрләре өчен махсус анкета-паспорт булдырылды. Анда җырчының исеме, фамилиясе, адресы белән бергә, әсәр исеме, аның кайда чыгуы яки җырчының аны кайчан ишетүе турында мәгълүматлар язылды.

Көйләрнең сүзләрен җырчы җырлаганча дөрес, төгәл язып алу өчен без Александр Сергеевич тәҗрибәсеннән файдаландык. Без текстны башта җырчыдан аерым язып ала идек. Аннары, ул фонографка җырлаганда, көйнең бизәкләре (мелизмнары), арттырылган тактлары белән текстка кергән үзгәртүләрне шунда ук билгеләп, үзе җырлаганча үзгәртә, аныңча итә идек.

Борынгыдан, иске заманнан буыннан-буынга сакланып килгән һәм революция, гражданнар сугышы елларында, аннан социалистик тормыш төзү шартларында туган халык җәүһәрләрен — үзебез язып алган иң яхшы, матур җырларны — 1939 ел башыннан Казан радиосы аша тапшыруны тәртипкә салдык. Фольклор кабинетының бу тапшырулары радио тыңлаучылар массасы арасында киң популярлык казанды. Кабинет бик кыска вакыт эчендә Бөек Октябрьга кадәрге һәм аннан соң чыккан 300 дән артык татар халык җырын җыйды.

Яңа җырлар җыю өчен Татарстан районнарына экспедицияләргә йөрүебез әле дә хәтердә. Республикабызның җырлар хәзинәсе саналган ямьле Агыйдел буйларына, Актаныш якларына 1939 елда оештырылган беренче экспедиция бик уңышлы булды, фонографка көйләре белән бергә йөздән артык җыр язып алынды[1]. Аларның күпчелеге Октябрь революциясеннән соң чыккан җырлар иде. Нотага салып, пианинода уйный башлагач, Александр Сергеевич алардан аерыла алмый иде. Ключаревның музыкаль хәтере бик яхшы, бүген нотага карап уйнаган көйләрне иртәгә инде нотасыз, күңеленнән уйный ала иде ул. Бервакыт шулай халык көйләрен бик озаклап уйнап утырды. Озын, моңлы көйләрдән соң кыска, күңелле көйләргә күчте, тагын озын көйләрне уйнап, аннары бию көйләрен исенә төшерде. Пианино янында шулай ике сәгатьләп утырды ул. Мин дә аның хәтеренең әйбәтлегенә, татар халык көйләрен оста итеп, аларның барлык моңын, бизәкләрен саклап уйнавына исем китеп тыңладым. Шуннан соң ул уйнавыннан туктап бераз уйланып утырды да:

— Beләсеңме, Мөхәммәт, хәзер өч йөзләп татар һәм башкорт көен күңелдән беләм, ә бит безнең яңа көйләр, бик матур көйләр, җырлар арта бара, менә нинди бай, бәхетле кеше мин! — диде ул һәм тагын уйнарга кереште.

Әнә шул рәвешчә, А. С. Ключарев халкыбыз талантларыннан язып алган һәр матур җырга сокланып туймый, һәр яңа җырны, алтын кисәге тапкандай, чын күңеленнән сөенеп каршылый иде.

Татар халык җырларының беренче томына сүз башы язар алдыннан безгә В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының фәнни китапханәсенә йөрергә, анда Октябрь социалистик революциясенә кадәр чыккан фольклорга бәйләнешле күп кенә хезмәтләр белән танышырга туры килде. Каюм Насыйриның «Казан татарларының халык әдәбияты үрнәкләре», И. Ф. Катановның «Казан татарларының тарихи җырлары» һәм халкыбызның сәнгатенә, музыка коралларына бәйләнешле башка кызыклы фәнни хезмәтләрне бик яратып, бирелеп өйрәнә идек. Ләкин «Живая старина» журналына тап булып, анда С. Рыбаковның 1894 елда басылган «Татар, башкорт, типтәрләрнең халык җырлары» дигән хезмәтендәге кайбер килешсез фикерләрне укып гаҗәпкә калдык. Әлеге буржуаз «белгечнең» «татарлар бит алар сәүдәгәрләр, маклерлар, базар әһелләре, шуңа күрә аларда поэтик хис, моң булуы мөмкин түгел» дигән фикере А. С. Ключаревны бөтенләй ярсытып җибәрде:

— Халыкны белмәгән, аның иҗатын өстән-өстән генә «өйрәнгән» кеше фикере бу,— диде ул бик хаклы ачуланып.— Шундый зур поэтик хисле, моңлы халык турында шушындый фикер әйтергә теле ничек әйләнде икән бу әфәнденең!?

Шуннан соң ул бастырып чыгарырга әзерләнә торган җырлар китабына сүз

[1] М. Садри. «Фольклор кабинетының беренче экспедициясе». «Совет әдәбияты» журналы, № 8—9, 1939 ел; «Бәхетле халыкның шатлыклы җырлары». «Яшь сталинчы» газетасы, 2 август, 1939 ел.

башы язганда да, җырларның үзләренә дә таләпне тагын да арттыра төште, нота-ларның һәр тактына, нота астындагы сүзләрнең һәр иҗегенә игътибар итеп, китап-ны чын фәнни-тарихи хезмәт дәрәҗәсенә күтәрү теләге белән, зур иҗади дәрт белән эшләде. Җырларны рус теленә эквиритмик калып белән тәрҗемә иткәндә дә композиторның татар телен белүе бик файдалы булды. Бу мәсьәләдә ул бигрәк тә таләпчән иде, тәрҗемәче белән нык бәхәсләшә, нота астына язылачак һәр сүзнең үзенчәлеген аңлатып бирә, күп җырларны тәрҗемәчедән яңадан эшләттерә иде.

Һәр яңалык өчен шатланып яшәргә өйрәнгән Александр Сергеевич кабинетта тупланып килгән яңа җырлар белән композиторларны таныштырырга, алар белән киңәшергә ярата иде. Безгә С. Сәйдәшев, М. Мозаффаров, Н. Җиһанов, Җ. Фәйзи иптәшләр, җырчылар, музыкантлар киләләр, яңа язып алган җырларны бергәләп тыңлыйлар, теге яки бу җыр турында үзләренең фикерләрен әйтәләр һәм аларда халык көйләрен музыкаль инструмент өчен, хор яки аерым җырлау өчен эшкәртү теләге туа иде. Мондый очрашулар халык җырларын җыю һәм пропагандалау эше-нә зур ярдәм иттеләр. Агыйдел буйларына үткәрелгән экспедиция материаллары да композиторлар белән бергә тыңланды.

Казан тел, әдәбият һәм тарих институты тарафыннан 1940 елның яз-җәй айла-рында Себер татарлары фольклорын язып алу, телен тикшерү өчен оештырылган экспедиция эшендә Казан музыкаль фольклор кабинеты да катнашты. Бараба дала-ларындагы авылларда, Новосибирск, Омск, Томск якларында, Иртыш буйларында, Тобол һәм Төмән шәһәрләрендә язып алынган җырларга, көйләргә композиторла-рыбыз югары бәя бирделәр. Казанның галимнәр йортына Себер җырларын тың-ларга барлык композиторлар килгән иде. А. С. Ключарев, В. И. Виноградов белән бергәләп без аларга йөзләп көй ишеттердек.

Фольклор кабинеты коллективы 1940 елның көзендә халык җырларының беренче томын нәшриятка тапшырды. Хәзер инде аның икенче томына керешергә кирәк иде. Себер көйләре шул томга керергә тиеш иде.

Ләкин мин халык җырларының икенче томын төзүдә катнаша алмадым, сугыш башланды, иптәшләр белән саубуллашып фронтка киттем. Җырларның беренче томы мин фронтта чакта, 1941 елда басылып чыккан һәм аның бер данәсен А. С. Ключа-рев истәлек итеп гаиләмә кертеп тапшырган икән.

А. С. Ключарев — татар халык җыр-көйләрен күңеленә сеңдергән композитор. Иҗатында ул аларны бетмәс-төкәнмәс чыганак итте: фольклорыбызның иң яхшы үрнәкләренең үзенчәлекләрен саклап, зур осталык белән эшкәртте, халык көйләре нигезендә үзе дә берсеннән-берсе гүзәл әсәрләр иҗат итте.

Ул Казанда туган. Аннары гаиләсе аны Оренбургка алып киткән. Казанда да, Оренбургта да татарлар арасында яшәп, татар халык җырларын, телебезне кечке-нәдән ишетеп, өйрәнеп үскән. Оренбург музыка мәктәбендә башлангыч белем ал-ганда ук татар халык көйләрен уйный башлаган. Ә Казан музыка техникумында укыганда төрле музыкаль кичәләрдә инде ул халкыбызның борынгы һәм яңа көй-ләрен пианинода күңеленнән уйный башлаган.

Александр Сергеевич халык көйләрен бөтен нечкәлекләре белән башкаручы атаклы гармунчыбыз Фәйзулла Туишевның шәкерте була. Музыка техникумы студенты буларак, ул Казанда татар артистлары, музыкантлары, әдипләре катнашында үткә-релгән әдәби-музыкаль кичәләрне калдырмаган. Шундый кичәләрнең берсендә, Фәй-зулла Туишевның осталыгына һәм аның репертуарының байлыгына исе китеп, аның белән танышкан, аңар үзенең көйләрен уйнап күрсәткән. Бу яшь талант өлкән музы-кантның күңеленә хуш килгән. Тора-бара алар бер-берсенә бик кирәкле кешеләр, ә концертларда исә аерылгысыз иҗади дуслар булып киткәннәр. Александр Сергее-вич аңардан күп кенә халык көйләре язып алып эшкәрткән, Ф. Туишев гармунна-рында башкару өчен махсус рәвештә «Ленин комсомолы сюитасы» һәм башка әсәр-ләр язып биргән. Ул шулай ук концерт гармуннарында уйнап танылган Фәйзи Бик-кинин өчен дә күп кенә матур әсәрләр язган.

А. С. Ключаревның актив иҗади эше П. И. Чайковский исемендәге Мәскәү дәүләт консерваториясендә укыганда башлана. Ул «Галиябану» җыры темасына беренче симфоник увертюра, «Зәңгәр шәл» җыры темасына балет яза. «Көләү Гайшә», «Туган ил» исемле һ. б. халык көйләрен кыллы квартетлар өчен эшкәртә

һәм алар дәүләт квартетларының репертуарларына керә. Студент вакытында ул Мәскәүдәге татар театрының музыка бүлеге мөдире булып эшли, драматургларыбыз әсәрләренә күп кенә җырлар, көйләр иҗат итә. Утызынчы елларда Александр Сергеевич татар хор музыкасын үстерүгә күп көч сала. Аның дүрт тавышлы катнаш хор өчен язылган әсәрләре аеруча зур игътибарга лаеклы. Соңрак музыка культурабыз үсешендә бер вакыйга саналган Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле оештырылгач, аның художество җитәкчесе буларак, ул репертуарны халык җырлары, үз әсәрләре һәм композиторларыбыз әсәрләре белән баетуга күп көч куя. Ключаревның халык җырлары нигезендә язган «Җырлап бию», «Колхоз бәйрәме», «Мәрфуга», «Сәлам колхозчылардан», «Көчләләр җыры» һәм башка әсәрләре, «Сабан туе» исемле эстрада спектакле өчен язган көйләрен ансамбль коллективы Казанда гына түгел, Мәскәүдә һәм Ленинградта, Донбасста һәм Уралда, Ерак Көнчыгыш шәһәрләрендә башкарып зур уңыш казанды. Бу ансамбль белән элемтәсен композитор гомере буена дәвам итте.

Татарстан шәһәрләре һәм авылларында шау-гөр килеп эшли башлаган үзешчән сәнгать коллективларының хор культурасын күтәрүдә композиторның хезмәте аеруча зур булды. Аның хор өчен язылган «Туган ил турында» (Н. Исәнбәт сүзләре), «Гармонь, гармонь» (Н. Исәнбәт сүзләре), «Яшьләр җыры» (Н. Исәнбәт сүзләре), «Татарстан турында җыр» (Г. Зәйнашева сүзләре), «Казан турында җыр» (М. Хөсәен сүзләре), «Чибәр егетләр» (М. Садри сүзләре), «Агыйдел», «Кара урман» һ. б. әсәрләре үзешчән хор коллективлары репертуарында киң урын били. Бөтенроссия хор җәмгыятенең Почетлы члены һәм Татарстан хор җәмгыяте идарәсе члены буларак, ул хор коллективларына гүзәл әсәрләре белән генә түгел, аталарча киңәшләре белән дә ярдәм итте, бу өлкәдәге зур тәҗрибәсе белән уртаклашты. Ул шулай ук Татарстан халык иҗаты йорты һәм Татарстан хор җәмгыяте тарафыннан Татарстан һәвәскәр композиторларының ел саен диярлек үткәрелгән семинарларын алып баруда якыннан торып катнаша иде. «Алар миннән өйрәнсәләр, мин алардан өйрәнәм»,— ди торган иде композитор.

...Бөек Ватан сугышыннан соң Казанга кайткач, 1946 елның көзендә мин Александр Сергеевичның өенә бардым һәм без аның белән туганнарча күрешеп, бик озак сөйләшеп утырдык.

Үз вакытында халыкның бай музыка мирасын җыеп туплау үзәгенә әйләнгән һәм халкыбызның музыка культурасын үстерүгә зур хезмәт куйган фольклор кабинеты сугыш елларында эштән туктаган һәм композитор Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә эшләвен дәвам иткән. Без очрашкан чакта ул «Тау әкияте» балеты өстендә эшли иде. Билгеле булганча, А. С. Ключаревның Уфада, Башкорт опера һәм балет театрында (1950), аннан яңа редакция белән Казанда, М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында (1959) куелып, уңыш белән барган «Тау әкияте» балеты татар һәм башкорт көйләреннән, аерым алганда, 1940 елда Себердән язып алып кайткан, Татарстан һәм Башкортстан якларында билгеле булмаган көйләрдән иҗади файдаланып язылa. Александр Сергеевич халык көйләрен йөрәге аша үткәреп иҗат итә иде. Ключарев музыкасының халыкчанлыгы — халыкның бай музыка иҗатын гомере буе игътибар биреп өйрәнүе, чын күңеле белән яратуыннан да килә.

Мин дә композитор Ключарев белән күп кенә җырлар иҗат иттем. 1938—40 елларда Татар җыр һәм бию ансамбле репертуарына кертелгән «Көчләләр җыры», «Туган ил», «Татарстан», «Сабан туе», «Батырларга дан» кебек җырлар уңышлы башкарылды. Бөек Ватан сугышыннан соң бергәләп язган «Бәхет турында җыр» («Ай, җырлыйм егетем...»), «Партия белән җиңәбез», «Ленин турында җыр», «Ак болытлар», «Яз җыры», «Иделгә карап...», «Якташлар», «Хисләрем кичәләр Иделне» кебек җырлар да халык күңеленә хуш килгән җырлар булды.

«Канатлы яшьлек» исемле җырлар җыентыгы һәм татар халык музыка иҗатын җыюда, аны пропагандалауда нәтиҗәле эшчәнлеге өчен А. С. Ключаревка 1970 елда Г. Тукай исемендәге республика премиясе бирелүен барлык музыка сөючеләр шатлык белән каршыладылар. Бу премиядә аңар халык рәхмәте, халык мәхәббәте чагылды. Кыскасы, Александр Сергеевич Ключарев, бөек рус халкы улы буларак, халыклар дуслыгы рухы белән яшәгән, бөтен гомерен татар халык музыка культурасын үстерүгә багышлаган халыкчан композитор иде.

# МАТУРЛЫК, МӘХӘББӘТ ҺӘМ МӘГЪРИФӘТ ҖЫРЧЫСЫ

Татар поэзиясенең күп гасырлы тарихында шигъриятькә зур яңалык алып килгән, заманының алдынгы идеяләре белән янып, иҗатында шуларны кыю рәвештә, новаторларча күтәреп чыккан каләм ияләре байтак. Шулар арасында шагыйрь Габделҗаббар Габделмәҗит улы Кандалыйның да (1797—1860) кабатланмас һәм мактаулы урыны бар.

XIX йөзнең беренче яртысында яшәгән шагыйрь шигъри талантының көче, поэзиясенең яңалыгы һәм камил гүзәллеге, теленең сафлыгы һәм халыкчанлыгы, уй-хисләренең тирәнлеге һәм бәйсезлеге, сурәтләү чараларының байлыгы һәм күпкырлылыгы ягыннан ул чор поэзиясендә тирән эз калдыручы, яңалыкка юл ачучы буларак күз алдына килеп баса. Г. Кандалый татар халкының рухи дөньясы тирән үзгәрешләр кичергән, милли иҗтимагый фикернең яңа этапка күчеш ясый башлаган, искелек белән яңалык арасында барган мәңгелек көрәш аеруча кискенләшә төшкән катлаулы чорда яши һәм иҗат итә. Кандалый, яңа лирик герой тудырып, аның кичерешләре аша чорның реаль тормыш картиналарын тасвирлый, крестьян массаларының, аеруча татар хатын-кызларының авыр тормыш шартларын реалистик дөреслек белән сурәтли. Объектив каршылыклардан азат булмаса да, шагыйрь күпчелек әсәрләрендә дөньяви фикер йөртә, рационализм идеяләрен алга сөрә, акыл һәм хис гармониясенә дан җырлый, кешенең табигать тарафыннан азат һәм гүзәл яратылышына нык ышана, аның чын бәхетне бу дөньяда табарга хаклы булуын раслый. Менә ни өчен Кандалый шигырьләренә беренчеләрдән булып татар мәгърифәтчеләре мөрәҗәгать итәләр. Билгеле булганча, шагыйрьнең берничә әсәрен бөек мәгърифәтче Каюм Насыйри (1825—1902), заман поэзиясенең җитлеккән җимешләреннән санап, аларның саф татар телендә һәм оста язылганлыгына искәрмә ясап, үзенең «Фәвакиһелҗөләсә» (1884) китабында бастырып чыгара. Асылда Кандалый иҗаты мәгърифәтчеләрнең төп концепцияләренә җавап бирә. Күптән түгел табылган «Ибраһим Әдһәм кыйссалары»[1] һәм башка әсәрләр шагыйрь иҗатының эзләнүләргә, тирән уйлануларга бай булуын, мәхәббәт шигырьләреннән генә тормавын раслыйлар. Мәсәлән, Ибраһим Әдһәм белән булган гаҗәп хәлләр турында сөйләп, автор чордашларын борчыган конкрет сорауларга җавап бирергә ниятләнә. Әсәрнең төп герое борынгы Бәлх патшасы Ибраһим, солтанлыгын ташлап, дәрвиш киемнәре кия һәм дөнья гизәргә чыгып китә. Ул тормышның асыл мәгънәсен табарга ниятләнә. Шул изге миссиясендә аңа төрле кешеләр белән очрашырга туры килә. Беренче кыйссада ук Кандалый Ибраһимны бәйсез, баш имәүчән, гадел шәхес итеп сурәтли. Ач булуына карамастан, ул патша биргән пылаудан баш тарта. Аның өчен иң кыйммәтле нәрсә — шәхси азатлыгы. Ә менә патшага бик тырышып хезмәт итүче шәһәр сакчысы соңгы чиктә бу тугрылыгы өчен остасы тарафыннан кыйнала гына (җиденче кыйсса). «Патшаларга якын булу — җанга бәла, була күрмә моның белән син мөбталә»,— ди шагыйрь. Авторны исәп-хисапка корылган дөнья белән изге ниятләр арасындагы тирән каршылык борчый, ул халык массасы һәм аның юлбашчысы кебек проблемаларны да чишәргә омтылыш

[1] М. Госманов. «Кандалыйның билгесез поэмалары», «Казан утлары», 1967, 6 сан, 135—186 битләр.

ясап карый... Кыскасы, Г. Кандалый бу әсәре белән үзен катлаулы фәлсәфи дастан язарга сәләтле шагыйрь итеп таныта.

Алдагы иҗатын ул мәхәббәт поэмалары язуга багышлый. Әмма «Сәхибҗамал», «Фәрхисорур», «Бәдыйга», «Бәгыйдә», «Фатыйма», «Кара кол тик» кебек поэма-шигырьләрендә ул интим хисләр җырчысы гына түгел, замандашларын борчыган мөһим проблемаларны күтәреп чыгарга сәләтле, татар поэзиясен йөзе белән реальчынбарлыкка таба боручы шагыйрь булып күз алдына баса.

Тулаем алганда, Г. Кандалый иҗаты тарихи оптимизм белән сугарылган. Шәхесне күтәреп күрсәтү, аның гүзәллегенә, акылына дан җырлау, гомумән, мәгърифәтчеләргә хас. Еш кына бу өндәмәләр иҗтимагый активлыкка чакыру булып яңгырыйлар. Кызганычка каршы, Кандалый яңа хәрәкәтнең яралып кына килгән дәверендә иҗат итте, ә бу аның иҗтимагый активлыгын бермә-бер киметүгә китерде. Аның уйлавынча, сөюсез — йөрәк үле, тормыш мәгънәсез һәм бәхетсез. Әмма мәхәббәт тә көткән бәхет гармониясен бирми. Чөнки чын мәхәббәт кешенең иҗтимагый интереслары тулылыгыннан туарга тиеш. В. Г. Белинский билгеләп үткәнчә, «Утны сүндермәү өчен май кирәк булган кебек, мәхәббәт өчен дә акыллы эчтәлек, мәгънә кирәк». Кандалый яшәгән чор, мохит шәхеснең гармоник үсешенә, иҗтимагый эшчәнлегенә мөмкинлек бирү түгел, хәтта аның табигый башлангычларын да гарипли, яралгы хәлендә буа иде. Менә ни өчен Кандалый язмышы, аның шәхси тормыш фаҗигасе — җавапсыз мәхәббәт, иллюзияләр җимерелү трагедиясе генә түгел, ә конкрет-тарихи шартларда яшәргә мәҗбүр булган олы шәхес трагедиясе итеп каралырга тиеш.

Шагыйрь тормышны төрле яклап күзәтә. Бер якта — икейөзле, надан руханилар, комсыз байлар, икенче якта — «йөзе чытык, кашы түбән» крестьяннар, алар гомер буе эш белән җәфа чигәләр. Табигать тарафыннан гүзәл яратылган крестьян кызлары да «колның колы» булырга дучар ителгән. Аларның язмышы — шагыйрьнең игътибар үзәгендә. Ул үзенә тормыш иптәшен бай-түрәләр гаиләсеннән эзләми. Аның күңеленә эшләп үскән, төскә-буйга чибәр, уңган, тырыш, зирәк крестьян кызы якынрак. Ул аны үзенә каратырга, үзенеке итәргә тели. Бу ният аны тар хиссият кысаларыннан җәмгыятьнең киң мәйданына алып чыга, тормышның реаль картинасына карашын юнәлтә. Еш кына лирик геройның эчкерсез мәхәббәте үзенең сафлыгы, куәте, кешелеклелеге белән сыйнфый изүгә корылган җәмгыятьтәге тәртипләргә капма-каршы куела.

Бу ягы белән Кандалыйның шактый әсәрләре бөек чордашы Некрасов шигырьләренә авproduced авааздаш яңгырыйлар.

> **От работы и черной, и трудной**
> **Отцветешь, не успевши расцвесть,**
> **Погрузишься ты в сон непробудный,**
> **Будешь нянчить, работать и есть, —**

дип яза рус шагыйре. Кандалыйның «Кара кол тик» шигыре, «Сәхибҗамал», «Фәрхисорур»дагы шигъри өзекләр бу юлларны тагын да тулыландыра төшә алырлар иде.

Кандалыйның лирик герое тормышка һәр вакыт актив мөнәсәбәттә тора, фикер йөртүендә ул үзен дин өйрәтмәләреннән азат саный. Аның иҗатында, Х. Госман билгеләп үткәнчә, «илаһи идея белән дөньяви идея бер-беренә кискен каршы куелган». Һәм бу каршылык геройның сөйгәненә язган хатларында аеруча ачык чагыла. Кандалый герое, тулаем алганда, дин йогынтысыннан арынып җитә алмаган әле. Хәтта хисенең тирәнлеген, сөйгәненең күркәмлеген тасвирлау өчен дә ул дин атрибутларыннан файдалана. Тик шунысы гаҗәп: бу алым, киресенчә, авторның бу дөнья интереслары белән янучы булуын гына раслый, сөйгәненең матурлыгы, аңа булган гыйшкының куәтен ачыграк күрсәтүгә ярдәм итә.

> **Бу сүзем чын: сөйләшәмен алдамый,**
> **Тәмам оныттыра яздың алламый.**
> **Кон дә сагыш, төн дә сагышың тотып,**
> **Бинамазым, биниазым ут йотып.**

Лирик, чын мәхәббәт көчен раслап, аның хакына динне ташлау мөмкинлеген дә читкә какмый:

**Бу инәлгәннәреми таш та белерде,**
**Урыс кызы, динен ташлап, килерде.**
**[«Фәрхисорур», 134 бит.]**

Лирик герой, легендалардагы романтик каһарман кебек, сөйгәне хакына әллә нинди батырлыклар эшләргә әзер, дин күрсәтмәләренә сыймаган, мулла исеменә тап төшерердәй эшләр кылудан да баш тартмый ул:

**Сәнең гыйшкың бәне аздырды юлдин,**
**Урлар идем сәне гел, килсә кулдин!**

Еш кына лирик геройның ашкынулы хисләре дини акыл кысаларын да җимереп чыгалар:

**Бу дөньяда кавыша алмасак,**
**Утта янсын заманасы!**

— ди ул.

Дин өйрәтмәләреннән читләшү, суфи шагыйрьләрнең аллага юнәлтелгән платоник хисенә табигый хис тантанасын каршы кую Кандалыйны гуманистик Көнчыгыш поэзиясенә, аеруча бөек якташы Кол Галигә якынайта. Шагыйрь поэзиягә романтик ашкыну, саф һәм куәтле мәхәббәт хисен кире кайтара.

Аның поэзиясендә бу хис, акыл культы, аң-белемне зурлау белән кавышып, үзенчәлекле мәгърифәтчелек романтикасын барлыкка китерә. Дин кешене алла колы дисә, Кандалый, киресенчә, гади җир кешесенә табына:

**Күз-кашыңны мәсҗедә михрап идәм,**
**Сурәтеңне көзгедик мохап идәм.**
**Аллаһ-әкбәр дип әгәр каксам колак,**
**Сурәтең күңлемә уладыр кунак.**

Татар кызын тиңсез биеклеккә күтәреп, аңа мәдхия җырлау турыдан-туры шәхес азатлыгы, хатын-кыз азатлыгы идеясенә барып тоташа.

Инде лирик геройның мәхәббәт объектына күз салыйк. Аны җир кызының тышкы гүзәллеге генә җәлеп итә микән?

**Дәхи күрдем мөбәрәк буйларыңны...**
**Белә алмадым вә ләкин уйларыңны!**

Менә бит ничек! Шагыйрь мәгъшукасының **рухи дөньясы** белән кызыксына. Бу үзе игътибарга лаеклы факт, чөнки ул чор поэзиясендә хатын-кыз рухи дөньяга ия, мөстәкыйль фикер йөртергә сәләтле зат булудан бигрәк, гашыйк ирнең соклану объекты буларак кына тасвирлана иде.

Ә Кандалый идеалы — белемле, уңган, чибәр кыз.

**Сылу булдым да, матур да,**
**Сабак укуда батыр да,**
**Дәхи язарга язу да**
**Гыйлемлекдин алып бәһрә,**

— дип әйттерә ул сөйгәне Сәхибҗамалга.

Кандалыйны нык борчыган мәсьәләләрнең берсе — авыл халкының наданлыгы. Башка мәгърифәтчеләр кебек, ул да наданлыкның социаль күренеш булуын аңлау дәрәҗәсенә күтәрелә алмый әле. Ләкин «надан» сүзе шагыйрь телендә иң еш кабатлана торган һәм аның өчен кешедәге иң ямьсез сыйфат. «Кара мужик»ның әхлаксызлыгын, тәртипсезлеген дә ул укымыйча, надан калуыннан күрә. Шул ук вакытта аңа уку өчен һичнинди мөмкинлек булмавын да белә ул. Бер караңгыдан икенче караңгыга чаклы бил бөгүче авыл кешесенең рухи зәвыгы чикләнгән булуы чагыштырмача яхшырак шартларда яшәгән Габделҗаббар муллага аңлашыла. Гашыйк герой гади авыл кызын үзенә карату өчен, крестьян тормышының коточкыч авырлыгын һәм ка-

раңгылыгын сурәтли. Кандалыйның каршылыклы шагыйрь булуы бу эпизодта бигрәк тә күзгә ачык ташлана. Бер яктан Габделҗаббар мулла мужик алдында үзенең өстенлеген күрсәтергә тели, икенче яктан шул ук «сасы мажик»ның кызын яратып, кызганып, сыкранып, аның ямьсез киләчәген тасвир кыла:

**Матур булсаң да, баргачдин наданга,**
**Кералмассың гомер буена санга.**

Ул халыкны яктылык, мәгърифәт юлына алып чыгучы затларны җәмгыятьнең иң белемле, культуралы катлавыннан эзли. Җир кызына да чын бәхетне, идеалының тормышка ашуын, Кандалый уйлавынча, фәкать ул үзе — белемле, әдәпле, иркә, игътибарлы авыл мулласы гына бирә ала.

Татар тормышында яңарыш орлыклары шыта гына башлаган заманда яшәгән Кандалый өчен уңай герой, әлбәттә, халыкны тәрбия кылучы, итагатьле, белемле, гадел мулла була. Хәер, татарның беренче мәгърифәтчеләре үзләре нәкъ шушы катлаудан чыкканнар да бит. (К. Насыйри, Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдинов һ. б.)

Г. Кандалый гомере буе балалар укыткан, авылдашларына үгет-нәсихәт кылган. Иген игү, бакчачылык кебек крестьян эшләре дә аңа чит булмаган. Киң карашлы фикер иясе буларак, ул гарәп-фарсы, рус, мари, чуваш телләрен яхшы белгән. Күрше авылда яшәүче руслар белән тыгыз элемтәдә торган, аларның күтеп алынган кунагы булган.

Г. Кандалыйның халыкчан лирикасы, еш кына интимлыгын югалтып, гражданлык яңгырашы ала. Бу аны татар мәгърифәтчелек поэзиясенең башында торучы шагыйрьләрнең берсе итеп санарга хокук бирә. Шигырьләренең берсендә ул:

**Балаларның балалары**
**Укытырлар һәм алары,**
**Догачы булалар бары —**
**Кирәк кыз да, кирәк ир дә.**
**Бу галимнәр эше илә**
**Болай ук кеше яши лә:**
**Догалары сәңа килә,**
**Үзең ятсаң да кабердә,**

— дип яза.

Кандалый шигыренең әһәмияте оныкларының «догалы» булуын күрергә теләвендә түгел, ә хатын-кызларның да ирләр белән бер дәрәҗәдә белем алачагына, галим кешенең, үзе кабердә ятса да, исеме һәм эше халык күңелендә сакланачагына, мәгънәле яшәешнең «галимлек кылу»га, ягъни туган халкыңа армый-талмый хезмәт итүгә бәйле булуына тирән ышаныч саклавында.

Кандалый үзенә чаклы һәм үзеннән соң иҗат иткән шагыйрьләрдән иң элек лирик шагыйрь булуы белән аерылып тора. Г. Утыз Имәни, М. Акмулла кебек шагыйрьләр әсәрләрен турыдан-туры киңрәк аудиториягә мөрәҗәгать итеп язганнар. Акмулла иҗатында без халык тормышына тирәнрәк үтеп керү, сыйнфый аңның ачыла баруын күрәбез. Кандалый аудиториясе, әлбәттә, таррак. Ләкин аның поэзиясендә мәгърифәтчеләр яклаган төп нәрсәне — кешенең табигыйлеген, хисләр сафлыгын зурлауны күреп була. Акыл һәм хис гармониясенә омтылу — Кандалый поэзиясенең көчле ягы. Әмма Кандалый матурлык һәм мәхәббәт җырчысы гына түгел, татар мәгърифәтчелек хәрәкәтенең куәтле дулкыны тудырган давыл кошы ул.

Шагыйрьнең мирасы, татар халкының рухи хәзинәсе буларак, безне һаман да үзенә җәлеп итә, без аның әсәрләрен укып сокланабыз, моңаябыз һәм көләбез. Чын сәнгать һәр вакыт шулай — күңелләргә эстетик ләззәт бирә.

**РАФИС ӘХМӘТОВ,**
**Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты гыйльми хезмәткәре.**

# ГАБДЕЛҖАББАР КАНДАЛЫЙ МИРАСЫН БАРЛАУ ЮЛЫНДА

Габделҗаббар Кандалыйның тормыш һәм иҗат юлы мине күптәннән җәлеп итеп килә. Әни ягыннан ерак бабам булуы да Кандалый белән кызыксынуны тагын арттыра төште. Кечкенә чагымнан мин Габделҗаббар бабай турында әллә никадәр истәлекләр, легендалар тыңлап үстем. Аның шигырьләрен минем әни генә түгел, башка кардәшләрем, авылдашларым да яттан беләләр иде. Кызганычка каршы, мин аларны үз вакытында кәгазьгә төшерә алмадым, күп нәрсә онытылган, истән чыккан. Шулай да Кандалый шигырьләрен җыю нияте миндә яшәп килде һәм, ниһаять, олыгаймыш көнемдә мин бу теләгемне өлешчә тормышка ашырдым кебек.

Мине иң борчыганы — Кандалый мирасының саклану-сакланмау мәсьәләсе иде. Шагыйрь үлеменә аз дигәндә 100 ел гомер узып киткән, аның чордашлары, аны күреп калган картлар да инде күптән дөнья куйганнар. Шулай да Кандалый яшәгән тирәдә, туганнары, кардәшләре, авылдашлары арасында аның аерым әсәрләре, шигырьләреннән өзекләр яки кульъязмалар сакланып калгандыр әле? Бәлки алар төпченеп эзләнүне генә көтеп яталардыр?

Г. Кандалый яшәгән Иртуган авылын татарлар элек-электән Иске Кандал дип йөрткәннәр, ә минем туып-үскән авылым Кызылсу (Тат. Урайкино) Иске Кандалдан 9—10 чакрым гына. Урайкино авылын Кандалый үзе дә шигырендә искә ала:

**Ишан сагышын сагышлап,**
**Ишан рухына багышлап,**
**Ашап-эчеп, күңел хушлап,**
**Гулять иттем Урайкинда!**

Дөрес, биредә шагыйрь күрше рус Урайкино авылын истә тоткан булса кирәк, ләкин ул безнең авылда да еш булгалаган. Туган авылымда мин озак еллар укыттым, анда миңа күпләр хәзер дә таныш, чордашларым, олы яшьтәге укытучылар белән әле дә хат алышып торам. Шуңа күрә Кандалый мирасын нәкъ менә Кызылсу авылыннан эзли башлавым очраклы түгел иде.

Мин өч айга сузылган сәяхәттә булдым. Йөрүемнән туган иң олы тәэсир шул: татар халкы Кандалый исемен олылап, ихтирам белән искә төшерә, хәтерендә саклый, аның шигырьләрен яратып укый. Бу әсәрләр картларга да, яшьләргә дә эстетик тәэсир көчен һич югалтмаганнар. Шунысы хак: шагыйрь әсәрләре әле дә булса табыла торалар, халык аларны саклый, бигрәк тә өлкән буын кешеләре арасында аның шигырьләрен яттан белүчеләр күп. Димәк, озакка сузмыйча, аларны эзләүне, барлау һәм өйрәнү эшен киңрәк һәм эзлеклерәк дәвам иттерергә кирәк. Шагыйрьнең исемен мәңгеләштерү буенча да эшләнәсе эшләр байтак әле. Проф. Х. Госман төзегән һәм 1960 елда басылган шигырь җыентыгы инде күптән таралды, үнҗиде ел эчендә бөтенләй яңа буын укучылар үсеп җитте. Бу вакыт эчендә Кандалыйның яңа шигырьләре, хәтта поэмасы табылды. Шуларның барысын бергә туплап, җентекле анализ биреп, шагыйрь әсәрләренең тулы басмасын чыгаруны көн тәртибенә куярга бик вакыттыр.

Шагыйрьнең исемен мәңгеләштерү мәсьәләсе мәрхүмнең туган авылында ничегрәк тора соң? Билгеле булганча, шагыйрь 1860 елда вафат булып, шушы авыл зиратына күмелгән. Ләкин бу кабер саклана микән соң?

Минем авылдашым һәм кордашым проф. Латыйф Җәләйне дә бу сорау бик борчый иде. Һәм мин аның киңәшен дә истә тотып, шагыйрьнең авылдашлары, пенсионер укытучы Әхмәт ага Сөләйманов һәм Мөбәрәк ага Габбасов белән Кандалый күмелгән зиратка бардым. Эзли торгач, без Кандалыйның каберен таптык. Ул бөтенләй ташландык хәлдә иде, чардуганы да юк, агач та утыртылмаган, кабер ташы да куелмаган. «Бу кабернең Кандалыйныкы булуын ничек ачыкладыгыз соң?» дигән сорау туарга мөмкин. Беренчедән, авыл халкы шагыйрь күмелгән җирне «изге урын», ә

каберен — «изге кабер» дип йөртә. Гасырдан артык вакыт узып, зиратта буш урын да калмаган, иске каберләр урынына яңалары барлыкка килгән. Ә халык бу каберго тимәгән. Әхмәт ага шагыйрьнең күмелгән җирен Садретдин бабай улы Мирхәйдәр Алферов аша белгән, ә Садретдин бабай — Габделҗәббар Кандалыйның үз улы.

Кандалый каберен табу мине канатландырып җибәрде. Озакка сузмыйча, мин Кандалыйның кем булуы, татар әдәбиятында тоткан урыны, табылган кабере хакында КПССның Ульяновск өлкә комитетына һәм башка оешмаларга хат яздым. Шагыйрьнең туган авылында кабат мин 1974 елда булдым. Яңадан Әхмәт ага Сөләйманов белән күрешеп, зиратка килдек, шагыйрьнең каберен яңадан эзләп таптык. Шул ук көнне Кандалый каберен «Восход» колхозы рәисе А. С. Сафиуллин һәм партком секретаре Р. М. Габбасовка күрсәттек. Кабер урынын билгеләп, казык кактык. Шагыйрьнең каберен рәтләү — таш кую, чардуган кору, мемориаль такта булдыру эшен һәм моңа тотылган чыгымны колхоз идарәсе үз өстенә алырга булды. Бу эшне тизләтү нияте белән мин Иске Майна район үзәгенә килдем һәм райкомның беренче секретаре В. С. Делин белән очраштым. Ул минем үтенечем буенча өлкә культура бүлегеннән тиешле боерык кәтелүе хакында әйтте. Һәм миңа 1976 елның 31 маенда мин түбәндәге хатны алдым (тәрҗемә):

«Хөрмәтле иптәш Тазюков Х. Г.!

Сезнең соравыгызга җавап бирә алабыз: Иртуган авылында Г. Кандалый кабеpенә граниттан ясалган кабер ташы куелды. Аңа татарча һәм русча түбәндәгеләр язылган:

«Татар шагыйре Габделҗәббар Кандалый»
«Татарский поэт Габделзаббар Кандалый»
(1797—1860)

Зират территориясе тимер койма белән әйләндереп алынды. Шагыйрь каберлеген мәктәп балалары шефлыкка алып, аны хәстәрләп торалар.

Культура бүлеге мөдире Н. А. Соколов. 19 май, 1976 ел».

Шулай итеп, бүгенге көндә теләгән кеше күренекле татар шагыйре Габделҗәббар Кандалый кабереңә барып, аның үлмәс образына баш ия ала.

Халык теләндә Кандалый турында төрле истәлекләр саклана. Шагыйрь биографиясен, карашларын ачыклауга билгеле бер ярдәм итәрләр дип, мин аларны да язып алдым.

*Г. Кандалыйның сәләтлелеге бала чактан ук билгеле булган. Мәсәлән, аны һәр көн мәдрәсәгә ат белән озаталар икән. Юлда урманга баручы кешеләр очрый. Кечкенә Габделҗәббар:*

*Мажиклар бара урманга*
*Агачларны тукырга,*
*Артларыннан мин дә барам*
*Мәдрәсәдә укырга,—*

*дип көйләп кала, имеш.*

*Димитровград шәһәре, Комсомольская урамы, 18 йортта яшәүче Мәрзия әби (1888 елда туган) истәлеге.*

*Иртуган авылында яшәүче алты бала бик яшьли ятим калганнар. Аларның алтысын да Габделҗәббар бабай тәрбиягә алып үстергән, аларга белем биргән, татарча һәм русча укырга-язарга өйрәткән. Ятимнәрне бик тырышып тәрбия кыла, төрле һөнәрләр өйрәтә. Кыскасы, Габделҗәббар бабай һәм аның хатыны аларга икенче ата-ана булалар. Үсеп җиткәч, Кандалый аларны, үз әтиләре кебек, башлы-күзле итә: ир балаларны өйләндерә, кыз балаларны кияүгә бирә. Безнең бабай һәм әбиләр гомерләренең ахырына кадәр Габделҗәббар бабайга гел рәхмәт укып яшәделәр.*

*Шагыйрьнең оныгы Ярулла Фәтхуллов сөйли:*
*Кандалый үз өенә авыл яшьләрен җыя торган булган. Аларга ул:*
*— Балаларны беркайчан да «рус килә, рус ала» дип куркытырга ярамый. Бу дөрес түгел, киресенчә, руслар белән дус яшәргә кирәк, алардан безгә әле күп нәрсә өйрәнәсе бар,— дип әйтә торган булган. Габделҗәббар бабай үзе гомере буе руслар белән дус булып, тату яши, еш кына аларга барып йөри, үзе дә чакырып, аларны ачык йөз белән каршы ала. Ул рус телен шундый оста белгән, хәтта рус танышлары да моңа шаккаталар икән. Ул халык медицинасы белән дә кызыксынган, төрле ырымнарга,*

*өшкерүләргә каршы булган. Халыкны чисталыкка, пөхтәлеккә өйрәткән. Үзе дә мунча керүне, себерке белән чабынуны бик яраткан:*

*Тра-ля-ля, тра-та-та,*
*Свежий винек вә кайнар пар*
*Сырхаулардан тазарта,—*

*дип чабына торган булган ди. Мунчадан соң лимон белән чәй эчәргә яраткан. Гомумән, чәй эчүне, кунак сыйлауны яраткан:*

*Самаварың торыр мисле торна,*
*Кунак килсә, самавар куймый торма,*
*Самавардыр кунакның күңелен алган,*
*Самавардыр хуҗасын байга салган.*

*Чәй турында язылган бәетне дә Габделҗаббар бабай язган дип сөйлиләр бездә. Кандалый тормышны бик яраткан, эш сөйгән, үзе дә күп һөнәрләр белгән. Кеше өстеннән көн күрүче байларга нәфрәт белән караган, гали, гадел кешеләрне якынрак күргән, шул ук вакытта һәркем белән артык түбәнсенмичә, үзен горур тотып сөйләшкән.*

*Үзенең кызы Гайшәне ул Кызылсуның ярлы крестьян малае Әбделхәергә кияүгә биргән. Киявенә ул һәр вакыт:*

*— Тырыш булсаң, хезмәтне сөйсәң, тормышың авыр булмас. Җиреңнең күңелен, хәтерен табарга тырыш, ашлама бир, әйбәтләп эшкәрт, шунда гына җир дә синең күңелеңне күрер: мул уңыш бирер,— ди торган булган. Киявенең гаиләсе ишәйгәч, ул аларга еш килә башлый, чөнки Кызылсуда аның башка туганнары да яши. Бервакыт Габделҗаббар бабай белән кияве Әбделхәер арасында мондый сөйләшү була:*

*— Күпме җир чәчәсең, кияү?*

*— Ике дисәтинә чәчәм, бабай, тик уңыш бик аз була, юк дип әйтерлек.*

*— Аны ничегрәк чәчәсең соң, улым?*

*— Сукалыйм да, себереп чәчәмен.*

*— Ике дисәтинә урынына берне генә чәч, ләкин җирне яхшырак эшкәрт, әүвәл сукала, аннан себер, тагын сукала, шуннан соң гына себереп чәч. Шулай эшләп, сынап кара әле, үзең күрерсең, бер дисәтинә дә икесе хәтле уңыш бирер. Тик әйбәтләп тиресләргә, җиреңне сыйларга онытма,— ди Кандалый. — Саран кешегә җир дә саран ул.*

*1890 елда туып, Казанда яшәүче Фазылҗан ага Хәмидуллин сөйләде:*
*Кандалый дөньяның туктаусыз хәрәкәттә булуын яхшы аңлаган:*

*Әл хәрәкәттә бәрәкәтөн,*
*Вәттәвани һәләкәтөн,—*

*дигән ул, ягъни дөньяның бәрәкәте — хәрәкәттә, ә торгынлык, ялкаулык бетүгә, сүнүгә алып бара. Шагыйрь үзе мич чыгара, йозаклар, ачкычлар, сәгатьләр төзәтә, киемне дә оста тегә белгән. Кием теккәндә үзе ясаган сызымнардан файдаланган.*

*Иң яраткан эше китап уку булган. Ул, гарәп һәм фарсы телләреннән тыш, рус, чуваш, мари телләрен белгән. Бөтен якта да яхшы санаган танышлары турында ул: «Бу урманда кабыгы белән үскән»,— дип әйтә торган булган.*

*Ульяновск өлкәсе, Иске Майна районы, Кызылсу авылында яшәүче, шагыйрь нәселдәше Маһисорур Таҗетдинова (1879—1958) сөйләгән иде:*

*«Габделҗаббар бабай табигатьне бик ярата торган кеше булып, буш вакытларын табигать кочагында: урман, болын, кырларда уздырган. Шигырьләрен дә шул вакытларында язган. Олыгая төшкәч, ул бигрәк тә ялгыз йөрергә яраткан».*

*Биредә шунысын да өстик: юл йөргәндә шагыйрь эчтән генә уйланып, ниндидер көй көйләп йөргән, авылдашлары белән дә ишарә белән генә исәнләшә икән. Кандалыйның мондый вакытларда шигырь иҗат иткәнен якташлары яхшы белгән, аңа беркем дә комачау итмәгән. (Авт.)*

*Шагыйрьнең оныгы Ярулла бабай Фәтхуллов болай дәвам итә:*

*«Габделҗаббар бабайны авыл байлары бер дә кыралмаганнар. Бер тапкыр җәй көнендә, «ике сука арасында», шагыйрьнең авылдашы бер бай түрә туй үткәрә. Шагыйрь үз бакчасы янына өелгән бүрәнәләргә сөялеп утыра икән. Кич җиткәч, туйда катнашучы исерек байлар һәм аның куштаннары ат җигеп урамга чыгалар. Кандалыйдан көлү өченме, аны куркытабыз дипме, атларын, чаптырып, аның өстенә юнәлдерәләр. Моны күргән шагыйрь ачуланмый-нитми, көлемсери дә читкә тайпыла. Ә чабучы атлар өйгән бүрәнә өстенә менеп китәләр, арба ава, ватыла, ә исерекләрнең күбесе имгәнә».*

*Шагыйрьнең нәселдәше, РСФСРның һәм ТАССРның халык артисты Габдулла Шамуков сөйләде:*

*«Минем әнинең әтисе Фәттахетдин бине Мифтахетдин Мәҗитов (Габделмәҗитов) (1861—1940) заманында Казанда К. Насыйрида укып белем алган. Укытучы абыйсының үтенүе буенча, үзләрендә сакланган Кандалый шигырьләрен аңа тапшырган. Га-*

*лимнең 1884 елда Казанда бастырып чыгарган «Фәвакиһелҗәласә» китабында урнаштырылган Кандалый шигырьләренең кайберләре, димәк, әнә шул рәвешчә дөнья күргән булса кирәк».*

*Иске Кандал белән рус авылы Малая Кандала арасы бер-бер ярым чакрым. Шушы ике авыл арасында ике юллы сукмак бар икән. Ул Иске Кандалның Габделҗаббар хәзрәт тоткан мәчетеннән башланып, рус авылына кереп югала. Моннан 60—70 ел элек бу сукмакларны мин дә күргән идем. Халыкта аларны «Габделҗаббар сукмагы» дип йөрткәннәр. Шул сукмак буйлап шагыйрь тиз генә арада күрше рус авылына, дуслары-танышлары янына барып килгәли икән. Моны ул икенде белән ахшам намазлары арасында башкарырга өлгерә торган булган. Рус авылыннан шагыйрь бераз «кәефләнеп» тә кайткалый, имеш.*

Җыелган мәгълүматлар әнә шулар. Инде шагыйрьнең төрле кешеләрдән язып алынган шигырьләренә күчик. Без аларның барысын да Кандалый үзе язган дип дәгъва кыла алмыйбыз, шуңа күрә кайбер өекләрне гипотеза рәвешендә генә китерәбез. Шулай да арада стиле, язылышы буенча, һичшиксез, Кандалый әсәрләрен хәтерләткән өзекләр бар. Аларны киләчәктә фәнни кулланылышка кертү-кертмәү мәсьәләсен шагыйрь иҗатын махсус өйрәнүче галимнәр хәл итәр.

**Иген икмәк бирер икмәк,**
**Белеп иксәң, бирер күпләп.**

(Ульянов өлкәсе, Иске Кандал картларыннан язып алынды.)

**Фәкыйрь керсә, уза алмый ишекдин,**
**Көләр байлар, сүләп туны тишекдин...**

(Ульянов өлкәсе, Димитровград шәһәре, Сара Сафиуллина, 1894 елгы.)

**Сәне анда, бәне монда таратты,**
**Арабызга олуг дарья яратты.**

(Х. Госман төзегән җыентыктагы «Сән һәм бән» шигыренә (55 бит) өстәмә була ала. Ульяновск өлкәсе, Үрән авылы, Габдулла Галимов һәм Маһикамал Галимовадан алынды, 1894 елгы.

**Үләм, җаныем, үләмен, тергезә күр,**
**Бер аулакта үзеңне күргезә күр!**

(Әлеге җыентыктагы «Күңелем тынасы юк» шигыренә өстәргә мөмкин. Шул ук Г. Галимов һәм М. Галимова бирде.)

**БИЛГЕ**

**Бу хатымны кабул итеп аласың,**
**Кабул итсәң, читен өзеп каласың.**
**Бу хатымны язган идем кичә көн,**
**Кабул итмәс исәң, ватма пичәтен!**

(Шул ук Г. Галимов һәм М. Галимовадан алынды.)

**Ерактыр ла ике ара,**
**Йөрәк-бәгърем көеп ала.**
**Ике көннең бере саен**
**Мөнәҗәтем укып кара!**

(Ташкент шәһәрендә яшәүче, шагыйрьнең населдәше Галимә апа Таҗетдиновадан язып алдык.)

**Әя, җаным, кызыл алмам,**
**Ки сәндин гайрени алмам,**
**Ки сәндин гайрени алсам,**
**Мәхәббәт бирмәсен аллам!**

(Әлеге җыентыкта 47 биткә «Кызыл алмам» шигыренә өстәргә мөмкин. Ташкент шәһәрендә яшәүче Сираҗетдин Албәков (1883 елгы) бирде.)

Каләм әйтер: караң улса, тагын яз,
Абыстайга укырга булмасын аз.
Каләм әйтер: тагын әзрәк язасы,
Абыстайның китә төшсен мазасы!

(С. Албәков әйтеп яздырды.)

## ГОМЕР

Гомер ул шылтырап суккан сәгать дик,
Тиз үтәр ул вакытлар, йөгрек ат дик.
И минем гомрем минуты әгълядыр,
Шунсы тырный эчләремне,
Шул минутлар агыладыр.

(Х. Госман җыентыгындагы 126 бит, 2 нче строфада бу өзекнең ике юлы бар. Ташкент шәһәрендә яшәүче Галимә Таҗетдиновадан язып алынды.)

Надан кеше керсә сәнең куйныңа,
Кыямәт көн богау салып муйныңа,
Әгәр ул китмәсә, сән кит, алып баш,
Күтәреп йөрмәгел тагъдин авыр таш.

(Г. Галимов һәм М. Галимова бирде.)

## УЛЫНА ЯЗГАН ХАТЫННАН

Ерак йирдә газиз башың,
Янында һич юк юлдашың,
Мөшкелдер сәнең тормышың,
Сабырлык булсын юлдашың.
Пароходлар төшкән чакта,
Газиз балам, сәне көттем,
Әткәң-әнкәңне калдырып,
Туган илдән ерак киттең.

(Үрән һәм Кызылсу авылы картларыннан язып алдык.)

Көләрмен мин, елый дошман
Бәнем бәхетем ачылганда,
Йөрәгенә төшә хәсрәт
Утый бездә басылганда!

(Ульяновск өлкәсе, Димитровград шәһәре, Сара Сафиуллина (1894 елгы) бирде. Куйбышев өлкәсе, Иске Җүрәй авылы картлары да расладылар.)

Ашап карачы бер кашык ашымны,
Кара кашларың ашады башымны!

Күңелем пакь улса,
Кальбем саф улыр,
Кальбем саф улса,
Күңелем шат улыр!

Х. ТАЗЮКОВ

# БӘХЕТКӘ ЮЛ — ГЕЛ АЛДА

*М. Хәбибуллинның иҗат портретына штрихлар*

Тормышның үзеннән килгән! Без бу сүзләрне Мөсәгыйть Хәбибуллинга карата әйтәбез икән, хакыйкатькә хилафлык китермәбездер. Чөнки ул әдәбиятка чын мәгънәсендә тормышның озын һәм катлаулы борылмаларын үтеп, аның кояшлы утрауларын да, күләгәле почмакларын да, җил-яңгырын, карын-бозын да күреп-тоеп килгән язучы. Ил биографиясендәге олы вакыйгалар аның да күңеленә эз салып үткәннәр.

М. Хәбибуллинның яшьлеге сугыш елларына туры килә. 1941 елның дәһшәтле 22 июнь таңы атканда аңа әле ундүрт яшь тә тулып җитмәгән була. Афәт кешене бик иртә җитлектерә шул — башка бик күп авыл малайлары кебек ул да колхоз эшенә муеннан кереп чума: җир сөрә, язгы чәчүдә катнаша, лабогрейкада ашлык ура, хәтта суктыргыч машинаны эшләтә. Ләкин озак та үтми, аңа үзенең туган якларын — Оренбург далаларын ташлап китәргә туры килә — ул бу өлкәнең Абдуллин районы, Габдрахман авылында туып үсә — язмыш җиле аны Урал тауларына, Магнитогорск шәһәренә китерә. Колхозда кирәк-сәнәк кенә тотып эшләгән малай биредә токарь һөнәрен үзләштерә. Заводта эшли башлый.

Бераздан техникумга укырга керә һәм аны тәмамлагач, Башкортстанның Октябрьск шәһәренә күчеп килеп, бораулау конторасында мастер булып эшли. Күп вакыт та узмый, еллар һәм юллар аны яңадан туган авылына алып кайталар. Ул колхозда инженер-механик булып эшкә урнаша.

1959 елда булачак язучыбыз Татарстанга килә. Баулыда башта шофер булып, аннары «Байрак» исемле район газетасының промышленность бүлегендә эшли. Читтән торып Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. 1970 елда Татарстан Язучылар союзы чакыруы буенча Казанга килә һәм союз идарәсенең секретаре итеп билгеләнә.

Тормыш анкетасыннан алынган шушы саран мәгълүматлар да аның шактый кызыклы биографиясе булуы турында искәртәләр. Ләкин язучының хезмәте үткән тормыш юллары белән генә түгел, барыннан да элек, күңел җимешләре — китаплары белән билгеләнә. Аның төп язмышы — язган әсәрләре, әдәби мирасы. Сүз шулар хакында.

Мөсәгыйть Хәбибуллинның күләмле беренче әсәре «Унсигезенче яз» повесте булды. Унсигезенче язын каршылаучы яшүсмер кызның тормышның асылы, яшәүнең мәгънәсе турында уйлануларын, гомумән аның, үз язмышына хуҗа булып, хаятка беренче мөстәкыйль адым ясаган чактагы кичерешләрен чагылдырган әсәр иде ул.

Әгәр биектән, бик биектән күз ташласаң, кешеләрнең яшәеше дә нинди дер кырмыскалар чабышуы кебегрәк буталчык хәрәкәтне хәтерләтер иде, диләр. Әйе, мәга-



ен, шулайдыр, әмма бу беренче карашка гына. Чөнки өнә шул буталчык булып күренгән хәрәкәтләрнең асыл нигезендә билгеле бер законнчалыклар, бетмәс-төкәнмәс эчке һәм тышкы бәйләнешләр, безгә билгеле һәм билгесез бихисап серләр ята.

Тормыш бусагасын әле атлап кына кергән яшүсмер өчен хәят та шул кырмыска оясы сыман серле бер нәрсә ич. Тагы да төгәлрәк әйтсәң, ул кырмыска оясына карап: «Кая чаба бу мәхлуклар», дип сөрән салган бәндә хәлендә генә. Бу дөньяда аңа шактый нәрсә таныш кебек һәм шул ук вакытта әле бик күп нәрсәләр таныш та түгел. Тормышка аяк атлаган һәр кеше алдында тылсымлы һәм могҗизави олы дөнья киңлеге ачыла. Ул андагы күренешләрнең серен ачарга, аңа үзенчә бәя бирергә, анализларга тиеш. Повестьның төп герое яшүсмер кыз Әнрүсә өнә шундый олы һәм катлаулы дөньяга килеп керә. Юк, бу дөнья Әнрүсәне үзенең серлелеге белән куркытмый, кеше табигатенә хас танып белергә омтылучанлык аны тормыш эченә бөтереп алып кереп китә, алга җилкендерә. Ул эзли, таба, югалта, тагын таба. Һәм Әнрүсә безгә үзенең өнә шул югалту-табышлары хакында сабыйларча беркатлылык белән бәйнә-бәйнә сөйләп бирә.

... Әнрүсәнең эшләре шәптән түгел әле, җырчы булу теләге челпәрәмә килде, үтә алмады. Нишләргә? Кая барып төртелергә? Кай тарафка карап юл тотарга? Әй, күрсәтүче булсын иде: нинди юллар илтә икән бәхеткә табан? Ни генә булмасын, кешеләр арасына ашыгырга кирәк — аның карары шундый. Һәм менә ул нефть чыгару конторасына лаборант ярдәмчесе булып эшкә килә. Эшкә, кешеләр белән якыннан аралашуга сусаган яшь күңел тиз арада үсенеп, канатланып китә. Бирредә ул үзенә чын дуслар, турылыклы юлдашлар таба. Шуларның берсе, иң якыны — Вәсил. Ул тормышны Әнрүсәгә караганда күбрәк күргән, тормышта аның үз принциплары, кыйблас бар: туры сүзлелек, гомуми эш өчен чын күңелдән яну, максатка ирешү юлында авырлыклар алдында туктап калмау хас аңа. Вәсил Әнрүсәдә дә шундый характер тәрбияләргә омтыла. «Әй син бирешмә, тагын бер сынап кара. Үз-үзеңне сына! Нигә сәләтле син: яшьлек хыялың буш куык кынамы, әллә булса киләчәк өметеңме? Әйтик, синнән опера артисткасы чыкмасын да, ди. Шуннан ни? Шуның белән барысы да җимерелергә тиешме? Юк, тагын бер тапкыр юк. Ә нигә, әйтик, бу хыялыңны тормышка ашыру өчен үзешчән сәнгать түгәрәгенә йөрмәскә. Хезмәтен түбәннән башлаган кешенең эше уң була, диләр. Берәүләр сине тыңлаудан ләззәт алыр, икенчеләренә синең җырың көч-куәт бирер, ә сиңа моннан ышаныч килер. Тормыш итү ул — көрәш, беләсең килсә».

Вәсил белән танышканнан соң, Әнрүсәнең сәлпәрәя башлаган канатлары кабат ныгый башлый. Авыр булыр, әмма ул барыбер үзенең максатына — бәхет вәгъдә иткән аргы ярга җитәр. Ул хәзер үзендә көч тә, ышаныч та сизә.

Кешеләрне якыннанрак белгән саен, Әнрүсә үз күңелендә торган саен күбрәк ачышлар ясый. Тормыш берәүне дә иркәләп, якты, җылы нурлары белән назлап кына тормый икән ләбаса. Ул кешене һәр адымында сынап тора икән. Менә, кара инде, ул лаборатория мөдире Ләйсән Хафизовнаны нинди бәхетле кеше дип йөри иде. Айхәл абый белән пар күгәрченнәрдәй яшиләр кебек иде бит, югыйсә. Баксаң...

«— Сез, сез, — дидем мин берәвык уңайсызланып торсам да, — Айхәл абыйны яратмыйсызмыни?..

— Мин ансыз — канатсыз кош. Күргәнең бармы, очып китмәсеннәр дип зоопарктагы очар кошларның канатларын кисәләр. Кызганыч аларга каравы. Алар, башларын кырын сала-сала, зәмраган зәңгәр һавага карыйлар. Аннан очып үткән кошларны күрәләр һәм, кайгылы-сагышлы аваз салып, каңгырып, канатларын җилпеп алалар. Тик

күтәрелеп кенә китә алмыйлар. Менә мин дә шул канаты киселгән кош сыман дөнья көтәм, семья хакы дип яши бирәм...»

Әнрүсә әнә шулай тормышның эчке каршылыкларын тирәнрәк аңлый бара. Яшәүнең асылы нидән гыйбарәт?! — һич көтмәгәндә, уйламаганда җавап таба ул бу сорауга, тормыш үзе җавап бирә. ...Әнрүсә үзешчән сәнгать түгәрәгенә йөри башлый. Казанга смотрга киләләр. Анда Мөнирә апасы белән очраша, күзгә-күз карап сөйләшәләр. Бөтенләй башка сыймаслык хәл ич — Мөнирә апасы аның үз әнисе икән, аңа бөтенләй башка, ят кеше күңел җылысын биргән икән. Юк, юк, аның әнисе бер генә — ул вафат инде. Әни дә, әти дә бер генә бу дөньяда, бер генә була ала! Мөнирә апасы (әйе, ул апа гына!) аны ташлап киткән — сабый чакта, бернәрсә дә белмәгән вакытта, сәнгатькә хезмәт итәм, үсәм дип. Бердәнбер юлмы бу?! Нигә соң әтисе ташлап китмәгән, ул да бит үсәргә тиешле, талантлы кеше булган?!

Өермәдәй булып узган шушы вакыйга Әнрүсәнең күңелен бөтенләй актарып ташлый. Я, кайсы бәхетсезрәк аларның: Мөнирә апасымы, әтисеме? Юк, кайсы бәхетлерәк?.. Гомумән, бәхетсезме алар әтисе белән?! Әнрүсә смотрда җиңеп кайтты, җырларга Мәскәүгә барачак. Ул максатына иреште, ул җырлый, җырчы булачак.

«... Әти миңа карый да, бөтен уй-кайгыларын онытып, көлеп җибәрә. Ул шат һәм бәхетле. Мин дә». Әйе, вафат булган әнисеннән дә сөйкемлерәк, көннәр буе сөйләшмичә, үз эченә бикләнеп, уйланып йөрүче әтисеннән дә кадерлерәк кеше юк бу дөньяда Әнрүсә өчен. Ярата аны әтисе.

Яшь кыз Әнрүсәнең рухындагы төп үсеш этаплары, рухи ачышлары менә шушылардан гыйбарәт. Ул хәзер шуңа инана: тормыш, яшәү компасы һәр вакыт бәхеткә табан юл күрсәтеп тора. Югалтулар да булыр, әмма кеше кеше булып калган очракта чын бәхет барыбер килер!

Әсәрнең шушындый якты идея белән сугарылуы аны укучылар күңеленә якынайта — җәмәгатьчелек повестьны чыннан да шактый җылы каршылады. Ләкин шул ук вакытта бу повестьта яшь авторның кайбер кимчелекләре дә төсмерләнеп калды. Дөресен әйтик, язманың башында без кырмыскалар оясы турында юкка гына бәхәс куертмадык. Безнеңчә, Мөсәгыйть Хәбибуллин бу әсәрендә тормышны чын художник буларак күзәтеп җиткерә алмады әле. Психологик мотивлаштыруның йомшаграк булуы, хис-кичерешләрне вакыйга-картиналар аша сурәтлисе урынга, күп урында аларны сөйләп кенә чыгу, билгеле ки, әсәрнең ритм-динамикасын, тәэсир-тылсым көчен беркадәр кимәтә төште. Шулай ук Мөнирә белән Галимнең рухи дөньялары, аларның «эчке механизмын» хәрәкәткә китерүче идеяләрнең зәгыйфьрәк тасвирлануы да (юкса, Галим эчә дә «кунак» җыя, аннары тагын көннәр буе авызына су кабып утыра: бу «йомыкый»ның эчендә ниләр бар — укучылар аны күрми дә диярлек) әсәрнең бөтенлегенә зыян китерә.

Французлар: «Исем әле җисем түгел»,— диләр диюен, ләкин М. Хәбибуллинның «Икмәк кадере» повестена салынган төп идея аның исеменнән үк башлана дисәк тә ялгыш булмас. Әсәрдә нәкъ менә «икмәк кадере» турында сүз бара һәм икмәккә — ипекәйгә мөнәсәбәттә геройларның мораль һәм рухи дөньялары ачыла.

Повестьның сюжеты гади: скважинада авария булу сәбәпле колхозның уҗым басуына нефть ага — төп вакыйга шуннан гыйбарәт. «Гаепләүче», билгеле, колхоз председателе Сәхаб Кадыйров, «гаепләнүче» — нефть чыгару идарәсе начальнигы Вәкил Ходайбирдин, «тикшерүче» — район партия бюросы һәм район партия комитетында яңа гына эшли башлаган беренче секретарь Бакир Галиев.

Бирედә бер сорау туа: ни өчен соң әле уҗым басуына нефть агу вакыйгасы шул кадәре җәнҗал тесен ала? Әмма эш аның белән генә чикләнми, асылда бер-берсенә капма-каршы булган ике төрле фәлсәфә, ипигә, җиргә, ахыр чиктә, тормышка, яшәүгә карата булган ике төрле мөнәсәбәт бәрелешкә керә монда. Бит бер дә юкка гына Сәхаб Кадыйровның да, Вәкил Ходайбирдиннең дә үткән тормыш юлларын, яшәү принципларын, дөньяга карашларын тәфсиллəп сөйләп бирми автор, ул аларның җаны һәм рухы белән идарә итүче эчке импульсларның нинди учактан очкын алуларын киңрәк тасвирларга омтыла.

Сәхаб — җир кешесе, гомере буе җиргә бил бөккән, җиргә баш игән игенче. Аның «кендеге җиргә береккән». Туендыручы һәм киендерүче җирдән дә кадерлерәк, тереклек чыганагы ипекәйдән дә изгерәк нәрсә юк аның өчен. Шуңа күрә дә

Сәхаб нефтьчеләрнең җирне теткәләп, пычратып бетерүләрен тыныч кына кичерә алмый.

«— Карагыз, нишләткәнсез җирне! Монда кайчан икмәк үсәчәк? Бу җир кайчан чәчәргә яраклы булыр? Беләсезме сез шуны, юкмы?! — дип, сафура бураннары чыгарып орыша иде». Ләкин соңгы «ЧП» аны бөтенләй чыгырыннан чыгара. Нефтькә баткан иген кырын күргә ул, йөрәге әрнеп, идарә начальнигына элдерә. Ходайбирдиннең күн диванга күмелеп тыныч кына тәмәке тартып утыруын күргәч, бөтенләй кабынып китә:

«— Скважинагыз шартлаган!.. Бөтен басуны нефть баса, ә сез тәмәке тартып тынычланып утырасыз... Оят түгелме?!»

Ходайбирдин исә бөтенләй икенче төрле фикер йөртә: «... Без аларга бу җирләрне пычраткан өчен дөнья чаклы акча түлибез. Нәрсә оттыралар алар?! Икмәк бәясе — нефть бәясе түгел! Без нефтьне алтынга сатабыз!..»

Икмәк бәясе — нефть бәясе түгел, имеш. Хәер, Ходайбирдиннең болай әйтүендә бер дә гаҗәпләнерлек нәрсә дә юк-югын. Иман дигән кыйбласының үз кулларыннан тайпылуы белән ул моңа инде күптән әзер иде. Институтны тәмамлап чыкмас борын ул, аны-моны исәпкә-санга сукмыйча, тизрәк начальник булырга, креслога менеп кунакларга ашыга. Һәм теләгенә дә ирешә. Бораулау конторасында баш инженер булып эшли башлый. Тик башбаштак характеры аның үз юлына киртә булып ята — беренче адымыннан ук ул кирегә каера башлый. Ул бөтен нәрсәне акчага гына кайтарып исәпли, ә мораль җаваплылык сизми. «— Беләсезме сез электр линиясен бер сәгатькә өзү күпмегә төшә? — диде Вәкил... Һаман тынычлана алмыйча сукранып торган бригадирга. — Сәгате ничәмә йөз сумга. Ә бодай җиренең бәясе аның ярты хакына да тормый...»

Аннары поши белән булган мәләкә, кыздырырга дип алып кайткан тере балыкларны ваннага җибәрү мәсьәләсендә кыз белән ата арасындагы бәрелеш! Кечкенә генә детальләр, әмма алар Вәкилнең характер сыйфатларын ачарга ярдәм итә.

Вакыйгаларның логик үсеше нигезендә Сәхаб белән Вәкил арасындагы конфликт иртәме-соңмы чишелергә тиеш иде. Һәм шулай була да: райком бюросы утырышында алар бөтенләй икесе ике якка китеп баралар. Сәхабның райком өстәле өстенә пешкән ипи куеп сөйләгән сүзләре ышандыргыч, көчле яңгырый». «— Кем таптый ала шушы икмәкне? Кем?!. Ә менә болар таптыйлар, ике аяклап менеп таптыйлар!..»

Вәкилнең астыртын көлүдән башка дәлиле юк: «— Иптәш Кадыйров, ипиегезне алып китегез, монда ач кешеләр юк». Бу сүзләр Вәкилнең үз өстенә гаепләү акты булып әйләнеп кайталар — күккә таш атсаң, үз башыңа төшүе мөмкин шул.

Әсәрдә башка сюжет сызыклары да бар, әмма бу очракта аларга тукталып торуның хаҗәте юк кебек. «Икмәк кадере» әсәренең идея максаты ачык: халык хәтере, халык күңеле, халык иманы булган икмәк образы аша кешеләр күңелендәге изге тойгыларны уяту, каткан күңеллелеккә каршы бер нәфрәт сүзе әйтү.

Ибраһим Гази бер чыгышында болай дип сөйләгән: «Икмәк кадере» повестен зур канәгатьләнү белән укып чыктым. Әсәр тормышны тирәнтен белеп язылган. Авторның әдәбиятка зур тормыш тәҗрибәсе белән килүе әсәреннән үк күренеп тора. Язучы өчен тормыш тәҗрибәсе бик зур сыйфат. Әсәрдә аеруча колхоз председателе һәм нефть идарәләре оешмаларының җитәкчеләре яхшы сурәтләнгән». Мөсәгыйть Хәбибуллинның аннан соң иҗат ителгән әсәрләре дә тормышны яхшы белеп язылган. КамАЗ төзүче шоферларга багышланган «Тау белән тау очрашмаса да...» повесте һәм авыл тормышын чагылдырган «Чоңгыллар» романы турында да шушы ук сүзләрне әйтергә мөмкин. Бу әсәрләрендә дә автор хезмәт поэтикасын, хезмәт романтикасын тасвирларга омтыла.

... М. Хәбибуллин үзе байтак еллар шофер булып эшләгән кеше. «Тау белән тау очрашмаса да...» повестенда без шушы авыр һәм катлаулы профессия кешеләренең тормышын, аларның кыен юлларда, иң җаваплы һәм авыр вакытларда да үзара ярдәмләшүен күрсәткән байтак уңышлы сәхифәләрне очратабыз. Аның геройлары юлны, машинаны һәм шулай ук тизлекне күңелләре белән тоялар...

Анысы шулай, әмма автор кайчак дуганы артыграк бөгеп җибәрмиме дигән шик тә туа. Кайсы гына әсәрне алма — авария, интрига. «Тау белән тау очрашмаса да...»

повестенда да шулай. Дөрес, дөнья булгач барысы да булырга мөмкин, ләкин язучы хәл-вакыйгаларның кайдан, ни сәбәпле килеп чыгуын, аларның социаль нигезләрен укучыларына дәлилләп аңлатырга, ышандырырлык итеп мотивлаштырырга тиеш. «—... Зөлфәт үз машинасының моторы тартмаганын да, шул мотор белән тауга менәсе барын да яхшы белә, шулай булса да балластны нормадан уздырып салдыра. Бу очракта безгә автор нияте генә аңлашыла: аңа тау менгәндә киеренке ситуация тудырырга кирәк. Ә менә аның герое нәрсә уйлый икән? Күңеленнән нинди хисләр, кичерешләр үтеп китә? Шуларга психологик нигезле, дәлилле җаваплар тапканда гына без геройларның сәер эш-хәрәкәтләрен кабул итә алабыз»,[1] — дип әйтүе белән Фәрит Хатипов хаклы. Психологик анализ булмадымы, әсәрнең кеше күңелен өйрәнүдән производство, технология мәсьәләләрен тикшерүгә кайтып каласын көт тә тор инде. Кызганычка каршы, соңгы еллар татар прозасына хас мондый кимчелекләр Мөсәгыйть Хәбибуллин иҗатында да төсмерләнә. Бу бәладән «Чоңгыллар» романы да тулысынча азат түгел әле.

Сүз дә юк, Мөсәгыйть Хәбибуллинның әдәби осталыгы үскәннән-үсә бара, моны берничек тә инкарь итеп булмый, ләкин әдәбият та язучы алдына торган саен зуррак бурычлар куя тора бит...

... Мөсәгыйть Хәбибуллинның әдәбият мәйданына килеп керүенә әле күп түгел. Шулай да инде ул берничә повесть, хикәяләр һәм роман авторы. Татар прозасында актив эшләп килүчеләрнең берсе. Акыл утырткан, тормыш тәҗрибәсе туплаган илле яшьлек ир-егет. Шулай икән, аның, артка әйләнеп карап, үткән юлына, кылган эшләренә карата нәтиҗә ясарлык, шулардан чыгып киләчәккә юл сызарлык хатирәләре дә бардыр. Язучы буларак, Мөсәгыйть Хәбибуллин алдында бер зур баскыч тора — производство-технология мәсьәләләрен полемик рәвештә алгы планга чыгарып иҗат ителгән әсәрләрдән югарырак күтәрелеп, кеше күңеленең бетмәс-төкәнмәс байлыкларын, мәңге кипмәс чишмәләрен зурлап җырлаган, чынбарлыкны художникларча фәлсәфи тасвирлаган әдәбият мәйданында тагы да алга үтәсе бар аның. Язучыны ачылмаган яңа әдәби катламнар — бәхетле мизгелләр көтә. Бәхеткә юл — гел алда.

**НАИС ГАМБӘРОВ.**

---

[1] «Казан утлары», 1976 ел, 8 сан, 161 бит.

# ПРОЗАБЫЗ ТУРЫНДА ХЕЗМӘТ

Интернациональ пафослы күп милләтле совет әдәбияты совет халыкларын эстетик тәрбияләүдә, аларның рухи бердәмлеген көчәйтүдә гаять зур роль уйный. Безнең күп телле әдәбиятларыбызның хәзерге чордагы үсеш үзенчәлеге шунда ки, алар уртак идея-эстетик принциплар, уртак закончалыклар нигезендә бер-берсен баетышып, тулыландырып, бер-беренә якынаеп үсәләр, чәчәк аталар. Илебездә һәр милли әдәбиятның иң яхшы үрнәкләрен совет халкының уртак рухи казанышы итү өчен бөтен шартлар тудырылган. Шул уңайдан милләтара телгә әверелгән рус теле аеруча зур роль уйный. Бу телдә илебез халыкларының дүрттән өч өлеше иркенләп сөйләшә ала икән, димәк, рус телендәге әдәбият белән дә шул кадәрле укучы танышa ала дигән сүз. Тагы шунысы да бар, милли әдәбиятларның рус теленә тәрҗемә ителгән иң яхшы казанышлары чит илләргә дә юл тота.

Төрле милләтләрнең рухи, шул исәптән әдәби хәзинәләрен барлык халыкларга җиткерүдә рус телендә чыккан фәнни һәм популяр хезмәтләр дә зур роль уйныйлар. Алар рухи культурабызның төрле өлкәләрендә, бу очракта әдәбиятта ирешелгән уңышларны, иҗади эзләнүләрне, хәл кылынасы мәсьәләләрне, үсеш тенденцияләрен бер процесс итеп күзалларга мөмкинлек бирә, бөтенсоюз укучысының әдәби офыгын киңәйтә алалар.

Әйтергә кирәк, мондый хезмәтләргә аеруча зур җаваплылык йөкләнә, чөнки алардан әдәби процессны бөтенсоюз укучысына объектив рәвештә иң характерлы тенденцияләре һәм сыйфатлары белән җиткерү таләп ителә. Әдәбият белгече һәм тәнкыйтьче Флүн Мусин, үз өстенә әнә шундый җаваплылык алып, «Тормыш координатлары буенча» дигән исем астында бүгенге татар прозасы турындагы уйлануларын, күзәтүләрен, фикерләрен Мәскәүдә «Современник» нәшриятында бастырып чыгарды. Баштан ук кисәтеп куйыйк: автор үз иңенә алган җаваплы вазифаны нигездә уңышлы башкарган.

Әлеге хезмәттә әдәбиятыбызның төп үсеш юнәлешен билгеләүче тармагы — прозаның 60—70 нче еллардагы сыйфат үзгәрешләре, проблемалары, үсеш тенденцияләре, кимчелекләре, чишәсе мәсьәләләре игътибар үзәгендә.

Китап соңгы еллар прозасының барлык тематик һәм стиль юнәлешләрен, төрле буын язучыларның әһәмиятле әсәрләрен үз эченә сыйдырган, нигез принциплар җирлегендә классификацияләгән, анализлаган һәм гомумиләштергән.

Ф. Мусин тарихка, авыл проблемаларына яисә эшчеләр сыйныфы тормышына багышланган әдәби әсәрләрне тикшергәндә элек-электән тамыр җәйгән һәм үстерелеп килгән традицияләрне гел күз уңында тота. Мәсьәләгә болай якын килүнең әдәбият фәне өчен зур әһәмияте бар. Мондый методологик алым әдәбият үсешенең мөһим бер закончалыгын — дәвамчанлыгын, икенче төрле әйтсәк, традицияләр белән новаторлыкның нисбәтен күзәтергә, бүгенге чорның, теге яки бу язучының мәгълүм темасы ачуга керткән өлешен, яңалыгын ачыкларга мөмкинлек бирә. Шуның өстенә фәнни тикшеренүнең бу алымы әдәбият үсешен бөтенлекле бер процесс итеп күз алдына китерергә ярдәм итә. Нәтиҗәдә 60—70 нче еллардагы прозаның табышлары һәм югалтулары калку булып күз алдына килеп баса. Бер мисал китерик. Соңгы елларда иҗат ителгән тарихи роман һәм повестьларны анализлаганда автор Г. Тукай, Г. Ибраһимов, М. Гафури,

М. Галәү, К. Нәҗми сызып калдырган буразналардан әйләнеп кайта, алар чәчеп калдырган орлыкларның җимешләрен барлый, шул җимешләрнең кайсысы бүген янә дә тирәнрәк тамырлар җибәргән — шуңа игътибарны юнәлтә. Икенче төрле әйтсәк, Ф. Мусин тарихилык принцибының киң мөмкинлекләрен шактый уңышлы төстә эшкә җиккән, бүгенгедән кичәгегә, кичәгедән бүгенгегә ныклы күпер сала алган. Моның исә бөтенсоюз укучысы өчен файдасы аеруча зур.

Соңгы еллар татар прозасының үсешен күзәткәндә автор үзгәрешләрне һәм яңалыкларны бүтән милли әдәбиятлардагы күренешләр һәм фактлар белән чагыштырып анализларга омтыла. Әйтик, халкыбызның бүгенге фидакарьлеген тарихи яссылыкта күрсәтү тенденциясенең өстенлек ала баруы хакында сөйләгәндә, Ф. Мусин төркмән әдибе Б. Кербабаев, үзбәк язучысы Җ. Абдуллаханов әсәрләренә мөрәҗәгать итә. Яисә Г. Ахуновның «Хәзинә» романындагы Кәрим Тимбиков образы турында сүз чыкканда аны әзербәйҗан язучысы С. Велиев һәм казакъ З. Кабдулов әсәрләренең геройлары белән чагыштыра, алар арасында уртаклыклар һәм аерымлыклар таба. Нәтиҗәдә әдәби анализның колачы киңәя, гомумиләштерүләр дәлилле булып чыга. Дөрес, китапта мондый чагыштыру-параллельләр аерым очракта тышкы охшашлыкларга корылган. Әмма шунысы әһәмиятле: милли әдәбиятларның казанышларын үзара чагыштырып өйрәнү әдәбият фәненең бүгенге үсеш стадиясендә бик тә мөһим методологик таләп булып тора. Ул һәр милли әдәбиятка хас үзенчәлекләрне дә, гомумсовет әдәбиятына хас закончалыкларны да тоемларга, ягъни интернациональ һәм милли моментларның нисбәтен ачарга ярдәм итә.

Ф. Мусин татар прозасының 60—70 нче еллардагы хәлен хәзерге әдәбият фәне ирешкән казанышлар югарылыгында күздән кичерергә тырыша. Автор уңае чыккан саен теоретик мәсьәләләргә, әдәби бәхәсләргә мөрәҗәгать итә, теге яки бу теоретик проблемага кагылышлы карашларны бәян кыла, аларга карата үзенең фикерен әйтә. Уңай герой, роман жанрының тамырлары, дастаный хикәяләүнең үзенчәлекләре, прозада документаль нигез, әдәбиятның публицистик пафосы, традицияләрне файдалану юллары, герой һәм мохит, милли стиль кебек проблемаларга китапта шактый зур урын бирелгән. Шунысы аеруча әһәмиятле, әлеге мәсьәләләр абстракт төстә генә түгел, ә аерым әсәрләр һәм конкрет әдәби күренешләрне анализлау барышында куела. Мәсәлән, автор соңгы елларда татар әдәбиятында повесть жанрының активлашуын раслый һәм шул уңайдан бу жанрга карата үзенең карашын бәян итә, аның алгы планга чыгуының сәбәпләрен ачыклый, кызыклы гомумиләштерүләр ясый. Әмма китапта күтәрелгән кайбер теоретик мәсьәләләрнең өстән-өстән генә хәл кылынуын яисә дөрес аңлатылмавын да әйтеп үтәргә кирәк. Мәсәлән, Ф. Хәсни иҗатын тикшерү җәһәтеннән Ф. Мусин милли стиль, аның асылы һәм үзенчәлеге кебек теоретик мәсьәләләрне куя һәм аларны ике-өч биттә «чишеп» чыга. Югыйсә, бу — махсус тикшеренүне сорый торган бик җитди теоретик проблема. Шунда ук «кечкенә кешегә» игътибарлы булу татар прозасының күптәннән килгән бер милли традициясе дип игълан итә (81 бит) һәм шул фикерне Ф. Хәснинең берничә әсәре белән «дәлилләп» тә бирә. Заманында бу мәсьәлә безнең әдәби тәнкыйтьтә күтәрелгән һәм аңа күпмедер дәрәҗәдә ачыклык та кертелгән иде инде. Хәтерләвебезчә, «кечкенә кеше» концепциясе кире кагылган иде. Шулай икән, аны янәдән өстерәп чыгарып татар әдәбиятының милли традициясе яки милли стиленең бер үзенчәлеге итеп күрсәтү нигә кирәкте икән? Мондый моментларны тагын да китерергә булыр иде. Әмма бер нәрсә ачык: авторның теория белән яхшы таныш булуы һәм әдәби күренешләрне анализлаганда аңа таянуы һәрьяклап хупланырга тиешле. Кызганычка каршы, безнең әдәбиятка багышланган байтак хезмәтләрдә нәкъ менә теориягә игътибарның җитмәве күзәтелә.

Югарыда саналган моментлар Ф. Мусин китабын киң сулышлы, дәлилле һәм бөтенлекле иткәннәр. Нәтиҗәдә 60—70 нче еллар татар прозасы ялгыз бер утрау булып түгел, ә үзенең кан тамырлары белән узганга да, күп милләтле совет әдәбиятының бүгенгесенә дә, әдәбиятның башка төрләренә дә (поэзия, драматургия) бәйләнеп үсә торган җанлы һәм бөтенлекле бер процесс булып күз алдына килеп баса.

Китапның «Узганнарга хөрмәт белән» дигән беренче бүлегендә халкыбызның үткән тормышы һәм тарихын гәүдәләндергән әсәрләр тикшерелә. Тарихка игътибар артуны Ф. Мусин ике сәбәп белән аңлата.

Беренчедән, социалистик милләтләрнең чәчәк атуы шартларында халыкның үзаңы үсә, аларның үз тарихлары белән кызыксынуы арта. Икенчедән, фән-техника революциясе кешелек яшәешенең табигый башлангычлары проблемасына аерым бер актуальлек бирә. Кызу темплар белән бара торган урбанизация чорында кеше үзенең үткәне белән элемтәсен тирәнрәк тоя. Сүз дә юк, узганнарга игътибар өзлексез арта баруны бу факторлар белән генә чикләргә ярамый. Әмма искә алынган факторларның безнең көннәрдә алгы планга чыгуы бәхәссез. Автор тарихи прозада узганнарның фәлсәфи асылына төшенү, аны сәнгатьчә тирәнтен гәүдәләндерү, жанр һәм стиль җәһәтеннән актив иҗади эзләнүләр алып барылуын күрсәтә. Ф. Мусин прозада тарихи тасвирлауның ике тибын игътибар үзәгенә куя. Аның фикеренчә, беренче тип бай документаль материалга нигезләнә, конкрет тарихи вакыйгаларга һәм шәхесләргә багышлана. Икенче тип тасвирлау исә документаль төгәллеккә дәгъва итми, һәм бу очракта автор фантазиясенә киң юл ачыла. Тегe яки бу әсәрдә бу ике тип тасвирлау үзара үрелеп барырга да мөмкин. Күп милләтле совет прозасында күзәтелә торган бу тенденциянең татар әдәбиятында да тамырланып урнаша баруын Ф. Мусин бай фактик материал җирлегендә исбат итә. Н. Фәттах, Г. Бәширов, И. Гази, Г. Гобәй, Г. Минский, А. Расих, Г. Әпсәләмов һәм күп кенә башка авторларның халкыбызның борынгы тарихына, XX гасырдагы тормышына (социалистик революция, социалистик төзелеш этаплары, Бөек Ватан сугышы, сугыштан соңгы еллар) багышланган әсәрләрен анализлап, автор шундый нәтиҗәгә килә: хәзерге әдипләребез тарихилык принцибын тирәнрәк төшенеп эш итәләр, халкыбызның рухи тормышына тирәнрәк үтеп керәләр, фәлсәфи-әхлакый проблемаларга күбрәк игътибар юнәлтәләр, аналитик пафосны көчәйтәләр. Авторның аерым әсәрләргә, аерым образларга бирелгән бәяләмәләре, аерым теоретик нәтиҗәләре белән килешмәскә, бәхәскә керергә мөмкин, әмма, безнеңчә, гомуми тенденция дөрес тотып алынган. һәм әлеге нәтиҗә әдәби процессны тарих барышы, тормыш агышы белән чагыштырып карап конкрет анализлау җирлегендә ясалган.

Хезмәтнең икенче бүлегендә автор сугыш еллары һәм сугыштан соңгы авыл тормышын тасвирлаган әсәрләргә тукталa. Г. Бәширов, Р. Төхфәтуллин, А. Гыйләҗев, Ә. Баянов, Ә. Еники, Б. Камалов, А. Расих, С. Рафиков, Г. Ахунов, Х. Хәйруллин, В. Нуруллин, М. Хәбибуллин һәм башка әдипләрнең әсәрләрен күзәтеп, Ф. Мусин «иске» теманы ачудагы яңарыш-үзгәрешләрне барлый. Тормыш вакыйгаларын сурәтләгәндә аек реалистик анализның көчәюе, фән-техника революциясе чорының җитди проблемалары турында фәлсәфи уйланулар, авыл һәм аның кешеләрен тарихи яссылыкта гәүдәләндерергә тырышу, чынбарлыкны чагылдыруда декларативлыктан качу, проблемалылыкка йөз тоту, әдәби геройның мохит белән үзара бәйләнешын тирәнрәк ачу, авыл темасының җир кешесе темасына әверелүе — автор фикеренчә, соңгы еллар прозасын характерлаучы төп тенденцияләр менә шулар. Ф. Мусин бу тенденцияләр юл ярганда килеп чыккан кыенлыкларга һәм югалтуларга да күз йоммый, аларның сәбәпләрен аңлата. Әмма авторның уңае чыккан саен искәртә килгән бер фикере белән бәхәскә керәсе килә, чөнки ул — нигез фикерләренең берсе. Сүз авыл һәм фән-техника революциясенең диалектикасы турында бара. Ф. Мусин әдәбиятның авылга игътибары артуын фән-техника революциясенең киң колач җәюе белән аңлата. Әлбәттә, бу шулай, хәлбуки, авыл темасы, автор үзе үк раслаганча, бездә иң традицион тема. Ләкин хикмәт анда гына түгел. Ф. Мусин, кайбер авторларга ияреп, авылны гасырлар буе тупланып килгән мораль нигезләрне, халыкның әхлакый тәҗрибәсен, аның күп гасырлык рухи хәзинәләрен саклаучы дип раслый. Әйтерсең лә фән-техника революциясе шул беренчел нигезләргә каршы юнәлтелгән. Чынлыкта эш алай тормый бит. Беренчедән, халыкның бай әхлакый тәҗрибәсен авыл белән генә чикләү дөрес булмас. Икенчедән, фән-техника революциясе авылга, аның кешеләренең аңына һәм психологиясенә кискен үзгәрешләр алып килсә дә, аларны бер-берсенә каршы куярга һич тә ярамый. Авыл беренчел нигезләрне саклаучы архивариус түгел. Ул җәмгыятьнең бүтән сфераларыннан Кытай стенасы белән аерып куелмаган. Гомуми социаль-экономик үзгәрешләр авылны да колачлый. Аннары фән-техника революциясе нәтиҗәләрен мөстәкыйль бер күренеш итеп карарга кирәкми. Алар, беренче чиратта, социаль үсеш законнарына бәйле. Социалистик җәмгыять нәкъ менә фән-техника казанышларын ке-

шегә хезмәткә куярга омтыла, фән һәм табигать, кеше һәм техника арасында гармонияле мөнәсәбәтләр урнаштырырга тырыша. Сүз фән-техника революциясенең авылга йогынтысы турында барганда боларны онытырга ярамас.

Өченче бүлектә Ф. Мусин бүгенге әдәбиятта заман темаларының, беренче чиратта, эшчеләр сыйныфы тормышына кагылышлы темаларның ничек яктыртылуын күздән кичерә. Прозабызның әлеге темага йөз белән борылуын һәм моның сәбәпләрен автор бик дөрес күрсәтә. Эшче темасын яктыртуда Ш. Камал, Г. Ибраһимов, М. Гафури, Һ. Такташ, М. Җәлил, Ф. Кәрим, К. Нәҗми, И. Гази, Г. Әпсәләмов традицияләрен искәртеп, Ф. Мусин 60 нчы еллар татар әдәбиятында әлеге темага игътибарның артуын республикабызда барган зур социаль-экономик үзгәрешләр белән бәйләп карый. Иң элек әдәбиятыбызга нефть һәм нефтьчеләр темасы килеп керде. Туган якның үзгәрүе, нефтьнең Татарстанны дөнья мәйданына алып чыгуы киң яктыртылды ул әсәрләрдә. Әдипләрнең бер ишесе, мәсәлән, Г. Ахунов, халкыбызның бүгенге фидакарь хезмәтен һәм яшәешен тарихи аспектта сурәтләргә омтыла. Эшче темасына багышланган әсәрләрнең уңышларын күрсәтү белән бергә автор кимчелекләр һәм аларны китереп чыгарган сәбәпләр турында да җитди уйлануларга бирелә. Аның фикеренчә, кайбер әдипләрдә, әйтик, Э. Касыймов, Мәхмүт Хәсәнов әсәрләрендә очрый торган кимчелекләр геройларның җәмәгать-производство сферасы һәм шәхси тормышындагы эш-хәрәкәтләрен дөрес бәйли алмаудан, мораль факторларны иҗтимагый-политик факторлардан аерып караудан килеп чыга. Ә менә Ш. Бикчуринның «Каты токым» романындагы уңышын автор нәкъ шул факторларның бердәмлегенә ирешүдә күрә. Геройны хезмәттә күрсәтә белмәү, аның иҗтимагый һәм шәхси тормышын үзара бәйли алмау, персонаж образына социаль анализ һәм бәяләмәләрнең җитәрлек булмавы, аның характерындагы үзгәрешләрне мораль-этик факторлар белән генә аңлатырга омтылу, әсәрләрнең конфликтлары йомшак булу кебек эшче прозасына хас кимчелекләрне Ф. Мусин аерым авторларның шәхси ялгышлары һәм бәлаләре итеп кенә карау ягында тормый, ә яңа тормыш материалын үзләштерү кыенлыклары белән бәйли. Әлбәттә, бу аңлатмаларда зур хакыйкать бар. Ләкин әлеге кимчелекләрнең нигезендә бүтән сәбәпләр дә яшеренеп ятмыймы икән...

Өченче бүлектә интеллигенция тормышына кагылышлы, семья һәм мәхәббәт проблемаларына багышланган әсәрләргә дә махсус игътибар бирелә, шул җәһәттән автор Г. Бәширов, А. Расих, Г. Әпсәләмов, Ф. Хөсни, М. Мәһдиев әсәрләрен анализлый, аларда заманга хас конфликтлар һәм геройлар эзли.

Укучы абайлагандыр, рецензияләнә торган китап кимчелекләрдән һәм бәхәсле моментлардан азат түгел. Аларның кайберләре хакында инде сүз булды. Тагын берничәнә өстик.

60—70 нче еллар прозасы турында сөйләгәндә, Ф. Мусин әдәбиятыбызның әһәмиятле ике жанрын — хикәя һәм очеркларны бөтенләй игътибардан читтә калдыра. Хәлбуки, зур күләмле булмаган бу жанрлар да прозаның үсеш тенденцияләрен билгеләүдә актив катнашалар.

Аннары автор теге яки бу әдәби күренешкә, фактка, әсәргә бәя биргәндә татар әдәбият белгечләренең һәм тәнкыйтьчеләренең хезмәтләрен бик аз файдаланган. Хәлбуки, безнең проза өлкәсендә эшләүче белгечләребез аз түгел, аларның кызыклы күзәтүләре, гомумиләштерүләре бар. Әйтик, тарихи проза хакында сүз алып барганда Х. Хәйри, бүгенге проза турында фикер йөрткәндә Р. Мостафин, Ф. Миңнуллин хезмәтләрен файдаланырга бик мөмкин иде. Ул чагында бөтенсоюз укучысы әдәби тәнкыйтебезнең торышы турында да өлешчә мәгълүмат алган булыр иде.

Хезмәттә бик күп исемнәр һәм әдәби әсәрләр саналган. Монда һәммәсен дә колачларга омтылу теләге үзен нык сиздерә. Безнеңчә, аларның санын киметә төшеп прозабыз үсешенең төп тенденцияләрен гәүдәләндерүче әсәрләргә күбрәк игътибар бирелгән булса, отышлырак чыгар иде.

Әмма йомгак урынына шуны әйтәсе килә: әдәбият фәне өлкәсендә иң актив һәм нәтиҗәле эшләп килүче галимнәрнең берсе булган Ф. Мусин соңгы еллардагы прозабыз турында бөтенсоюз укучысы каршында йөз кызартмаслык җитди хезмәт иҗат иткән, әдәбиятыбызның бик әһәмиятле тармагын тулы бер процесс итеп колачлый алган. Инде туган әдәбиятыбызның бүтән төрләренә һәм жанрларына багышланган яңа китапларны да күрергә насыйп булсын.

**ФЛОРИД ӘГЪЗӘМОВ.**

# УКУЧЫ НИЧЕК КАБУЛ ИТӘР...

Яңа шигырь җыентыгы шагыйрь өчен генә түгел, киң катлам укучылар өчен дә бер вакыйга ул. Әмма нинди вакыйга?.. Менә шундый уйлар белән кулга Бөек Октябрьның данлы юбилее елында дөнья күргән ике җыентык — Фаил Шәфигуллин[1] һәм Разил Вәлиевларның[2] шигырь китапларын алдым. «Дулкынга дулкын» һәм «Яшен тамыры» — аларның беренче китаплары түгел, соңгылары да булмас дип ышанырга кирәк. Һәр ике шагыйрьнең исеме яшь авторлар хисабына инде байтактан кертелми, поэзиябезнең аксакаллары сафына басар өчен дә әле күп вакыт һәм зур иҗат юлы үтәргә кирәк. Кыскасы, сүз ир уртасы булып килгән шагыйрьләр иҗаты турында бара. Шуңа күрә сөйләшүебез дә ирләрчә, егетләрчә булыр дип өметләнергә кирәк. Кыйнасаң — имгәнер, әле яшь, янсә өлкән шагыйрь бит — үпкәләр дип тартынып торыр урын юк.

Рәсүл Гамзатов «Коммунист» журналында (1977, 9 сан) басылган мәкаләсендә, шагыйрьне шагыйрь иткән нәрсә образлы фикерләү һәм рифмалы итеп сөйли белү генә түгел, бәлки аның үз замандашлары күңелендәге әрнү һәм шатлыкларны аңлый, кичерә белүе, — дип саный. Шагыйрь йөрәгендә бөек көч — кешеләргә тартылу хисе яшәргә, кешегә игелек итәргә омтылыш уты дөрләргә тиеш. Җыеп кына әйткәндә, шагыйрь, барыннан да элек, гражданин булырга тиеш дип саный Дагстан халык шагыйре.

Хәер, бу хакта беренче генә ишетүебез түгел, бит Тукайны — Тукай, Такташны — Такташ, Җәлилне — Җәлил иткән, дөресрәге, шагыйрь иткән нәрсә дә — аларның үз кайгы-шатлыкларын онытып, халык һәм ил язмышы өчен янып яшәве, кирәк икән, туган җир өчен газиз җаннарын да кызганмавы түгелмени?.. Гомумән, тормыш юллары зур гражданлык мисалы булып, бөтен иҗаты патриотизм һәм гуманизм идеяләре белән сугарылган әдипләр бездә аз түгел. Аларның бай мирасы әдәбият мәйданына килүче һәр яңа буын өчен якты маяк булып тора.

Р. Вәлиев һәм Ф. Шәфигуллин Тукай, Такташ һәм Җәлил традицияләрен яхшы үзләштереп, әдәбиятка зур теоретик әзерлек белән килүче яңа буын вәкилләре. Заман сулышы һәр ике җыентыкның беренче сәхифәләреннән үк күзгә ташланып тора. Разилның «Мин яшьтәше атом бомбасының...», Фаилнең «Төнге күктән атылып төште яшен...» һәм «Мәңгелек ут» шигырьләре Җир һәм бөтен кешелек язмышы өчен җитди борчылу, соңгы елларда гаять зур актуальлек алган, тынычлыкны саклау проблемасы турында уйланулардан гыйбарәт.

**Мин яшьтәше атом бомбасының...**
**Мин мәңгелек уйда утырам.**
**Галимнәр, сез бомба ясаганда**
**Әниләр бит безне тудырган.**

(Р. Вәлиев.)

**Кем ул төнлә факел тотып чаба**
**Киләчәккә, еллар каршына! —**
**«Уяу булыгыз, кешеләр!» — дигән сүзләр**
**Уелып кала мәйдан ташына.**

(Ф. Шәфигуллин.)

— кебек юлларны укуга ук күз алдына заманыбызны киеренкелеккә тотучы гаять зур әһәмияткә ия булган мәсьәләләр белән янып яшәгән, иҗтимагый-политик позицияләре аермачык булган лирик геройлар килеп баса, шул мизгелдән аларны аңлый башлыйсың, күңелдә үз итү хисе туа. Һәм башка шигырьләрен тагы да бирелебрәк укырга керешәсең.

Тулаем алганда да шагыйрьләрнең һәр икесе тема кытлыгы кичерми. Аларны җирдә иминлек саклау мәсьәләсе бер үк дәрәҗәдә борчыган кебек, туган ил һәм туган җиргә мәхәббәт, аның күрке булган табигатьне саклау темасына да әлеге җыентыкларда зур урын бирелә. Бу ике китапка кергән әсәрләр жанрлары ягыннан

---

[1] Фаил Шәфигуллин. Дулкынга дулкын. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1977.
[2] Разил Вәлиев. Яшен тамыры. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1977.

да шактый охшаш — аларда фәлсәфи һәм лирик шигырьләргә үзәк урын бирелгән, шулай ук ике авторның да лирик җыр текстлары өстендә уңышлы гына эшләп килүләре игътибарны җәлеп итә.

Әмма, бер агач яфраклары да бер-берсенә тулысынча охшамаган кебек, бер-берен кабатлаган ике шагыйрь булмый. Ф. Шәфигуллин һәм Р. Вәлиевларны үзара бутау мөмкин түгел. Аларның үзләрен генә борчыган мәсьәләләр бар, шагыйрьләрнең аерым темаларга мөнәсәбәте, образлы фикер йөртүе, тел һәм стильләрендә дә индивидуальлекләр байтак. Безне нәкъ менә шул үзенчәлекләр кызыксындыра да инде, чөнки аларда авторларның һәм уңай, һәм кимчелекле яклары аеруча ачык булып күзгә ташланып тора.

Фаил Шәфигуллинның «Дулкынга дулкын» җыентыгына якты бер төс биреп торган цикл — ул, әлбәттә, диңгез темасына язылган шигырьләр. Әдәбиятка җиде диңгез кичеп килгән Миргазиян Юныс соңгы елларда прозабызга әлеге теманы яктырткан әсәрләре белән яңа бер сулыш өргән иде инде. Зәңгәр киңлекләрнең иркенлеге, хозурлыгы һәм кырыслыгыннан илһамланып, курку белмәс диңгезчеләргә мәхәббәт һәм соклану белән язылган бу шигырьләр дә укучылар өчен матур бер бүләк булыр дип ышанасы килә. Чөнки ул шигырьләр ерак диңгезләрдә йөзеп, Ватан һәм туган җиргә булган кайнар мәхәббәте тагы бер кат сыналган лирик геройны сурәтли.

**Бала-чага**
**Ярга чаба,**
**Бар да ак туннан.**

**Карап тора**
**Боланнар да**
**һәйкәлләр сыман.**

**И шыгырдый,**
**Нидер җырлый**
**Баскан саен кар.**

**Сагындырган**
**Карлы урам,**
**Нәзек каеннар.**

**Якты йөзләр,**
**Якты күзләр**
**Карый һәр яктан.**

**Бозлар сарган**
**Шушы ярдан**
**Башлана Ватан.**

Шул ук китапта урын алган тагы бер шигъри цикл — хезмәт кешесе һәм производство темасына язылган шигырьләргә дә махсус игътибар юнәлтми үтү ярамас. Бәхәссез, тема үзенең актуальлеге белән гаять зур әһәмияткә ия. Һәм шагыйрьнең, зур җаваплылыктан курыкмый, әлеге темага алынуын хупларга гына кирәк. Әмма Ф. Шәфигуллинга теманың актуальлеге генә әдәби әсәрнең уңышын тәэмин итмәгәнлекне дә онытмаска иде бу очракта. «Тумырган да сөягән, балта-пычкы тимәгән» дигәндәй, ул укучыга шигъри фикерләү һәм сәнгатьле сурәтләү чараларыннан мәхрүм ителгән бер көлтә шигырь тәкъдим итәргә җөрьәт иткән. Тәвәккәллек һәм кыюлык билгеле бер очракларда шагыйрьне бизәсә дә, «Завод җыры», «Кою цехында», «Эш коткара» кебек «тезмәләрне» укыганда һич кенә дә авторның кулын кысасы килми. (Шагыйрь гафу итәр, без ул нәрсәләрне шигырь дип исемли алмадык.)

**Нишләр идем эш булмаса**
**Эч пошканда!**
**Салкын сүздән җаным туңса,**
**Эш коткара,**

— кебек юллар белән автор ни әйтергә теләде икән? Коммунистик җәмгыятьнең материаль-техник базасын төзүче буын өчен хезмәт — эч пошканны басучы бер шөгыль генә микәнни?.. «Коммунистлар» дип исемләнгән шигырьнең дә фикер ягы гаять дәрәҗәдә сай һәм примитив булуын искәртеп узмый ярамас, автор бу очракта да темага шигъри ачкыч таба алмаган. Теманың җаваплылыгы үз-үзеңә таләпчәнлеккә туры пропорциональ бәйләнештә булырга тиешлекне онытмаска иде бит! Шигырьдә күпме генә зур әһәмияткә ия булган мәсьәлә кузгатылмасын, ул һәр очракта да шигырь булып калырга тиеш түгелмени. Бу нәфис һәм гармонияле жанрның коры фәлсәфә, буш сүз, публицистик нотык һәм чиле-пешле язмалар белән ни мөнәсәбәте бар, Фаил?.. Шул уңайдан, нечкә шигъри зәвыкка ия булган олуг тәнкыйтьчебез Г. Ибраһимовның «йөрәктән чыкмаган нәрсә йөрәкләргә керә алмый, диләр»[1] кебек сүзләрен хәтергә төшереп үтәсе килә. «Хыялыңда дөньяга чыгарга ашкынып торган бер сурәт, йөрәгеңдә ташып барган бер тәэсир, бер мәгънә булмагач, үзеңне ник көчләргә...»[2], шигырь язу

[1] Г. Ибраһимов. Әдәбият кануннары. Казан, 1918.
[2] Г. Ибраһимов. Матбугат вә әдәбиятыбызның барышы. «Аң», 1914, 1 сан.

әдәбиятка килгән һәр автор өчен үзмаксат булып тормый лабаса. (Укучыларга Ф. Шәфигуллинның оста хикәяче булуы мәгълүм булса кирәк.)

Хәер, «Дулкынга дулкын» җыентыгында укучының күңелен биләп алырга сәләтле, шагыйрь йөрәгеннән ургылып чыккан хисләр тәэсирендә язылган шигырьләр дә юк түгел. Әйтик, туган як табигатенә сокланып һәм аның язмышын кайгыртып язылган шигырьләрне укып битараф калу мөмкин түгел, аларда җиргә һәм кешеләргә гашыйк шагыйрь образы калку булып күз алдына килеп баса. Ф. Шәфигуллинның табигатькә мөнәсәбәте бигрәк тә шул ягы белән кызыклы, ул аңарга пейзажчы күзлегеннән генә карамый, аның табигать турындагы уйлануларында кешеләрдә булган күркәм һәм тискәре сыйфатлар шигъри чагылыш таба.

**Шыр ялангач кыргый кыяларда,**
**Ташларда да ник гөл үсә соң!**
**Таш бәгырьле кешеләр, дигән сүздән**
**Оялалар ташлар, күрәсең,**

— кебек тирән мәгънәле юллар җыентыкта аз түгел. «Карт чыршы», «Шәфкать туташ», «Тау буенда ялгыз бер карама...», «Каеннар» дип исемләнгән шигырьләр шул хакта сөйли.

Җыентыкта мәхәббәт лирикасына урын соңгы чиратта гына бирелгән, әмма ул шигырьләр урынны поэзия сөючеләребезнең күңел түреннән табар дип ышанырга кирәк, чөнки аларда шагыйрь күңелендә озак йөреп җитлеккән һәм шуннан соң гына кәгазьгә күчерелгән саф поэтик хисләр урын тапкан. Ул шигырьләрдә моң да, сагыш та җитәрлек, күрәмсең, мәхәббәтнең мәңгелек юлдашыдыр инде алар. Ә безгә исә Фаилнең романтик рух һәм ачык төсләр белән өртелгән шигырьләре аеруча якын.

**Хәтерлимсең, ак көймәгә утырып,**
**Ап-ак җилкән корып ак таңда**
**Ак дулкыннар ярып киткән идек**
**Ерактагы ап-ак атауга.**

Шигырь ич, менә дигән юллар! Ф. Шәфигуллинның поэзиядә дә, үз-үзенә таләпчәнлекне бермә-бер арттырган тәкъдирдә, потенциаль мөмкинлекләре аз түгел икән.

Мәхәббәт лирикасына Разил Вәлиев җыентыгында да шактый урын бирелгән, әмма шома гына язылган ул шигырьләрнең күп өлеше укучылар өчен яңалык булмас. «Сөйләмә мәхәббәт турында», «Ядкарь», «Вәгъдә», «Тау кызына», «Сине эзләп мин тауларга мендем...» кебек шигырьләр кемдә генә сәнгать әсәренең куәтенә соклану хисләре уятыр икән? Гадәти альбом шигырьләре диләр андый әсәрләр турында, әмма югары эстетик зәвыкка ия булган заман укучысы үз альбомына күчереп утырырмы соң аларны?..

Ә менә нибарысы бер биткә сыйган ике шигырь — «Әкият» һәм «Гашыйк булгач» турында алай дип әйтеп булмый. Чөнки болары уңышсыз мәхәббәт тарихыннан фрагментлар хикәяләү түгел, күп үзгә, монда бары да — сүзләр дә, төсләр дә, шигъри хисләр дә поэтик гармониягә буйсынган.

**Чишмәдәге сулар — төссез.**
**Булмәдәге һава — төссез.**
**Океан — зәңгәр.**
**Күк тә — зәңгәр.**
**Кайчандыр бу күзләр төссез иде...**
**Хәзер — зәңгәр!**

Шулай да мәхәббәт лирикасында Разил әле үзен чагыштырмача йомшак хис итә һәм бу уңайдан аңарга ниндидер киңәш эзләп маташу кирәкме икән?.. Довженко: «Тетрәндерү өчен үзеңнең дә тетрәнгән булуың зарур», — дип юкка гына кабатламагандыр.

Фәлсәфи лирикада исә Р. Вәлиев иҗаты бөтенләй башка сыйфатлары белән ачылып китә. Иң элек, ул югары идеяле, җитди һәм актуаль поэзия. Аның яшәү мәгънәсе һәм тормыш турындагы уйланулары аеруча кызыклы. Шагыйрь күңелендә үткән заман, бүгенге көн һәм киләчәк бергә очрашып үзара күрешә, якалаша кебек бер карашка. Әмма нәтиҗә ясарга ашыкмыйк. Үткәндәге күп кенә гадәтләр бүген юкка чыга-чыгуын, бит алар урынына яңалары да туа тора, дөнья, табигать һәм кеше зур үзгәрешләр кичерә, шул сәбәпле офтанырлык урыннар да бар кебек, ләкин куанычлар күбрәк. «Яшен тамыры» җыентыгының беренче ике бүлегенә кертелгән шигырьләрдәге фәлсәфә шундый гомуми фикергә китерә.

Разилның туган як табигатенә чиксез зур мәхәббәт һәм аның язмышы өчен чын күңелдән борчылып язылган шигырьләре дә укучыны битараф калдырмас дип ышанырга кирәк. Беренчедән, бу тема бу-

ген гаять актуальлеккә ия. Икенчедән, ул билгеле бер чор өчен генә әһәмияте булган кампания дә түгел, мәңгелек тема. Ләкин, искә алып үткәнебезчә, теманың актуальлеге генә әдәби әсәрнең дәрәҗәсен күтәрми бит әле. Шагыйрь бу очракта җитди мәсьәлә өстендә уйлануларын гүзәл картиналар һәм үзенчәлекле образлар аша, бер сүз белән генә әйткәндә, шагыйранә тасвирлауга ирешкән. Ул җаны-тәне белән табигатькә гашыйк, аның мәхәббәте күңел түреннән ташып чыккан ярсу хисләрендә — романтикларга хас ашкынуы һәм канатлануында.

**Табындым мин иманнәргә,**
**Табындым мин усакларга...**
**Агачларны бергә җыеп,**
**Их, бер кысып кочакларга!**

Ярсу хисләр ташып торган шундый шигырьләрне укыгач та халкыбызның бөек шагыйре Г. Тукай иҗатына гашыйк тәнкыйтьче Җ. Вәлидинең: «Шигырь!.. Ул нәрсә? Мәхәббәт тавышы түгелме...» — кебек сүзләре келт итеп хәтергә килеп төшә. Уйлап карасаң, искиткеч тирән мәгънә бар икән бит бу юлларда. Әйтик, күңелендә җиргә һәм бөтен кешелеккә олы мәхәббәт хисләре сакламаган, туган илгә һәм аның табигатенә җаны-тәне белән гашыйк булмаган, бер чибәрне янып сөймәгән шагыйрь нәрсә турында язар иде икән... Кемгәдер, нәрсәгәдер мәхәббәт хисләре булмаган кеше нәфрәтләнә дә алмас иде. Шагыйрьне канатландырган да, шигырьләргә сихри көч биргән дә — мәхәббәт, бары мәхәббәт кенә. Йөрәктә шушы хис ташып тормаганда язылган шигырь, белмим, буламы икән... Булса да ул шигырь булмый торгандыр.

Р. Вәлиевнең «Диңгездә ява яңгыр», «Яз», «Юлларым, юлларым, юлларым...» кебек шигырьләрен укып битараф калу мөмкин түгел, аларда шагыйрьнең ихлас күңеленнән чыккан хисләр шигъри гәүдәләнеш тапкан, алар олы мәхәббәтнең кайтавазы булып яңгырый.

Әмма «Яшен тамыры»нда әле шигъри рухтан мәхрүм калган яисә шагыйрьнең әйтергә теләгән фикере бик үк ачык булмаган шигырьләр дә байтак кына. Мәсәлән, «Карап торам шәһәр урамына...», «Самолетта», «Тау кызына» һәм «Бакчасарай фонтаны» кебек шигырьләрне аларда автор позициясе булмау һәм фикернең кирәгеннән артык абстрактлылыгы берләштерә. Шул уңайдан тагы бер кат поэзиянең иҗтимагый функциясен һәм идея-эстетик мөмкинлекләрен гаять югары бәяләгән тәнкыйтьче Җ. Вәлидигә мөрәҗәгать итәргә туры килә: «Шигырьдә исә сәнагъ нәфисәнең башка нугларына караган вакытта да фикер ачык вә аңлаешлы булырга тиеш. Шигырьдә фикер тирән, гади яки нечкә вә күркәм булсын» [1].

**Үпкәлә син аннан мәхәббәткә...**
**Нигә мине читләп уза ул!**
**Нигә килми!! Йөрәк ачык тора —**
**Алынган бит биге, йозагы.**

**Минем мондый шигырь язуыма**
**Ачы җилле көзгә үпкәлә.**
**Шул җилләрдән аралыйсың килсә,**
**Син мине дә кайчак үпкәлә...**

«Йөрәк», «мәхәббәт» һәм «шигырь» кебек сүзләргә урын түрдән бирелгән бу «тезмә»не сызгалауда йөрәк һәм мәхәббәтнең катнашы булдымы икән, ә шигырьгә килгәндә — ул юк та юк инде. Нидер әйтергә дә тели, ахры, Разил, ләкин аңлашылмый. Бәлки «бик» һәм «йозак» янына «английский ключ», шигырьнең ахырындагы «үпкәлә» янына «кочаклаштыргала», «сыйпаштыргала» сүзләрен дә өстәргә кирәк булгандыр, хәер, ул кадәресе турында шагыйрьнең үзенә тагы бер кабат уйланырга кирәк булыр.

Р. Вәлиев шигырьләрендә (бер аңарда гына микән?) әледән-әле зур төшенчәләр — кояш, йолдызлар, космос, океан, диңгез һәм җир шары кебек сүзләр кабатланып тора. Шагыйрьләрнең шулай киң колач белән фикер йөртүенә, бер карагандa, куанырга гына кирәк тә бит, әмма шундый төшенчәләр арасында еш кына кеше һәм аның бай эчке дөньясы юкка чыга кебек. Моңарга игътибар итәргә вакыт җитмәдеме икән?

Р. Вәлиев һәм Ф. Шәфигуллин җыентыклары белән танышканда тагы бу авторларның аерым сүзләргә, бигрәк тә рифмадаш сүзләргә таләпчәнлекне кимәтә төшүләре белән дә килешеп булмый. Бер урынсыз юл, бер пешеп җитмәгән рифма матур гына шигырьне муены кыйшайган нәни үрдәк бәбкәсенә охшата да куя. Югыйсә, үз-үзеңә таләпчәнлекне аз гына арттыра төшкәндә дә ул шигырьләрне га-

[1] «Вакыт», 1913, 1257 сан.

риплектән коткару мөмкин булыр иде бит. Ф. Шәфигуллинны укыганда «мачтасы» — «төште соң», Разилда «өлешен» — «өләшә», «бар бездә» — «Робинзон», «килмәгән» — «көлмәге» кебек рифмалашучы парларга килеп төртелгәч, ирексездән, яхшы гына язылган шигырьләрне кызганып куясың. Шагыйрьләр үзләре соң әлеге тойгыдан мәхрүм ителмәгәндер бит?..

«Дулкынга дулкын» һәм «Яшен тамыры» җыентыкларын кулга алганда күңел бары тик тирән һәм мәгънәле уйланулар, нечкә вә нәфис хисләр белән генә очрашуга омтылган иде. Чынлап та, Р. Вәлиев һәм Ф. Шәфигуллинның байтак кына шигырьләре күңелдә матур һәм җылы гына тәэсир калдырды. Шагыйрьләрнең һәр икесен әһәмиятле һәм җитди мәсьәләләр кызыксындыра, йөрәкләрендә замандашларына әйтер фикерләр дә аз түгел, иң әһәмиятлесе — аларның күңелен изге хисләр борчый. Ләкин, аерым шигырьләрен укыганда, авторларның үз-үзләренә таләпчәнлекне киметүләренә дә күңел рәнҗемәслек түгел. Йөрәк һәм күңелдәге хисләрдән бигрәк, каләм катнашы белән генә иҗат ителгән шигырьләрне укучы ничек кабул итәр — бу кадәресен дә онытмаска иде... Кыскасы, шигырь җыентыкларында урын бары тик шигырьләргә, югары камиллеккә ия чын поэзия әсәрләренә генә бирелергә тиеш.

**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ.**

Нурихан Фәттах

# ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ ЯНЫНДА СӨЙЛӘШҮ

„Казан утлары"ның былтыргы 9, 10, 11 саннарында басылган «Ерак гасырлар авазы» дигән мәкалә уңае белән, журнал укучыларыбыздан редакциягә, автор исеменә күп кенә хатлар килде.

Хат авторларының күпчелеге мәкаләне кызыксынып укулары турында язалар, үзләренең фикерләре белән уртаклашалар.

Сөйләшүне Ташкентта яшәүче Г. Фәхретдинов иптәшнең хатыннан башлап китик. Аның хатында: безнең «анабыз Бүре» булгач, «атабыз Төлке» булып чыкмасмы, һәм шуның өчен безне кимсетмәсләрме, дигәндәй фикер сизелеп кала. Мондый шикләнүләргә, әлбәттә, бернинди дә нигез юк. Г. Фәхретдиновның хаты, гомумән, баштан алып азагына кадәр җылы рухта, теләктәшлек рухында язылган.

Хат авторының берничә соравы да бар. «Сез «корбан чалу» турында язгансыз, ә менә үзбәкләр думбыраны да «чалалар» — шуны аңлатмассызмы?» ди ул. Моңа өстәп мин башкортның: «Гыж-гыж курай тартаһың, тал төбендә ятаһың» дигән җырын да искә төшерер идем. Татар кураенда **уйный**, башкорт әнә **тарта!** Чынлыкта бит курайны тартмыйлар, курайга өрәләр. Тарту белән чалу бер үк төрле хәрәкәтне белдерә, һәм бу сүзләргә махсус аңлатма биреп торуның кирәге юктыр кебек. Безгә бары бу сүзләрнең «музыкаль» мәгънәсен генә аңлатырга кирәк. Безнең бик борынгы бабаларыбызның иң беренче музыка кораллары, күрәсең, **тартып, чалып** (ягъни кылга чиртеп, кылны тартып) уйный торган корал булгандыр. Менә бу факт бүгенге көнгәчә телдә үзгәрешсез сакланып калган һәм бу иң беренче термин тартып, чалып уйнала торган музыка коралларына карата да, тартып, чалып уйналмый торган музыка коралларына карата да кулланыла икән.

Кайбер укучылар, теге-бу сүзнең аңлатмасы белән килешмичә, үз аңлатмаларын тәкъдим итәләр. Шундыйлардан Татарстанның Питрәч районы Көлкәмәр авылы укытучысы иптәш И. А. Долговның хатын күрсәтергә мөмкин. Иптәш И. А. Долгов **Казан** сүзенең килеп чыгышы мәсьәләсендә **каз** (кош) гипотезасын яклый. Аныңча, **каз** тамыры катнашкан барлык сүзләр, шул исәптән, әлбәттә, **Казан** атамасы да каз дип аталган кошка охшату нигезендә барлыкка килгән булырга тиеш. «Аш пешерә торган казанның да каз гәүдәсе формасына, каз утырган ояга, каз үзе ясаган чокырга охшашлыгы бар», дип яза автор. (Җир) **казу** сүзе дә, аныңча, каз-кош атамасына кайтып кала. «Каз бит судамы, саздамы, ишек алдында утырамы, һаман казынган көне», ди И. А. Долгов. **Казакъ** сүзе дә, аның фикеренчә, каз кошына охшашлык принцибында барлыкка килгән. («Чиктә торучы атлы сакчы һәрвакыт уяу булучы казга охшамыймы соң?!») Шәригать законнары буенча хөкем итүче **казый** (судья) да каз кошына охшаган икән. (Казый «шул ук сакта торучы, тәртип саклаучы кеше була бит».)

Бик борынгы заманнардан бирле каз татар халкының иң яраткан кошы булган. Бүгенге көндә татар авылында каз асрамаган бер генә кеше дә тапмассың. Каз өмәләре бары безнең халыкка гына хас күренеш. Безнең өчен каз әле дә «изге», якын һәм кадерле. Тик шулай да **Казан** атамасын һәм каз тамыры катнашкан **казакъ, казу, казый** кебек сүзләрне казга охшарга тырышу нигезендә ясалгандыр дип әйтеп булмый. Моның өчен дәлилләр җитәрлек түгел.

Татарстанда туган, хәзер исә Ерак Көнчыгышта Амур өлкәсенең Болонь станциясендә яшәүче иптәш Н. Я. Николаев «Ка-

зан утларыын алдыруы һәм анда басылган материалларны кызыксынып укуы турында яза. «Мин үзем татар түгел, татар теленә болай гына өйрәндем», ди ул. Илтәш Н. Я. Николаевны әкәй әнәсе сүзенең килеп чыгышы кызыксындыра. «Арча якларында мари хатыннарына әкәй дип әйтәләр, әкәй әнәсе дигән сүз дә әкәйләргә бәйле рәвештә барлыкка килмәде микән», ди ул.

Башкортстанның Дүртөйле районы Таймурза авылыннан М. Бәширова да үзләре ягында әкәй әнәсе дигән сүзнең кулланылуы турында яза.

Арча ягы Дүртөйле районнарында гына түгел, башка төбәкләрдә дә мари хатыннарын әкәй дип әйтүләрен мин дә беләм.

Нинди сүз бу? Фәндә моңа бернинди аңлатма юк. Бу сүз шулай ук бернинди сүзлеккә кермәгән. Ләкин бу сүз бар һәм ул халык телендә яши бирә. Бу уңайдан безгә ар, чирмеш сүзләрен дә искә төшерергә туры килә. Мәгълүм булганча, ар дип удмуртларга, чирмеш дип мариларга әйтәләр. Ар әкәе булса — удмурт хатыны, чирмеш әкәе булса — мари хатыны була. Болай булганда, әкәй сүзе хатын-кыз дигән мәгънәгә туры килә кебек. Ләкин Казан янында Әки (Әкәй) дигән авыл да бар бит әле!

Әкәй әнә сүзен мари хатыны яисә удмурт хатыны дигән сүздән чыгарып буламы соң? Әгәр дә мәгәр татарлар әкәй әнәсен күршеләреннән алган булсалар, конкрет кемнән алганнар икән — ар әкәйләреннәнме, чирмеш әкәйләреннәнме? Берьюлы икесеннән дәме? Әллә безнең ерак бабаларыбыз мари һәм удмуртларны бер үк халык дип уйладылар микән? Алай дип әйтер идең, һәр халыкны алар әнә аерым-аерым атаганнар: берсе ар, берсе чирмеш, төркичә, татарча атаганнар!

Шулай итеп, логика безнә «Тупик» станциясенә китереп туктатты.

Бүгенге көндә ар, чирмеш, әкәй сүзләре рәсми телдән һәм сүзлекләрдән төшеп калганнар. Ләкин бу сүзләрнең рәсми телдә кулланылмавына карап кына алардан кул селтәү дөрес булмас иде. Бик борынгы заманнарда бу сүзләрнең бернинди мыскыл төсмерләре булмаган, киресенчә, алар бик дәрәҗәле атама булганнар. Һәм, әйтергә кирәк, сүзлекләрдән төшеп калган менә бу ар, чирмеш, әкәйләрдә Идел-Кама буе халыкларының, безнең халыкның зур тарихи серләре саклана.

Шуңа күрә мин әкәй әнә мәсьәләсендә үз фикеремдә калам. Борынгы төрки телдә акинак (ак инәк) сүзе булган. Сүзнең төркичә төзелеше, мәгънәсе, язма чыганаклар — барысы да шул турыда сөйли. Акинак дигән сугыш коралы кулланудан төшеп калгач, аның термины зур әнәгә — инәгә күчкән дип уйларга була. Тора-бара ак инәк сүзенең беренчел мәгънәсе дә онытылган һәм, ихтимал, халык этимологиясе нигезендә, хатын-кыз мәгънәсендәге әкәй сүзе белән якынайгандыр. Әкәй әнәнең турыдан-туры ак инәк сүзеннән үзгәргән булуы да бик мөмкин (ак инәк — акинәк — әкәйнә).

Татарстанның Буа шәһәреннән язган һәм ни өчендер исемен, адресын куймаган бер иптәш мишәр сүзенең мәгънәсен аңлатуны сораган. Мишәр сүзе дә, ар, чирмеш, әкәй сүзләре кебек үк, бөтенләй диярлек ачыкланмаган. Минемчә, мишәр атамасында да татар халкының ерак тарихы яшеренеп ята. Безнең галимнәр исбат иткәнчә, мишәрләр болгарларның бер өлеше, бер тармагы булганнар. Мишәрләрнең рухи һәм материаль культурасы болгар һәм Казан татарлары культурасыннан аерылмый. Билгеле, аларның кайбер үзенчәлекләре дә бар [1].

Башкортстанның Әлшәй районы Раевский поселогында яшәүче Н. Рәмиев иптәш әтисенең 1911 елдан башлап тарих һәм туган тел укытуы, халкыбызның борынгы тарихы белән кызыксынучы кеше булуы турында яза: «Бер мәртәбә мин бала чакта сорагач, скифлар турында бик ышанырлык итеп: «алар төркиләр, безнең бабаларыбыз», дип әйткән иде», ди Н. Рәмиев. Күрәсез, бу да кызык кына факт.

Казаннан язган Р. Сафин иптәш «иргә чыккан урта яшьләрдәге киленне, хатынны Кырым татарларының әбети дип атаулары турында әйтә һәм әбетине скифларның Табити дигән хатын-кыз аллалары белән мәгънәдәш булырга тиеш дип уйлый. Әбети татар теле диалектларында да бар икән. Тау ягы, Чүпрәле, Тархан, Чистай якларында бу сүз абыстай мәгънәсендә кулланыла [2]. Дөресен әйтим, бу турыда мин белми идем, шунлыктан ул (әбети сүзе) мәкаләдә файдаланылмады. Әбети белән Табитинең бер үк сүзләр булуы бик ихтимал нәрсә.

Казанда яшәүче Ш. Хөснетдинов иптәш татар телендә алынма дип аталган сүзләрнең күбәеп китүенә пошыну белдерә. «Тер-

[1] Мишәрләр турында 1972 елда Мәскәүдә рус телендә чыккан «Р. Г. Мухамедова. «Татары-мишари» дигән китапны укырга була.

[2] Татар теленең диалектологик сүзлеге. Казан, 1969 ел, 539 бит.

ки телләр(не) фин-угор, монгол телләре хисабына баеган диләр. Бездә еш кына елга, авыл, үсемлек һ. б. исемнәрен шул телләргә мөрәҗәгать итеп аңлаталар (Мәсәлән, «Татарстан АССРның антротопонимнары». Авторы — Г. Саттаров)», — дип яза иптәш Хөснетдинов.

Татар телендә алынма сүзләр мәсьәләсе — җитди һәм катлаулы мәсьәлә. Безнең сүзлекләр, дәреслекләр, тел турындагы барлык төр хезмәтләр татар телендә алынма сүзләрнең, бигрәк тә гарәп-фарсы элементларының күплеген күрсәтәләр. Алынма «элементлар» өчен бездә — татар теле орфографиясендә — махсус орфография булдырылган! Без **әдәм** дип сөйлибез, әмма **адәм** дип язабыз. Болар гарәп сүзләре дип исәпләнелә һәм безнең, әлбәттә, гарәп теле орфографиясенең хәтерен калдырырга хакыбыз юк.

Безнең алынма сүзләребез **әдәм, әммә** белән генә чикләнми, билгеле. Нинди генә «культурный», дәрәҗәле сүзгә тотынма, әле гарәп-фарсыдан, әле кытайдан, санскриттан я булмаса монголдан, фин-угорлардан алынган булып чыга. Кайбер галимнәрнең фикеренчә, безнең элек хәтта **кеше, хатын, ир, тун, аш** кебек сүзләребез дә булмаган, имеш. **Битек, китап, чирү, сарай** кебек сүзләрне инде әйтеп тә торган юк!

Битек, китап, сарай кебек сүзләрнең алынма булуы ихтималына без инде күптән күнегеп беткәнбез. Бу сүзләрнең гарәпчә әдәбият, китап белеме аша кергән булуы мөмкин һәм еш кына андый «алынма»ларны шулай аңлаталар да. Ләкин безнең кайбер галимнәребез халык телендәге гап-гади, көндәлек сүзләрне дә яисә Татарстан, Башкортстан территориясендәге авыл-елга исемнәрен дә алынма дип аңлаталар икән, моңа ничек карарга? Татарстандагы **Мишә** елгасының исеме фарсыча **бешә** (имән) дигән сүзгә туры килә икән. Шул нигездә Мишә — фарсы сүзе дип язып чыгалар. Мондый фәнни «ачыштан» соң бер генә нәтиҗә ясарга мөмкин. Димәк, без, бүгенге татарлар — элекке иран-фарсы кабиләләре яисә Татарстанда татарларга кадәр фарсылар яшәгән.

Татар теле этимологиясе белән шөгыльләнүче Рифгать Әхмәтҗанов татар телендә «алынмалар»ны аеруча күп таба. Аныңча, **юа, яра, тана, чабата, бияләй, аркан** кебек сүзләр барысы да фарсыныкы. Кайчан, кайда алдык икән соң без аларны? Мишә буенда фарсылар белән күршеләр булып яшәгәндәме, әллә соң санскрит чорында укмы? (**Тун** сүзен Р. Әхмәтҗанов санскрит сүзе дип исәпли.) Шулай итеп, төркиләрнең элек чабатасы да, бияләе дә, арканы да, танасы да, туны да булмаган булып чыга. Битек, китап, сарайларны инде әйткән дә юк!

Соңгы елларда «Алтай бердәмлеге» теориясен яклаучылар төрки телләрдә монгол сүзләре эзләү, табу белән мавыга башладылар. Казакъ галимнәре С. Кенесбаев белән Т. Җанузаков, мәсәлән, **бога-буга, юлбарыс, болак, буран, ел-җыл, алтын, ага** кебек саф төрки сүзләрне монголныкы дип исәплиләр [1]. Мәскәү тюркологы Л. В. Дмитриева **карагай** сүзен дә монголныкы ди [2]. Ул моны болай аңлата: **кара** сүзенә **гай** кушылган да, карагай сүзе килеп чыккан ди. **Кара** — төсне аңлата. Бу монгол һәм төрки телләр өчен уртак сүз. **Гай** дигәне, имеш, монгол теленә генә хас сүз ясаучы кушымча икән. Мондый аңлатманы кагыйдә дип кабул итсәк, безнең **җана-гай, кайна-гай, сула-гай, яла-гай, была-гай** кебек сүзләребез дә монголныкы булачак. Ялагай белән сула-гайдан башка әле бит безнең гүзәл **тургаебыз** да бар! **Гай**ның **гәй, кай-кәй** вариантлары да булуын истә тотсак, **кара-кай, гөл-кәйләребез** дә бик җиңел генә монгол сүзләренә әверелачәк. Аннан соң инде төрки телләрне монгол теленнән аерылып чыккан дип исбатлау бөтенләй җиңел булачак.

Р. Әхмәтҗанов та **нарат, кодагый, кияү** кебек сүзләрне монголныкы дип уйлый. **Печән** сүзе дә, аныңча, монголныкы булырга тиеш [3]. **Печән, билчән** кебек сүзләрнең ата-бабасын Р. Әхмәтҗанов монголча **белчи-белчил** (тибендә йөрү, ашану, туену; көтүлек, утлык) сүзенә илтеп тоташтыра. Печән белән билчән арасында, печән белән көтүлек, утлык яисә ашану-туену сүзләре арасында тигезлек билгесе куеп булмаганлыгы һәркемгә аңлашыладыр дип уйлыйм.

Аннары шунысы да бар. Монголиядә терлекләр елның-ел буена тибендә туена. Монголиядә печән, печән чабу дигән нәрсәне, күп булса, соңгы 20—30 ел эчендә генә белә башладылар. Безнең җирдә — Урал-Идел буйларында печән чабу кимендә Болгар чорыннан ук мәгълүм [4].

[1] «Советская тюркология» журналы. 3 сан, 1976 ел, 78—88 битләр.
[2] Шунда ук, 37—40 битләр.
[3] «Советская тюркология» журналы. 1 сан, 1976 ел, 117—120 битләр.
[4] Археологлар җир астыннан болгар чалгылары табалар. Кара: «История Татарии в документах и материалах» дигән җыентык. Мәскәү, 1937 ел, 13 бит, 1(3) рәсем.

Монда тагын икенче бер нәрсәгә дә игътибар итеп китәргә кирәк. Монгол әдәби теле, язу системасы төрки уйгурлар тәэсирендә бары тик XIII гасыр башларында гына, Чыңгыз хан заманнарында гына формалаша. Монголия территориясендә (монгол халкы тарих сәхнәсенә чыкканчы) мең ел, мең ярым ел дәвамында югары культуралары, оригиналь язу системалары, җитлеккән әдәбиятлары булган төрки халыклар, төрки дәүләтләр яши. VI—VIII гасырлардагы Алтай төркиләренең рун язмалары, X—XII гасырлардагы борынгы уйгур язмалары моңа кире кагылгысыз дәлил булып тора.

Монгол теленең төрки телләргә тәэсире турында сөйләнүләр менә мондый тарихи факторлар фонында шактый йомшак һәм нигезсез тоела.

Безнең республикада аеруча соңгы елларда гуманитар фәннәр күзгә күренеп үсә башлады. Бу үсеш өчен без барыннан да элек тынгысыз, талантлы яшьләребезгә — тарихчыларга бурычлыбыз. Бүген без «тарих» дигән киң төшенчәле фәннең күп кенә тармаклары турында ышанып сөйли алабыз. Татарларда революцион хәрәкәт тарихы, татарларда иҗтимагый фикер, философия тарихы, Татарстанның борынгы чор тарихы, Болгар чоры тарихы, урта гасырлар чоры тарихы, татарча китап басу тарихы, татар сәнгате тарихы, татар музыкасы тарихы... Әнә күпме «тарих» бар бездә! һәм бу буш сүз генә түгел — бу тарихларның барысы да реаль хезмәтләргә — төпле, нигезле фәнни хезмәтләргә таяна.

Татар тел гыйлеменең дә зур тарихи һәм бай традициясе бар. Ә шулай да татар телчеләренең эшләгән эшләренә карганда, эшлисе эшләре күбрәк. Билгеле, телчеләр дә тик ятмыйлар: яңа хезмәтләр языла, дәреслекләр, сүзлекләр төзелә. Тел гыйлемендә дә яңа тармаклар барлыкка килде. Гомәр Саттаров, мәсәлән, җиң сызганып Татарстан топонимиясен өйрәнә. Бу өлкәдә ул иң актив эшләүчеләрнең берсе һәм... бердәнбере.

Авыл, елга, тау исемнәре — гомуми тел байлыгыбызның аерылгысыз бер өлеше ул. Шуңа күрә Татарстандагы һәм шулай ук күрше өлкәләрдәге татарча топонимик атамаларның барысын да бер генә кеше өйрәнеп-тикшереп бетерә алмаячак. һәм аның аңлатмалары да һәр очракта дөрес булмаска мөмкин. Чыннан да, Г. Саттаровның кайбер гипотезалары ышандырып җиткерми. Укучы Ш. Хөснетдинов әйткәнчә, ул **татарча** топонимик атамаларны финугор, монгол телләре ярдәмендә аңлату белән мавыга. **Арча** сүзен, мәсәлән, Г. Саттаров арларга (удмуртларга) бәйле рәвештә хәл итмәкче була. Аныңча, хәзерге Арча урынында элек удмуртлар яшәгән булып чыга. **Кукмараны** марича «ике мари» дигән сүз ярдәмендә аңлатырга тырышу да ышандырмый. Кукмара — ике мари дигән караш ул халык этимологиясе тәэсиренә бирелүнең бер күренеше генә.

Археологлар, борынгы шәһәр, авыл калдыкларын казып, җир астында күмелеп калган бай тарихыбызны ачыклыйлар. Тарих җир астында гына түгел, җир өстендә дә «күмелеп» ята. Авыл, шәһәр, тау, елга, чишмә һ. б. ларның исем-атамалары — әле беркем тиешенчә укып бетерә алмаган язу укый алмаган Тарих битләре ул. Шулай ук татарча кеше исемнәренә дә безнең тарих яшеренгән. Топонимик атамаларны өйрәнү, әйтелгәнчә, җанлана башласа да, кеше исемнәренә әлегәчә беркемнең күзе төшмәгән. Татар телен өйрәнгәндә кирәге чыкса, телчеләр үзләре гадәттә В. К. Магницкийның 1905 елда басылган «Чувашские языческие имена» («Чувашларда мәҗүси исемнәр») дигән китабыннан файдаланырга мәҗбүрләр. Хәер, бездә татарча кеше исемнәрен генә түгел, авыл, шәһәр, елга исемнәрен туплаган хезмәтләр дә юк. «Татарстан АССРның административ бүленеше» дигән китапка бары авыл, шәһәр исемнәре генә кертелгән һәм ул китап фәнгә катнашы булмаган башка максатларда чыгарылган.

Республикабызның йөзе күз алдында үзгәрә бара — кечкенә авыллар бер үзәккә туплана, елгалар үз агымнарын үзгәртәләр, кайбер урыннарда калкулыклар, болыннар, тугайлар зур су астында кала. Юкка чыкмасын, онытылмасын өчен аларның исемнәрен-атамаларын да тизрәк язып алырга, бергә тупларга һәм китап итеп чыгарырга кирәк. Кем башкарыр бу эшне? Әлбәттә, без — галимнәр, галим булмаганнар — телебезнең, тарихыбызның киләчәк язмышын кайгыртып торган кешеләр.

«Ерак гасырлар авазы» мәкаләсе басылуга белән редакциягә, авторга хат язган һәм «Түгәрәк өстәл янында» шушы сөйләшүдә катнашкан барлык укучыларга чын күңелдән рәхмәтемне белдерәм.

# Х. БӘДИГЫЙ

(1887—1940)

Күренекле фольклорчы һәм тел галиме Хуҗа Бәдигыйга шушы елның 24 декабрендә 90 ел тула. Ул 1887 елда Казан губернасы Мамадыш өязе Югары Берсут авылында дөньяга килә. Кечкенә чагыннан ук аң-белемгә омтылучы үсмер 1900 елда Казанга килеп «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга керә. Бераздан анның әтисе вафат була. Гаиләдән булышып торучы булмагач, шәкерткә уку һәм көн күрү шактый авырая. Ләкин бу авырлыклар аны аң-белем юлыннан тайпылдыра алмый, Хуҗа үз көнен үзе күреп, укуын дәвам иттерергә тырыша: җәйге ял вакытларында үзе кебек ярлырак шәкертләр белән бергә сукно фабрикасында, сәүдәгәр кибетләрендә, Мәкәрҗә ярминкәсендә кара эштә йөреп бераз акча төшерә һәм кышларын шул «байлык»ка тамак туйдырып яши.

1905 ел революциясен Х. Бәдигый «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкерте буларак каршылый. Шул елларда ул революцион һәм демократик хәрәкәткә катнаша башлый, шәкертләр хәрәкәтенең үзәгендә кайный. Үзенең биографиясендә Х. Бәдигый ул турыда: «Революция елларында иптәшем Гали Агишев (Габдрахман Мостафин) исемле студент җитәкчелегендә, шәһәр читендә урнашкан бер революционер квартирасында төннәр буе татарча прокламацияләр күчерә һәм шуларны кирәк урыннарга ябыштырып йөри идек»,— дип яза. Шул елларда ул журналистлык эшен башлый, «Әльислах» газетасында мәдрәсә тормышыннан язылган мәкаләләр бастыра.

1908 елда «Мөхәммәдия»не уңышлы тәмамлагач, мәдрәсәнең педагогик советы тәкъдиме белән, ул шунда ук укытучы итеп калдырыла. Ул вакытларда мәдрәсәдә рус теле укыту җәйга салынмаганлыктан, шәкертләрне алдынгы рус культурасы белән таныштыру эше бик сүлпән барган. Х. Бәдигый бу хәлне мәдрәсәдә укыту эшенең зур кимчелеге итеп саный һәм үзлегеннән рус телен өйрәнергә керешә.

Совет властеның беренче көннәреннән үк тәҗрибәле педагог-галим җиң сызганып халыка аң-белем бирү, мәктәпләрне яңача үзгәртеп кору, укытучы кадрлар хәзерләү, мәктәп балалары өчен дәреслекләр төзү кебек мөһим эшләргә тотына. 1918 елдан 1926 елга кадәр ул К. Насыйри исемендәге педагогия техникумында, Казан хатын-кыз укытучылары семинариясендә, мөселман пехота курсларында, Көнчыгыш академиясенең татар рабфагында, Коммунистик университетта, М. Вахитов исемендәге мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укыта. Х. Бәдигый Академик үзәк эшендә дә актив катнаша. 1926 елда аны, Академик үзәк тәкъдиме белән, Ленинград Көнчыгыш институты каршындагы тюркология семинариясенә укырга җибәрәләр. Институтны уңышлы тәмамлагач, аны аспирантурада калдыралар. Ул, аспирантурада уку белән беррәттән, Герцен исемендәге педагогия институтында рус теле методикасы буенча лекцияләр дә тыңлый. Шул елларда «Төрки телләрнең чагыштырма морфологиясе» дигән темага диссертация язып тәмамлый.

1930 елда Х. Бәдигый Казанга кайта һәм гомеренең соңгы көннәренә (1940 елга) кадәр Көнчыгыш педагогия институтында укытучы, доцент һәм соңгы елларда профессор була.

Х. Бәдигыйның халык иҗаты белән кызыксынып китүе «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыган чорда ук башлана. 1907 елда татар һәм чуваш фольклорын өйрәнү максаты белән Казанга венгр галиме Ю. Мессарош килә. Аңа татар фольклоры, этнографиясе һәм татар теле буенча дәресләр бирердәй бер ярдәмче кирәк булгач, мәдрәсә мөгаллимнәре бу эшкә Хуҗаны тәкъдим итәләр. Алар күренекле галим белән икәүләп Казан шәһәрендә һәм тирә-як авылларда халык иҗаты әсәрләре җыялар. Хуҗа Бәдигый күренекле галимнең фольклор җыю һәм өйрәнү алымнарын күзәтә. Ю. Мессарошның теоретик һәм методик ярдәме белән ул үзе дә халык иҗатын җыю һәм өйрәнү эшенә керешә.

«Мөхәммәдия» шәкертенең халык әдәбияты белән ныклап кызыксынып китүенә аның халык шагыйре Г. Тукай белән очрашу һәм сөйләшүләре дә зур йогынты ясый. Х. Бәдигыйның Тукай турындагы истәлекләреннән күренгәнчә, шагыйрь яшь фольклорчы эше белән даими рәвештә кызыксынып торган. Тукай белән «Әльислах» газетасы редакциясендә беренче мәртәбә күрешүләре турында Х. Бәдигый болай яза:

«Тукай минем халык әдәбияты җыеп кайтканымны алдан ишеткән булса кирәк, миңа туп-туры карап:

— Ә, халык әдәбиятын җыючы кеше синмени әле ул? Нихәл, эшләпә туламы, әллә эшләпәнең төбен тишеп капчык тектеңме? — диде. Мин башта, аның соравын аңламыйча, бераз кызарып алдым...

— Әле капчык тегү түгел, эшләпәнең үзен дә тутырып булмый, ул эш җиңел түгел икән, — дидем.

— Зур эшне башлап җибәргәнсең, инде шул юлыңда дәвам ит!»[1].

Х. Бәдигый бу елларда халык иҗатының күп жанрларын эченә алган «Халык әдәбияты» исеме белән бер серия китаплар чыгарырга ниятли. Шул теләген тормышка ашырып, ул 1912—13 нче елларда «Мәкальләр», «Табышмаклар» дигән фольклор җыентыкларын чыгара. Күп тә үтми, «Бәетләр» җыентыгы һәм «Җырлар» китабы да дөнья күрә. Бу сериядәге китапларны чыгару эшен ул Бөек Октябрь революциясеннән соң да дәвам итә. 1919 елда китап сөючеләр игътибарына «Мәкальләр» җыентыгы, ә 1926 елда «Халык әдәбияты. Мәкальләр һәм табышмаклар» дигән күләмле хезмәт тәкъдим ителә.

Хуҗа Бәдигый халык иҗатын киң күләмдә өйрәнүче галим. Аның игътибарыннан фольклор жанрларының һәм төрләренең берсе дә читтә калмый. Шул нәүбәттән ул балалар фольклоры әсәрләрен дә җентекләп өйрәнә, аларны махсус җыеп, бастырып чыгару эшен башлап җибәрә. 1913 елда чыккан халык иҗаты җыентыгына ук Бәдигый балалар телендә йөри торган такмак һәм такмазаларны, бишек җырларын кертә. Ул халык һәм балалар уеннарын да җыя, аларны төрле җыентыкларда, журналларда бастыра.

Фольклорчы-галим югары уку йортларында һәм гомуми белем бирү мәктәпләрендә фольклор фәнен укытуның беренче программаларын төзүдә катнаша, Казан педагогия институтында татар фольклоры буенча лекцияләр укый.

Гомумән, татар халкының авыз иҗатын җыю эшендә үзенең остазлары К. Насыйри һәм Г. Тукай традицияләрен дәвам иттергән, марксизм-ленинизм тәгълиматына таянып татар фольклористикасының методик һәм теоретик нигезләрен салуга зур өлеш керткән олы галим ул Х. Бәдигый. Аның хезмәтләре фольклор һәм тел гыйлемебез тарихында аерым бер этап. Ул калдырган бай мирасны барлау, җыйнау һәм дөньяга чыгару алдагы көннең бер бурычы булып кала.

**РӘШИТ ЯГЪФӘРОВ.**

[1] Тукай турында замандашлары. Казан, 1960, 119—120 битләр.

# ХӨСНИ КӘРИМ

(1887—1965)

Хөсни Кәримнең әдәби һәм иҗтимагый эшчәнлеге шул заманның билгеле мәдрәсәсе булган «Галия»дә башланып китә. Ул Галимҗан Ибраһимов, Шәһит Әхмәдиев һәм Фатих Сәйфи кебек әдәбиятта дан казанган әдипләр белән укый. Алар барысы бергә аралашып-дуслашып яшиләр.

Язучының бала чагы бик авыр шартларда уза. Унике яшендә авыл кулакларында ялчы булып йөри, бераз үсә төшкәч, Самара — Златоуст тимер юлына эшкә керә. Аннары инде уку, белем алу турында уйланган-хыялланган егет «Галия» мәдрәсәсенә юнәлә. Укыганда ярдәм итәр кешесе булмаганга, төрле җирдә төрле эшләр табып, үз тамагын үзе туйдыра.

1907 елны Стәрлетамакта Х. Кәримнең «Шакир хәлфә дәресе» дигән ике актлы комедиясе басылып чыга. Ә тагын дүрт елдан Уфаның үзендә «Ак мәче» исемле хикәясе дөнья күрә.

Сабакташлары әсәрне хуплап, яратып каршы алалар һәм югары бәя бирәләр. Яшь егеткә бу көч бирә, ул дәртләнеп иҗат эшенә керешә.

Мәдрәсәдә уку дәверендә яшь әдип үзлегеннән русча өйрәнә, русча уку җаен эзли һәм тырыша торгач, Царицынның реаль училищесына керү бәхетенә ирешә. Аның күптәнге хыялы — укытучы булу — тормышка аша. Училищены тәмамлап, Астраханьның рус-татар мәктәбендә укыта башлый. Шул ук вакытта аның фельетоннары, кыю мәкаләләре һәм хикәяләре Астраханьда чыга торган «Идел» газетасында басыла торалар. Яшь мөгаллимнең бу эшчәнлеге, үткен теле патша властьларының тамагына сөяк булып утыра, — аны шәһәрдән көчләп китәргә мәҗбүр итәләр. Шуннан Х. Кәрим Уфага кайта, ә аннан Бөре өязенең Богданово авыл китапханәсенә урнаша. Монда да яшь әдип тик ятмый, крестьяннар арасында агитация-пропаганда эше алып бара.

Бөек Октябрь аның алдында киң юллар, зур мөмкинлекләр ачып җибәрде. Революциянең беренче елларында ул Бөре өязенең мәгариф бүлеге җитәкчесе булып эшли. 1919 елны Х. Кәрим партия сафларына кабул ителә. Шул ук елның башында ул дошман контрразведкасы кулына эләгә. Аклар аны атарга хөкем итәләр. Хөкем карары җиренә җиткерелгәнен көтеп, Хөсни Кәрим ярты ел чамасы төрмәдә ята. Төрмәдән аны кызыллар килеп коткара.

Хөсни Кәрим гражданнар сугышыннан соң, 1924 — 1926 елларда Казанның юридик курсларын тәмамлап, обллит җитәкчесе, Татарстан Үзәк Башкарма Комитетының читтән торып уку бүлеге мөдире, радиокомитетның әдәби-музыкаль секторы мөдире булып эшли.

Үткән көрәш еллары әдипнең сәламәтлеген какшаткан була, ул 1938 елны каты авырып китә. Шуңа да карамастан, иҗат эшен ташламый, күп санда хикәяләр, истәлекләр яза.

Үзенең иҗат дәверендә Хөсни Кәрим ике йөз илледән артык хикәя, очерк, шигырь һәм поэмалар язды. Аның тугыз китабы дөнья күрде. Ул 1945 елдан СССР Язучылар союзы члены иде.

# СӘХАБ УРАЙСКИЙ

(1907—1957)



Татар совет поэзиясендә мәгълүм бер эз калдырган коммунист шагыйрь Сәхаб Урайскийның тууына 70 ел тулды.

1907 елның 21 декабрендә хәзерге Ульяновск өлкәсе Кече Кандал районы, Тат. Урайкино (шагыйрьнең псевдонимы — авыл исеменнән) авылында ярлы крестьян гаиләсендә туып үскән Сәхаб Камал улы Мәүлетов Октябрьгача тормышның, ятимлекнең бөтен кыенлыкларын татып үсә. Көтүче булып тамак туйдырган, яшьтән рәтләп укый да алмаган егет 1926 елда җидееллык мәктәпкә укырга керә. Аннары Куйбышевта ачылган татар-башкорт педагогия техникумында укый.

Техникумны тәмамлаганнан соң, Урта Идел буе татар совет-партия мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта, 1932 — 38 елларда исә Куйбышев өлкә газетасы — «Колхозчы», 1938 — 41 елларда Казанда чыга торган «Яшь сталинчы» газетасы редакцияләрендә эшли.

1941 — 45 елларда Сәхаб Урайский Совет Армиясе сафларында хезмәт итә — сугышта ул автотранспорт батальонында политик җитәкче була.

1946 — 48 елларда ул республика партия мәктәбендә укый, газеталарга язышa.

Гомеренең соңгы елларында С. Урайский Татарстан китап нәшриятында редактор булып эшләде.

... Сәхаб Урайскийның иҗат юлы егерменче еллар азагында башлана: бу елларда ул үзенең беренче хикәяләрен һәм очеркларын бастыра; ләкин укучылар арасында ул Бөек Октябрь китергән яңа тормышны, аның данлы кешеләрен, беренче бишьеллыклар чорын дәртләнеп җырлаган шагыйрь буларак танылa.

Шагыйрьнең беренче китабы («Көтүче кызы») 1933 елда, икенчесе исә («Таныш елмаю») 1934 елда Куйбышевта басыла.

1933 — 56 еллар арасында С. Урайскийның шактый күп шигырь китаплары дөнья күрде. Менә аларның кайберләре: «Ике очрашу» (1937), «Давыллар аша» (1940), «Шигырьләр» (1941), «Бәхетле балалар» (1948), «Яшьлек тавышы» (1950), «Якты еллар» (1950), «Жигули буйларында» (1951), «Сайланма шигырьләр» (1956). Шагыйрь сүзләренә язылган җырлар да шактый киң танылды.

Ул шулай ук халкыбызның хезмәт батырлыгын тасвирлаган, табигатьне үзгәртеп коручылар, Иделдәге зур үзгәрешләр турында очерклар да язды; каләмдәш дуслары иҗатына багышланган мәкалә-рецензияләр белән чыкты — алар төрле газета-журналларда еш басыла килде.

Сәхаб Урайский төрле елларда М. Лермонтов, Т. Шевченко, Җамбул, К. Хетагуров, М. Исаковский, А. Барто кебек шагыйрьләрнең әсәрләрен татарчага тәрҗемә итте.

Шагыйрь 1957 елның 15 февралендә вафат булды.

# ДУЛКЫННАР ЯРГА КАГА

Мәхмүт Хәсәновның бер хикәясе әнә шулай дип атала. Ак дулкыннар ярып барган ак пароходның уңай каютасында чал чәчле агай юлдашына үзенең тормышы турында сөйләп килә. Сугыш елларында, өсләрендә бомба-мина шартламаса да, хатыны белән улы һәлак булган аның. Күпме ялгызлык газапларын кичергәннән соң, агай үзенең кабат гаилә бәхетен таба алган. Хикәя әнә шул турыда. Биредә бернинди автобиографик мотивлар юк-югын. Ләкин мин М. Хәсәнов иҗаты турында уйлый башладыммы, нигәдер аның шушы хикәясе хәтеремә килә дә төшә.

Бәлки, бу шуңадыр: хикәясендәге охшаш вакыйгалар булмаса да, Мәхмүт үзе дә тормыш дулкыннарын ярып үтә белүче егет.

...Бөек Ватан сугышы аларның — унөч-уңдүрт яшьлек малайларның — язмышын кинәт көтелмәгән якка борып җибәрә. Зеленодольск урта мәктәбендә укып, шунда әдәбият түгәрәге эшендә янып-көеп йөргән Мәхмүт тә, сугыш башлануга, һөнәр мәктәбе укучысы була. Тиздән заводта көнне төнгә ялгап, слесарь булып эшли башлый. Ләкин аңа карап, күңелендә әдәбият-сәнгатькә бала чактан ук кабынган мәхәббәт уты аз гына да сүрелми, аның, көчәя, дөрли генә бара. Һәм менә шушы мөкатдәс ут уналты яшьлек Мәхмүтне — безнең гаскәрләр Көнчыгыш Пруссиягә бәреп кергән, әмма олы Җиңү салютлары яңгырасын өчен әле бик авыр сугышлар барган көннәрдә ук — А. В. Луначарский исемендәге Бөтенсоюз театр сәнгате институты студенты итә.

Сәнгатьнең гаять катлаулы һәм нечкә серләренә үтеп керү өчен ашкынулы һәм тынгысыз көннәр, төннәр... Сугыш һәм сугыштан соңгы чорның мәхрүмлекләре, шуларны студентларча бер тапкырлык һәм шуклык белән җиңеп чыгулар... Биш ел шулай үтеп тә китте. Мәхмүт кесәсенә институт дипломы һәм Татар дәүләт академия театрына эшкә юнәлтү язуы тыгып, Мәскәүдән Казанга кайта.

Шул елларда аның фамилиясе газета-журнал битләрендә, очерклар, хикәяләр авторы буларак, шактый еш күренә башлый. Ә эш урыны итеп инде ул Татрадиокомитетны, аннары яшьләр газетасы редакциясен сайлый. Озакламый тору урыны да үзгәрә: нефтьчеләрнең Азнакай поселогына күчеп китә. Бирелә М. Хәсәнов озак кына еллар культура сараеның художество җитәкчесе, хәзерге көндә район газетасы редакциясендә бүлек мөдире булып эшли.

Күренә ки, көтелмәгән борылышлар бар язучы биографиясендә. М. Хәсәновның иҗаты да, тормышындагыча, дулкын-дулкын булып, еш кына давылланып, тагын тына төшебрәк ага сыман.

Илленче еллар иде. Республиканың Шөгер, Баулы, Әлмәт якларында еллап-айлап түгел, көнләп-сәгатьләп куәтле нефть промышленносте үсеп килә, ә әдәбиятта бу турыда җитдирәк әсәр юк иде әле. Шул чак «Совет әдәбияты» журналында исеме моңарчы укучыларга аз таныш булган авторның нефть разведчиклары турында «Яңа горизонт» дигән повесте басылып чыкты. Өлкәнрәк әдипләр кузгалганчы, тынгысыз һәм армас Мәхмүт «кара алтын» хәзинәсе якларын айкап йөргән, өйрәнгән һәм күләмле генә әсәр дә язарга өлгергән. Повестьны үз вакытында укучылар әйбәт кабул иттеләр, ул әдәби тәнкыйтьтә дә уңай бәя алды. Яшь авторның бу беренче уңышының шау-шуы тынып та җитмәстән, журналда аның икенче повесте басылды: «Урман шаулый». Монысы — өлгер авторның республика урман хуҗалыкларында озак-озак йөреп кайтулары нәтиҗәсе иде.

Иҗатының менә шушы беренче көчле генә дулкыныннан соң, Мәхмүт, каләмдәш дусларын хафага да салып, беразга тыныбрак калды. Юк, каләмен бөтенләй ялга куеп торды дигән сүз түгел бу. Язды Мәхмүт. Хикәяләре чыкты. Әлмәт драма театрында аның «Нурихан», «Зөләйха», «Рамай» дигән пьесалары куелды. Азнакай культура сараеның драма түгәрәге өчен дә әледән-әле пьесалар язып торды ул. Алайса, без автор турында нигә «тыныбрак калды» дибез соң әле? Бу чордагы хикәяләре һәм пьесалары белән Мәхмүт, дөресен әйтергә кирәк, әдәбиятта әллә ни яңа сүз әйтә алмады — әнә шул хафага салган иде безне.

Дулкыннар, бер тынып торса, тагы да көчлерәк чайпала башлый. М. Хәсәнов иҗатында алтмышынчы еллар әнә шундый яңа дулкын булды. Бер-бер артлы күләмле яңа әсәрләр бирде ул бу елларда. Авыл хуҗалыгында яңа күтәрелеш чорын чагылдырган «Саф җилләр» романы, автострада төзүчеләр тормышыннан «Юллар, юллар» әсәре чыкты һәм шулар артыннан ук татар халкының Бөек Октябрьга килү сукмакларын күрсәткән «Саумы, кояш» тарихи романын өлгертте. Шунда без аңлап алдык: әлеге «тынып тору» чоры Мәхмүтнең эзләнү, көч җыю еллары булган һәм гаять киеренке иҗади хезмәт белән үткән икән. Бу романнарны инде без авторның әлеге «эзсез» калган әсәрләре рәтенә һич кертә алмыйбыз. М. Хәсәновның бу романнары алтмышынчы еллар әдәби процессында үзләренең тиешле урыннарын алды. Бу яктан «Саф җилләр» романының урыны аеруча нык. Андагы Мәдинә, Хәдичә,

Шапрай карт үзләренең тормышчанлыклары, калку индивидуаль характерлары белән әдәбиятыбызның образлар галереясен баеттылар.

Аннары, шушы елларда иҗат ителгән «Җирән кашка» повестен мин авторның иң уңышлы әсәрләреннән берсе дияр идем. Ат язмышы аша халкыбыз тормышының кызыклы һәм гыйбрәтле сәхифәләре ачыла әсәрдә, сюжеты мавыктыргыч һәм җыйнак, теле дә йөгереклеге һәм нәфислеге белән куандыра.

Җитмешенче еллардан М. Хәсәнов иҗатында өченче дулкын башланды. Бүгенге көн колхоз авылы терлекчеләре турында «Хәдичә» романы «Казан утлары»нда басылды. «Кама таңнары» романы аерым китап булып чыкты. Күптән түгел журналда бу романның дәвамы — «Инженерлар» дөнья күрде.

Дилогия мәшһүр КамАЗ төзүчеләре тормышыннан. Бу турыда соңгы елларда шактый гына әсәрләр язылды. М. Хәсәнов дилогиясе исә, башлыча, автогигант төзелешендәге электрон-хисаплау үзәге инженерлары тормышын, аларның иҗади эзләнүләрен чагылдыра. Шушы фәнни-техник үзәкнең җитәкчесе, зур тормыш юлы үткән, иҗади фикерле Котдусов үзенең профессиональ сыйфатлары белән генә түгел, сизгер җанлы, бай рухлы, тирән хисле шәхес буларак та укучылар күңелен яулап ала.

Укучылар бәлки тагын бер нәрсәгә игътибар итәр. М. Хәсәнов иҗатындагы әлеге дулкыннар илебез һәм республикабыз тормышындагы иң мөһим һәм актуаль вакыйгалар белән бәйле рәвештә күтәрелде. Язучының тормыш белән бергә атларга омтылуын бик матур күрсәтеп тора бу! Теләгебез шул: мондый өлгерлек, бу мактаулы омтылыш әсәрнең сыйфат-тирәнлек ягына зыян китерә күрмәсен! Каләмдәш дус моны, әлбәттә, бик яхшы аңлый, тәнкыйть сүзенә сизгер, эчкерсез колак сала белә ул, һәм аның каләме әсәрдән-әсәргә ныгый бара.

Язучы үзенең 50 яшьлеген яңа әсәрләр белән каршылый. «Ялкын» журналында аның «Шайтан малае» повесте басыла, нефтьчеләр тормышыннан «Шөгеровлар» дигән яңа романы тәмамланып килә.

Эшчән һәм ару-талу белмәс Мәхмүт Хәсәновка яңа куәтле иҗат дулкыннары телибез!

**РАФАИЛ ТӨХФӘТУЛЛИН.**

Шәүкәт Галиев

# БУЛАТ ХИКМӘТЛӘРЕ

## Булат белгән

Нинди әни
Сайлый белгән,
Нинди әти
Сайлый белгән!
Дәү әниләр
Сайлый белгән,
Дәү әтиләр
Сайлый белгән!

Сайлый белгән
Нинди заман, —
Бөтенесе
Бигрәк таман!
Бәхетен ул
Җайлый белгән —
Туган җирне
Сайлый белгән!

## Булат карый

Булат карый
Дөньяга —
Аңа бар да
Өр-яңа!
Урамагыз
Юрганга —
Карый яңа
Урамга!

Кыстамагыз
Йокларга —
Карый яңа
Йортларга!
Карый аңа
Дөнья да —
Булат та бит
Өр-яңа!

## Булат эшли

Зур начальник
Булат монда —
Техника күп
Кул астында.
Тракторны
Эшләтәсе...
Танкларны
Нишләтәсе?

Ансын ары
Илттерәсе,
Бусын бире
Китерәсе...
Уйлый Булат,
Җитди төсе —
Уен түгел,
Җитди эше!

## Булат яктырта

Кайтып керә-
Керүенә
Электрга
Ул үрелә —
Тизрәк алгы
Якка уза,
Берәм-берәм
Ут кабыза.

Лампочкадай
Үзе көлә —
Күзе көлә,
Йөзе көлә.
Ул кердеме,
Өй яктыра —
Бәр кешене
Елмайттыра!

## Булат бии

Әделдәти-
Үтәти,
Тик тормыйдыр
Бу тәпи!
Тып-тып кына,
Тып кына,
Юргалыйдыр
Мут кына!

Нинди көйгә
Көйлидер,
Нинди телдә
Биидер:
Әделдәти-
Үтәти,
Әти тәти!
Мин тәти!

## Булат сызгыра

Ни кызык бар
Кошсыз гына?
Куаклыкта
Кош сызгыра!
Булат — кошча,
Кош — аныңча,
Буламени
Охшашмыйча?

Тыңлаштылар,
Аңлаштылар,
Сызгырулар
Алмаштылар.
Белмим, нидер
Тел төбендә —
Сөйләшәләр
Кош телендә!

## Булат чаба

Поезд фырлап,
Тузып чаба,
Һәммәсен дә
Узып чаба:
Ыргып барган
Ат та кала,
Машиналар
Артта кала —

Улап чаба,
Дулап чаба!
Поезддан тиз
Булат чаба!!
Әйе, әйе,
Уйлап кара —
Ул бит вагон
Буйлап бара!

## Булат ничәдә

Булат, Булат,
Яшермә,
Әйт, син ничә
Яшеңдә?
Мыштым гына
Йөрмә гел,
Исәпликче
Бергә бер:

Былтыр булса
Бердәнбер,
Быел артты
Бермә-бер!
Бигрәк зирәк
Бала шул —
Яшен саный
Ала шул!

## Роберт Миңнуллин

### Йолдыз буласым килә

Кайчагында минем бик тә
Йолдыз буласым килә.
Күккә — йолдызлар янына
Менеп кунасым килә.

Мин йолдызга әйләнүнең
Хикмәтен әгәр белсәм,
Әкияттәге шикелле
Йолдызга әверелсәм,

Әнием төннәр буена
Һаваны күзләр иде,
Күпме йолдыз арасыннан
Гел мине эзләр иде...

Кайтып керсәм, әни башта
Аптырап калыр иде.
Таныгачтын мине шундук
Кочаклап алыр иде.

Ә малайлар уенчык дип
Уйнарлар иде бугай,
Уйнамасам, усаллары
Кыйнарлар иде бугай.

Кыйнасалар, тыелалмам —
Минем еласым килер.
... Шуннан соң минем яңадан
Үзем буласым килер.

### Автобуста

Ишек ачылып киткәчтен,
Мин кем керә дип торам:
Малайлардан да уздырып
Килеп керде ак буран.

Бераз аптырап торды да
Тузгытып ак карларын,
Безнең аяк астына ук
Кереп качты аннары.

Песи кебек йомарланып
Бара ул тып-тын гына,
Кондуктор күрмәсен диеп,
Шым гына, мыштым гына.

Җәяүле буран да хәзер
Алдатмый — ай-яй, оста:
Безнең кебек рәхәтләнеп
Йөри ул автобуста.

## Акбай шулай ди

Акбай дустым бик акыллы.
.Мин аның телен беләм.
Ул үзе дә нәкъ кешечә
Сөйләшә минем белән.

Ул миннән берни яшерми:
Сиңа бер сер сөйлим, ди.
Мин бит безнең урамдагы
Малайларны сөймим, ди.

Урамга да чыгып булмый,
Мине рәнҗетәләр, ди.
Я миңа таш аталар, ди,
Я үртәп үтәләр, ди.

Үртәсеннәр әле, әйдә,
Мин әлегә түзәм, ди.
Әгәр тагын үртәсәләр,
Чабуларын өзәм, ди.

Алай да туктамасалар,
Аякларын тешлим, ди.
Алар миңа нишләсәләр,
Мин дә шуны эшлим, ди.

Урамга да чыгармыйм, ди,
Тагын усаллансагыз...
Әнә үзеннән сорагыз,
Әгәр ышанмасагыз.

Зәки Нури

# ЧӘНЕЧКЕЛӘРДӘН МУЕНСА

## ТУКТАЛДЫ

Биш минутлык дигән бер киңәшмә
Ярты көн барды.
Тукталмас та иде әле бәлки...
Мөдир бик арды.

## РЕЖИССЕР КҮРСӘТМӘСЕ

Сәхнәдән чыкканда артист
Каты басып атламасын —
Тамашачылар уянып
Сызгырыша башламасын...

## САКАЛЫН АЛДЫРА ЕГЕТ

— Сакалымны кырыксак иде, кызлар!
Я, кайсыгыз тизрәк аны башлар?
Тик чамасыз итеп кыскартмагыз, —
Юкса, мине өйдә танымаслар.

## БҮЛЕНГӘН СҮЗ

— Ярый, дустым, трубканы куям...
Картым, ахры, безне ишеткән —
Әрчи торган бәрәңгесен ташлап
Чыгып килә әнә ишектән.

## АЛЛАГА СЫЛТАУ

— Алайса, «талант — ходайдан» дисең?..
— Әйе, сәләтне «алла бирә» дим.
— Ә бит алла юк! Талантым юкка
Гаепле түгел шуңа күрә мин.

## ҮПКӘЛӘШКӘННӘР

Өч ел инде сөйләшмиләр алар.
Елына бер җибәрелгән хат та
Тик чип-чиста кәгазь бите була,
Бер хәреф тә булмый анда хәтта.

## КӨТМӘГӘНДӘ КОТ ОЧУ

— Нинди тавыш, нинди гауга анда?
Кешеләрнең оча коты ник?
— Хулиганнар бер тинтәкне кыйный...
— Әйдә, тизрәк качып котылыйк!

## КИЛЕРЛӘРЕ ЮК ТҮГЕЛ...

— Аласыз сез каян, нинди килер —
Син, Сакалбай, һәм син, тәти яр?
— Дүрт пенсия килә! — икебезгә
Ике ана, ике әти бар.

## ЕГЕТНЕ КӘЛӘШ УРЛАДЫ

Укыттылар аны агрономга,
Ә ул качты безнең колхоздан —
Бөгелмәдә сыра сата хәзер:
«Аерылыпмы әллә кал кыздан?!.»

## ӘНИСЕНӘ ХАТ

— Терел, әни! Мин дә исән-саумын —
Тормыш буйлап әкрен генә юртам.
Кайта алмыйм. Сездә юллар начар,
«Жигули»ем ватылыр диеп куркам.

## САМОГОН ҖЕНЕ ТИГӘН ҖАН

— Бар әле, Нәби, белеп кил: Хәсби
Кереште микән теге эшенә!
— Иртән үк булдым... Өметеңне өз —
Бүген ул бары коймак пешерә...

## КҮЗЕНӘ БӘРЕП ӘЙТТЕ

— Ник эшкә соңгарып килдең?
Шелтә төшә башыңа!
— Чөнки шулай әкрен йөри
Син төзәткән машина...

## ТАЛАШМАСЫННАР ӨЧЕН

— Кибетчеләр авыз-борын бәйләп эшли,
Әллә тагын килә микән явыз грипп?
— Юк, минемчә, бәйләткәннәр, талашмагыз
һәм кешедән көлмәгез, дип, авыз ерып.

## ИКЕ БӘРӘН СӨЙЛӘШӘ

— Ишеттеңме, бүре эштән «очкан»!
— Мә-әә! Кайчан?
— Инде өч айлап.
— Бик шәп булган! Аны тәнкыйтьләргә
Күптән йөрдем мин дә теш кайрап...

## ФЕРМА КӘҖӘСЕ ЗАРЫ

Мамык шәлләремне бәйләп
Сатарга онытмыйлар.
Җылы йонымны кыркалар,
Фермамны җылытмыйлар.

## МӘЧЕТКӘ ЙӨРҮ

— Мәчеткә еш йөрисеңме, бабай?
— Мин кәҗәмне — менә күрәсең! —
Көн дә йөртәм шунда ашатырга, —
Үлән басты мәчет тирәсен.

## ЯҢА БИНА

— Ничек эшли безнең китапханә?
— Ишегенең ябылганы юк.
— Халык күпме?
— Түгел, ишегенә
Әле тупса кагылганы юк.

## БИШ БҮЛМӘЛЕ ФАТИРДА

— Әбидән хат бар. Кунакка килә.
Ә ничек каршы алырбыз икән?
Коридор... Кухня... Караңгы бүлмә...
Йокларга кая салырбыз икән?..

## ИРЕ БИРГӘН БӘЯ

— Күрче, менә нинди күлмәк тектердем, —
Дип мактана чибәр ханым иренә. —
Әйт, матурмы? Ошадымы модасы?
— Төймәләре шактый матур күренә...

## УЙЛЫЙ БЕРӘҮ

Сигезенче март! Шәп бәйрәм!
Күктән төшкән төсле ул:
Безгә, ирләргә, ел саен
Бер ял көне өсти ул.

## ПЕЛӘШЕ АКЛАДЫ

— Шулпагызда ике бөртек чәч йөзә бит!
Повар кайда? Ник сатасыз мондый ашны?
— Повар — мин ул. Каян килсен ди монда чәч?
Күрмисеңме әллә, мин бит пеләш башлы.

## ҮШӘН ПЕГАС

Дүрт аякка бер пар канат...
Юлда йөрми, очканы юк.
Илһам чишмәсенә иелеп
Хәтта су да эчкәне юк.

## МӨДИР БЕЛӘН КАРАВЫЛЧЫ ГӘБЕ

Мөдир әйтә: — Мәхмүт кәкре куллы,
Күзне аңа күбрәк сал син, — ди.
— Бездә теккән начар читекләрне
Кем урласын һәм... кем алсын ди?

## ТРАНЗИСТОРЛЫ БҮРЕ

— Әйдә, Бәрәнкәй, урманга керик —
Кайнар кояштан, ят күздән качыйк!
Исемдә калсын матур очрашу,
Музыка тыңлап бер күңел ачыйк...

## БАТАСЫ ЮК

«Таһир бата, Таһир!» дигән сүзләр
Тәшвишле һәм хәтәр иделәр...
Су буена беркем ашыкмады:
«Ул сай йөзә... батмас!» диделәр.

## ӨЙЛӘНГӘЧ

— Ник бик ашыгасың өйгә?
Тукта, эшеңне тикшерим.
— Хатыным ач утырадыр,
Тизрәк кайтып аш пешерим.

## УРМАНЧЫ САЛДЫРГАН ЙОРТ

— Инде дәү дә соң! Бәясе,
Имеш, унбер меңнән ашкан.
— Күпме агач тотты икән
Салыр өчен шуны таштан?

## БЕЛГӘНЕН ӘЙТТЕ

— Туебызны безнең төштә күрдем...
Кайчан булыр никах? Чынлап та,
Мин нишләргә тиеш инде, егет?..
— Иртәрәк тор, җаный, соң ят та.

## ДИССЕРТАЦИЯ

Башта аны яклый ул,
«Юганда» — эчә, ашый.
Ә аннары тик шуның
Артына качып яши.

## ИСКЕ КҮРЕНЕШ

Физзарядка ясап йөри ире —
Йөгереп уза буп-буш урамнан.
Ә хатыны кул арбасы белән
Утын ташый өйгә урманнан.

## КҮН ТӨПЛЕ ЧАЛБАР

Күн төпле чалбар тектерде куштан
Утырышларда тузмасын өчен.
Утырышны ул изге чара саный
Гомере бушка узмасын өчен.

## БӘЙЛӘҮ ОСТАСЫ

— Шул хәтле күп әйбер бәйләгәнсең,
Салсаң сыймас чемоданга!..
— Җыелышларда, утырышларда бәйлим.
Һәм... Лекция тыңлаганда.

## ҖЫР КАРАГЫ

Тик җил югында беленә
Флюгер характеры:
Җыры аның — тик җил җырын
Урлаган карак җыры.

## АУДАН КАЙТКАЧ

— Дөп-дөресен әйтми булмый ачык итеп:
Ай буена ит алмабыз инде, хатын!
— Ике потлы кабан атып кайттың мәллә?
— Эчеп бетереп кайттым айлык хезмәт хакын.

## ЯРӘШКӘНДӘ АҢЛАШУ

— Күтәреп кенә йөртермен сине! —
Иң җиңел йөгем булырсың, тиңем.
Күктә пар коштай очу шул булыр...
— Ә соң машинаң юкмыни синең?!

## ЯЛГАН ТӨС

Үз сурәтен үзе сызды күке,
Кызыл буяу кушып дегеткә.
«Герой ана» дигән исем биреп,
Алып китте шуны кибеткә.

oooooooooooooo

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## РСФСР ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНДА

Сентябрь аенда РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретариаты Россия прозасы советының Казанда үткәрелгән күчмә утырышы йомгакларын карады. Бу утырыш «Бүгенге татар әдәбиятында хезмәт кешесе образы» дигән темага багышланган иде. РСФСР Язучылар союзы идарәсе күчмә утырышта эшчеләр сыйныфы турындагы татар прозасын тикшерү югары идея-иҗади биеклектә һәм теоретик югарылыкта булуына басым ясап әйтте.

Секретариат Совет Татарстаны язучыларының бөтен халык белән бергә Бөек Октябрьның 60 еллыгына лаеклы хәзерләнүен һәм СССР Конституциясен тикшерүдә актив катнашканлыгын да билгеләп үтте.

Секретариат утырышында РСФСР язучылар союзы секретарьлары А. Алексин, Ю. Комаров, С. Орлов, М. Шевченко чыгыш ясадылар.

## ЖУРНАЛ ТУРЫНДА ФИКЕР АЛЫШУ

16 сентябрьдә Татарстан Язучылар союзы каршындагы башлангыч партия оешмасының ачык җыелышы булды. Ул «Казан утлары» журналының 1977 ел, 1—6 саннарында басылып чыккан әсәрләр турында фикер алышуга багышланган иде. Җыелышта проза буенча Аяз Гыйләҗев, поэзия буенча Наис Гамбәров, әдәби тәнкыйть буенча Альберт Яхин, публицистика һәм очерклар буенча Кояш Тимбикова докладлары тыңланды. Фикер алышуларда Барлас Камалов, Сибгат Хәким, Фатих Хөсни, Әдип Маликов һәм башкалар катнашты. Йомгаклау сүзе белән ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов чыкты.

## ӘГЕРҖЕДӘ ӘДӘБИЯТ БӘЙРӘМЕ

1977 ел башында Әгерҗе районының Пушкин исемендәге колхозы белән ТАССР Язучылар союзы үзара хезмәттәшлек буенча килешү төзегәннәр иде. Бу килешү буенча, Татарстан язучылары авыл хезмәт ияләренең тормышын һәм эшләрен яктырткан яңа әсәрләр иҗат итәргә, колхозда әдәби кичәләр уздырырга өстенә алган, ә Пушкин исемендәге колхоз шул әсәрләргә конкурс игълан итеп, иң әйбәтләренә премия билгеләгән иде. Конкурс нәтиҗәләрен билгеләү өчен идарә колхоз председателе М. Исмәгыйлов җитәкчелегендә жюри төзеде.

Жюри язучы Мөсәгыйть Хәбибуллинның «Чоңгыллар» исемле китабын иң яхшы әсәр дип бәяләде һәм аны Пушкин исемендәге колхоз лауреаты итеп билгеләде. Колхозда шушы әсәр буенча укучылар конференциясе үткәрелде.

25—26 сентябрьдә Г. Ахунов, М. Хәбибуллин, Разил Вәлиев, Эльс Гаделев һәм Шәһидә Максудова составындагы ТАССР Язучылар союзы делегациясе Пушкин исемендәге колхозда булдылар. Колхоз идарәсе М. Хәбибуллинга диплом һәм бүләкләр тапшырды.

Икенче көнне колхоз культура сараенда Г. Ахуновның «Идел кызы» романының беренче китабы буенча укучылар конференциясе узды. Анда әдәбият сөючеләр романның Әгерҗе яклары җирлегендә язылуының үзләре өчен шатлыклы булуы, геройларның ышандыргыч һәм оста эшләнгән икәнлеген әйттеләр. Конференция барышында язучылар Г. Ахунов һәм М. Хәбибуллин халык депутатларының Әгерҗе район комитетының Мактау грамоталары белән бүләкләнделәр.

Пушкин исемендәге колхоздагы әдәби бәйрәм Татарстан артистлары куйган концерт белән тәмамланды.

## КӘРИМ ТИНЧУРИННЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Сентябрь аенда Татарстан җәмәгатьчелеге күренекле татар совет драматургы, театр эшлеклесе, язучы Кәрим Тинчуринның тууына 90 ел тулуны билгеләп үтте. 22 сентябрь көнне Казанда К. Тинчуринның әдәби һәм җәмәгать эшчәнлегенә багышланган фәнни конференция булды. Докладлар белән СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты директоры профессор М. Мөхәррәмов, шушы институтның фәнни хезмәткәрләре Б. Гыйззәт, М. Хәбибуллин, Казан культура институты укытучылары Р. Игъламов, Х. Кумысников, Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрының баш режиссеры М. Сәлимҗанов, ТАССРның халык артисты Х. Сәлимҗанов, ТАССР Дәүләт музееның фәнни хезмәткәре Ф. Абдуллин чыкты.

Конференция эшендә КПССның Татарстан өлкә комитетының фән һәм уку йорт-

лары бүлеге мөдире Ә. С. Миндубаев катнашты.

23 сентябрьдә Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры бинасында әдип юбилеена багышланган тантаналы кичә булды. Кичәне Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге председателе Р. Җиһаншина ачты. К. Тинчуринның тормыш һәм иҗат юлы турында ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов доклад сөйләде. Тантаналы кичә соңында сәнгать осталары көче белән зур концерт бирелде.

## ТАТАР КИТАПЛАРЫ — ХАЛЫКАРА ЯРМИНКӘДӘ

6 сентябрьдән 14 сентябрьгәчә Ватаныбыз башкаласында Беренче Мәскәү халыкара китап күргәзмә-ярминкәсе булып узды. «Китап тынычлык һәм прогресс өчен көрәштә» дигән девиз астында үткәрелгән бу күргәзмәдә 65 илнең меңярымнан артык оешма һәм фирмалары, шул исәптән АКШ, Бөекбритания, Франция, Италия, Япония кебек илләрнең иң зур нәшриятлары катнашты.

Билгеле булганча, Советлар Союзы китапны иң күп укучы илләрдән санала. Шуңа күрә күргәзмә-ярминкәдә иң зур урын СССРда басылып чыккан китапларга бирелүе табигый иде. Совет бүлеге экспозицияләрендә Татарстан китап нәшрияты чыгарган китаплар да лаеклы урын алды.

Күргәзмәне караучылар В. И. Ленин әсәрләренең татар телендәге дүртенче басмасының аерым томнары, СССРның яңа Конституциясе проектының татарча басмасы, КамАЗ елъязмасының ике китабы («Батыр үргә күтәрелә», «Батыр сынау үтә»), Габдулла Тукай, Муса Җәлил әсәрләренең дүрт томлыклары, Тукай, Җәлил, С. Хәким әсәрләренең бүләк өчен чыгарылган кечкенә күләмле махсус басмалары, Муса Җәлилгә багышланган фотоальбом, Равил Фәйзуллинның «Шигырьләр. Поэмалар» дигән китабы белән таныштылар. Күргәзмәдә шулай ук татар язучыларының үзәк нәшриятларында басылып чыккан кайбер әсәрләре, аерым алганда, Габдулла Тукайның «Сайланмалар» («Советская Россия» нәшрияты), Шамил Бикчуринның «Каты токым», Эдуард Касыймовның «Чулман — оныклар елгасы» («Современник» нәшрияты) дигән китаплары да куелган иде.

## ДРАМАТУРГЛАР КИҢӘШӘ

Октябрь башында Казанның Актерлар йортында Татарстан драматургларының республика семинары булды. Аны Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге, Татарстан Язучылар союзының драма секциясе оештырды. Семинарны алып барыр өчен Мәскәү театр белгечләре — «Театр» журналының редколлегия члены, сәнгать фәннәре кандидаты О. Дзюбинская, режиссер А. Шатрин, Бөтенроссия театр җәмгыятеннән А. Вольфсон килде.

Бөек Октябрьның 60 еллыгына багышланган бу иҗади киңәшмәдә драматургларыбызның соңгы елларда язылган әсәрләре хакында фикер алышу булды, шулай ук, яшь драматургларның яңа әсәрләрен тикшереп, аларга практик ярдәм күрсәтелде. Семинарда республика театрларының режиссерлары, әдәби бүлек мөдирләре дә катнашты.

## ТУКАЙ ӘСӘРЛӘРЕ ПЛАСТИНКАДА

Бөтенсоюз «Мелодия» фирмасы чыгарган бу пластинка «Габдулла Тукай. Шигырьләр. Мәсәлләр» дип атала. Тукай әсәрләрен ТАССРның халык артисты, Тукай бүләге һәм башкаручыларның Бөтенсоюз конкурслары лауреаты Айрат Арсланов укый. Пластинканың тышлыгындагы аннотацияне РСФСРның М. Горький исемендәге премиясе лауреаты шагыйрь Сибгат Хәким язган.

## СОВЕТ УТЫРЫШЫ

Сентябрь азагында РСФСР Язучылар союзы каршындагы тәнкыйть буенча совет бюросының киңәйтелгән утырышы булды. Анда бу советның киләчәк эш планнары каралды. Доклад белән совет председателе В. Дементьев чыкты. Фикер алышуларда РСФСРның төрле шәһәрләреннән һәм автономияле республикаларыннан килгән язучылар белән рәттән Татарстан тәнкыйтьчесе Нур Гыйззәтуллин да чыгыш ясады.

## ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫ СЕБЕРДӘ

КПССның Юрга шәһәр комитеты чакыруы буенча республикабыз комсомолының М. Җәлил премиясе лауреатлары Илдар Юзеев һәм Туфан Миңнуллин Кемерово өлкәсенең Юрга шәһәрендә, Сарсаз һәм Кышлау авылларында әдәби кичәләр үткәрделәр. Кичәләрдә Юрга шәһәренең «Победа» культура сарае каршындагы татар үзешчән сәнгать коллективы катнашты.

## АВЫЛ УКУЧЫСЫНА

Татарстан Язучылар союзы каршындагы матур әдәбиятны пропагандалау бюросы әледән-әле язучылар бригадаларының укучылар белән очрашуларын оештырып тора. Сентябрь аенда язучылар Нәби Дәүли, Роберт Әхмәтҗанов, бюро директоры Эльс Гаделев һәм Бөтенсоюз конкурсы лауреаты жырчы Вафирә Гыйззәтуллина Кама Тамагы районы авыл эшчәннәре белән очраштылар. Алар «Большевик», Тукай исемендәге, «Беренче май», XXII партсъезд исемендәге, «Ирек» колхозларында булдылар.

## ӘДӘБИ ТҮГӘРӘКЛӘРДӘ

ТАССР Язучылар союзы идарәсе каршындагы яшьләр белән эшләү комиссиясе председателе шагыйрь Шәүкәт Галиев, ТАССР Язучылар союзы идарәсенең әдәби

консультанты шагыйрь Илдар Юзеев һәм «Азат хатын» журналының баш редакторы урынбасары язучы Габдулла Шәрәфетдинов Зәй, Түбән Кама, Тукай һәм Алабуга районнарындагы әдәби түгәрәкләрдә яшь язучылар белән очраштылар.

## ЯЗУЧЫ БӘЙРӘМЕ

30 сентябрьдә Казанның Актерлар йортында язучы Рәйсә Ишморатовага 60 яшь тулуга багышланган тантаналы кичә булды. Кичәне «Казан утлары» журналының җаваплы секретаре язучы Ләбибә Ихсанова ачты. Р. Ишморатованың тормыш һәм иҗат юлы турында язучы Кояш Тимбикова сөйләде. Әдипне КПССның Бауман райкомы, Татарстан Язучылар союзы, китап нәшрияты, республика газеталары һәм театрлары, Арча районы вәкилләре һәм ТАССР Эчке эшләр министрлыгы делегациясе исеменнән идеология эшләре буенча министр урынбасары полковник С. Г. Тайбинский котладылар, кыйммәтле бүләкләр һәм котлау адреслары тапшырдылар. Актерлар йортының фойэсында Р. Ишморатова иҗатына багышланган күргәзмә оештырылган иде.

Кичәдән соң ТАССР сәнгать осталары тарафыннан концерт бирелде.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

14 сентябрьдә бүлек утырышында нефть ягы язучыларының көндәлек матбугатта катнашуы турында сөйләшү булды. Бу турыда Мәхмүт Хәсәновның доклады тыңланды. Фикер алышуларда язучылардан Әдип Маликов, Рафаил Төхфәтуллин, Сажидә Сөләйманова, Клара Булатова, Хәниф Хәйруллин, Җәмит Рәхимов, яшь шагыйрь Нур Әхмәдиев катнашты.

*

* *

Чираттагы утырышта Баулы газетасында эшләүче журналист Зөфәр Абдуллинның «Без — Минзәлә яклары» исемле повесте тикшерелде. Г. Афзал, Р. Төхфәтуллин, Ә. Маликов әсәрне камилләштерү юнәлешендә авторга теләкләрен белдерделәр.

*

* *

Әлмәт әдәбият берләшмәсе утырышында яшь язучы Фәрит Гыйльметдиновның «Казан утлары» журналында басылган (1977, август) «Урсай тау итәгендә» дигән повесте буенча фикер алышу булды.

Чыгыш ясаучылар авторның тормышны яхшы белеп, юморга бай тел белән язуы турында ассызыклап әйттеләр. Соңыннан әдәби берләшмәнең штаттан тыш консультанты шагыйрә Сажидә Сөләйманова йомгаклау сүзе әйтте.

* *

*

Урып-җыю чорында Лениногорск шәһәрендәге «Чишмә» әдәбият-сәнгать берләшмәсеннән Шамил Бикчурин, Җәмит Рәхимов, Әсрар Галиев, Рәшит Башаров, Разим Вәлиуллин, Шәрига Таһирова, Таһир Шәмсуаров, Наил Гыйләҗев, шулай ук үзешчән артистлар районның Мичурин исемендәге колхозында һәм Куйбышев исемендәге колхозның Мөэмин-Каратай авылында әдәби-музыкаль кичә уздырдылар.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМ

СССР Верховный Советы Президиумының 1977 ел, 16 сентябрь Указы белән Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры артисты **Шәүкәт Хәсән улы Биктимеровка** совет театр сәнгатен үстерүдәге зур хезмәтләре өчен **СССРның халык артисты** дигән мактаулы исем бирелде.

## ВЛКСМ ҮЗӘК КОМИТЕТЫНДА

Яшьләргә эстетик тәрбия бирүдә актив эшләгәннәре өчен хезмәт иясе депутатларының Сарман район советы культура бүлеге мөдире **Баязитов Ә. Н.** һәм шул районның Культура йорты директоры **Сафин И. Д. ВЛКСМ Үзәк Комитетының Почет грамотасы** белән бүләкләнделәр.

*

* *

ВЛКСМ Үзәк Комитеты инициативасы белән, СССР Художниклар союзының бер төркем яшь рәссамнары һәм скульпторлары комсомол удар төзелешләрендә булдылар. Аларның бер группасы безнең республикабыз башкаласында, авылларда, борынгы Болгар җирендә, кыр станнарында, КамАЗда булып, Татарстан хезмәтчәннәренең тормышы, эше белән таныштылар, күп кенә эскизлар ясадылар.

## РОССИЯ РӘССАМНАРЫ КҮРГӘЗМӘСЕ

9 сентябрьдә Мәскәүнең Үзәк күргәзмә залында Россия рәссамнарының Бөек Октябрьның 60 еллыгына багышланган күргәзмәсе ачылды. Анда РСФСР Художниклар союзының 70 өлкә, край һәм автономияле республика оешмаларыннан килгән 1806 авторның 3625 әсәре куелды. Алар арасында Татарстаннан да 18 рәссамның әсәрләре куелган. Татарстан рәссамнары үз әсәрләрендә республикабыз тормышының күрке булган КамАЗ төзелеше, нефть яклары һәм авыл хезмәтчәннәре тормышы турында сөйлиләр.

## КҮРГӘЗМӘ УҢАЕ БЕЛӘН

Сентябрь аенда Әлмәт шәһәрендә Татарстан рәссамнарының Бөек Октябрьга багышланган күргәзмәсе ачылды. Анда республикабызның төрле урыннарында яшәп иҗат итүче, төрле яшьтәге рәссамнарның 150 дән артык әсәре куелды.

Күргәзмә ачылган көндә Әлмәт шәһәрендә ТАССР Художниклар союзы идарәсенең күчмә утырышы булды. Көн тәртибен-

дә рәссамнарыбыз иҗатында республика нефть һәм газ чыгаручылары тормышын тирәнрәк чагылдыру мәсьәләләре куелды.

Татарстан Художниклар союзы Әлмәттәге сынлы сәнгать галереясына 50 дән артык әсәр бүләк итте.

*

* *

Казанның Яшьләр үзәгендә мәрхүм рәссам Константин Васильев әсәрләре күргәзмәсе булды. 34 яшьлек, гомеренең күп өлешен Татарстанның Васильево поселогында үткәргән бу рәссамның байтак әсәре күрсәтелде.

### САТИРА ТЫНЫЧЛЫК ӨЧЕН КӨРӘШТӘ

Минск шәһәрендә рәссамнарның «Сатира тынычлык өчен көрәштә» дигән өченче халыкара күргәзмәсе эшли. Экспозицияләрдә Татарстан графиклары С. Насыйрова, Л. Насыйров, Л. Бочкова, Ю. Денисов, И. Бобровицкий, Л. Елькович, И. Хантимеров, В. Игнатьев әсәрләре дә куелды.

### ЯҢА КОЛЛЕКТИВ

Быел Оренбург филармониясе каршында «Ялкын» исемле татар эстрада бригадасы оештырылды. Өч-дүрт ай эчендә ул Оренбург ягы районнарында чыгышлар ясады, тамашачыларның ихтирамын яулады.

### ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ — ӘДӘБИЯТ СӨЮЧЕЛӘРГӘ

Татарстан китап нәшрияты РСФСРда иң зур нәшриятларның берсе. Ул ел саен 350—360 исемдә басма әдәбият чыгарып килә. Аларның зур күпчелеге — матур әдәбият китаплары. Нәшриятның 1978 елга тематик планында да матур әдәбият әсәрләре шактый.

Проза сөючеләр алдагы елда Г. Ахуновның «Идел кызы» (трилогиянең беренче кисәге) әсәре, Ш. Хөсәеновның «Мәхәббәт сагышы», Б. Камалның «Канат ярганда», Ә. Гаффаровның «Теге гозер», А. Вергазовның «Дулкыннар ни сөйли», Г. Кашаповның «Сәмум җиле» исемле повестьлары, М. Хужин, М. Рафиков, А. Тимергалин хикәяләре, А. Гыйләҗев, Л. Ихсанова, Ф. Мансуров, Җ. Рәхимов җыентыклары, Ә. Маликов очерклары һ. б. белән танышачаклар.

Поэзия сөючеләрне дә күңелле очрашулар көтә. Алдагы елда шагыйрьләребездән Н. Арслановның «Уйлар-сагышлар», Ш. Маннурның «Күңел бакчасы», М. Садриның «Җырым юлдаш булсын», Ш. Галиевнең «Шигырьләр, поэмалар», И. Юзеевнең «Өзелмәс кыллар», М. Шабаевның «Көн артыннан көн», Г. Рәхимнең «Моңнарым», Р. Гатауллинның «Ирләр булыйк» исемле китаплары, М. Әгъләмов, Р. Мингалимов, Зөлфәт, Р. Харисов, Ф. Яруллин, Ә. Гадел, Р. Рәхимов һәм башкаларның шигырь җыентыклары дөнья күрәчәк.

Драма жанрын яратучыларга Х. Вахитның «Яшьлек эзләре», Т. Миңнуллинның «Китәр юлың еракмы», башкорт драматургы Ә. Мирзаһитовның «Күршеләр» исемле җыентыклары тәкъдим ителә.

Нәшрият татар әдәбияты классикларының әсәрләрен чыгаруга даими игътибар бирә. Бу эш 1978 елда да дәвам иттереләчәк. Аерым алганда, күренекле драматург Тажи Гыйззәт әсәрләренең 4 томлык җыелмасының дүртенче томы, шулай ук Г. Камал, Ш. Усманов, Ф. Кәрим, А. Алиш, Ә. Фәйзи һ. б. әсәрләре дөньяга чыгачак.

Партиябезнең әдәбият-сәнгать тәнкыйте турындагы мәгълүм карарыннан соң бу өлкәдә эш шактый җанланды. Нәшрият ел саен әдәбият белеме һәм әдәби тәнкыйтькә караган дистәгә якын китап чыгарып килә. 1978 елда Х. Госманның «Шигърият гомере», А. Таһирҗановның «Тарихтан әдәбиятка», Ф. Борнашның «Әдәбият һәм сәнгать турында», И. Ахунҗановның «Художник һәм аның сүзе», М. Вәлиевнең «Яшьләр мәйданга чыга» исемле хезмәтләре дөнья күрәчәк.

Татарстан китап нәшрияты татар халык иҗаты җәүһәрләренең 12 томлык җыелмасын чыгаруны башлап җибәргән иде. Киләсе елда исә халык авыз иҗаты әсәрләреннән «Әкиятләр»нең беренче китабын һәм «Дастаннар» томын чыгару күздә тотыла.

### 1977 ЕЛ КИТАПЛАРЫ

Хөрмәтле укучылар!

Татарстан китап нәшрияты 1977 елда түбәндәге китапларны бастырып чыгарды:

**Габдулла Тукай.** Әсәрләр, 4 томда, дүртенче том; **Тажи Гыйззәт.** Әсәрләр, 4 томда, өченче том; **Мәхмүд Максуд.** Сагынган минутларда (Муса Җәлил турында истәлекләр һәм уйланулар); **Фәхри Әсгать.** Сүзләрдән чәчәкләр. Нәсерләр, хикәяләр; **Фатих Хөсни.** Мәйдан; **Әхсән Баянов.** Елларга сәяхәт. Шигырьләр һәм поэмалар; **Шамил Бикчурин.** Алтын җирдә ятмый. Хикәяләр һәм очерклар; **Мәхмүт Хәсәнов.** Урман шаулый. Повестьлар, хикәяләр; **Зәет Мәҗитов.** Рәхмәт яусын. Шигырьләр, поэмалар; **Рафаил Төхфәтуллин.** Акбүз ат. Хикәяләр, очерклар; **Фәнил Мансуров.** Ак буран. Повесть; **Гәрәй Рәхим.** Ак күлмәкле кыз. Хикәяләр; **Фаил Шәфигуллин.** Дулкынга дулкын. Шигырьләр; **Вакыйф Нуруллин.** Яшьнәп үткән яшьлек; **Рафаэль Мостафин.** Алга барышлый. Тәнкыйть мәкаләләре; Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Беренче том.

Бу китаплар урыннардагы китап кибетләрендә булмаса, аларны түбәндәге адрес белән соратып алдырырга мөмкин.

г. Казань, ул. Октябрьская, 18,
магазин № 14, «Книга-почтой».

# 1977 ЕЛДА ЖУРНАЛ БИТЛӘРЕНДӘ БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР

*«Казан утлары» журналын «Почет билгесе» ордены белән бүләкләү турында СССР Верховный Советы Президиумы Указы. № 2.*

*1977 ел өчен Габдулла Тукай исемендәге республика премияләре лауреатлары. № 6.*

Ф. Табеев. **Гүзәл һәйкәлләрнең берсе. № 11.**

ЯҢА КОНСТИТУЦИЯ ПРОЕКТЫН ТИКШЕРӘБЕЗ

Г. Ахунов. **Дәверләр документы. № 9.**

М. Шолохов. **Дүртенче баскыч. № 9.**

**Яклыйбыз, хуплыйбыз! № 9.**

ОКТЯБРЬНЫҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА

М. Абдуллин. **Мөселман социалистлар комитеты һәм буржуаз тарихчылар. № 1.**

С. Батыев, М. Абдуллин. **Октябрь һәм Татарстан. № 7.**

О. Броневский. **Октябрьга баш иям.** Шигырь. **№ 5.**

В. Белокопытов. **Яшәү хакына. № 10.**

И. Варавва. **Бүләк.** Шигырь. **№ 5.**

М. Гәрәев. **Җиңелмәс капитан. № 5.**

Ә. Галиев. **Давыллы еллар аша. № 10.**

Д. Дәүләтшина. **Үзгәрешләр үргә илтә. № 4.**

И. Зарипов. **Туган кыр батыры. № 4.**

В. Иванов. **Мәгърифәтле Казан. № 5.**

В. Кабанов. **Шагыйрь мактар иде аны. № 5.**

Ә. Маликов. **Мәйдан тоту. № 9.**

Р. Мусин. **Киләчәккә атлый Казан. № 6.**

М. Миншин. **Ташкын.** Очерк. **№ 6.**

З. Нури. **Җиңүче солдат, сүз синең хакта. № 5.**

И. Низамов. **Кызыл укчылар. № 8.**

Җ. Рәхимов. **Тынгысыз як. № 8.**

Х. Хәйруллин. **Бригадир Зөфәр.** Очерк. **№ 10.**

Р. Хәйретдинов. **Керәшкә бирелгән тормыш. № 5.**

С. Шакир. **Казан Кремле янында. № 9.**

Ф. Яруллин. **Туган ягы кирәк кешегә.** Шигырьләр. **№ 5.**

Р. Әмирханов. **Вакытлы матбугат һәм цензура. № 1.**

ОКТЯБРЬ ТУДЫРГАН ӘДИПЛӘР БЕЗ

М. Гайнуллин. **Укыдык, укыттык, эшләдек, эшлибез. № 10.**

Р. Гамзатов. **Беренче номерлы пост. № 10.**

Р. Ишморат. **Изге көн, изге ел. № 10.**

А. Расих. **Өч фарыз. № 10.**

Г. Әпсәләмов. **Юл күрсәтүче йолдыз. № 10.**

## ПРОЗА


Г. Ахунов. **Идел кызы.** Роман. **№ 1, № 2, № 3, № 4.**
Ә. Баянов. **Тавыш — табигать бүләге.** Повесть. **№ 12.**
В. Багряшевский. **Чуал.** Хикәя. **№ 6.**
Ә. Гаффар. **Кашан җыры.** Повесть. **№ 10.**
Д. Зөбәерова. **Сызган балдак.** Хикәя. **№ 2.**
В. Иваненко. **Арча.** Хикәя. **№ 4.**
В. Исхаков. **Карт һәм чәчәкләр.** Новелла. **№ 10.**
Р. Ишморатова. **Язмышлар.** Повесть. **№ 6.**
Б. Камалов. **Канатлы кырмыска.** Повесть. **№ 2.**
М. Маликова. **Язгы такыялар.** Повесть. **№ 11.**
Г. Рәхим. **Көннәр язга авышкач...** Повесть. **№ 8.**
Р. Рөстәмова. **Ике нәсер. № 1.**
Х. Сарьян. **Бер ананың биш улы.** Повесть. **№ 9.**
М. Скороходов. **Тундра хикәяләре. № 12.**
Р. Төхфәтуллин. **Китә казлар...** Повесть. **№ 4.**
Ф. Хөсни. **Күп балалы... бабай.** Хикәя. **№ 1.**
Ф. Хөсни. **Җуля — кайгылы эт.** Хикәя. **№ 6.**
М. Хуҗин. **Өч хикәя. № 10.**
М. Хәсәнов. **Инженерлар.** Романнан өзек. **№ 5.**
М. Әмир. **Без бәләкәй чакларда.** Повесть. **№ 6, № 7.**
Г. Әпсәләмов. **Атакай, Анакай.** Хикәя. **№ 8.**
Г. Әпсәләмов. **Яктыга таба.** Хикәя. **№ 11.**


## ПОЭЗИЯ


Н. Арсланов. **Алтын кояш.** Шигырьләр. **№ 6.**
Н. Арсланов. **Аяз булсын тирмәң.** Шигырьләр. **№ 11.**
Г. Афзал. **Чияле тау итәгендә.** Шигырьләр. **№ 1.**
Г. Афзал. **Тарих мең дә...** Шигырь. **№ 11.**
Ш. Анак. **Һәр көнне, һәр сәгатьне.** Шигырь. **№ 11.**
Ә. Баянов. **Кунаклар килде.** Шигырь. **№ 11.**
К. Булатова. **Чатнап торган аяз кичнең...** Шигырьләр. **№ 3.**
Р. Вәлиева. **Мәхәббәт дәфтәреннән.** Шигырьләр. **№ 3.**
Ә. Гадел. **Казан.** Шигырь. **№ 12.**
М. Галиев. **Кайтавазлар.** Шигъри парчалар. **№ 3.**
С. Гәрәева. **Тимер елый.** Шигырьләр. **№ 3.**
Р. Гатауллин. **Европада татар шагыйрьләре.** Шигырьләр. **№ 9.**
Р. Гәрәй. **Күккә менеп...** Шигырьләр. **№ 9.**
Н. Дәүли. **Мадам Клод трагедиясе.** Шигырь. **№ 11.**
Зөлфәт. **Яңа шигырьләр. № 2.**
Р. Закиров. **Шахтер моңы.** Шигырьләр. **№ 8.**
М. Каюмов. **Казаным...** Шигырьләр. **№ 7.**
Г. Латыйп. **Тополь.** Шигырьләр. **№ 11.**
Ш. Маннапов. **Гимнастерка.** Шигырьләр. **№ 4.**
Ш. Маннапов. **Сөембикәң белән.** Шигырь. **№ 12.**
Н. Мадьяров. **Ашкынам болыннарга.** Шигырьләр. **№ 1.**
Р. Мингалимов. **Мин күрмәгән ике якташ.** Шигырь. **№ 12.**
Э. Мостафин. **Атлар китә...** Шигырьләр. **№ 12.**
З. Нури. **Октябрь язы.** Шигырь. **№ 11.**
Н. Нәҗми. **Иблис.** Поэма. **№ 7.**
З. Насыйбуллин. **Корыч коя кеше.** Шигырь. **№ 11.**
К. Обойщиков. **Татарстанга хат.** Шигырь. **№ 6.**
Ә. Рәшитов. **Маяклар.** Шигырьләр. **№ 1.**
Г. Рәхим. **Юлың якты.** Шигырь. **№ 11.**
Г. Рәхим. **Сокланыйк без...** Шигырьләр. **№ 3.**

Г. Садә. **Яңа шигырьләр. № 1.**
Ф. Сафин. **Безнең хакта хак сүз... № 11.**
Д. Сирай. **Шул җырны көйлим.** Шигырьләр. **№ 12.**
С. Сөләйманова. **Казан — күңелем һәйкәлләре иле.** Шигырьләр. **№ 10.**
С. Сөләйманова. **Яр-Чаллы.** Шигырь. **№ 11.**
Х. Туфан. **Иртәләрнең берсе.** Шигырьләр. **№ 1.**
Ш. Таһирова. **Тукайга.** Шигырьләр. **№ 3.**
Р. Фәйзуллин. **Яңа шигырьләр. № 6.**
С. Хәким. **Яңа шигырьләр. № 3.**
М. Хөсәен. **Кояш җайдак...** Шигырьләр. **№ 1.**
Р. Хәлиуллина. **Каенана.** Поэма. **№ 10.**
Э. Шәрифуллина. **Диңгезче малае.** Шигырьләр. **№ 3.**
Ф. Шәфигуллин. **Кызыл мәйдан аша.** Шигырь. **№ 11.**
Ф. Шәфигуллин. **Ник кайтмый.** Шигырьләр. **№ 4.**
И. Юзеев. **Уйланулар.** Шигырьләр. **№ 4.**
И. Юзеев. **Өзелмәс кыллар.** Поэма. **№ 10.**
И. Юзеев. **Мәңгелек хис.** Шигырь. **№ 11.**
Ф. Яруллин. **Без — беренчеләр.** Шигырь. **№ 11.**
М. Әгъләмов. **Бердәнбер кыз турында...** Шигырьләр. **№ 4.**
Р. Әхмәтҗанов. **Уяну.** Шигырьләр. **№ 4.**



## ДУСЛАР ҖЫРЫ

В. Кочетков. **Учак.** Шигырьләр. **№ 5.**
М. Мирмухсин. **Йөрәк җылысы.** Шигырьләр. **№ 11.**
Ж. Мулдагалиев. **Көтеп алган бәхет.** Шигырьләр. **№ 11.**
О. Шестинский. **Әнием.** Шигырьләр. **№ 5.**

## КЛАССИК ӘДӘБИЯТ ҮРНӘКЛӘРЕ

А. Блок. **Тилгән.** Шигырьләр. **№ 1.**
Г. Уэллс. **Тәвә кошлары белән сәүдә.** Хикәя. **№ 12.**

## ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

М. Галиев. **Яңа көрәшчеләр өчен.** Шигырьләр. **№ 8.**
Ф. Гыйльметдинов. **Урсай тау итәгендә.** Повесть. **№ 8.**
Ә. Мөхмүдов. **Халкыма.** Шигырьләр. **№ 8.**
Р. Низамиев. **Ленин кулы.** Шигырьләр. **№ 8.**
Б. Сөләйманов. **Себердән хатлар.** Шигырьләр. **№ 8.**
Р. Хәйри. **Юллар.** Шигырьләр. **№ 8.**
Н. Әхмәдиев. **Үзәктә.** Шигырьләр. **№ 8.**

## СӘХНӘ ӘСӘРЛӘРЕ

Г. Сабитов. **Чулпан таңны уята.** Пьеса. **№ 7.**
С. Шәкүров. **Кыз бирү.** Пьеса. **№ 10.**

## НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

Ш. Галиев. **Яз чиге шушы икән.** Шигырьләр. **№ 2.**
Ш. Галиев. **Булат хикмәтләре.** Шигырьләр. **№ 12.**
З. Гомәрова. **Зәңгәр чәчәк.** Шигырьләр. **№ 5.**
Р. Миңнуллин. **Йолдыз буласым килә.** Шигырьләр. **№ 12.**
Э. Мөэминова. **Бөяштым.** Шигырьләр. **№ 5.**
З. Туфайлова. **Ватаным.** Шигырьләр. **№ 1.**

## ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

Н. Арсланов. **Нурихан Фәттахка. № 5.**
Г. Афзал. **Сәфәргали сәфәрдән кайтты. № 6.**
Ф. Абдуллин. **Көрәшче Тимерләр һәм Миңҗамал җиңги.** Хикәя. **№ 3.**

**Венгр дусларның шаян уклары. № 7.**
Ә. Еники. **Чикерткә.** Әкият. **№ 5.**
К. Задә. **Таяк турында.** Шигырь. **№ 5.**
С. Кальметов. **Үз-үзеңне дәвалау.** Юмореска. **№ 2.**
М. Корюн. **Күп лыгырдау бәласе.** Шигырьләр. **№ 3.**
Кизәнов. **Чәнечкеле монологлар. № 2.**
**Каратау мәзәкләре. № 2.**
**Көрд халык иҗатыннан. № 3.**
**«Капкын» журналы бездә кунакта. № 4.**
Мәмди. **Гыйбрәтле диалоглар. № 3.**
З. Нури. **Чыршы бәйрәме уклары.** Шигырьләр. **№ 1.**
З. Нури. **Чәнечкеләрдән муенса.** Шигырьләр. **№ 12.**
Г. Нәбиуллин. **Мин һәм Салман.** Шигырь. **№ 10.**
**Сатира — һөҗүм коралы. № 5.**
Г. Шәрәфи. **Дәгъва.** Хикәя. **№ 8.**
**Шул да булдымы әхлак. № 11.**
**Әпкәли язмалары. № 10.**
М. Әпкәли. **Пародияләр. № 5.**

## МӘСӘЛЧЕЛӘР МӘҖЛЕСЕ

**Сулхан-Саба Орбелиани. № 9.**
**Сүз әрмән фольклоры геройларына бирелә. № 8.**
**«Панчатантра». № 6.**

## ХАЛЫК ИҖАТЫ

Р. Мөхәммәтҗанов. **Муса Җәлилнең әнисе Рәхимә апа балаларына язган шигъри васыять-хат. № 5.**
Р. Мөхәммәтҗанов. **Эзләсәң — табыла. № 9.**

## ӘДӘБИ БӘЙРӘМНӘР

### Габделҗаббар Кандалыйның 180 еллыгына

Х. Тазюков. **Габделҗаббар Кандалыйның мирасын барлау юлында. № 12.**
Р. Әхмәтов. **Матурлык, мәхәббәт һәм мәгърифәт җырчысы. № 12.**

### Галимҗан Ибраһимовның 90 еллыгына

И. Абдуллин. **Әдипнең тагын бер хаты. № 3.**
Р. Ганиева. **Галимҗан Ибраһимов һәм Көнчыгыш әдәбиятлары. № 3.**
М. Мәһдиев. **Ибраһимов әсәрләрендәге образларның прототиплары. № 1.**
Р. Мөхәммәдиев. **Җаваплылык хисе. № 3.**
С. Поварисов. **Тел диңгезе. № 3.**
Ә. Рәшитов. **Җалита... Җалита.** Шигырь. **№ 3.**
Ш. Турдыев. **Ул безгә дә кадерле. № 2.**
Г. Халит. **Чынлык һәм гүзәллек гармониясе. № 3.**
М. Хәсәнов. **Әдипнең бөеклеге. № 3.**
А. Әхмәдуллин. **Галимҗан Ибраһимов һәм татар драматургиясе. № 3.**
Г. Әхәтов. **Язучы фразеологиясенең кайбер үзенчәлекләре. № 3.**
Н. Юзиев. **Академиянең 250 нче әгъзасы. № 3.**

### К. Тинчуринның 90 еллыгына

Р. Игъламов. **Заман көзгесенә куеп. № 9.**
Р. Ишморат. **Дус һәм остаз. № 9.**
А. Яхин. **Без кабызган утлар... № 9.**

### Ф. Туйкинның тууына 90 ел

Э. Шәрифуллина. Илебез — кадерле җиребез. № 6.

### Г. Нигъмәтинең тууына 80 ел

Х. Госман. Онытылмас остазыбыз. № 7.
Ф. Әгъзәмов. Күренекле журналист. № 7.

### Мохтар Әуэзовның тууына 80 ел

М. Әуэзов. Өйләнү. Хикәя. № 12.

### Бари Рәхмәтнең тууына 80 ел

Р. Кукушкин. Ул бүген дә, киләчәктә дә бар. № 5.

### Б. Урманчега 80 яшь

А. Новицкий. Зирәклек һәм камиллек гадилеге. № 2.

### И. Газиның тууына 70 ел

Ә. Маликов. Әдәбият һәм хезмәт. № 2.
И. Гази. Чирәм ерту — һәр язучы бурычы. Мәкалә. Хатлар. № 2.

### Гази Кашшафның тууына 70 ел

Н. Юзиев. Фидакарьлек. № 4.
Г. Кашшаф. Журналистлык кайда бетә! № 4.

### Мирсәй Әмиргә 70 яшь

Ф. Миңнуллин. Талантлар юлы. № 1.

### Гариф Гобәйгә 70 яшь

Ф. Ибраһимова. «Фикерләрем — китапларымда...» № 8.

### Миргазиян Юныска 50 яшь

М. Мәһдиев. Секстан белән йолдызлар үлчәргә. № 5.

### Кави Латыйпка 50 яшь

К. Латыйп. Өмет белән карыйм доньяга мин. Шигырьләр. № 5.

### Казан радиосына 50 ел

Ш. Рахманкулов. Тыңлагыз, Казан сөйли. № 11.

### ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСТӘЛЕГЕНӘ

И. Брагинский. Габдулла Тукай һәм Урта Азия әдәбиятлары. № 4.
Илебез әдипләре Тукай турында. № 4.
М. Хәсәнов. Тукай турында сүз. № 4.

### ГЕРОЙ-ШАГЫЙРЬ ИСТӘЛЕГЕНӘ

А. Клабуков. Онытылмас кешем. № 2.
Р. Мостафин. Соры плитәләрдә ал кан таплары. № 2.
Л. Небенцаль. Җәлил рухы. № 2.

## ИСТӘЛЕКЛӘР

Н. Арсланов. **Ахирәтем Әл-Искәндәр. № 12.**
Г. Кайбицкая. **Дустым Сара турында. № 4.**
М. Садри. **Һәрчак хәтердә. № 12.**
М. Фәйзуллин. **Мирхәйдәр Фәйзи көндәлекләреннән. № 1.**
Х. Якупов. **Үз шагыйребез. № 8.**

## ОЧЕРКЛАР

И. Абдуллин. **Х. Ямашев автобиографиясе. № 11.**
Х. Зарипов. **КамАЗ елъязмачысы. № 3.**
М. Зарипов. **Моңлы Казан, нурлы Казан. № 12.**
**КамАЗ елъязмасы. № 1, № 2.**
Э. Касыймов. **Ык тамагында. № 3.**
М. Рафиков. **Урманым — һәйкәлем. № 7.**
М. Рафиков. **Бер дистә Мифтахетдиновлар. № 11.**
А. Хәсәнов. **Буровой юлларында. № 1.**
Р. Хәйретдинов. **Татарстанда Октябрь тарихыннан. № 11.**
К. Тимбикова. **Кара юрга. № 2.**
З. Әхмәтҗанов. **Еллар үткәч. № 2.**
М. Яһудин. **Калининның Татарстанга килүе. № 11.**

## ПУБЛИЦИСТИКА

Р. Мостафин. **Фән-техника революциясе һәм милли әдәбиятлар үсеше. № 10.**
Р. Нәфиков. **Беренчеләр беренче сафларда. № 12.**

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Ә. Баянов. **Яшь шагыйрьләр юлга чыга. № 5.**
Р. Вәлиев. **Ни чәчсәң, шуны урырсың. № 8.**
Н. Гамбәров. **Бәхеткә юл — гел алда. № 12.**
К. Миңлебаев. **Камиллеккә омтылу. № 9.**
Ф. Сафин. **Рәшит Гәрәй лирикасы. № 6.**

## ЯШЬ ТӘНКЫЙТЬЧЕНЕҢ БЕРЕНЧЕ РЕЦЕНЗИЯСЕ

Г. Моратов. **Һаман юлда. № 8.**
Г. Садә. **Язгы урман яшеллеккә атлый. № 8.**

## КОНКУРСКА КИЛГӘН РЕЦЕНЗИЯЛӘР

Р. Гыйззәтуллин. **Офыклар артында ачышлар. № 1.**
Р. Лотфуллин. **Алгы сызыктан репортаж. № 1.**

## КИТАП КҮЗӘТҮ

И. Ахунҗанов. **Көлү уен эш түгел. № 7.**
Е. Байтуков. **Әдәбиятларыбыз дуслыгы. № 9.**
Ш. Бикколов. **Витаминлы шигырьләр өчен. № 2.**

Р. Батуллин. Кызык өчен түгел. № 11.
И. Бәширова, М. Вәлиев, Р. Мостафин. Бер китапка өч караш. № 1.
Р. Ганиев. Жорж Сандның романтизмы. № 6.
Х. Зарипов. КамАЗчылар турында сүз. № 7.
Ж. Миндубаев. Гимназист Ульянов турында яңа китап. № 2.
Б. Камалов. Лачын кызлар. № 9.
Р. Мостафин. Йөз дә беренче могҗиза. № 4.
Р. Мөхәммәдиев. Замандаш турында уйланып. № 6.
Р. Мөхәммәдиев. Укучы ничек кабул итәр. № 12.
З. Рәмиев. Үзәк проблемалар. № 4.
М. Садыйков, Х. Мәхмүтов. Татар мәгърифәтчелеге турында яңа хезмәт. № 3.
Ш. Садретдинов. Мәгърифәтчелек дәвере әдәбияты. № 10.
Ф. Урманчеев. Җәлил белән яңадан очрашу. № 8.
Ф. Урманчеев, Р. Әхмәтҗанов. Җырлагыз, дуслар... № 10.
Г. Хантемирова. Иҗат яшьлеге. № 5.
Ф. Әгъзәмов. Данлы юбилейны каршылап. № 11.
Ф. Әгъзәмов. Прозабыз турында хезмәт. № 12.

ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

И. Андреева. И. Франко әсәрләре Татарстанда. № 6.
С. Акбиев. Татар мәгърифәтчесе таулар илендә. № 11.
Т. Каһһари. Уйгур-татар мәдәни бәйләнешләре. № 11.
Н. Мурадымов. Дуслык эзләре. № 11.

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Я. Абдуллин, Ә. Хәйруллин. Мәгърифәтчелек хәрәкәте карлыгачы Габденасыйр Курсави. № 1.
И. Зәбиров. Муса Җәлил иҗатында Ленин. № 5.
Р. Мөхәммәдиев. Югалмас мирас эзеннән. № 9.
Г. Хөсәенов. Утыз Имәни Башкортстанда. № 1.
С. Шакир. Илем өчен, җырым өчен. № 5.

ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

Т. Галиуллин. Һәр шагыйрь — трибун. № 8.
Ф. Мусин. Бердәмлек һәм күптөрлелек. № 4.
Г. Хантемирова. Ф. Әмирхан иҗатында хатын-кызлар азатлыгы темасы. № 8.

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

М. Ф. Вәлиев. Якты маяк. № 10.
С. Алишев. Тарихтан бер сәхифә. № 3.

СӘНГАТЬ

Д. Вәлиева. Болгар сәнгате сәхифәләреннән. № 1.
Д. Вәлиева. Борынгы да, бүгенге дә. № 9.
Ш. Монасыйпов. Сызылып кына моң чыкканда... № 2.
К. Таҗиева. Татар музыкасы классигы. № 6.

М. Фәйзуллаева. **Татар драма театры һәм опера сәнгатебез. № 5.**
Т. Әйди. **Былбыллар сайратучы. № 8.**

ТӨРЛЕСЕННӘН

А. Сәләхетдинов. **Төньяк җәлилчеләре. № 7.**
И. Сибгатуллин. **Капитанның төньяк одиссеясе. № 2.**
В. Семенова. **Алексей Толстой Казанда. № 2.**
Н. Фәттах. **Түгәрәк өстәл янында сөйләшү. № 12.**
**Х. Тәхфи шигырьләре. № 3.**
Ш. Әхмәдуллин. **Заман таләбе. № 6.**
**Безнең сафка. № 8, № 12.**

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**Ф. Агиевның тууына 90 ел. № 8.**
**Ә. Баяновка 50 яшь. № 12.**
Х. Гарданов. **Остазларның өйрәнчеге була. № 5.**
**Р. Башкуровның тууына 50 ел. № 5.**
Т. Дунаева. **Татарстан дәүләт исәп-теркәү библиографиясенә 50 ел. № 1.**
М. Зарипов. **Хезмәт — иң зур ләззәт.** Р. Сабировның 50 еллыгына. **№ 1.**
**В. Исхаковка 50 яшь. № 10.**
**Хөсни Кәримнең тууына 90 ел. № 12.**
**З. Мәҗитовка 50 яшь. Яшь шытымнарга карап.** Шигырьләр. **№ 8.**
Ш. Рамил. **Китапханәгә 70 ел. № 10.**
Ә. Сабирова. **Шиһап Рамазановның тууына 90 ел. № 10.**
**Б. Сиринның тууына 80 ел. № 1.**
Р. Төхфәтуллин. **Дулкыннар ярга кага.** Мәхмүт Хәсәновның 50 еллыгына. **№ 12.**
**С. Урайскийның тууына 70 ел. № 12.**
**З. Ярмәкинең тууына 90 ел. № 1.**
Р. Ягъфәров. **Х. Бәдигыйның тууына 90 ел. № 12.**


УКУЧЫ СҮЗЕ

**Ә. Еникигә хатлар. № 3.**
Р. Исмәгыйлова. **Сәмум кичкән геройлар. № 11.**
М. Нурмөхәммәтов. **Заман герое. № 11.**
С. Хәйбуллин. **«Ташлардагы язулар». № 1.**
Р. Шәрифуллина. **Язучыга бер сорау. № 11.**
М. Янбаев. **Уралдан хат. № 11.**

**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары. № 1—12.**

ҖЫРЛАР

Р. Абдуллин музыкасы, Р. Вәлиев шигыре. **Иделем акчарлагы. № 6.**
З. Хәбибуллин музыкасы, Зәки Нури шигыре. **Җиңү атлый Ленин эзеннән. № 11.**



*«Пролог»*

## *Хөрмәтле укучыбыз!*

Кулыгызда журналыбызның шушы елдагы соңгы саны.

Алда сезне яңа елның яңа әсәрләре, язучыларыбызның яңа табышлары, яңа хезмәтләре көтә.

«Почет билгесе» орденлы «Казан утлары» журналы 1978 елда үзенең беренче санын Габдрахман Әпсәләмовның «Агыла болыт» исемле романы белән ача. Ул шагыйрь Муса Җәлилнең тиндәшсез батырлыгына багышлана.

Журнал тарафыннан игълан ителгән замандаш конкурсына күп санлы хикәяләр килеп тора. Беренче саннан башлап аларның иң уңышлылары журналыбызда басыла барачак. Бу санда шулардан беренчесе — Рөстәм Мингалимовның «Мәскәү, Токио, Нью-Йорк» дигән хикәясен укырсыз.

Поэзия бүлегендә Тукай премиясе лауреаты Гамил Афзалның «Рухым», Гөлшат Зәйнашеваның «Иң мөһим көй» дип исемләнгән шигырьләр циклы, Әнвәр Давыдов архивыннан алынган шигырьләр һәм Хәкимҗан Халиковның нәниләр өчен язылган әсәрләре бирелә.

Очерклар бүлеге И. Буркованың «КамАЗда очрашулар» һәм Ләбибә Ихсанованың «Профессор Равилә» дигән очеркларын тәкъдим итә.

Январь аенда күренекле драматург Фәтхи Бурнашның тууына 80 ел тула. Азат Әхмәдуллинның шул уңай белән басылган «Коммунистларча принципиальлек белән» дигән мәкаләсе кызыклы.

Әдәби тәнкыйть бүлегендә Р. Сверигин һәм Ф. Хатиповлар «Тормыш моңын тоеп», М. Вәлиев «Язмышлар турында уйлану» дигән мәкаләләрен бастыралар. Аларның беренчесе Әмирхан Еники, икенчесе Аяз Гыйләҗевнең иҗат принципларына, әдәби осталыкларына анализ ясый.

Сәнгать бүлеге СССР халык артисты Шәүкәт Биктимеровның иҗат портретын бирә. Очеркның авторы театр тәнкыйтьчесе И. Илялова.

«Казан утлары» журналының беренче санында шулардан тыш «Безнең сафка», «Безнең календарь», «Тәрлесеннән», «Нәниләр дөньясы», «Елмаеп та, көлеп тә...» бүлекләре күп санлы кызыклы хикәяләр, очерклар, фәнни мәкаләләр, төрле информацияләр һ. б. материаллар урнаштыра.

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары да сезне күп хәбәрләр белән таныштырачак.

**ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫБЫЗ!**

«Казан утлары» журналына вакытында язылa алмаган булсагыз, исегезгә төшерәбез: журналыбызга елның һәр аенда, 20 нче числодан соңга калмыйча, барлык элемтә бүлекләрендә язылa аласыз. Аның бәясе 1 елга 6 сум.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210